# Казан утлары

8

АВГУСТ-1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

8

АВГУСТ
1972

## Бу санда

А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Урталыкта. Повесть . . . . . . 3
С. ХӘКИМ. Үлгәннәргә хәтта моң кирәк. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 51
М. ӘГЪЛӘМОВ. Каурый. Шигырьләр . . . . . 56
Р. ИШМОРАТОВА. Милиция лейтенанты. Повесть . 61
Ф. ЯРУЛЛИН. Кеше. Шигырьләр . . . . . . . 96
Р. НИЗАМИЕВ. Привалда. Шигырьләр . . . . . 98
Н. ИХСАНОВ. Давылда. Хикәя . . . . . . . . 99

ОЧЕРКЛАР

Б. КАМАЛОВ. Ул һаман солдат . . . . . . . 108
В. ГУДКОВА. Профессор Мештәри һәм аның мәктәбе . . . . . . . . . . . . . . . . 112

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

А. ХАЛИКОВ. Дунай Болгарстаны — кардәшләребез иле . . . . . . . . . . . . . . . 121

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Г. МӨХӘММӘДОВА. Киев вакыйгасы . . . . . 133
Әхмәт ибне Фазланның Идел буе болгарларына сәяхәте . . . . . . . . . . . . . 152

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ

Ф. УРМАНЧИЕВ. Легендалар эзеннән . . . . . 160

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**В. ВОЗДВИЖЕНСКИЙ.** Зур таләпләр югарылыгыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. ГАЛӘВИН.** Яңа сүзлек белән танышкач . . . . 178

ЯҢА КИТАПЛАР

**М. ГАЛИЕВ.** «Идел»нең яңа саны . . . . . . . . 182
**Х. МӘХМҮТОВ.** Татар мәкальләре рус телендә . 184

ТӨРЛЕСЕННӘН

**М. НОГМАН.** Тагын караимнар янында . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 6/V-1972 ел. Басарга кул куелды 6/VII-1972 ел. ПФ 09023.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 85046 экз.
Заказ Г-328. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1972 ел.

**Аяз Гыйләҗев**

# УРТАЛЫКТА

ПОВЕСТЬ

Режиссер Габдулла абый Юсуповның якты истәлегенә багышлыйм бу әсәремне.

*Автор.*

## 1



Баязит абыйны больницага салуларын мин байтактан ишетеп йөри идем инде. Август урталарында күршеләремнең берсе дачадан шәһәргә кайтып килде дә безнең бакча яныннан: «Гарифуллин агайны кунакка чакырырга барган идем, чирләгән, ГИДУВка салганнар»,— дип әйтеп узды.

Хатыным белән бер-беребезгә караштык, ул минем ни әйтеремне дә көтеп тормастан:

— Барып кайтырга бик кирәк иде дә, бүгеннәрдә вакыты юграк шул Сәгыйтьнең... Карлыган да коела,— дип куйды.

Кулымдагы агач табакны әйләндерә-әйләндерә: «Алай икән, алай, кара син аны, чирләгән!» — дидем. Күршем артыгын нечкәләп тормады, мин өстәп сорашмадым, сүз шушының белән тәмамланды.

Эш карлыганда түгел иде анысы, хатыным нәрсә дип телгә китереп кыстыргандыр шул чүп-чарны, дөресен әйткәндә, быел яздан ук табигатьнең рәте булмады, я гел яңгыр, я суык җил дигәндәй, менә соңгы атналарда гына көннәр утырып китеп, зарыгып көткән җылы һава килде. Шимбә-якшәмбеләрдә дача сукмакларына шәһәрдән яу төште — авызлары колакларына җиткән, вокзалда ук төшереп алган ваемсыз, сау-сәламәт, шау-шулы кунаклар өер-өер булып йөри башладылар. Шул елның иң кадерле, иң тантаналы минутларына дип Мәскәү кадәр Мәскәүдән үк адарынып алып кайткан кыйбатлы коньяклар, ниһаять, табынга чыкты. Иң тантаналы минутлар җәйге ял вакытына туры килгән икән, моның ни гаебе бар?! Рәт белгән кунаклар үзләре дә буш кул белән килмәделәр, алдан ук хәстәрен күреп куйганнар, шулай җыйнаулашып мәш киләбез, иртә таңнан ризык-мазарын төйнәштереп көймәләргә төяләбез дә Иделгә, Казан диңгезен чуарлаган бәләкәй,

яшел утрауларга керер китэбез. Өчаяк бастырып казан асабыз, өреле, тәмле Идел ухасы пешерәбез, арка кыздырабыз. Су җиленнән, коенудан, уха исеннән ялыксак, дачаларга ук авып торган күгелҗем нарат урманына юл тотабыз, көнебезне шунда уздырабыз.

Мондый мәҗлесләр, тамашалар хатын-кыз өчен аерата болгавыр, мәшәкатьле була, ни әйтсәң дә, без ирләр ашыйбыз да качабыз дигәндәй, таякның юан башы һаман хатыннар җилкәсенә төшә. Әмма көннәрнең шундый тоташ шәпләнеп китүе, гадәттә, тиешле-тиешсез йөргән кунакны бик үк өнәмәгән хатынымның күңелен дә йомшартты, барыбыз да дөньяның ялыктыргыч ыгы-зыгысыннан котылып, хәтта радио-газет хәбәрләренә дә колак салмыйча, шәһәр газыннан арынган күкрәкләребезне тутырып саф һава сулый-сулый, кинәнеп, комарланып яши идек...

Татымаган ризык, сөйләнмәгән анекдот калмады, яз гына алган туп күн чүпрәккә әйләнде, тәннәр карала барган саен күңелләр ачылды, дус-дошманны аермый башладык, бирдек кирәген дөньяның!

Шушындый чакта кемнеңдер авырып, больница палатасында саргаеп ятуына артык ис китмәде. Күңел тынычлык, онытылу, тормыш мәшәкатьләреннән читләшү теләгән, төрле юллар белән юаныч эзли, акыл миңгерәүләнгән, зиһен томаланган бәхетле чак иде бу, хәсрәтле хәбәрләр бер колактан керделәр, икенчесеннән чыга тордылар...

Җитмеш яшен тутырып килгән кешенең аз-маз сыкрап алуы да алай гаҗәп түгел. Баязит абыйны июнь урталарында (әллә иртәрәк тә идеме икән?) урамда очраклы гына күреп калган идем. «Быел сабан туенда йөгерешкә барып булмастай тоела, адым авырайды, радикулитым кузгалырга тора»,— дип ярым көлемсерәп сөйләнгән иде.

Димәк, куркырлык әллә ни юктыр, сыкрар-сыкрар да, палатаның тынчу һавасыннан туйгач, ялт итеп килеп чыгар.

Ә көннәр кәеф, валлаһи, кәеф! Акча биреп сатып ала алмассың мондый көннәрне! Кадерен белеп калырга кирәк, сулар үргә акса да гомер ике килми ләбаса! Иртәнге чәй янында кинәнеп, изү чишеп утырганда «Җитәрлек эт кудык, карлыган бик коела»,— дип, хатын да мырламаса... Мырлый шул, мырлап куя, рәхәтлекнең кадерен белми.

Күләгәдә, җиләстә шулай уйланып ята идем, кылт итеп исемә Баязит абый килеп төште. Юкка кергән ул больницага, тазалык эзләп арыш басуына чыгарга кирәк хәзер, урманда качып гөмбә-мазар җыярга кирәк. Беләм мин аның чирен, аңлыйм, сәбәбен дә сизәм, очрашмасак та тамырына тиклем күреп торам. Дару-дәрманның файдасы булмас аңар, карт абзыкайга, пенсионер кешегә, хәзерге заманча әйтсәк, аңа психотерапия кирәк. Бары шул.

Әйтер идем бер: тапкан чирләр вакытын, тапкан авыруын, радикулит та булдымы чир, инде башка әмәлен тапмаса, килсен иде үзебезгә, без аны момент дәвалар идек, теркелдәп чыгып китүен сизми дә калыр иде...

Ялым бетәргә күп тә калмады инде, вак-төяк нәрсәләр алырга базарга кайттым, ит тә кирәк иде, помидор тозларга тазарак имән кисмәк булмасмы,— былтыр юкә тәпәнгә тутырып куйган идек, октябрь бәйрәменә хәтле дә чыдамады, боламыкка әйләнде, помидорны әйтәм. Юк йомышны бар итеп, эш урыныма — проект институтына да кагылдым. Берәрсен очратып ялымның шәплеге, тормышымның житешлеге, муллыгы белән мактанып аласым килде бугай.

Коридорда беренче күргән кешем (юрауларга, ырымнарга ышанмасам да, ялдан, командировкалардан кайтканда беренче булып кем очравына игътибар итми калмыйм!) Сухуми ягында, көньяк кояшында ята-ята каралып беткән озын, фырт Гали Кадыйров булды. Ни сәбәпле коридорга чыгуы булгандыр, папирос төтенен туп-туры миңа таба өреп:

— Нихәл, җир корты? — диде.

— Ярыйсы,— дидем мин шәбәеп.— Кара дингездә каралмасак та яшәп яткан көн.

— Каралыр өчен урын кайда да бар,— диде ул, һавалы гына.

— Җаны теләгәнгә җае бар,— дидем мин дә, сер бирмәскә тырышып.

— Тормышының шәплеге чыраена чыккан,— диде ул, каядыр өскә карап.— Тик анда Баязит абыең бик каты авырып ята икән.

Сизендем, мин килгәнне тәрәзә аша күреп торып, шуны әйтергә чыккан! Телемнән:

— Кайда? — дигән ахмак сорау ычкынды.

Баязит абый белән безнең ара хәтсез вакытлар бик якын булганга, картның чирләп ятуын Галигә караганда мин ачыграк белергә тиеш идем. Җитмәсә, ялга да аның сыман Каф тавы ягына олакмадым.

Гали җәһәт кенә миңа күз ташлап алды. Күзләре чәнечкеле аның, кап-кара...

— Өендә,— диде ул, маникюрлы тырнаклары белән тәмәке көлен чиертә-чиертә.

Оят булса да әйтим, мин бу мизгелдә Баязит абыйны түгел, үземне уйлый идем. Гали Кадыйров та минем ни уйлавымны аермачык белә кебек тоелды. Әйе, әгәр Баязит абый элекке куәтендә булса, җаваплы һәм миңа кирәкле урында эшләсә, белмим, Галинең хәбәреннән соң «Кайда?» дип сорашып, үз ахмаклыгымны үзем раслап торыр идемме икән?.. Әле ярый, ул минем бу хәбәрне элегрәк ишеткәнемне белми...

— Бик куерталар, теге яман чир ялмаган картны,— дип дәвам итте Гали.— Үпкәсендә дә бар, имеш, умыртка баганасы тирәсенә дә җәелгән. Дөрескә чыкса, карт соңгы санаулы көннәрен яши.

— Көннәр барыбызга да санап бирелгән,— дидем мин, таркау гына.— Чутсыз гомер бирәүнең дә юк.

— Кешенекен санау ансатрак, билгеле...

Минем ышанмыйрак икеле-микеле кыланып торуым кинәт юкка чыкты. Гали, үзенә игътибарны җыярга теләгәндә төрле юк-бар уйдырмаларны уйлап чыгаргаласа да, бу юлы дөресен сөйли иде. Әллә картны азрак кызгана да инде?..

— Өендә ята, диләр... Үземнең кереп чыга алганым юк әле... Бернинди өмет чаткысы калмаганга больницадан чыгарганнар. Барып кайт инде син, күрешеп кал, заманында дус булып йөрдегез бит... Мин дә кереп чыгарга дип торам. Баязит абый миңа да күп яхшылык күрсәткән кеше.

— Гарифуллин алай гына бирешер микән? — дидем мин, Галидән тынычландыру, юату сүзе суырып алырга өметләнеп.

— Белеп булмый,— диде ул, ниһаять, чын күңеленнән.— Шулай да күрешеп чык. Яхшылыкны онытырга һич тә ярамый.

Хатынымның кисәтүләре, хәтеремдә тәкърарлап килгән базар йомышларым онытылды, бу хәбәр шундый көтелмәгән иде, һавалы, тәкәббер Галинең сүзен шулай кешелекле теләктәшлек, хәсрәт белән тәмамлавы мине кинәт кенә аяктан екты, бер мәлгә гәүдәм бөтенләй эреп, аяк-кулларым сәлперәеп төште. Аз-маз зиһенемне җыйгач, кешемазар күргәләгәнче дип, институттан чыгып киттем. Яхшы әле, башка берәү дә мине күрмәде, поездга да шулай исәнгерәгән рәвештә барып кердем, вагонның саргылт карындык төсле тоныкк тәрәзәсенә карап әллә ниләр уйлап бетердем.

Баязит абый үләргә ята диген... Гарифуллин...

Әйе...

Моңарчы картның килде-китте чирләргә генә түгел, куркынычракларына да баш биргәне юк иде. Моннан ун еллар элек аяктан егылганы хәтеремдә... Кайберәүләр «инфаркт» диделәр. «Түгел» дип раслау-

чы белгечләр дә табылды. Берәү булса, шушы хөкемнәрдән тәкатьсез калып, яшәүнең бар ямен җуеп, үлем көтеп саргаеп гомер кичерер иде. Баязит абый исә больницадан бераз хәлләнеп чыкты да элеккедән дә хәрәкәтчән, тынгысыз тормышын куа бирде.

Әй, гомерләр диген! Ул чагында мин проект институтына яңа күчеп, әле генә үз сукмагын сала башлаган инженер кисәге идем. Бер көн коридордан җил-җил атлап пеләш башлы, үткер күзле тәбәнәк кенә берәү менеп килә. «Баязит Гарифуллин» диделәр...

Без ничектер тиз арада якынаеп киттек.

Гарифуллин хәтле Гарифуллинның миңа булган мөнәсәбәтеннән баштарак һаваланыбрак йөргән идем, соңра, якыннанрак белешкәч, аның бик күп яшьләргә дус икәнлеген аңлап алдым. Аның гадәте, яшәү халәте шундый иде: беркем йөкләп кушмаса да, ул яшь белгечләрне күзеннән ычкындырмый, үзенә таба тарта, бар белдеге, белеме белән ярдәмгә килә, кирәк икән, вакытын да, көчен дә кызганмый.

Эш өстендәге кешенең төрле чаклары була, Баязит абый да җитди уңышсызлыклар кичерде, корган планнары тар-мар килгәләде, бериш шәкертләре шундый вакытларда шыпырт кына аннан тайпылдылар, әмма ул холкын үзгәртә алмады, яшьләрдән читләшмәде, һаман аларга тартылды.

Тагын да гаҗәбрәк хәлләрдә дә Баязит абый Баязит абый булып кала белде. Аның ярдәме белән тернәкләнеп китеп, җылы урыннар, мактаулы исемнәр алган бериш якыннары, азау тешләре ныгыгач, Баязит абыйны усал-усал гына тешләштергәләделәр. Аны Мәскәү галимнәре, чит ил белгечләре белән янәшә куеп карап: «Фи-и, кем ул Гарифуллин?.. Тар карашлы, камерный бер кеше, адымы вак, үлчәү берәмлекләре бәләкәй. Производствоның вак-төяк йомышларын үтәп килүче институтта кырык ел чалбар төбен туздырган... Анда да сектор мөдире булып кына калган... Италияне күрмәгән, Англиягә бармаган, Американы күз алдына да китерә алмый... Андый тар карашлы кеше хәзерге югарылыкта, фән-техника революциясе киңлегендә эшли алмый!» дип астыртын да, өстертен дә кимсетеп килделәр.

Шуны да ачыкларга кирәк, Баязит абый безнең институтка нигез салучыларның берсе. Алар эшли башлаганда бик нәни булган әле ул, байтак еллар Мәскәү институтының филиалы булып кына килгән. Әмма соңгы елларда бер Казанда гына түгел, Идел-Кама төбәге шәһәрләрендә аның даны киң таралды. Безнең инженерлар, конструкторлар бөтен Союзга атаклы заводларның заказларын үти башладылар.

Әйе, байтак егетләр безнең институтны да, Гарифуллинны да бәләкәйсетеп ташлап киттеләр. Ул аларның хыянәтләрен авыр кичерде, ләкин бервакытта да, беркемгә дә зарлану сүзен ишеттермәде, үзенчә яши бирде, үзенчә эшли бирде.

Кешеләрнең күбесен яратса да, күңеле киң булса да, безнең аның белән мөнәсәбәтләр тирәнрәк, якынрак иде. Эшкә урнашкан беренче елларымда мин башкарган байтак эшләргә Баязит абый җитәкчелек итте. Төрле фәнни семинарларда утырдаш булдык без аның белән, фикердәш булдык, бер-беребезгә кунакка йөреп ризыгыбызны бүлештек. Яшь аермабыз бик күп диярлек, дәрәҗәләребез дә тигез түгел, әмма без уртак тел таптык, дуслаштык һәм бер-беребезне тутырып яшәдек.

Байтак вакытлардан бирле мин металл эшкәртү процессына үзгәреш кертә торган махсус җайланма турында уйланып килә идем. Бер уйладым мин бу турыда, ун уйладым, серемне Баязит абыйга сөйләдем. Техник яктан катлаулы булганга, ничек-ничек икәнен сөйләп тормыйм, әмма Баязит абый минем фикерне: «Гаҗәп нәрсә булачак бу!» дип күтәреп алды, тиз арада җәмәгатьчелек алдына да куйды. Безнең байтак галимнәр, инженер-конструкторлар: «Фикернең практик

нигезе юк, алдан ук уңышсызлыкка дучар ителгән сафсата, прожекторлык бу!» дип кире кактылар. Теманы расларга тиешле гыйльми совет икеләнеп калды...

Безнең бүлектәге кайбер егетләргә проектның тәме йөгергән иде инде, шулар белән бергә министрлыкның техника идарәсенә, башка институтларның шул юнәлештәрәк эшләгән кафедраларына, фәннәр академиясе президиумына, партия органнарына берничә гариза яздык. Нәтиҗәдә, безнең тәкъдимне өйрәнү өчен авторитетлы комиссия төзелде...

Бәхеткә каршы димме, бәхетсезлеккә булдымы, комиссия проектны яклап чыкты!.. «Металл эшкәртүдә Казан институты инженерлары тәкъдим иткән методның нәтиҗәле булуы бик ихтимал һәм якын елларда бу кыю проектны тормышка ашырырлык шартлар да тудырылыр», диелгән иде аның карарында.

Минем башым күккә тиде, җирдән түгел, һавадан йөрдем мин ул көннәрдә!..

Гали Кадыйров һәм тагын берничә кеше һаман да проектка каршы иделәр. Шул чагында Баязит абый аларны тар-мар итеп чыгыш ясады, Рудольф Дизельнең сүзләрен мисалга китерде. «Тәҗрибә уңышсыз тәмамланган очракта ачыш башлана»,— дигән Дизель. Әгәр яшь иптәшләрнең идеясе тормышка ашарлык нәтиҗәләр дә китерсә, бу инде нур өстенә нур булачак.

Министрлык приказы белән безнең институтта яңа җайланманы проектлаучы группа төзелде. Группаның штатын, сметасын һәм программасын төзүдә Баязит абый безгә бик нык ярдәм итте. Группа җитәкчесе итеп мине расладылар.

Ах, ул көннәр, ул көннәр!

Әй, ул еллар, ул еллар!..

Күңелемнең түрендә салават күпере күк җемелдәп торалар ул еллар!.. Сиңа утыз биш тә тулмаган булсын, бөтен институтны кузгаткан эшне син башлап йөр, синең эшең белән Мәскәү, Ленинград, Томск институтлары даими кызыксынып яшәсен, синең дусларың арасында Баязит абый Гарифуллин кебек сабыр акыллы, мөгътәбәр кеше, карт большевик булсын!..

Тәҗрибәне без Казанның үзендә, машина төзүче заводларның иң һәйбәтендә үткәрдек. Айлар буе заводтан чыкмыйча куна-төнә эшләп, исәпләп-хисаплап яттык. Баязит абый безнең группада булмаса да, һәр көн диярлек заводка килеп йөрде, телефоннан шалтыратты, Мәскәүдән консультантлар китертте. Безнең кайгы-шатлыкларны ул да үз иңенә күтәрде.

Әмма тәҗрибә көтелгән нәтиҗәләрнең чиреген дә бирмәде. Теориядә бик ачык, бик нигезле күренеп торган нәрсәләр практикада расланмады яки бөтенләй кире юнәлешкә кереп китте...

Институтта безне ашыктырмадылар, бераз салкын канлырак булырга киңәш биреп, яңадан эшкә угырттылар. Үзебез узган юллардан эзгә-эз, борылышка-борылыш, чатка-чат яңадан бардык, ярты ел буе ялгышларыбызны, хаталарыбызны тикшердек. Чагыштырдык, укыдык, бәхәсләштек, акыл сорап галимнәргә, белгечләргә, металл эшкәртү осталарына хатлар яздык. Хаталарыбызны тапкан кебек булдык...

Яңадан завод цехларына бардык.

Әмма бу юлы да барып чыкмады... Кат-кат сынап карасак та, безнең фикерләр җанлана алмады...

Баязит абый белән мине Мәскәүгә чакырып алдылар, безне министрның беренче урынбасары кабул итте. Солтанатлы гына кеше, каршысына утыртты да: «Я, ни уйлашабыз? Нәрсә тәкъдим итәсез?» — дип сорады. Мин аптырап Баязит абыйга карадым, ул каушамыйча-

нитмичә: «Тәҗрибәләрне дәвам итәргә кирәк, эшне өзәргә ярамый»,— диде.

Министр урынбасары институт директоры җибәргән белешмәне укып күрсәтте. Ике ел эшләү дәверендә группага 70 мең сум хезмәт хакы түләнгән... 150 мең сумлык материал һәм җиһазлар исраф ителгән... Нәтиҗәдә, бер тиенлек файда алынмаган... «Бездә әндри казнасы юк», диде урынбасар кырыс кына... Әмма Баязит абый бирешмәде, мин дә канатланып киттем, мәсьәләне министрлыкның фәнни-техник советына куйдылар. Галимнәр, белгечләр җыйналды.

Сүзләр күп булды, бер тирләдек, бер өшедек, әмма совет безнең җайланманы перспективалы, өметле һәм тормышка ашырырга мөмкин булган эш дип тапты... Министр урынбасары үзе дә шушы фикерне яклады.

Поезд күтәргә түземебез юк иде, шул төнне үк Мәскәүдән Казанга очтык. Сөйләшеп сүзебез бетмәде, шунда юлда ук исәпләү-хисаплау эшләренә керештек. Юлдашларыбыз: «Нинди туктаусыз мыгырдау инде бу, йокы бирмисез!» — дип зарланганнар иде...

Өченче тәҗрибә дә көткән нәтиҗәне бирмәде...

Ничә еллар дәвамында күпме көч, акча, күпме вакыт бушка сарыф ителгән булып чыкты!..

Гыйльми совет җыелды...

Анда ишеткән сүзләрне әллә кайчан онытырга кирәк иде дә, юк, онытып булмый!.. Мине эт иттеләр, Баязит абыйга да безнең уңышсызлыкның күләгәсе төште. «Гарифуллин әйбәт проектчы, яхшы конструктор, әмма бик начар теоретик!» — диделәр...

Хөкем карары бүген дә колак төбендә яңгырый:

«Бүгенге практик эшләрдә үзләрен күрсәтә алмаган кайберәүләр бик теләп киләчәк фәнен хәл итү проблемаларына алыналар, прожектерлык, күз буяу, җил куу белән шөгыльләнәләр. Киләчәк өчен дигән булып, бүгенге табыннан майлырак калҗа эләктерергә маташучыларга каты кисәтү ясарга вакыт!»

Җыелышның секретаре Гали Кадыйров иде...

Икенче көнне мин Баязит абый белән киңәшеп тә тормастан, директор янына кердем һәм безнең группаны таратуын сорап гариза тапшырдым.

Без — группадагы егетләр — үзара талашып беттек...

Ике көннән игъланнар тактасына приказ элделәр...

Гарифуллин мине үз янына чакырып кертте.

— Үз фикереңнең дөреслегенә ышанасыңмы? — диде ул һәм, җавап та көтеп тормастан, дәвам итте: — Ышанасың, югыйсә, син шушы кадәр вакыт эчендә нихәтле кешене үз артыңнан ияртә алмас идең!.. Димәк, син кире чигенергә уйладың?..

— Моның әһәмияте бармы икән хәзер? — дидем мин, аның йөзенә карамаска тырышып.

— Бик бар,— диде ул, каты итеп.

— Ышанудан ни файда? — дидем мин өзгәләнеп.— Приказ эленгән, без таралдык.

— Ах, алаймы? Алайса, син ир түгел, син — куркак! — дип кычкырды ул, ике арада сүзнең мәңгегә өзелгән икәнлеген аңлатып.

Мин бер агардым, бер күгәрдем, ләкин минем булдыксызлыгым аркасында үзе дә күп сүзләр ишеткән киңәшчемә, өлкән иптәшемә каршы төшә алмадым. Ә үзем күңелемнән генә башкачарак уйладым... Юк, дидем, мин куркак ук түгел, әмма дәүләт акчасын, кешеләрнең миңа булган ышанычын чамасыз рәвештә исраф итәргә дә көчемнән килми... Тәҗрибәләрне дәвам итү өчен министрның үзенә керергә, гыйльми советны ышандырырлык дәлилләр табарга кирәк иде...

Күңелем гасабиланган, борчылган, икеләнгән иде, андый дәлилләр миндә юк иде. Арыган идем мин!.. Без тәҗрибә уздыра торган заводта да безне «жилкуарлар» дип атый башлаганнар иде. Анда кире кайту мөмкин түгел иде...

Боларның барысын да белеп торган Баязит абыйның миңа «куркак!» дип кычкырырга хакы бар идеме соң?!.

Юк, дип уйладым мин һәм безнең аралар черек җеп кебек черт итеп өзелеп китте, ничектер үзеннән-үзе ерагайдык, алар йортында минем эзем суынды...

Гомергә аерылышмас кебек йөрешкән кешеләр арасында да экәмәтләр була икән!.. Безнең уңышсыз тәҗрибәләрне җыелышларда ике ел рәттән сөйләделәр, шундый чакларда башкаларга сиздермичә генә бер-беребезгә ялт карап ала идек!..

Баязит абыйга мөнәсәбәтем көннән-көн үзгәрә барды, мин дә аңарда дошманнары әллә кайчан тапкан тарлык, искелек, бәләкәйлек сыйфатлары күрә башладым. «Җитәкчең Гарифуллин ише булганда нинди нәтиҗә көтәргә мөмкин?» — дип ычкындырган чакларым да булды...

Фикеремнең ялгыш, алай гына да түгел, гайбәт, ялган икәнлеген шул чакта ук ачык белә идем! Нишлисең, ничә еллар янәшә барган кешеләр шулай бер көнне ят булдык та калдык. Ул пенсиягә чыкты, безнең аралар тагын да ерагайды. Заманында «остазым» дип, «өйрәтүчем» дип атап йөрткән кешемне хәзер айлар буе күрмим, моны бер дә сәерлеккә санамыйм.

Ни булды безгә? Ни булды миңа?

Ни үзгәрде? Баязит абый минем остазым иде ич, ул шулай булып калды да... Остазсыз ярамый, өйрәтүчесез, укытучысыз булмый, ә мин аны кем белән алыштырдым? Күңелемдәге хисләремне нәрсә каплап китте?

Теге тәҗрибәмнең уңышсызлыгына гаепле итеп нигә мин аны гына саныйм?! Бу бит чиктән тыш хаксызлык, кешелексезлек...

Ул бит бары яхшылык кына теләде!..

Менә шул олпат ир авырып ята, алай гына да түгел, ул азамат терелеп тормаячак, алтмыш еллыгына без җыелып бүләк иткән сәгать аның соңгы минутларын җыя... Ике-өч ел чынлап көрешми яшәгәннән соң, аның бер аягы белән кабер ягасында торганын белгән хәлдә, мин аның катына барырга тиеш. Тиеш кенә түгел, бурычлы!.. Әгәр мин аз-маз гына намус, гаделлек, өлкәннәр алдындагы бурыч турында уйлансам, хәзер үк, шушы минутларда ук, аның янына йөгерергә тиеш!..

Алдашуны, хыянәтне кичермәгән, астыртынлыкны, ялагайларны сөймәгән сизгер кеше катына хәзер ни йөзем белән барырга?!.

Яшәешнең һәртөрле мизгелләрен уртак кичереп уздырган, бергә чакта бер-беребезнең күз карашыннан, ярты сүзеннән тел төбен аңлашырга гадәтләнгән кешеләр, бүген очрашсак, ни җаен табып, нинди әмәлләр кулланып чын уйларыбызны яшерербез?

Ни рәвешле, нинди сүзләр табып юатырмын мин аны? Минем юатуыма мохтаҗмы ул, әллә аңа башка сүзләр кирәкме?..

Уйласам, башым чатный, акылым җитми.

Әллә соңгы очрашкандагы сыман гамьсез, уйсыз, хәтта ваемсыз булып кыланыргамы? Үзе шундыйрак юнәлеш бирде ләбаса! «Сабан туенда йөгерешкә катнашып булмас кебек»,— диде. Чирли башлаган заманында әйтелгән сүз ич бу!..

Теле шулай диде, ә күзләре!..

Карадыммы шул чак күзләренә, хәтерләмим. Әллә үзем турындагы уйларга өстенлек биреп, аңа юньләп багып та тормадыммы?

Әйе, тотарга да барып кирәргә, юк-бар сүзләр сиптереп, шукланып, дөньяның артына тибеп яшибез дигән кебегрәк чыгып китәргә кирәк булыр. Иң ансаты, мөгаен, иң дөресе дә шул!..

Анысы алай да, ул байтактан хәл эчендә ята...

Ул мине көтеп мең тапкыр уйлангандыр...

«Институттан ул синең аркада гына китте»,— диделәр кайберәүләр. Бәлки алай ук та булмагандыр... Кем белсен!..

Шулай да ул минем беренче сүземә үк, тәүге күз сирпелешемә дикъкать итәчәк, кул хәрәкәтемнән ясалмалылыкны, ирен кыймылдавымнан йогышсыз хәйләмне, ясалма сүзләремнән аның язмышына салкын, битараф булуымны аңлап алачак...

Чирле кешегә туп-туры берни әйтергә дә ярамый, диләр. Кешенең актыккы минутларын авыр уйлар белән каралтырга ярамый, диләр...

Моны бит исәннәр, монда калучылар әйтә. Дөньядан китүчеләр соңгы секундларындагы теләкләрен борылып кайтып сөйләмиләр. Ә без ялгышмыйбызмы? Үз хәтеребезне саклап кына алардан чынлыкны яшермибезме?

Болай да, тормыш шулай куша, әхлак-мораль нормалары шулай өйрәтә дип, атлаган саен бер-беребездән чынлыкны яшереп гадәтләнгән гөнаһлы җир уллары, инде иң ахыргы, иң соңгы форсат барында, нигә чынны сөйләп калырга талпынмыйбыз?..

Ничә ел бер теләктә, уртак уйда яшәдек, ничә еллык гомеремнең күп серләренә ул гына шаһит. Әгәр терелмәсә, минем гомеремнең иң бай, иң кызыклы, иң әһәмиятле елларын ул үзе белән алып китәчәк...

Икебезнең гомер уртасына басып уйлана торгач, куркынып киттем: без бер-беребез хакында артык күп, чамасыз күп беләбез икән...

Ах, моннан берничә ел элек бергә эшләгән чаклар булса! Бергә эшләгән чак булса, аның авыруын җиңеләйтә алмас идем алуын, әмма безнең мөнәсәбәтләр икебез өчен дә ачык булыр иде.

Кеше яши. Гомер иткән саен күңеле сайлаган дуслары азая бара кешенең. Аның әти-әнисе, туганнары, кардәшләре өрагая, җан дуслары читләшә, аның янәшәсендә эш-хезмәт дәрәҗәсе, чины табып биргән, торак урыннары уртак булган очраклы кешеләр урын ала бара.

Мин дә шул баскычларны узып барам. Гәрчә Баязит абый эш урынымда туры килгән җан дустым булса да, тора-бара мин аны да оныттым. Без аның белән мәңгелекнең бөек хөкеме алдында гына очрашабыз. Берең китеп, икенчең калганда ничек аңлашырга?..

Хәер, безнең мөнәсәбәтләр ничек булырга тиеш?

Теге чакта соңгы сүзе итеп ул миңа «куркак!» дигән иде.

Соңгы сүз...

Аннан элек арабызда барысы да ап-ачык диярлек иде. Ул яше белән дә олы, тормыш тәҗрибәсе белән дә миннән өстен. Гражданнар сугышында катнашкан, Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән карт большевик. Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр сугыш кырыннан чыкмаган, артиллерист. Сул кулбашында Дутов казагы кылычының эзе, тәнендә фашист-илбасар минасының ярчык эзләре уелып калган...

Дөрес, эштә мине аңа караганда фантазиягә бай, талантлырак итеп йөртсәләр дә (бер-ике сәбәбе чыкты шуның, каһәр суккыры!), бер кайчан да мин аннан өстенлекне дәгъваламадым шикелле, аның дустанә ярдәменә, акыллы киңәшенә, сабыр уйлануларына һәр чак мохтаж булып килдем. Без икебез дә: ул шул ярдәмне бирә алуына, мин аның эчкерсез сузылган кулын файдага җигә белүемә куанып яшәдек. Яшермим, Баязит абый мине үзен яратканга гына түгел, мине «мин» булганым өчен дә якын күрәдер дип уйлый идем.

Хәзер без кемнәр?

Теге унышсызлыктан соң минем аннан йөз чөереп йөрүемне ап-ачык сизде бит ул! Без ничек очрашырбыз?

Яфракларына каратут йөгерә башлаган куе карлыган куаклары арасыннан үзе белән куе, көчле ис ияртеп хатыным килеп чыкты, уйларымны бүлде.

— Ни булды сиңа? Поездан төшкәннән бирле исәр кеше күк бер ноктага карап каттың? Ит алып кайтмагансың... Кыяр тозларга кирәк иде. Кисмәк белешмәгәнсең. Шикәр белән аралаштырып төеп карлыган куярга савыт та юк. Күпме вакыт йөрдең үзең. Ә монда карлыган шыбырдап утыра. Чат витамин бит ул карлыган. Кышын бер стаканын әҗәл даруы күк эзләрбез әле менә...

Мин аңгырайган кебек хатынымның сүзләрен кабатладым. Бер карышусыз, зарсыз-сүзсез аның белән ризалаштым. Әйе, кисмәк кирәк. Тәпән табарга иде! Имән кисмәк! Әйе, карлыган чат витамин гына бит ул. Тазалыкны саклау өчен үтә файдалы. Карлыганны коярга ярамый, җыярга, җыярга, җыярга...

Шунда кинәт тагын бер мәртәбә күз кабакларым астында яшен уйнады, дөнья яктырды, киңәйде, зурайды, кешегә кеше булып калуның ничек авыр икәнлеген тагын бер кат сиздем дә, үземнең яшәешем, үткәнем, бигрәк тә бүгенгем кызыксыз, мәгънәсез, буш кебек тоелды...

Үзем, сыер саугандагы кебек чүгәләп, ике куллап кап-кара карлыганнарны сыдырам, үзем дәү чиләккә кап-караңгы уйларымны тутырам кебек... Киләчәк турында, иртәгәге көн турында, үзем турында ныклап уйланырга куркам. Минем микроскопик күзәнәкләрем үземә сизелеп кыймыл-кыймыл сүнәләр. Тик Баязит абыйның якты хатирәсен үзләренә алган күзәнәкләр әле һаман сакта, һаман яшиләр, һаман тынгысызланалар.

Караңгы төште, теләсәң-теләмәсәң дә ул сине иртәгәге яктыга алып барачак...

## 2

Ул көнне Баязит абый янына бара алмадым. Үзваемсызлыгымның сәбәпләрен эзләп маташа торгач, тагын ике көн үтте.

Я инде, дидем мин үз-үземә, теге вакытта «куркак» дигән икән, ышетелгән көннәрендә генә авыр булды ич миңа! Тора-бара Баязит абыйның хаклы булуына ышана төштем, соңгы вакытларда исә аның бу кискен бәясе белән тулысынча килештем. Әгәр шул аерылышу гына булса икән минем ваемсызлыкның сәбәбе!..

Тагын ике көн узды. Минут, секунд узган саен, очрашуның ике як өчен дә читенләшкәнен ачык тойган хәлдә, башымны юләргә салып, һаман нидер көттем, бер икеләндем, бер тәвәккәлләдем...

Болай дип уйлаган идем мин: була, шундый хәлләр дә була, сау чагында теге яки бу кеше белән әйбәт кенә исәнләшеп, хәл-әхвәл сорашып йөргән буласың, ул кеше җир куенына мәңгелеккә ингәч, әлбәттә, кызганыч була, авыр була, әмма күңел артык сызланмый, җан тамырлары битараф кала. Мондый очракта акланып тору кирәкме икән? Һәр адәм баласы кызганыч, һәр җан иясе сиңа кан кардәш, әмма нишлисең?.. Мәңгелекнең хөкеме — аяусыз, хәрәкәтнең ахыргы асылы — бетү, үсешнең нәтиҗәсе — алмашу дип раслый диалектика. Барыбызның да рәхимсез юлга чыгасы бар. Кеше гомере буе мәңге яшәүне хыял итә. Мәңге яшәү өчен ул җан юаткыч чараларын да уйлап тапкан. Үзе үлсә дә, якты көндә аның тәне, гореф-гадәтләре, нәселе, эш-хезмәт нәтиҗәләре кала. Шәһәрләр кала, уртак авыллар кала, уртак күк кала, уртак Идел кала. «Әпипә» кала, «Галиябану» кала, Тукай, Сәйдәшләр кала...

Шуны да ачыкладым: Баязит абый минем өчен сирәк дәрәҗәдә кадерле кеше, югары зат икән.

Безнең ун еллык гомеребез уртак!

Әгәр минем аның үзен кадерләргә күңел җылылыгым җитмәсә, мин әнә шул үзебезнең кадерле уртак гомеребезне бәяләргә тиешмен.

Ун ел!

Күңелемнең юрга тайдай уйнап чапкан еллары! Өмет белән озатылган тынгысыз кичләр. Сүнмәс дәрт белән каршы алынган нурлы иртәләр. Дөньяның дүрт ягын да иңләрдәй булып тибрәлгән якты хыялларым!.. «Яшибез» дип Казан урамнарыннан, «эшлибез» дип институт коридорларыннан дөп-дөп басып, йөрәк кагып узган мизгелләрем. Бассам, идән бөгелә, таянсам, өстәлләр шыгырдый иде. Өчәр төн рәттән йокламый идем, иптәшләрем янына килеп көлеп чыга идем. Ул өйрәтте бит боларның барысына да! Ул!.. Адым саен «эш, хезмәт» димәде, эшләп күрсәтте, хезмәт итеп күрсәтте...

Ул барыбызны да аңлады, белде, хуплады, ярсытты, көч бирде...

Уянгач та беренче сүзем шул булды: «Әгәр бүген дә бармасам, нәселем корысын, әткәм кушкан Сәгыйть исеме харам булсын!»

Күрче, ничек каргана белә башлаганмын...

Дөньяда иң зур бәхет — уйның ачыклыгы, төгәллеге, камиллеге! Инженер буларак мин уйларымны кәгазь өстенә сызарга күнеккән. Кәгазь өстенә төшерәсең дә уйларыңның көчен, сәләтен, гайрәтен күреп куанасың!

Ә үз гомерем, яшәешем турындагы байтак уйларымны кәгазь өстенә төшерү түгел, берәүгә дә сөйләгәнем юк иде. Хәтта хатынга да. Ул да аңламас аларны, кабул итмәс...

Баязит абый катына барасың икән инде, барысына да әзер булырга тиешсең, аңа сөйләмичә кала алмассың, ул ярты сүздән барын аңлар...

Җиденче троллейбуста Баязит абыйлар тукталышын — Совет мәйданын узып та киткәнмен, төшкәч, борылып акрын гына җәяү килдем.

Тышкы ишек ачык, бусаганы атлап керүгә ишле аяк тавышлары ишеттем, өскә күтәрелеп карасам, бер төркем кеше икенче катка менеп бара. Гали Кадыйровны җилкәсеннән таныдым да шып туктап калдым.

Тукталдым. Уйларым кичәгечә, бигрәк тә Гали каршысында Баязит абый белән очрашасым килмәде...

Борылып ишегалдына чыктым.

Бу йортта тагын танышларым бар минем. Безнең институт хезмәткәрләренә моннан алты-җиде ел элек фатир биргәндә бәхетләре шушыннан булды. Баязит абыйлар белән бер үк подъездда, өченче катта бүлек начальнигы Камалов... Ә менә унда, соңгы подъездда, беренче катта кайчандыр без бергә эшләгән Гайфи Бикмуллин квартирасы. Гайфи ихтыярый-мәҗбүри генә безнең институттан киткән кеше, шуннан бирле безнең очрашканыбыз да, күрешкәнебез дә юк диярлек.

Әлбәттә, әле кичә генә мин аларның ишек катыннан салкын гына узып китә алган булыр идем, бусагасыннан атлап кереп, Гайфигә кулымны бирмәс идем. Без аның белән начар аерылыштык. Ызгышмасак та, аннан ким булмады... Бар иде шул аның сәбәпләре...

Теге каһәр суккан группада Гайфи дә бар иде шул...

Кичә кермәс идем аның янына, бусы шиксез... Ә бүген борылдым да нык-нык басарга тырышып, алар подъездына кереп киттем.

Минме бу? Кем янына кереп барам? Нигә?

Әйе, әйе, Гали Кадыйровлар киткәнче посып торырга урын да кирәк иде әле миңа! Мин башкаларны танымадым, аркалары гына күренеп калды, әмма миңа Гали дә бик җиткән...

Гайфи белән очрашу Гали белән очрашуга караганда күңеллерәк...
Дөрес, Гайфинең өйдә булуы, гомумән, аларның квартирасында җан иясе булуының һич ихтималы юк. Ул, минем ишетүемчә, хәзер ялгыз яши, җитмәсә, кайсыдыр төзү трестына проектчы-консультант булып эшкә дә кергән, имеш...
Звонок төймәсенә кагылган булдым, ярым караңгы баскычларында беркем юк, караңгы; әчегән кәбестә һәм песи исе килә. Эчтә дә шылт иткән тавыш ишетелмәде, ишеккә кагылмадылар. Инде батыраеп, катырак итеп тагын шалтыраттым, бу юлы кеше барлыгы сизелде, сорамый-нитми генә тишектәге ачкычны бордылар.
Ишекнең теге ягында яшь кенә мөлаем кыз басып тора иде. Ул мине танып елмайды, мин дә аны хәтерләргә тырышып, аксыл чәчләренә, яшькелт су төсле зур күзләренә карадым. Әйе, әйе, минем дә бу кызыкайны күргәнем бар...
Үзем җитәкчелек иткән группаны һаман хәтергә төшерергә туры килә! Ниләр генә кыйланып бетермәдек үзебез дә! Көне-төне заводта яту гына җитмәгән, ял көннәребездә әле бездә, әле Гайфиләрдә җыйналабыз, иртәдән кара төнгәчә һаман хисаплыйбыз, ярышып-ярсып бәхәсләшәбез! Шул эш чорында Гайфи безгә килеп йөрде, мин дә бик теләп аларга баргаладым...
Шул чагында ишетелер-ишетелмәс адымнар белән почмактан почмакка шушы кыз йөрде түгелме соң?
— Гайфи абыең өйдәме? — дип сорадым кыюланып.
— Эштә,— диде кыз һәм мине ашыгып бүлмәгә чакырды.— Керегез, кер, Сәгыйть абый.
— Урнаштымы ул? — дип сорадым керә-керә.
— Эшләп йөри,— диде кыз, шактый сөенеп.
Кызның исемен онытканмын икән. Нәфисәме, Галияме, әллә Зәкиямe?.. Түгел, түгел, кем соң әле?.. Үзәк универмагта сатучы булып эшли дигән иде аны Гайфи. Бик дефицит чакта «Соната» транзисторын шушы сеңелкәше аркылы алдырдым дигән иде. Әнә ич, таныш «Соната» ялтырап шкаф өстендә утыра.
Исемен хәтерли алмадым, болай сөйләшергә сүз юк иде. Гайфи турында аны-моны сораштырып утыргач, кузгалып ишеккә борылдым. Кызганыч, тәрәзәләре ишегалды якка карамаган, тегеләрнең китүкитмәүләрен күреп торыр идем...
Кыз каушады, кыюсыз гына мине туктатты, ике бите дә алланды:
— Чак кына утырсагыз ла, Сәгыйть абый.
Аның бу үтенече күкрәк тирәнлегеннән калтырап, үзәкне өзеп чыкты, мин кызга гаҗәпсенеп карадым.
Кара-каршы утырыштык. Мин диванда, ул журнал өстәле артында, урындыкта. Ике арабызда илче булып әлегә таркау күз карашлары гына йөри, арадагы ике метрлы бушлыкны шулар гына тотырып тора.
Нинди рәхәт шулай сүзсез, уйсыз, бер-береңалдында бурычсыз утыру! Без ят кешеләр, бер-беребезне белмибез диярлек. Мине бу ишеккә нинди җилләр ташлавын да, минем ми күзәнәкләремне нинди матдәләр тетрәтүен дә ул белми...
Без поезд вагонында очраклы юлдашлар кебек җыен юк-барны олы итеп рәхәтләнеп сөйләшә алабыз! Без бер-беребезне үкенечсез генә алдый алабыз... Без яңадан бервакытта да очрашмабыз.
Сискәнеп киттем, кызның куллары зур, көчле икән, кемдер башка берәү аның артына качкандыр да кулларын аның нәфис тез йомрыларына куйган төсле. Калкынып, үрелеп карадым, ул кызарынды, карашым өскә күтәрелде, аның яшькелт су төсле күзләре белән очрашкач, олы куллары онытылды. Тик кыз, минем нидән сискәнгәнлегемне аңлаган сыман, кулларын өскә күтәрде, сул учын уң кул аркасына

тәрәп, күпер ясады, терсәкләрен тезе өстенә куеп, няген шул күпергә куйды. Ял итә. Тәне дә, җаны да ял итә. Бәхетле, ваемсыз, кабатланмас яшьлек!..

Безнең арадагы бушлык кими бара төсле, мин калкынып алам, ул иелеп-иелеп куя, ләкин без аңа карап бер-беребезгә якынаймыйбыз. Ул бөтенләй башка нәрсәләр, минем күңелемдә күптән онытылган чит нәрсәләр турында уйлый булыр. Кыз кеше ни турында уйласын — матур күлмәкләр, елтыр колак алкалары, танцалар, киноартистлар, чигешләр турында уйлый торгандыр... Мин аның яшькелт күзләреннән бөркелгән гаепсез-гөнаһсыз җиңел, татлы уй дулкыннарында чайкалып ял итәм. Аның тыныч карашы шул кадәрле иркәли мине, күзләремне йомып диван аркасына башымны салдым...

— Бер дә күренмисез, Сәгыйть абый.

— Тәрәзәләрегез ябулы бит.

Өй җиһазларын кояш ашамасын дип, тәрәзә әлгеләренең күбесе саргайган газеталар белән томаланган иде.

Кыз няген «күпер»дән алды, куллары кая барырга белмичә, әле яңак, әле чәч тирәсендә буталышып йөрделәр дә тагын йомры тезләр өстендә иплләнделәр.

Сүзсезлек артык озакка сузылды, безнең ике арадагы бушлык кызыксыз, тоныкка әверелде. Кыз минем алар квартирасын тирән дот итеп сайлавымны белми ич!.. Иренеп кенә:

— Һаман әнәме? — дип сорадым.

— Юк дисәң дә ярый, әйтмәгәнем булсын. Ашказаны белән бик интекте: больницада да ятып чыкты.

— Камилә апаң киләме?

— Нишләп йөрсен ди?.. Бер аерылгач...

— Шулай да... Байтак гомерләре уртак иде... Уллары бар... Тәлгат ни хәлдә?

Мин Гайфинең карлыгач кебек сылу, нәзакәтле кара хатынын, сөрмәле зәңгәр күзле бердәнбер уллары Тәлгатне хәтерләдем. Камилә ханым, врач булу өстенә, халык театрында күренекле генә артистка иде.

— Тәлгат әнисендә. Әни янында хәл ничек булсын ди — яхшы. Быел миңа укырга керә. Гайфи абый аларга барып йөри бугай, аның ачык белмим. Икебез янәшә ике бүлмәдә яшәсәк тә, без бит аз сөйләшәбез.

— Нигә алай? — дидем мин, сүз юктан сүз ясап.

— Сез миңа бөтенләй сөйләшмисез ич. Ни гомер килгәнегез юк.

Тураеп утырдым, кызга карадым.

— Без... бөтенләй башка мәсьәлә.

Кыз, миннән җавап таләп иткән кебек, текәлеп карап утыра, ике арадагы рәхәт бушлык кинәт дулкынланды, чайкалды, хәвефлегә әверелә язды. Урынымнан кубып стенада эленеп торган гитара янына килдем. Камилә ханым гитарасын алып китмәгән диган сүз.

— Театрны ташладымы әллә, Камилә апаңны әйтәм?

— Юк. Әллә ишетмәдегезме? Ул «Гүзәлем Әсәл»дә Әсәлне уйнады... Телевизордан да күрсәттеләр. Камилә апаны театрга да чакырганнар!..

— Алаймыни!..

— Бер булган кешегә талантын да биргән инде...

Гитара кылларына чиртеп карадым, кыллардан тузан катнаш яшелле-мөшелле тавышлар өзелеп чыкты. Гайфи дә уйнаштыра торган иде бит...

— Гайфи тотмый, ахрысы, моны?

— Бик күптәннән.

— Шунда универмагта эшлисеңме? — дидем мин кинәт.

— Юк. Әлегә «Балалар дөньясы»нда. Элек ул кибет универмагның филиалы иде, хәзер ике хуҗалыкка аердылар. Мин бүленеп калдым.
— Ошатмыйсың сыман?
— Универмагка, элекке эшемә кайтырга йөрим.
Кыз минем сорауларыма күңелле генә тавыш белән җавап биреп, сорашуыма сөенеп, куанып утыра иде.
— Радиотоварлардамы әле син?
Без икебез дә шкаф өстендәге «Соната»га карап алдык.
— Түгел, мин пластинкалар бүлегендә идем.
— Ә хәзер?
Ул яшереп кенә көлеп алды.
— Хәзер балаларга бүрек сатам, башлык сатам.
— «Балалар башы буенча» квалификацияле белгеч инде син, алайса?
Ул кычкырып ук көлеп җибәрде, аның көлүе үтә яңгыравыклы, үтә кызык, куанычлы, дәртле икән! Кинәт көлеп җибәрде дә, үз көлүен үзе тотып калырга теләгәндәй, бөтен гәүдәсе белән алга талпынды.
— Эх, Сәгыйть абый! Сез безгә килеп йөргәндә күңелле иде, ичмасам!.. Өй гөрләп тора иде... Кеше килгәнне бик яратам мин.
— Ә хәзер?
— Хәзер өебез буп-буш... Тып-тын... Гайфи абыйга ияреп кайткалыйлар, иптәшләре дим, мүкәләп йөриләр...
— Килеп булмый шул, бергә эшләмәгәч...
— Сезне эш кенә дус итә идеме әллә? — Кызның битләре тагын да алланды.— Мин башкачарак уйлый идем...
Теләсә ни уйласын, аның белән аңлашып, акланып азапланасым юк. Сүз куермый торсын әле, кирәкми... Бүген болай да күп нәрсәләрне актарып чыгарга туры киләчәк, Баязит абый янында дим...
— Синдә ни хәлләр?
— Безнең нәрсә булсын,— диде ул, тагын да ачылып.— Менә сезнең тормыш кызыктыр ул.
— Кемгә ничектер,— дидем беренче тапкыр чын күңелемнән.— Күрше тавыгы күршегә каз булып күренә диләр...
— Мин бит сезне беләм!
— Рәхмәт!.. Кырыкка житкән инженерның хәлен белер өчен кырыкка житеп, аны узып карарга кирәк. Искитәрлек берни дә юк... Гапгади көнлекче инженермын...
Ул миңа ышанмыйча, әмма тирән кызыксыну белән карады.
— Мактатасыгыз киләме, Сәгыйть абый?
— Макталасы киләдер, тик синең кулда мине мактарлык дәлил юк бит.
Ул хәйләкәр генә елмайды, күзен кысып куйды.
— Мине надан бер кибетче дип уйлыйсыз инде, газеталарны бер дә укымый дип беләсез.
— Куркытма инде мине, зинһар.
Кыз торып ук басты.
— «Автоматизация-69» күргәзмәсендә сезнең теге атаклы линиягез беренче дәрәҗәле диплом алган. Котлыйм, Сәгыйть абый.
— Гайфи әйттеме? — дидем мин, коры гына.
— Үзем укыдым, ихлас.
— Әй,— дидем мин теш арасыннан гына,— былтыр үлгән ябалакның биел чыккан хуш исе!.. Үземнең гап-гади бер көнлекче икәнлегемне әйтеп авыз ачарга ярамый инде миңа, тоталар да шул нәләт суккан линияне телгә алалар.
Кыз минем «көнлекче» кушаматына үзем теләп риза булуыма ышанмады, минем сүземне гадәти бер шаяру, наянлык дип санап, йом-

ры тезләрен көчле учлары белән кысып, киеренке кыяфәттә миннән нидер көтте. Мин дәшмәгәч, үзе сүз башлады:

— Дефибрерларның ни икәнен генә аңлый алмадым, Сәгыйть абый. Надан шул әле мин!..— диде.

— Аңлауның кирәге дә юк сиңа.

— Беләсе килә дә...

— Бикме?

— Бик.

— Һе... Ул кәгазь комбинатында бүрәнәдән агач массасы ясый торган механизм... Бүрәнәне, агачны изеп ботка ясый, аннан кәгазь. Шул дефибрер дип атала.

— Элек агачны кул белән тутырганнармы аңа?

— Әйе.

— Сез шуны автоматлаштырып тоташ линия ясадыгызмы?

— Алдамасалар, шулай диләр... Күптән булган хәл ич инде ул!.. Мин аңа бик ышанып та бетмим, ай-һай, булдымы икән?..

Кыз тырышып-тырышып сораштырып утыра, мин эчемнән генә көлемсерим... Булды, узды заманнар! Мин линияне эш арасында гына, планнан тыш кына эшләгән идем. Баязит абый белән аралар суыпганчы булды ул хәл. Яшь чак шул, егәрле чак! Көтмәгәндә линияне күтәреп алдылар, миңа зурлап авторлык таныклыгы тоттырдылар. Мәскәүдәге Халык хуҗалыгы күргәзмәсе Зур алтын медаль бирде. Егерме ил линиянең патентын сатып алды. Австрия фирмасы «Фойт» совет лицензиясе буенча җитештереп шул линияне башка илләргә сата башлады.

Күктә салават күпере аша гына йөргән чакларым минем!..

Менә бүген исемсез кыз шул эш өчен мине мактарга итә, ә минем аңа бер тамчы да исем китми, киресенчә, нигәдер хурланам, гарьләнәм. Әйтерсең лә үз гомеремдә мин шул линияне генә эшләгән! Аның даны миңа бәла булды инде... Нинди эш башкарсам да шул линия белән чагыштырып карыйлар, шуның нәтиҗәсе белән үлчиләр... Әйе, бу эше дә начар түгел Сәгыйтьнең, шулай да теге линиясеннән кайтышрак... Линия бит ул... Вот это да!.. Окей, вери гуд!.. Чит ил фирмалары таңга калды... Алтын медаль!.. Ах та ух, ух та ах!..

Бу кызыйның матур колагына шул хәбәр генә килеп ирештеме икән, әллә минем мәтәлеп барып төшүемне дә ишеткәнме ул?

Баязит абый яныннан таралыштылар микән тегеләр? Монда кыз янында инде эчем поша башлады. Гали Кадыйровларның чыгып китүләре миңа тәгаен кирәк иде, шуңа күрә Баязит абый янына керергә ашыкмадым. Кызны онытып, бөтенләй башка нәрсәләр турында, бетеп килгән ялым турында, көймә моторымның ватык стартеры турында, Гайфинең мине «старик» дип кенә атап йөрүче бәләкәй улы Тәлгат турында, тагын шундый бик күп вак-төяк турында уйландым.

Соңгы вакытлардагы бик бәләкәй үзгәрешләр дә мине гел узганнарга алып кайта, нәтиҗәдә мин үземнең бүгенге яшәешем хакында борчылып, уфтанып уйланам.

Чын дөньямны таптыммы мин? Үземнең дөньямны? Яшәешемнең эчтәлеген минем көндәлек эшләрем тутырып тора аламы? Нигә үткәннәремне һәм бүгенгемне уйлаганда күңелсезләнәм әле болай? Минем тирә-ягымда яшәү мәгънәмне аклый алырлык ни-нәмәрсәләр бар? Әллә анда бушлык кынамы? Билгесезлекме?.. Менә бу кыз дефибрерны телгә алуга ук мин үзгәрдем ләбаса, салкынайдым, җансызландым...

Бу кызыкай да билгесезлек... Шушы булмә дә... Минем серем сыймый бу кызга, аның серләре миңа кирәксез. Шулай түгелмени?..

Монда да озак ышыкланып торып булмады, тизрәк чыгарга кирәк. Тизрәк, тизрәк!..

— Сау бул, сеңелем!

Кызый бу юлы мине туктатырга кыймады, сәбәп тапмады, ачык ишек яңагына сөялеп озатып калды.

### 3

Звонокның кара, елтыр төймәсенә сак кына кагылдым — үземнең төпчек улымның борынына «пип-пип» итеп басып уйнагандагы төсле генә. Эчтәгеләр мине көтеп чамалап торганнар диярсең, ишек шундук ачылып китте, ярым караңгылыкта Баязит абыйның хатыны Гөлсәйрә апаның агарынган, талчыккан йөзе күренде. Ул мине күреп елмайды, ут кабызды, чуар кәгазь ябыштырылган стенага сөялеп, ботинкаларымны салганны түзем генә көтеп торды. Зал ишеге ябылган иде. Гөлсәйрә апа артыннан кухняга уздым. Кухня өстәлендә дә шешәләр, дарулы банкалар тора.

— Бер дә күренмисең,— диде Гөлсәйрә апа, каушаган чыраема карап.

Монысы әле әрләү түгел, бу йомшак җилнең сыйпап китүе генә. Шулай да мин, мөмкин хәтле кызганычрак тавыш чыгарырга тырышып:

— Шулайрак булды инде,— дидем. Дөресен әйткәндә, Гөлсәйрә ападан юату сүзе, тынычландыру сүзе көтә идем.— Бушаган да юк диярлек... Эш-эш дип егәрне бетереп ташлыйбыз да, ялга чыккач, иләсмиләс ятабыз... Сез ни хәлләрдә?

Кем турында соравым мәгълүм булса да, Гөлсәйрә апа сабыр гына үзе турында, тагын кузгалган баш өянәге турында зарланып алды.

Тышта жып-жылы көн булса да, аларның ялтыр лаклы яшел идәннәре чиклы болын төсле сап-салкын иде, әле бер аягымны күтәреп, әле икенчесен күтәреп, ата каздай тыпырдап басып тордым. Ниһаять, Гөлсәйрә апа минем сорауга җавап бирде:

— Бер көйгә мыштырдыйбыз инде, Сәгыйть... Ишеткәнсеңдер, хәлләр шул...

— Баязит абыйны күрәсе иде.

— Аның да сине күрәсе килә,— диде Гөлсәйрә апа, мине тагын да каушатып, сораштырып та куйгалый.— Тик бүген түгел инде, яме?

— Бүген ярамыймы?

— Бүген кеше бик күп килде, Сәгыйть, абзаң бик арыды. Аннары йокысы бер дә юк, дару биреп, укол-мазар белән генә азрак йоклатабыз... Хәзер нәкъ менә шул чагы... Йокыда абзаң...

— Гөлсәйрә апа!..

— Нәрсә сораганыңны беләм, Сәгыйть... Өзеп кенә бер сүз дә әйтә алмыйм... Бик кызганыч бит! Дөнья бәясе торырлык кеше ауды да китте... Мин ышанмыйм, һаман терелер сыман. Үзе дә ышанмый, икебез дә өметләнәбез... Син килеп йөр, Сәгыйть, яме!.. Уллары белән кил, аларны бик ярата иде бит Баязит абзаң...

Мин гадәттәгечә юату сүзләре мыгырдандым, ул мине беренче каткa хәтле озата төште.

— Килермен, Гөлсәйрә апа.

— Хатының Разиягә сәлам әйт.

— Рәхмәт, Гөлсәйрә апа.

Мәйданны кисеп, кыеклап трамвай тукталышына чыга башладым. Көн гаҗәп жылы, кояшлы, яфрак очлары тутлана башлаган сузан каеннар астында күбәләкләр оча. Янәшәмдә генә кемдер бара, әмма минем күтәрелеп карыйсым килми. «Баязит абыең сине көтә», дисә дә, Гөлсәйрә апа мине аның янына кертмәде. Галиләр, мөгаен, кергәннәрдер. Ярамаса да кергәндер Гали. Ә мине борып чыгардылар.

Тукта әле, нигә мин гел шулай кире якка, киреләккә генә сукалыйм?!. Бүген кирә алмаганмын икән, иртәгә күрешербез... Хәзер килеп керү җиңелрәк булачак.

Янәшәмдә баручы кыз тыелып кына көлеп куйды: теге кыз ич бу!

— Ә син кая барасың?

— Барам әле, Сәгыйть абый, гаризамны карамадылармы икән, мәктәпкә дә кагыласым бар.

— Мәктәпкә?

— Кечке мәктәптә укып азапланам әле мин. Соңгы елым.

— Алай икән.

Кыз минем янәшәмдә сүзсез генә бара, мине гаҗәпләндереп аның яшькелт күзләре туктаусыз елмаялар, нидер көткән сыман әле тирәнәяләр, әле зураялар. Гайфи абыйсы турысында сораштырасы киләме әллә? Миннән бер-бер ярдәм, киңәш көтәме? Аның юлдан язган абыйсын хак эзгә төшерерлек көч миндә бар дип өметләнәме?

Кем дип беләсең син, кызый, Сәгыйть абыеңны?.. Күргәзмәдән алган алтын медальләр, газеталардагы төче мактау сүзләре сине сукырайткан ич!.. Түгел, эшлекле, төпле кеше түгел Сәгыйть абыең, Гайфине үзгәртерлек көч аңарда юк. Көчле кеше аның үзенә кирәк!.. Япаялгызы яшәп ята ул!..

Трамвай тукталышына җиткәндә генә кемдер арттан кычкырды:

— Эшкә барасыңмы, Рузалия?

Рузалия бит әле аның исеме, Рузалия! Ишеткәнем бар икән, сөйләшеп торганым да бар. Тик кайчан иде соң әле бу?

Икебез дә борылып карадык.

— Әйе, апа, шунда таба барыш.

Тик апасы аңа карамый да, ул йотардай булып миңа ябырылган. Тукталдык. Тик апасы яңадан берни сорашмады, хәтеренә сеңдерергә җыенган төсле баш-аягымны тикшереп чыкты.

Исемсез чакта кызый серлерәк иде. Ярым караңгы бүлмәдә каракаршы утырганда безнең бу әңгәмәбезнең күңелне кымырҗыта торган гүзәллеге бар иде... Хәзер без икебез дә бердәйләр, гади кешеләр, исемле кешеләр...

Кеше үзенең чын йөзен кайсы очракларда күрсәтә? Менә Гөлсәйрә апа янында мин бер кеше идем, хәзер, Рузалия янында, бөтенләй икенче кеше. Асылы үзгәрәме кешенең, тойгылары гынамы?..

Рузалия миңа карый да елмая, ул көн яктысында тагын да күркәмрәк, чибәррәк. Хәер, бусын тәгаен өзеп әйтергә дә куркам. Кырыкны узган күзләргә бик күп кызлар матур күренә, алар яшьлекләре, сафлыклары белән көнләштерәләр.

— Ничә яшь сиңа, Рузалия?

— Күп инде, Сәгыйть абый.

— Шулай укмыни?

— Унтугыз тула!

Ул үзенең яшеннән читенсенгән төсле авырсынып, оялып әйтте бу санны. Унтугыз яшьлек чагы!.. Шулай да мин аны чак кына олырактыр дип уйлаган идем. Гәрчә унтугыз яшьлек кыз — унтугыз яшьлек егет түгел, ул инде олы кеше.

— Сез үзгәргәнсез дип әйтимме, Сәгыйть абый?

— Сизеләме? — дидем мин, чигәләремне капшап.

— Кистереп әйтү кыен...

Аның шулай тикшереп, аңлатып азаплануыннан көләсем килде, шушы кыска вакыт эчендә мине бәяләп тә өлгергән!

Трамвайлар килә тора, кеше тутырып китә тора, без юк-барны гәпләшеп кала бирәбез. Рузалиянең үзе хакында сораштырдым, Гайфинең кеме ул, кайсы якта туып-үскән кыз, әти-әнисе бармы, кемнәр...

Казан арты кызы икән, Гайфинен туганнан туганы икән... Әнисе исән...

Бу сораулар минем ихтыярдан башка бирелделәр, бернichә көн рәттән гел бер юнәлешкә уйлаган күнелем хәзер таралып, җиңеләеп калган иде. Аңа гади, гадәти сүзләр, хәйләсез-рыясыз сөйләшүләр кирәк булгандыр, ахры. Рузалия минем сорашуымнан мәгънә табып, иренмичә, бөртекләп аңлатып бирде.

— Сәгыйть абый, әйдәгез, берәр тукталыш арасы җәяү барабыз. Көн дә матур, сезнең вакыт булса, минеке иркен,— диде ул көтмәгәндә.

Кызның миндә йомышы бар! Бусы инде ачыкланды. Нигә турыдан-туры шуны сорамый соң ул?..

— Укыйм дигенме әле?

Бераз тын баргач, шулай дип куйган булдым.

— Үз вакытында укымагач, азапланам шунда.

— Үз вакытында нишләп укымадың?

— Сыек чыбык белән чабаклаучы булмаганга... Ятимлек тә сәбәп булгандыр инде... Гайфи абый да укы димәде.

— Тора-бара чыбыклы кеше табылдымы?

— Әйе,— диде ул. Дулкынлана башлады исә, аның ике бите дә комач кебек аллана иде.

— Ярый,— дидем мин эшлекле генә.

— Сәгыйть абый!

— Әйтеп кара, Рузалия.

— Сез бая сораштыгыз да сораштыгыз, мин дә бер-ике сорау бирсәм, ачуланмассызмы?

— Яудыр әйдә!

Ул, иреннәрен кыса төшеп, беравык уйланып барды.

— Сез... бая уйнап кына әйттегезме?

— Кайчан?

— «Көнлекче» дип, тагын шундый йогышсыз сүзләр сөйләдегез.

— Ошадымы?

— Ошамады. Сезнең яшьтәгеләр хәзер дөньяны кулларында тоталар дип беләм мин. Шуларга кызыгып йөрим... Әйе, сез мине бала-чагага санап, шаярткансыздыр, бәлки...

Кара син кызыкайны! Мыштым гына тыңлап утырган иде, мыегына чорнап барган икән!

— Мин үз яшьтәшләрем исеменнән, аларның вәкиле булып сөйләмәдем, Рузалия, бары үз эшем турында гына иде сүзем!

— Кешенең эше уеннан аерыламы?

— Я инде,— дидем мин, аның юлына аркылы төшеп.— Ни пычагыма кирәк сиңа болар? Вакыты җитәр, төшенерсең. Төшенмәсәң, чорт с ним!

— Минем хәзер аңлыйсым килә шул,— диде кыз кирелэнеп.

— Кабаланма. Бәхетле яшә. Иркен яшә, ваемсыз яшә!.. Ничек яшәсәң дә ахыры бертөсле булачак бит...

— Ахыры,— диде ул, уйлары белән уртаклашырга теләмичә генә.— Ахыры... Соңы... Сез Баязит абыйларга кердегезме?

— Керсәм соң?! — дидем мин шикләнеп.

— Бик тиз чыктыгыз... Хәле ничек?

— Йоклый иде...

— Гайфи абый да сирәк-мирәк керә башлады аларга. Андый көн бәйрәм була минем өчен. Шешә яламый, ичмасам!..

Чираттагы тукталышка трамвай да килеп җитте, без дә барып туктадык.

— Сез ашыгасыздыр, мөгаен? — диде ул, уңайсызланып кына.

— Әйе,— дидем мин, ялганлап.

Кердек. Алдарак буш урын бар иде, кызны шунда утырттым да үзем арткарак бастым. Ул борыла-борыла барды да түзмәде, торып минем яныма килде.

— Күңелсез лә анда, Сәгыйть абый.

— Сиңа «күңелсез» еш буламы?

— Булгалый инде... Төрлесен күрәбез.

— Синең сөйгән кешең бармы? — дидем мин турыдан-туры.

Ул тагын июнь шәфагы төсле кабынды.

— Шулай сорыйлармы инде, Сәгыйть абый?

— Сөйгән эшең, яраткан кешең булса...

— Бар дип раслый алмыйм, юк дияргә дә көчемнән килми. Бар да, юк та...

— Сәер... Сине егетләр яраталардыр?

— Гайфи абый мине «ямьсез» дип тирги, күзләрең ак, ди.

— Ачуланышасызмы?

— Ничек кенә әле!.. Мин бит лепелдәгән тавык төсле юаш кына яши белмим. Авылда мине «Чәтертән Рузалия» дип йөртәләр иде... Абыйга көн күрсәтмим кайчагында, шул ошамый. Усаллыгым җилбәзәклегемнән генә килә дип уйлый... Сез дә, Сәгыйть абый, мине җилбәзәк бер адәм дип уйлыйсыз ич!

— Булсаң ни?

— Җилбәзәк түгел мин, бик күптәннән. Олы кеше мин, Сәгыйть абый.

Мин карыйм, ул карый. Мин сап-салкын, ул елмая.

— Сезнең эшегез, тормышыгыз турында уйласам, кызыгам мин! Гаҗәп күңелле бит сезнең тормыш!

Олы кеше!.. Кызыга! Елмая!.. Үзе түгел лә, балалыгы елмая. Барын да беләм, барын да аңлыйм дип куана. Бичара яшьлек, тиле яшьлек...

Безнең дә тиле, давыллы чаклар бар иде!

Дөнья агышына без бер буын булып килеп кердек.

Яшьтәш кызлар, яшьтәш малайлар...

Мең тугыз йөз егерме сигезенче елда туганнар. Борынгыча әйтсәк, Балык елында туганбыз без.

Туфракның бер катламы, агач каусәләрендәге бер сыр безнеке булды. Дөнья тарихының бер елын без туган елыбыз иттек.

Үстек, аякка бастык, тернәкләндек.

Кешеләрнең язмышы бер-берсенә охшамаган кебек, буыннарны да үзгә, охшаш булмаган язмыш көтә...

Әтиләр, абыйлар мылтык тотып, кылыч асып Ватан сугышына чыгып киткәндә, без мәктәп балалары идек...

Без — ятим, тол әниләрнең сыңар канатына сыенып үскән малайлар, кызлар. Сугышның утлы сулышы нәкъ безнең елгыларга килеп житеп тукталды, егерме җидедә туганнарны армиягә алдылар, без өч-дүрт ел никрут булып йөрдек.

Без ипине утыз яшькә җиткәч кенә туя ашадык. Шоколадны беренче тапкыр егерме биштә татып карадым мин, морожныйны егермедә. Шампан шәрабен утызны узгач кына...

Җилкәләрдә йөргән авыр капчыклар, саллы юеш бүрәнәләр, таш төялгән, күмер тутырылган вагоннар — ул без!

Үзебез сабанга җигелеп сөрелгән әремле кырлар — ул без!

Станокларга буебыз җитмәгәч, бүкәнгә басып тимер кырган — ул без.

Чи утын ягып, пыш-пыш килеп, көне буе барган, инә буе җир киткән пароходлар, паровозлар — ул без.

Ягылмаган класслар, дәфтәр урынына — саргайган газета битләре — ул без.

Әниләрнең ябык куллары, яшькә манчылган зур күзләре — ул без.

Нужа кешене ашыгып яшәтә, без бик иртә ир булдык. Ир булгач инде елашмадык, бирешмәдек, сатылмадык. Без аз сүзле идек, кырыс идек, нык идек.

Без барысына да үзебез шаһит: җинүне дә яулаштык, ачыны-төчене дә бүлештек, хаксызга рәнҗегсәләр дә, үпкәли белмәдек...

Безнең күзләр барын күрде. Авторитетлар, ярым аллалар, без табынган затлар пьедесталлардан безнең алда чәчрәп төштеләр. Тугрылыкның, хаклыкның бәясе бермә-бер күтәрелде.

Боларның барысын да бер күңелгә сыйдырып бетерү, аңлату читен булса да, без бирешмәскә тырыштык...

Тормыш дулкыннары безне, беләкләре ныгып килгән егет-кызларны, күнегелгән авыл нигезләреннән куптарып, зур калаларга китерде. Кәҗә бәрәннәре, сарык бәтиләре, ак муенлы көчекләр белән янәшәдә аунап үскән малайлардан без бер көнне кала абзыйлары булдык.

Авылда барысы да бик гади иде.

Үткәннәр, әнә алар, ап-ак ташлар булып зират өстендә тезелешеп утыралар...

Туган ил, туган җир төшенчәсе аермачык иде.

Туган ил...

Тегермән арыгыннан шаулап аккан инеш суы...

Тыкрыкларга сыймый каңгылдашып кайткан ак казлар...

Көзге урман юлларында тәгәрмәч эзләреннән йөгерешкән сары өрәңге яфраклары.

Бабайлар, этиләр шулай яшәгәннәр...

Авыл белән шәһәр ул чагында бер-берсеннән бик ерак торалар иде, тормышларында аерма зур иде.

Без, чабаталы авыл малайлары, бер мәлгә аптырашта калдык. Берәүләр сыгылдылар, берәүләр егылдылар, берәүләр яраштылар, берәүләр югалдылар.

Без таралыштык һәм янадан бер-беребезне җыеп ала алмадык...

Бәлки, бу кичерешләр минем баштан гына узгандыр? Бөтен бер буын исеменнән сөйләргә беркем дә мине вәкил итмәде. Әмма узганнар эзсез генә югалмады, узганнар безне бүгенге көн кешеләре итеп ясады...

Рузалияләрнең тормышы башкача булыр!..

Мин алар буынын аңлап бетермим, алар безне аңлап бетермиләр булыр. Кайчагында, җае чыгып, узганнарны хәтергә төшерә башласам, яшь танышларымнан берсе болай дия торган иде: «Сез кешеләрне кечерәйтәсез, сезнең буын вәкилләрендә эгоизм көчле. Шул сәбәпле гел авырлык турында, авырлыкка күнегү турында сөйлисез. Ягъни менә без кемнәр, менә без авырлыкларны күпме кичердек дип, бездән нидер таләп итәсез. Сез авыр яшәгән дип, без үзебезгә мөмкин булган рәхәтлекләрдән баш тартыйкмыни инде?!»

Юк, Рузалия безнеңчә яшәмәсен ул, тормыш юлы башкача булсын.

— Сәгыйть абый дим, килеп җиттек!

Вагон уртасында икәүдән-икәү генә калганбыз, ургылып яңа пассажирлар кереп киләләр.

— Төшәбез, Рузалия, төшәбез.

Бу — «Кольцо». Казанның казаны шушы инде. Тукталыштан бер читтәрәк басып торабыз.

— Менә безнең институт!

Мин «Совет» гостиницасы каршындагы ак бинаны күрсәттем.

— Белә-әм ич мин аны!

Елмаерга кирәк иде, коры гына эндәштем:

— Сау бул!

Кыз хушлашырга ашыкмады, аның сүзсезлегенә күнегеп килҙә идем, сабыр гына көтеп тордым.

Тагын ни кирәк сиңа, кызый? Алыш-бирешебез тәмам ич, күрмисеңме әллә, кирәк чагында мин синең янга сыенып кала алдым, рәхмәт!.. Без синең белән хәзер ят кешеләр, безнең күләгәләр асфальт өстендә ялгыш кына янәшә яталар.

Син пластинкалар бүлегенә күчүенне белешергә киләсең, мәктәпкә керәсең бар, ә мин Баязит абый яныннан кайтып киләм...

Я, соңгы сүзенне әйт тә хушлашыйк. Яхшы сүз әйтсәң дә, яманны әйтсәң дә, үпкәләмим.

Баштарак абайламаганмын икән, почмактагы мебель кибетенең ишеге төбендә бер исерек ауный, ике-өч малай, борыннарын казыйказый, аны тамаша итәләр.

Мин кайтып барам, Рузалия мәктәбенә бара, исерек аунап ята... Бер нәрсәдә гаме юк, дөньяны туфан бассын, ай-кояшның чите кителсен, аңа берни түгел, кап-каты асфальтта изрәп йоклый... Торып аягына баскач та ул мәңге айнымас, дөньяның дүрт ягына шөбһәле күз белән карамас, кеше гомеренең башы-азагы турында уйлап азапланмас. Йолдызлы сихри күкләргә карап яшәүнең мәңгелек кануннары турында уйланмас.

Йокла, кеше — әгәр сиңа кеше исеме харам булмаса! Йоклый бир. Синең ми тартмаңа истәлекләр түгел, өч тәңкәлек аракы сөреме генә тутырылган. Торма, кеше, ят, ят!.. Синең замандашларың да, узганың да, киләчәгең дә юк. Син замандашларың юлыннан тайпылу өчен шушы ысулны сайлагансың.

Син берүзең!

Синең Баязит абыең да, Гали Кадыйровың да, Гайфиең дә юк, Рузалияң дә юк. Бөтен урамнарга, миллион кешеле Казанга бу мизгелдә син берүзең!

— Сәгыйть абый!

— Гафу ит, Рузалия, әллә нәрсә бүген... Онытылып китәм.

— Сәгыйть абый, сез берни дә күрмәдегезме?

Нигә алай куркынып эндәшәсең миңа, балакай? Нигә исерекне жилкәң белән миннән капларга тырышасың?!

— Хушыгыз, Сәгыйть абый, сау булыгыз!

Бу юлы минем Рузалиядән аерыласым килми, әллә ничек күңелем нечкәрде, елыйсым да килә кебек...

— Универмагка күчсәң, синең янга кагылырмын әле.

— Күчәм, күчәм, Сәгыйть абый.

— Әйбәт пластинкалар булса, мине онытмассың.

— Онытмыйм, Сәгыйть абый, һич онытмыйм. Сезгә нииндиләр кирәк булыр икән?

— Скрипка концертлары, Рузалия. Миңа тагын ни кирәк булсын? — дидем мин жиңеләеп, шатланып.— Ялгыз башың кичләрен өстәл янына утырасың да, әйеме?.. Паганининың «Кампанелла»сы... Яша Хейфиц башкаруында Сен-Санс туры килмәсме?.. Сарасате очрамасмы?..

— Сез өйгә дә килегез, Сәгыйть абый. Кибеткә генә түгел.

Сизәм, кашларым жыерылды...

— Өйгә? Гайфи абыең яратмый ич мине!

— Өйдә бер Гайфи абый гына түгел, мин дә бар... Бүген кердегез, Сәгыйть абый, монысына рәхмәт.

— Һм-м, кердем шул...

— Абый сезгә кирәк булмаса да, сез аңа кирәк. Бик кирәк дип беләм мин...

Күземне ныклабрак ачып караганда янымда Рузалия юк иде инде. Әнә, аның бик килешеп торган кыска соргылт күлмәге тегендә —

урамның аргы башында чагылып китте. Арырак такси тукталышы. Кулын күтәреп такси туктатырга азаплана кебек күренде дә Рузалия бөтенләй югалды.

Институтка кагылмадым инде, нигә күз көеге булып күренеп йөрергә? Алар бүген Баязит абый янында булып кайттылар, ә Гөлсәйрә апа мине кертмәде.

Ресторанда халык бик аз иде, өстәлләр буш. Коньяклары җылы, шулпалары салкын булып чыкты. Йөз чытып кына эчтем, яратмыйча гына ашадым.

Урамга чыккач, борылып карадым, теге исерек юк иде инде.

Тукта! Нигә Рузалия тиктомалдан кабалана башлады бая? Такси алып кая барырга җыенды?.. Гайфи булмадымы икән, анда кибет төбендә...

Барып чыккан икән бичара... Рузалиянең әйтәсе килмәгәндер, сиздерәсе килмәгәндер...



## 4

Эшкә чыктым. Бүлмәдәшләр белән бер-ике авыз сүз алыштык. Һәммә кешенең телендә Чаллы. Безнең институт Кама автомобиль заводын төзүгә турыдан-туры катнашачак!..

Сәгать уннарда мине институт директоры Гайшә Хәлиловна чакыртып алды.

Курыктым, директорның бер ел инде мине чакырганы юк иде, сектор мөдиреннән:

— Нигә икән, белмисезме? — дип сорадым.

Сектор мөдиребез яңа кеше, яздан гына бездә эшли, белсә дә мине бик аз беләдер, соравыма туры җавап бирмәде:

— Беләм, әлбәттә. Тик Гайшә Хәлиловна үзе сөйләшер,— дип кенә куйды.

Башка вакытта ачык йөз белән каршылаучы мөдиремнең шулай сер саклап азаплануы бик шөбһәле иде.

Соңгы елларда әллә ни эш күрсәтә алганым юк шул, институт җитәкчеләрен, хезмәттәш буларак, канәгатьләндерә дә алмыймдыр...

Өченче катка мендем. Директор янына берәү кереп өлгергән икән, чак кына көтеп торырга куштылар.

Безнең директор Гайшә Хәлиловна хакында: «Йоглар системасы белән дәвалана икән»,— дип сөйлиләр. Белмим, ул кадәресенә керә алмыйм, әмма директорыбыз — илленең теге ягында булса да, чемкара сумала чәчле, көчле, бетмәс-төкәнмәс хыялларга бай хатын. Институтта бик күпләр аны яраталар, бик күпләр яратмыйлар. Яратмаганнар аңардан куркалар, бусы — табигый. Белгечлеге буенча ул — химик. Түбән Кама химкомбинатында, Казанның оргсинтез заводында ул үз кеше. Байтак кына хезмәтләре Союзга билгеле.

Шуның өстенә, ул атаклы театрал, премьераларны калдырмый, администраторларга «син» дип кенә дәшә, һәр елын диярлек чит илләрдә сәяхәттә уздыра, кино-фото белән мавыга. Япониядән алып Испаниягә кадәр ул булмаган ил юк. Инде сон гына, кырык биш яшьләрендә, үзе бик яхшы белгән инглиз теле өстенә испан, немец телләрен өйрәнде. Гайшә ханым үз вакытында Баязит абыйны байтак гайбәтләрдән аралап калды, алар бер-берсен якын күрәләр иде.

Заманында без дә бер-беребезне чит итми идек! Эч серебез сыя иде, мин йомыш юк чакларда да аның кабинетына кергәлим, директорның сөйләшерлек вакыты табылса, дөнья яңалыклары турында фикер алышып, гәпләшеп утыра торган идек. Ул җәмәгать эшләренә күбрәк катнашканга күрә (Казанга чит илдән-мазардан делегация

килсә, аны шундук каршыларга җибәрәләр!), вакытлы матбугатны, техник информацияне күзәтеп барырга вакыт җитми дип зарлана, мин исә үз профилебезгә караган журналларны су кебек эчә идем. Шул җирлектә якынайдык та бугай...

Якынайдык та, башка бик күпләр белән булган кебек үк, ерагайдык та. Ничек килеп чыккандыр, мена бер елга якын күзгә-күз сөйләшкән дә юк диярлек. Мин башкарган эшләр директор кабинетына ук менеп җитмиләр, шунда түбәнгерәк катларда ансат кына, шау-шусыз гына хәл кылыналар. Мин моңа эчтән генә сөенеп йөри идем...

Нигә чакырыр мине болай? Эшкә чыгуымның беренче көнендә үк ни йомышы төшәр!..

— Саумы, Сәгыйть,— дип каршылады ул мине.— Ял килешкән, тазаргансың, чибәрләнгәнсең...

Уф, әгәр яман хәбәр өчен булса, сүзне болай башламас иде, шәт, хәерлегәдер...

— Ял итәргә өйрәнеп киләбез, Гайшә ханым, рәхмәт.

Сәламәтлек, ял турында үзаралый әйтелә торган сүзләрне кабатлаганнан соң, мин:

— Ишеттегезме, Баязит абый чирләп егылган,— дидем.

Яңа хәбәрне аңардан да элек үземнең әйтеп каласым килде. Сүземнең тәэсире ничегрәк булды икән дип күтәрелеп карадым. Гайшә Хәлиловна, мин көткәндәгечә, агарынып китмәде, сабыр гына, әдәп белән генә авыруның хәлен сорашты. Үзе дә шушы араларда гына Баязит абый янында булган икән, белгәне минекеннән артык булып чыкты, хәтта больницада аерым палата алуга кадәр ирешкән, ләкин Гөлсәйрә ханым яңадан больницага салырга ризалык бирмәгән.

— Баязит абый сезгә берәр нәрсә әйтмәдеме? — дип сорады Гайшә Хәлиловна.

— Юк,— дидем мин, кызарынып. Үземнең күрешә алмавымны танырга көчем җитмәде.— Нәрсә әйтергә тиеш соң ул миңа?

Гайшә ханым минем соравыма җавап бирмәде, өстәлдә яткан кәгазьләр арасыннан берсен сайлап алып, миңа күрсәтте.

— Менә нәрсә, Сәгыйть туган... Гайфи Бикмуллиннан гариза керде.

— Нәрсә язган? — дидем мин кызыксынып.

— Институтка кайтырга теләге бар.

— Гаризаны үзе китердеме?

— Юк. Гаризаны сылу гына бер кызыкай китереп китте. Бикмуллинның туганы булса кирәк. Кыю гына бала! Абыйсын эшкә алуларын ул да бик үтенде, әгәр алмасагыз, абыем һәлак булачак, ди.

Мебель кибете төбендә аунап яткан кеше күз алдыма килеп китте, ләкин мин Гайшә Хәлиловнага берни дә әйтмәдем.

— Мин нәрсә әйтә алыйм соң, Гайшә Хәлиловна?

— Нигә әйтә алмыйсың? — диде ул каты гына.

— Мин бит...— Сүз эзләп тотлыгып калдым,— кечкенә кеше, Гайшә Хәлиловна!

— Кайчаннан бирле кечкенәгә әйләндең әле син?.. Бикмуллин белән бергә эшләдең, аны беләсең. Син сектор мөдирегезгә караганда да төплерәк сүз әйтә аласың, ул яңа кеше.

Ул, минем барлыгымны да оныткан кеше төсле, ниндидер кәгазьгә йотылды, телефон шалтыратып, кемнедер үз янына чакырды. Мин китәргә дә, китмәскә дә белмичә, аптырап утыра бирдем. Бары тик шул Гайфи өчен генә чакырганмы әллә ул мине? Исерекләрне сөймәгәнен беләм ич, нигә аның белән булашуны кирәк тапкан?..

Чыгып китәргә уйлап урынымнан куптым, ул кузгалмаска кушып кулын селкеде.

— Галим дә, инженер да, язучы да, игенче дә үз кояшы чыкканны көтеп, гомере буе шуңа әзерләнеп яши, Сәгыйть туган. Бусы синең

өчен яңалык түгел. Синең өчен шундый минут килеп житте. Сине азмы-күпме беләм, фикерем дөрестер, ялгышмыйм дип тә өметләнәм. Баязит абый шәкерте икәнлегеңне син расларга тиеш. Синең эш-иҗат чорың озын гомерле булыр. Без барыбыз да аның шәкертләре.

— Мин тыңлыйм, Гайшә ханым, тыңлыйм...

— Син ялда чагында министрлыктан хат килде.

— Нинди хат?

— Минем сорауга җавап хаты... Чаллы автозаводы базасында сина теге проектыңа — металл эшкәртү процессына — кайтырга мөмкинлек бирерләр төсле.

Маңгаема шундук кайнар тир бәреп чыкты, авыз эчем кипте, телем көрмәкләнде:

— Ничек, ничек дидегез сон?

— Әлбәттә, сине бирәү дә көчләми, әмма безнең барыбыз өчен дә синең ул эшкә алынуың кирәк.— Гайшә ханым «барыбыз өчен дә» дигән сүзләрне аерым басым ясап әйтте.

Барыбыз өчен дә?!.

Директор белән күз карашларыбызны кисештереп алабыз, ул сүзеннән бүленә, әле телефон шалтырый, белгечләр йомыш белән керен-чыгып йөри. Телефонның ешрак шалтыравын, кешеләрнең озаграк юануын телим. Гайшә ханым үзе дә мине ашыктырырга җыенмый сыман...

Зиһенемдә өзлексез чылбыр булып уйлар йөгерешәләр...

Ничәнче елымны институтта эшлим инде?..

Беренче айлар-еллар. Ул чакларда мин эш дип көне-төне чаба идем. Ял көннәремне, «ичмасам, ялгыз башым калып, кинәнеп эшләрмен» дип, зарыгып көтеп ала идем. Еллык отпускама һич адәм көтмәгәндә я кышкы бураннарда, я ерып йөрмәслек язгы пычракларда чыга торган идем. Чөнки отпускам чираттагы эшемә бәйле була иде. Кызык! Ялга чыгам да җимерттереп эшлим! Кинәнеп, тәмләп, рәхәтләнеп, очынып! Ни кушсалар да аз иде миңа. Ул чагында эшнең зурысы, кечесе турында уйланылмаган, ни бар, мин шуңа әзер!..

Шулай булды, шулай булып килде.

Хәзер дә мине шәп эшли диләр, квартал ахырында премиядән калдырмыйлар, эшсез дә утырмыйм. Ләкин соңгы елларда ял көннәремне һәйбәтләп Иделдә үткәрәм, отпускага да елның асыл вакытын чамалап кына чыгам, бирмәсәләр талашам, хезмәтләремне, стажымны исләренә төшереп, барыбер җиңеп чыгам. Элек миңа «авыр эш» дип әйтсеннәр генә иде, куян күргән бурзай кук атылырга гына тора идем!..

Мактау-дан китерә торган олырак эшләр миннән читтәрәк йөрде бугай... Бер тапкыр алынып карадым, анда да борыным канаттым...

Бәлки, кеше гомерендә бер генә килә торган үзәк мизгел хәзер килеп җиткәндер? Күк капусы хәзер ачыладыр?..

Автогигант — гаять зур эш, ил күләмендә генә түгел, дөнья күләмендәге атаклы эш. Андый эшләргә ялгыз инженер гына түгел, институт үзе дә еш катнаша алмый... Ни әйтсән дә без Мәскәү, Ленинградның карт институтлары белән ярыша алмыйбыз, мөмкинлек тә, хокук та таррак.

Ни өчен «барыбыз өчен дә» диде директор?.. Институт өчен дисә, аңлыйм... Ни өчен сүзне Гайфидән башлады ул?!

Дөм орынып, кагаеп утырып булмас, Гайшә ханым миннән сүз көтә!.. Акылым барын да исәплән бетермәде, телем:

— Рәхмәт ышанычыгызга, Гайшә Хәлиловна, әмма ул эшкә янадан алына алмыйм,— дип ычкындырдым.

Ул миннән нәкъ шундый җавап аласын белеп торган икән, йөзе бер тамчы да үзгәрмәде.

— Булдыра алмыйм,— дип кабатладым мин.

Каян килде миңа мондый эшәке кирелек? Ни өчен алына алмавымны нигезләргә, акларга кирәк иде. Канатым сыну турында мыгырдандым, кайчандыр очынып йөргән Сәгыйть түгел инде мин, дидем. Ләкин болар барысы да ир-егет сүзләре түгел иде. Директор артык җитди, ул уртага салган мәсьәлә артык олы, мин исә таркау һәм таралган идем...

Ул, ачуымны китереп, мине мактарга тотынды. Инженерларыбыз арасында иң талантлысы син, диде. Башкалар да шулай уйлый, бөтен кеше шул фикердә, синнән «бер-бер хикмәт» чыгуын көтәләр, ышаналар, диде.

Ичмасам, нигә бу сүзләрнең чиреген генә моннан ике-өч ел элек, мин аларга бик мохтаҗ чакта әйтмәдегез соң сез!.. Эшем барып чыкмаган ел булса да, мөгаен, мин ул сүзләргә ышанып идем. Бүген исә, күңелемдә нидер өзелгәнен, кайсы буынымныңдыр шартлап сынганын белеп, сызланып утырганда, нигә бу мактау сүзләре?! Өметсезгә дәртләндерү нигә? Арбага бишенче тәгәрмәч кую гына ич болар!..

— Юк, Гайшә Хәлиловна... Мин үз көчемә ышанмыйм... Мин ул эшкә кайта алмыйм...

Без авыр гына хушлаштык. Гайшә ханым ашыкмаска, сабыр гына уйланырга, әзерләнергә кушты.

Бүлмәдә мине Гали Кадыйров көтеп тора иде, көрсенеп кенә аңа карадым.

— Я, ничек? — диде ул мине күрү белән.

— Нәрсә ничек?

— Сәгыйть, нигә чакыруларын беләбез ич.

— Белгәч, тагын ни кирәк?

— Ризалаштыңмы?

Ачуым чыкты.

— Барын да белеп торырга осталыгың бар икән, сиңа тагын ни җитмәгән?!

Урындыгыма утырдым, җайсыз, аяклары какшаганмы, шыгыр-шыгыр итә. Әйбәт яңа урындык та алып куя белмиләр инде...

Әгәр яңадан кайтып теге эшкә тотынсам, группага кемнәрне сайлар идем икән?.. Хәзер бит киңәшергә Баязит абый юк...

Юк, юк, иҗат эше кузна уены түгел. Ул, белем һәм тәҗрибәдән тыш, илһам да таләп итә. Илһамны чакырып та, кыстап китереп тә булмый. Табигатьнең бөек бүләге кеше күңеленә үзе иңә. Иҗат эшенең сиксән проценты кеше ихтыярыннан тыш туа торган илһамга бәйләнгән.

«Галиябану» көен, «Ак бүре» әкиятен иҗат иткән кешеләр, бәлки, артык талантлы да булмаганнардыр, әмма күңелләренең йолдызлы язгы бер таңнарында аларның тар офыкларын илһамның шифалы җиле каерып ачып ташлаган.

Әнә шул илһам дигәннәре соңгы вакытларда минем күңелемдә сирәк уяна, бик сирәк. Шагыйрьләр теле белән әйтсәк, бәхет кошым башка куак сайлады.

Элек мин эшләмичә, уйламыйча бер секунд, бер минут тора алмый идем. Уйлау, эш минем табигый халәтем иде. Өстәл янына иелүгә, миемә корт күче булып фикерләр, идеяләр саркыла иде... Мин аларны ваклап-ваклап, бүлекләп-бүлекләп бик күп исемсез эшләргә сала бардым.

Чәчәк тоташ килеш кенә чәчәк дип уйладым мин. Аның сабагын яргалап, яфракларын йолыккалап, чәчкәсен-таҗын, күзәнәген-тамырын аерып-аерып тезеп салганда, аның хуш исе дә, яме дә калмый. Аның чәчәк икәнен ботарлаган кеше үзе генә белә.

Үзе генә белә.

Мин беләм дә, әнә Баязит абый белә.

Ун ел, ун ел...

Утыз белән кырык арасы. Бу — ун сират кичү, бу — күктән йолдыз чүпләп төшү, бу — иң тирән, серле чоңгылга октябрь суыкларында ун тапкыр чуму чоры.

Ә минем сиратлар кичелмәде, йолдызлар күктә калды. Берәү дә шулай соңга калып, яр читләренә беренче челтәр көмешләр йөгергәндә, чиркәнчек алмый, чиркәнчек алуны суык көзгә калдырган кешеләр, гомумән, коенмыйлар.

Кичкәнем инеш булды, чүпләгәнем — түшәмнән күгәргән кадак, чумганым — аулак Идел тугае...

Хәзер мина күккә үрелеп карарга кушалар, заманында бер чумып та, төбенә төшеп җитә алмаган чоңгыл янына китереп, «энҗе табып чыкчы», диләр.

Күңел җирси, күңел карыша, күңел икеләнә...

Энҗе эзләп чумган чакта, йолдыз алам дип үрелгәндә, мин егылып төштем. Сез барыгыз да минем янымда идегез ич! Нигә кул сузмадыгыз?.. Минем коры ярда калган маймыч кебек тырпылдап яшәвемне күреп, күзәтеп тордыгыз.

Әллә соңгы вакытларда дача, кадаклар, кәймәләр, төнге учаклар белән женләнеп гап-гади Идел мещанына әвереләдемме?..

Бу — ансат һәм җиңел җавап...

Гали Кадыйров минем хакта шулай уйлый... Гайфи дә... Баязит абый булып, ул да шулай түгелме дип шикләнә...

Гайшә Хәлиловна тәмам кул селекмәгән икән әле, мине тагын бер сынап карарга нияте бар...

Борыныма хуш исле папирос төтене килеп керде. Мин Гали турында бөтенләй оныткан идем, ул урындыгын тәрәзә төбенә үк тартып китергән дә ачык тәрәзәгә карап тәмәке тарта.

— Кара диңгез сагындырамы? — дидем мин усал гына.

— Малай кулын сындырган әле, Сәгыйть.

— Ничек?

Моңарчы мин Гали Кадыйровны хатынлы, бала-чагалы итеп һич тә күз алдына китерә алмый идем. Керә, йөри, бер ялгызы кебек. Баксаң, ул ике бала атасы икән, олы малае пионер лагеренда агач башыннан сикереп төшеп кулын сындырган.

Без икәүләп тәрәзә каршына бастык. Юан юкә астында Рузалиянең юка гәүдәсе күренеп киткән кебек булды. Әйе, ул!.. Ашыгып кына баскычтан төшәсе иде дә урамга чыгасы иде!..

— Ничек соң, Сәгыйть, тәвәккәллисеңме?

Көләме Гали, мыскыллыймы?

Мин дәшмәдем.

— Әгәр тотынсаң, мине дә үз группаңа ал.

— Эчтән торып таркатыргамы?..

— Тормыш безне һаман өйрәтә тора, Сәгыйть... Мин теге вакыттагы эшегезне яңадан кайтып карадым... Гайшә Хәлиловна карарга кушкан иде... Очына чыгарга кирәк аның!.. Тотынасың икән — мине калдырма!..

Гали чыгып киткәч тә, мин озак кына берни эшли алмый утырдым... Гайфи кайтаруларын сорап гариза биргән... Гали минем группага керергә тели... Бер көн өчен бу яңалыклар житеп ашкан иде...

Тәрәзәдә тагын Рузалия күренгән кук булды.

Йөгереп урамга чыктым. Берәү дә юк. Эш вакытында нишләп монда йөрсен ди ул?! Үзем дә тиле!..

Дача белән саубуллаштым, хатын, бала-чагалар төялешеп калага кайттык. Былтыр сентябрьдә дә мин дачада яшәп калган идем, эшкә дә шушыннан гына йөреп тордым. Быел кайтырга ашыгуымның сәбәбен хатыным һич аңлый алмады:

— Сентябрьдә һавалар бик әйбәт булачак дип язалар газеталар. Рәхәтләнеп торырсың. Алмагачларны сындырып бетермәгәйләре... Анпары былтыр сентябрьдә малай-шалай бик азынды бит, ничәмә-ничә дачаны бастылар. Син торсаң, тынычрак булыр иде,— дип үгетләде ул.

— Юк, Разия, кайтам!..

Малайлар китап кибетләренә ташландылар, кичтән ваннада юынып, тәмле ашлар ашап мәйханә килдек.

Иртән уянганда күңелем тыныч, тәнем җиңел, балалар шат, хатыным көләч иде.

Троллейбуста «Гайшә Хәлиловна тәкъдимен кабатламаса гына ярар иде»,— дип теләп барсам да, «күн төшмәде», көндезге уннарда ук мине директор кабинетына дәштеләр. Баш тартырга тагын да нигезлерәк сәбәпләр эзләп, ашыга-ашыга, Гайшә ханым янына кердем.

— Утыр, Сәгыйть...

Утырдым, нишлисең...

— Баязит абый янына кайчан барырга ниятлисең?

— Иртәгәдән дә калмам дигән идем.

— Син бүген үк бар, хәзер.

Мин сорау белән аңа карадым.

— Кичә мин аларга кереп чыктым, Баязит абыйның сине күрәсе килә икән.

— Алайса, эш бетүгә туры шунда китәм.

— Ныклап эшкә керешкәнче, барып кайт инде син.

Бер яктан, үзем барырга торганда бу эшне йомыш итеп йөкләүләре читен тоелса да, теге эш турында сүз кузгатмавы өчен директорыбызга эчтән генә рәхмәт укыдым. Моннан соң ул һичкайчан мине борчып маташмас, тын гына үз урынымда эшли бирермен. Ни кушсалар, шуны эшләрмен, шулай булыр...

— Теләсәң, машина ал, хәзер шалтыратам.

— Зарар итмәс.

Ишек тоткасына кагылгач, ничектер, борылып карыйсы иттем. Гайшә Хәлиловна елмаеп мине күзәтеп тора икән.

— Кичәге сүзне Баязит абыйга җиткерерсеңме?

— Юк дип уйлыйм.

— Яхшы.

Базарга төшеп Ташкент үзбәкләреннән «кызбармак» исемле затлы виноград үлчәтеп алдым, алма-грушаларның иң асылларын өстәдем, шуларга кан кебек ал эчле әзербайҗан гранаты куштым, әйбер-караларны артка урнаштырдым, үзем шофер янына утырдым. Бик тиз барып җиттек. Шофер белән без байтактан таныш. Яңа квартирага күчкән көнне нык кына сыйлаганым да бар үзен.

— Көтеп торам,— диде ул, сүз башлап.

— Ашыгам димәсәң...

Гөлсәйрә апаның алъяпкычына чәчрәп күбек тигән иде.

— Нихәлләрдә сез? Үзгәрешләр юкмы? — дидем мин, кулымдагы күчтәнәчләрне читенсенеп кенә өстәлгә тараттым. Гөлсәйрә апа башта, хәле болай ару гына, дип торды да тезеп китте: — Үзгәрде, бик үзгәрде... Менә бүген... Беренче ясаган чәемне «күл суы кебек тоныкс» диде... Икенчесен «салкын» дип кире борды... Өченчесендә «шикәре аз» диде... Дүртенче тапкырында «өрәңге суы сыман иренгә ябыша» диде... Бишенче стаканымны гына ошатты...

Димәк, кәефсез көнне килгәнмен!
— Бүген миңа да керергә ярыйдыр, шәт?
— Юк шул, Сәгыйть,— диде, өзелеп, Гөлсәйрә апа.— Бүген абзаңны юындырабыз, урын-җирләрен алыштырабыз, өс-башларын. Туганым апа белән күрше хатыннар маташалар анда... Юындыргач йоклап китмәсме!.. Үткәнендә дә син килде дигәч бик кыбырсыган иде дә, язмаган икән!.. Башка вакытта инде, Сәгыйть, яме!.. Күчтәнәчләрең өчен бик рәхмәт, ярты базарны кубаргансың, үзеңнең дә бала-чагаң күп...
Гөлсәйрә апа сөйләнә-сөйләнә мине озатып чыгарып та җибәрде:
— Үпкәләмә инде, килүеңә рәхмәт...
— Юк, юк, Гөлсәйрә апа...
— Абзаң терелеп китмәсме димен, бүген тамагына да ашап алды... Үзе дә дәртләнеп китте. ГИДУВта чакта рентгенга төшергәннәр иде, шул рәсемне эзләтеп алдырды, алдагы дүшәмбедә атаклы профессор килеп карамакчы.
— Ялгыш диагноз куймаганнармы?
— Тс-с...
Шофер тәмәке тартып чирәмдә утыра иде, «ничек» дигәнне аңлатып, күтәрелеп карады.
— Тамагына ашый башлаган,— дидем мин.— Үзен күрә алмадым. «Мунча» чабындыралар.
— Алайса, картка күп калмаган икән.
— Нигә, Миша?
— Үлем килеп житәрәк кеше организмы бер тартышып ала,— дип аңлатты шофер.— Фронтта чакта байтак күрдем мин андый хәлләрне. Юлга чыккан әҗәле килеп җитә торгандыр.
Машина ишегенә тотынуыма, артымнан:
— Сәгыйть абый! — дигән тавыш ишетелде. Кулына бәрәңге, кыяр, суган тутырган җәтмә тотып Рузалия базар ягыннан кайтып килә иде.
— Әллә күрешми дә китәсез инде, ай-һай,— диде ул үпкәләп.
— Бу синмени? — дидем мин.— Саумы?
— Кайтып житмәсәм, китеп барасыз икән.
— Син кайта тор,— дидем шоферга.— Рәхмәт!
Ишек катында икәүдән-икәү текәлешеп торабыз.
— Сәгыйть абый, сез кичә килмәгән идегезме?
— Нигә?
— Сезне көткәнгәдер инде, килгән күк тоелган идегез.
— Ялгышуың хәерлегә булсын.
— Сез һаман шаяртасыз.
Кызый миннән нидер көтә, кулындагы бәрәңгеле җәтмәсен бер кулыннан икенчесенә күчерә, кул беләзеге бау эзеннән сырланып, кызарынып беткән.
— Абыеңа миннән сәлам әйттеңме?
— Кушмадыгыз ич.
— Бусы үзеннән-үзе аңлашылса кирәк. Мин аны эзләп кердем, сәлам әйтергә иде.
— Керүегезне әйттем.
— Нәрсә диде?
— Әй, аны!
— Димәк, Гайфи дус минем файдага сөйләмәгән.
— Беренчедән, ул сезнең дустыгыз түгел, икенчедән, ни өчен сезнең файдага сөйләсен ди? Сезне яратмый ул, «астыртын гына яшәп ятучы карьерист» дип атый. Ишетәсегез килсә, мәгез, рәхим итегез.
Мин көлеп җибәрдем.
— Сез нык кына бәргәләштегезме?
— Моның өчен түгел!..

— Нәрсә өчен тагын?

— Анысы... сер!

Кызыкаем җиң сызганып көрәшкә чыкканга охшый. Гайфине чынлап торып җиңәргә уйлыймы әллә? Мине үзенә союзник, ярдәмче итәргә дә тели, ахры...

— Өегезгә чакырмыйсың инде бүген? — дидем мин шукланып.

— Юк, Сәгыйть абый,— диде кыз уйчан гына.— Чакырмыйм. Рөхсәт итсәгез, бераз озата барыр идем.

— Рөхсәтен рөхсәт, сумкаңны кертеп куй башта.

Рузалияне күрергә кирәк иде миңа. Чыннан да, ул китергәнме Гайфи абыйсының гаризасын? Яздыручысы да ул түгел микән?.. Нәрсәгә таянып эш йөртә соң ул кызыкай?..

Әмма без бүген сүзне бик ерактан башладык, уратып-уратып. Ни сөйләшсәк тә капма-каршы фикерләргә килеп йомгакладык. Кыз соңгы вакытта үзе караган картиналарны мактады. Миңа ошаган картиналарны «коточкыч» диде. Бергманның «Җир җиләге аланы»н яртысыннан ташлап чыктым, яшисе килми башлады, диде. «Көл һәм алмаз»га бармаска иптәш кызларын өндәп йөргән. «Анда шундый үтерешләр, мин чәчәкләрне, кояшны яратам!» ди. Мин: «Заманыбызның шундый куркынычлы, хәвефле икәнлегеннән ник йөз чөерергә?» дигәч, аның яшькелт күзләрендә алтын-сары утлар кабынды. «Хәвефле дип, елап, кул кушырып утырып булмый, Бергманнар төсле төшенкелеккә бирелсәң, дөньяны хәвефтән кем коткарып калыр?» — дип куйды.

— Син коткарырга җыенмыйсыңдыр бит? — дип көлгәнемне ишеткәч, бик җитди итеп җавап бирде:

— Нигә коткармаска? Мин бит үз исемемнән генә сөйләмим. Без бергәләп сөйләшәбез болар турында, иптәшләрем белән, яшьтәшләрем белән!..

Иң яратканнарымнан берсе Акира Курасаваны аның ишеткәне дә юк иде.

Әллә мин, без төрле буын вәкилләре буларак бер-беребезне һичкайчан аңлый алмабыз, дигән фикеремә дәлилләр генә эзләп азапланам инде?

Күктән җиргә якынаерга бик вакыт!

— Эш ягыңны кайгырттыңмы? — дип сорадым.

— Һаман күчермиләр, Сәгыйть абый, тинтерәтеп йөртәләр.

— Алайса, нигә бүген өйдә?

— Буш көнем.

— Ә-ә...

— Баязит абый ни хәлдә?

— Ята...

— Кичә мин дә кереп чыктым аның янына.

— Син аны әлек тә беләидеңме?

— Белмичә... Иплап, Сәгыйть абый, машина килә.

Яныбыздан иләмсез зәү үзбушаткыч узып китте.

— Мин эшкә чыктым, Рузалия.

— Сезнең эш ифрат кызыктыр, ә?.. Мин Гайфи абыйны шуңа күрә аңламыйм да: шундый эшне ничек итеп аракыга алмаштырырга мөмкин?

— Эш кайда да бер. Эш белән аны башкаручының мөнәсәбәте аерылса аерыладыр.

— Иҗат эше белән башкаларны чагыштырып булмый инде анысы, Сәгыйть абый.

— Иҗат эшен уйлап янгач, нигә пластинкалар сатарга омтыласың?

Ул үпкәләмәде:

— Бүрек яки чәйнек сатып тору түгел ул пластинкалар,— дип аңлатты.— Аралашкан кешеләр арасында ифрат кызыклары килеп чыга.

Музыка, башкару осталыгы турында төрле фикер ишетәсең. Сезнең кереп караганыгыз юктыр, кайнап тора ул пластинкалар рәте!

Ике-өч трамвайны уздырдык.

— Минем заказны онытмадыңмы?

— Яша Хейфицнымы? Бүлеккә күчермәселәр дә табып бирәм мин аны. Мин, Сәгыйть абый, вәгъдәле булырга яратам.

— Күчәргә тырыш, үкенерлек булмасын.

— Сез әллә нишләгәнсез, Сәгыйть абый,— диде ул аптырап.— Әллә көләргә үк уйлыйсыз инде миннән?

— Көлмим... Гайфи абыең нихәлдә?

— Бер көе,— диде кыз юаш кына.

— Гаризаны син илттеңме? — дип сорадым турыдан-туры.

— Әллә ярамыймы? — диде ул, минем күзләремә карап.

— Ярый да...

— Нәрсәсе ошамады, Сәгыйть абый.

— Юкка йөрисең!..

— Юкка түгел,— диде ул, күкерт төсле кабынып.— Эш кирәк ана, чын эш!..

— Эшләп карады бит инде, үзен күрсәтте.

— Гел-гел кыекка китмәс әле эш дигәне, Сәгыйть абый!..

— Юк, Рузалия... Инде кырыкка хәтле булмаган икән, моннан ары юк диген сүз ул!..

Ул аскы иренен тешләп, ярсулы сүзләрен чыгармый тыеп тора, яшькелт күзләрендә алтын-сары утлар яна иде.

— Сәгыйть абый!.. Сез Баязит абый янына авыру булганы өчен барып йөрисез бит... Безгә дә керегез әле. Гайфи абый белән сөйләшегез!.. Сөйләшеп карагыз!

— Вакыт ягы таррак бит, Рузалия...

— Ял көнне килегез.

— Ял көнне мин һәрвакыт Иделдә булам...

— Кайда Иделдә?

— Дачада.

— Башка вакытта килергә тырышыгыз.

— Уйлап карармын, Рузалия. Әлегә хуш, әнә трамвай килә.

Мин дөбердәп китеп бардым, ул зур күзләрен тутырып мине озатып калды.

## 6

Кырык яшь...

Мин монысын уйнап кына әйтмәдем Рузалиягә. Берәүләр кырык яшьләренә ургылып, көчәеп, шаулап килеп керәләр, дөньяның кендеген кулларында тоталар. Берәүләр шикләнеп, куркып калалар...

Минем төшемә еш кына атом сугышы керә. Ике-өч ел инде шундый яман куркынычта интегеп уянам. Төшләрем ике тамчы су кебек берберләренә охшаганнар.

Зәңгәр күкне мәңгегә икегә ярып бомба шартлый. Кара сөрем, үлем-дәһшәт убырылып-убырылып мин басып торган ноктага ташлана. Мин илереп-тилереп бәргәләнәм, өч ягымдагы өч улымны кая куярга белмичә, ничек коткарырга әмәл табалмыйча, кыл буанакка нәфис аягы уралган сары песнәк төсле чәбәләнәм. Йөгереп тә, атлап та, кымшанып та булмый.

Мондый төштән уянып кына котыласың.

Йөрәк, күкрәк читлеген ватарга теләгәндәй, дөп-дөп тибә, аркакүкрәкләр манма су булган, күз кабаклары сызлый.

Йокы бөтен ярыкларга кереп кача: дөнья ярыкларына, күңел ярыкларына, өй ярыкларына...

Өч улымның бәби чаклары, аларның көймәле бәләкәй арбалары, беренче киеп туздырган оекбашлары, алар колаксыз калдырган зәңгәр яллы уенчык тайлар күз алдымнан тезелешеп үтә. Уйлар богавыннан котылып торыр өчен, күңелемне бизгән якты истәлекләрне кузгатып карыйм, ләкин мабыгып китәрдәй хатирәләрне аяусыз төш үтереп бетергән. Элек рәхәт иде, ичмасам!.. Төнлә уянсам, тиз үк айнып, хәтергә планнар, фикерләр килүгә, тынычлана торган идем.

Кече улыма, төпчегемә, әле ике дә тулмаган.

Иртән, ул уянгач, нәни кошчыгымны кулыма алып сөя башлауга, төнлә газаплаган төш хәтеремә килә. Кемнәрдер шул хәтәр сугышны әзерлиләр бит!.. Борчулы күзләремне улыма күрсәтмәс өчен аны кысып-кысып кочаклыйм, идән таптап йөренә башлыйм. Аннары үчтиүчти итәм. Әбисе бәйләгән йон башмаклы нәни аяклары минем иң башында. Әйдә, улым, тәбәнәгем, йолдызларга үрел!..

Ул оча, мин тотып калам. Үчти-үчти!.. Көчем, егәрем җитә, күзләрем аның очышын сагаеп күзәтә. Ул чамасыз сөенеченнән шаркылдап көлә, мин аның кайнарланган тәмле исле тәнен кысып кочаклыйм да тагын күзләремне якты көннән яшерәм.

Киң дөньяны улым белән икәү дүртенче кат тәрәзәсеннән тамаша итәбез.

Урамда маэмайлар уйный. Малайлар уйный. Төймә борынлы кызлар уйный...

Юк, улым, тәбәнәгем, абыйлар уйнамый инде, алар зур үскәннәр. Абыйлар кубиклардан биек-биек йортлар салалар. Бакчалар, мәктәпләр, кибетләр, театрлар салалар. Абыйлар үзләренә, үз гомерләренә шәһәр исемле һәйкәл салалар.

Малайларга карап та, маэмайларга карап та, яңа ташпулатларга карап та без куана башлыйбыз, көләбез. Дымлы учымда нәни улымның очар коштай тырпылдаган йөрәге. Ул минем кулымны пешерә, көйдерә, ашыгыч ритмына минем йөрәк тибешен дә ияртеп, әйдәп алып китә!..

Сугыш һәм балалар турында һәрвакыт бергә кушып уйланам мин. Өнемдә дә куркынып куйган вакытлар була...

Бер вакыт Идел өстендә, бер башым гына балык тотып утырганда, көнбатышка борылып карагач имәнеп киттем. Дәү җилпәзә кебек киерелгән болытлар батарга җыенган кояш нурларында куркыныч кан төсенә манчылганнар иде. Югарыда җил иде, ахрысы, болытлар атылып төшкән судай актарылып-актарылып кайнадылар. Әле сыек, әле куе болытлар, кызылсу дәһшәт булып, әҗәл тулы сөремле куеннарын ачарга җыенгандай, Идел өстенә, Казан өстенә, минем өч улым өстенә ябырылып-комарланып ашыгалар төсле тоелды. Бер мәлгә артыма борылып карарга имәнеп, көймә төбендә бөгәрләнеп утырдым.

Ә Рузалия: «Без көрәшмәсәк, кем көрәшер?» — диде...

Эштәге җансызлык кешенең бөтен яшәешенә тәэсир итәдер, ахрысы...

Гайшә Хәлиловна мине яңадан чакырмады.

Мин җиңел сулап куйдым. Шулай да, төш алдыннан бүлекнең архивына кереп, безнең группа эшчәнлегенә караган барлык материалларны соратып алдырдым.

Байтак нәрсә җыелган икән. Шуларны актарып утыра идем, тагын Гали килеп керде. Көяз дә инде, каһәр! Өйләнергә җыенган егетмени, якасы кардай ак, костюм-чалбарында бер генә дә таушалган урын күрмәссең... Адымы салмак, гәүдәсе төз.

— Улыңның хәле ничек? — дип сорадым, исәнләшкәч.

— Гипста йөри...

— Яшь тән, төзәлер...

Ул күз кырые белән генә папкаларга карады да:

— Эшкә керешәсеңме? — диде.
— Менә, алдым.
Ул урындыгы-ние белән миңа табарак тартылды:
— Синең Гайфи дигән кешене күргәнең бармы? Нәрсә булган аңа? Тресттан тагын куганнар үзен! Әрәм була бит егет. Талант әрәм була.
— Талант,— дидем мин, аның соңгы сүзенә аерата игътибар итеп.— Бармы икән аңарда талант?!
Бу турыда бәхәсләшеп китсәк, сүз озакка сузылачак иде. Гали моны үзе дә сизенеп, бөтенләй башка нәрсәләргә күчте, әгәр мин чынлап торып эшкә керешсәм, үзен дә читтә калдырмауларын үтенде.
Бүген эшкә кулым бармады. Гали минем янга тагын ике тапкыр кереп чыкты, әллә материалларны бергәләп карыйбызмы, дип әйтеп карады. Аның белән янәшә утырып уйланырлык дәрәҗәдә түгел идем әле мин. Өйгә кайтып киттем. Безгә кайчагында бу рөхсәт ителә, эшне өйгә дә алып кайткалыйбыз, тик сектор мөдиренә әйтеп китәргә генә кирәк.
Баштa агымдагы эшләрне карадым. Дөрес, барысы да кирәкле, ашыгыч эшләр, ләкин алар күңелне баетмыйлар, дәртне үстермиләр. Ай ахырында түккән хезмәтеңнең нәтиҗәсе кыштырдавык кәгазь булып сиңа әйләнеп кайта. Акчага икмәк-тоз, чәй-шикәр аласың. Тән эшли, тән туена...
Гел шундый туктаусыз әйләнеш бара, шуңа күрә мин үземне аяусыз рәвештә «көнлекче» дип атыйм...
Өйдә дә тынычлык юк.
Башта хатыным бәйләнде.
— Баязит абый янына бардыңмы?
— Юк әле...
— Ата ялкауга әйләндең син, Сәгыйть... Ялкау тамырларың чыбыркы сабы юанлыгы булып бүрткәндер...
— Барам, барам...
— Бу нинди папкалар?
— Болармы?.. Ә-ә, вак-төяк... Теге заман папкалары... Хәтерлисеңме? Кызып йөргән идек бер вакыт, Разия, ә?..
— Тагын инә белән кое казырга тотынасыңмы?
— Юк. Болай гына, яшьлек җүләрлеге генә итеп карап утырам.
Кәгазьләремне таратып ташлауга, «Әттәм!» дип нәни улым килеп җитте, кулымны тарткалый башлады. Мин аңа ачуланмадым. Мин аңа ачулана алмыйм. Абыйлары да, кечкенә чакта, нәкъ аның төсле итеп «Әттәм!» дип өзелеп яныма киләләр дә кәгазьләремне тарткалыйлар иде. Ә мин!.. Мин... ул чакта дөньяны кузгатырлык эш башкарам дип атлыгып йөргән исәр кеше, «Комачауламагыз!» дип сабыйларымны очыртып кына җибәрә торган идем. Ишек төбендә «Әти җылата да җылата» дип үпкәләп торганнары әле дә күз алдымда!.. Шуңа исем китми иде бит, барысын онытып, сызымнар өстенә иелә идем! Тормыш агымын яхшыга, бары яхшыга гына үзгәртергә мөмкин, һәм без шул эшне башкарырга тиешле, бүтән нәрсәнең әһәмияте юк дип саный идем.
Җүләррәк булганмын!
Тырышлыгымның нәтиҗәсе хәзер күз алдымда. Яшелле-кызыллы каләмнәр белән инвентарь номерлары сугылган тузанлы папкалар... Олыга омтылып, үземне иң гади кеше тоярга тиешле рәхәттән, бала сөю бәхетеннән мәхрүм иткәнмен. Көне-төне күз челәйтеп казганып ятуымнан ни үзгәрде?!
Хәзер төпчегем белән алай кискен кыланмыйм.
Гомумән, минем кечкенә улыма мөнәсәбәтем бөтенләй башкача. Яратам да мин аны, куркам да. Минем чордашлар бер бала белән сакал сыпырып куанып ятканда, без, әнкәсе белән, өч малай алып кайт-

канбыз бит! Шушы буталчык дөньяга, күктәге кояш янына мең кояшлы атом бомбалары эленгән дөньяга өч җан иясе тудырып калдыру артык олы җаваплылык түгелме?..

Төпчегемнең елавын тыныч кына тыңлый алмыйм, аның тавышы минем һәрчак сагайган бәгыремне телем-телем тураклый, үзәгемне өзә, кырыкмаса кырык эшем кырылып ятса да, мин йөгереп аның янына барып җитәм. Мин башкарган һәм башкарачак эшләр «дөньякүләм» әһәмияткә ия булсалар да, алар минем нәни улымнан кечерәкләр!..

Ул үзенең нәп-нәни алсу бармакларын тырпайтып, сакау теле белән: «Әттәм, без-без» дип яныма килә башлауга, дөньяда мин үзем теләп кигән яки тормыш кидергән камытлар шундук салыналар, җир түгәрәгендә ике котып арасында без икәүдән-икәү генә калабыз. Нинди татлы-тәмле аның тыны, нинди йомшак, назлы аның тәне, чәчләреннән, ялган чокырыннан атом болытлары капламаган, завод-фабрикаларның агулы төтеннәре тоныкландырмаган чын кояш исе килә.

Без-без, без идек,
Без уникe кыз идек.
Келәткә кердек, бал ашадык,
Базга төштек, май ашадык,
Кап та коп, Якуп!
Авызың йом!..

Безнең бабайлар, этиләр, үзләренең нәни орчыкларын тезләренә утыртып, гомер-гомергә «бал ашарга келәткә кергәннәр», «базга төшеп майдан авыз иткәннәр», «күке-чыпчык тәрәзәдән очып чыгып» малайларга тәти кашыклар, майлы боткалар калдырган...

Кояшны яратканнар безнең бабайлар!.. Ябырылып килгән күләгәне «эт кояшы» дип атаганнар...

«Без-без, без идек!»

Нинди кадерле, җанга якын сүзләр болар!

Шушы гади, сәке өсте уеннары ничәмә-ничә буын сабыйларын тәмле ризыклар турында хыялландырган, аларны кеше булырга, юмартлыкка, булганын бүлешергә өйрәткән...

Мин улларымны шушы уеннар белән мавыктырырга тырышам. Үзенне-үзең кеше итеп тою өчен болар да бик кирәк нәрсәләр ич!

Без-без, без идек,

Без уникe кыз идек!

Уникe йолдыз булып как сәкедә тезелеп утырган татар кызлары!.. Яр читенә баскан уникe керәшә... Сайрап таңны уяткан уникe былбыл!.. Әнкәйнең эссе мичендә тезелеп утырган уникe калач!.. Сабыйның ике ирене арасында җемелдәгән уникe энҗе!..

Сезнең нәфис, сылу гәүдәләрегез әллә кайчан көлгә әйләнгәндер, әмма «Уникe кыз»ны без һаман онытмыйбыз.

Сезнең оныкларыгызның туруннары [1] тешсез әби булып кеткелдәп сабыйларга һаман шул «баллы келәтләрне, майлы базларны» тәкърарлап торалардыр!

Әйдә, улым, әйдә! Кем алдан көлеп җибәрә.

Җинсә дә, җиңелсә дә, мангаема улым чиртә.

Улым минем, төпчегем! «Чыгышым һәм баешым минем!»

Эш алга бармый, улым, уйлар тышауланган, әйдә, булмаса, урамга!..

Әнисен эшкә озаттык. Абыйлары укуда. Икәү генә урамга чыгып киттек.

---

[1] Оныкнын балалары.

Урамда иясез этләр, иясез песиләр күп хәзер. Барысына сәлам биреп, барысы белән дә сөйләшеп йөрдек. Берсен иркәләдек, ә бер песине иркәләмәдек. Битен юмаган, шапшак мәче булып чыкты.

Иясез этләрне, хуҗасыз мәчеләрне иркәләп балаң алдында яхшы атлы булып йөрү җиңел ич ул!..

Кайттык...

— Әт-тәм, без-без уйныйк!..

Өстәлемдә папкалар. Өстәлемдә без өч ел интеккән эшнең сызымнары...

— Юк, улым... Син бәй-бәй итеп ал!.. Юк, балакаем!.. Сине йоклатам да мин аз гына утырам әле... Йокыңнан торгач, күбекле суда юындырырмын үзеңне!.. Йокла, балам!

Ул йоклый, мин кәгазьләргә йотылам...

Өч вариант. Төп принцип саклanса да, алар бер-берсеннән нык кына аерылалар. Күп хаталар төзәтелгән, күп ялгышларны ачып салганбыз. Ә барлык хаталар төзәтелгән дип кем әйтә ала?.. Бәлки, безнең түземлелек, тәҗрибә җитеп бетмәгәндер?..

Күзем саннар, сызыклар өстеннән йөри.

Күңелдә дә саннар, сызыклар гына.

Каләм тоткан кулым сөңге тоткан батыр кулы төсле нык.

Хатынымның кайчан эштән кайтып керүен дә ишетмәгәнмен. Звонок тавышына күтәрелеп карасам, Разия кухнядан чыгып ишеккә юнәлде. Бераздан пошаманга төшкән хатыным телеграмма тотып яныма килде.

— Ни бар, Разия? Ни бар, әнкәсе?

— Срочная. Гөлсәйрә ападан. Баязит абый сине чакыра.

— Әллә?

Ул мине тыңлап та тормады, күтәрелеп бәрелде:

— Бар, дидем мин сиңа!.. Исән чагында күреп кал, дидем. Кешедән яхшы түгел... Үзегезне кеше иткән абзагызны бөтенләй ташладыгыз!.. Шул инде, адәм баласының исән чакта гына кадере бар... Әнә, Шамкаевның хатыны үлгән иде, ике атна да тормаган, сары чәчле бер марҗа иярте кайткан!..

Улым сандалиларын күтәреп килгән дә, «нанали-нанали» дип лепелдәп, мине тагын урамга йөрергә чакыра.

— Хәзер, балам, хәзер!.. Анда бер бабай «өф» булган!..

* * *

Гөлсәйрә апа кулларын кушырып тәрәзә кырына баскан иде. Ул мине туп-туры авыру янына алып кереп китте.

— Хәле бик мөшкелме?

— Түгел сыман! Сине чакыра... Артык озак юанмаска тырыш!

Болай да шүрләп бара идем, аның пышылдавын ишетеп, коелып калдым. Шулай ук хәле куркынычмыни?

Иң элек Баязит абый үзе түгел, аның аяк очына баскан кеше күземә чалынды. Тәбәнәк кенә, каратут йөзле бу кешенең күз төпләренә арганлык галәмәте булып күгелҗем-сары күләгәләр яткан, чырае йокысызлыктан таушалган иде. Төнге авыр сменадан кайткан карт шахтер кыяфәтенә кергән бу кеше артык олы яшьтә булмаска тиеш үзе.

Димәк, безнең сүз шаһитлар алдында барачак.

Аннан соң гына Баязит абыйга карадым...

Сакал-мыеклары тоташтан ак икән инде аның! Эре-эре бөртекләр тиресе тартылган какча яңакны тишкәләп, әрсезләнеп тырпаешып торалар. Кишергән күксел иреннәре дә шыргый ак төкләр арасына

посынганнар. Хәрәкәтсез зәгыйфь муенында да кактус энәләре төсле төкләр.

Идел ярында җәй уздырып, чуен тәнле яшь-җилкенчәк арасыннан килгәнгә, аның чирле аклыгы аерата күзне кисте... Тоныкь, хәрәкәтсез кайнар күз алмаларын күреп имәндем...

Күңелемдә кузгалган беренче уйларымны сиздермәскә тырышып учыма йөткергәләдем дә бугазыма килеп тыгылган коры, эссе төерне уздырып җибәрдем. Аннары артистланып, шактый үк көр тавыш чыгарырга тырышып:

— Авырып киткәнсең икән ич син! — дидем.

Кул алыштык, аның учы коп-коры һәм кап-кайнар, минеке дымлы һәм калтырый иде.

— Шулай,— диде ул, ияген кагып.— Ятып торыш...

Сораша башламасмы, ярсымасмы, әрләмәсме дип сабырымны җыеп тик кенә тордым. Ләкин аның тоныкь-саргылт чыраенда бернинди үзгәреш чагылмады, шатланмады да, кайгырмады да, киресенчә, минем басып торуымны бөтенләй белмәгән төсле, тик карап ята бирде. Бераздан яңак сөякләрен кыймылдатып иренен ялады.

— Фоат, карачы, зал якның форточкасы ачыкмы?

Тәбәнәк кеше түбәнчелек белән аның аяк очындагы җәймәне рәтләде.

— Ачык, ачык, Баязит абый.

— Бу якның да пәрдә кырын азрак тарта төшмисеңме?

Фоат тәрәзә янына сөяп куелган озын, шома таякка өстәге җиз балдакны эләктереп, пәрдәне бер тотам гына сыерып китерде.

— Җитәрме? — диде ул, таягын кул очында тотып.

Баязит абыйның күгелҗем чокырлары тагын да тирәнәеп калды, мин аның сүз башлавыннан куркып, әңгәмәгә юл салырга теләдем, ашыгып-ашыгып, отпускага кадәр Мәскәүдә командировкада булуымны, соңыннан ничек ял итүемне, кунаклар белән өзмәс әвәрә килүемне вагы-төяге белән эчпошыргыч озын итеп сөйләргә тотындым.

Тамагым кипте, тавышым тимергә тимер ышкылгандай ямьсез чыкты, җитмәсә, тигез җирдә абынган үшән ат төсле, өч-дүрт мәртәбә тотлыктым, сүземнең һич инәсе-җебе булмады. Я ходай, дип каргандым эчемнән генә, синең юк йомышны бар итеп, хатын кушкан вак-төякләрне алырга дип командировка юллавың, Мәскәү урамнарын таптавың, кунакларың белән күпме коньяк чөмерүең кафеңгә урала башлаган адәмгә нигә кирәк?!

Ятып тыңлаган хәрәкәтсез кеше белән сөйләшү гаҗәп читен икән!.. Син аның күз сирпелешен тоймыйсың, кул хәрәкәтләре, ишарәләре, ымнары белән ул үзенең тәэсирләрен белдерми, иреннәре җөмлә арты саен әле елмаеп, әле көлеп сине хупламый. Икәүдән-икәү кара-каршы сөйләшкәндә сүзне телдән бигрәк бөтен гәүдә әгъзалары — кул-аяклар, йөзнең меңләгән сызыклары, маңгай сырлары ышанычлырак һәм күбрәк сөйли ләбаса! Кеше гомере, кеше әңгәмәсе шулар белән тулы һәм камил ич.

Ә минем сүзләрем торган саен ваклана, очсызлана барды, ләкин тукталырга әмәлем юк иде. Туктарга курка идем, ярамый иде...

— Минскидан килгән кунакларым гына киткән иде, хатын, балачагаларын төяп, Ригадан Костя кайтып төште. Аның хатыны Дон казачкасы, Баязит абый, үзе турында бер сөйләгән дә идем... Ростовта мореходка бетергән, хәзер чит илләрдә йөк ташучы корабта капитан... Хатыны унган да инде, ул аш-суга дисеңме, «лунатик»ларны шундый пешерә! Ит инде ул ит, әллә ничек телемләп турый да дуңгыз колагы итеп бөтереп кыздыра!.. Ну, сала, каһәр!.. Берүзе бер яртыны тарта, эһ тә итми... Аның янында ирлекне саклыйм дисәң, бетте баш... Костя белән табак-савытны үзебез юуга күчтек...

Чеәләп күтеп торам: ник кенә бер каш бөртеге кыймылдасын!

— Бакчалар бик күңелләләнде, кара карлыган котырып уңды, яфрагы күренми шомлыкның...

Күтәм, дәшми, туп-туры караган да ята бирә.

— Карлыган файдалы диләр бит... Чат витамин...

Туктадым, аның күксел иреннәре кузгалдылар, тик бу юлы да ул миңа эндәшмәде:

— Иреннәремне чылатчы, Фоат.

Фоат урындык аркасыннан чип-чиста тастымал алып, зал ягына чыгып китте, Гөлсәйрә апайның кайчан, ничек чыгып киткән мин абайламый да калдым.

Ниһаять, бүлмәдә без икәүдән-икәү генә... Икебез дә тынлыкны тыңлыйбыз... Хәзер ачуланса да, эт итеп ташласа да җиңелрәк булачак, чит күзләр юк, чит колаклар ишетеп тормый. Тик ул һаман эндәшмәде.

Мин, суга чумарга җыенгандай, тартылып аңа таба атладым:

— Сине бу хәлдә күрү үтә сәер, Баязит абый,— дидем чын күңелемнән.— Элек мин авырган чакларымда сиңа әйтергә ояла идем. Баш бирми идең син чир-чорларга!

Аның тонык карашы җылынгандай булды, сүземне җүпләп нягген какты, мин күрсендем.

— Билне бирми, гәүдә кымшанмый,— диде ул, үз гомерендә беренче тапкыр зарланып.

Тагын ялганларга туры килде:

— Шул радикулитың котырына торгандыр,— дидем мин искиткеч гөнаһсыз кыяфәт белән.— Әсәнбаевны беләсең ич, имән дөмбәскә кебек егет, баһадир, тегермән ташы хәтле ике бәлешне ашап бетереп, бөтен Өфене таңга калдырган егет. Әкият итеп Урал арьягында да сөйлиләр аны, менә шул... Мәскәүдә укыганда радикулиты егып сала торган иде тегене, чалып ташлаган үгезмени, үкерепме-үкерә малаең! Ул чир бит бөтереп кенә ала, биләүдәге бала күк атна буе ауный иде Әсәнбай!.. Әй, тотынабыз алмаш-тилмәш тегенең аркасын кайнар үтүк белән өтеләргә, бирепме-бирәбез.

Шыпырт кына көлгән тавышка аркам көеп китте, сискәнеп әйләнеп карадым. Фоат көлә икән. Ул тастымалны юешләп алып керде дә Баязит абыйның үзенә бирде. Тастымалны үрелеп алганда Баязит абыйның күлмәк җиңе сыерылып төште, кәшәкә сабы төсле дүрткел ак беләкләре күренеп калды, мин иренемне тешләдем...

Ул тастымалны иреннәренә тидерде дә пөхтәләп, дүрткә бөкләп кире кайтарды.

— Егуын ега, анысы мәгълүм, ничек торгызыр...

Тавышы да ят иде аның...

— Шул радикулит җәфалый инде адәм баласын,— диде Фоат, мине куәтләп. Диагнозны артык бердәм куеп без Баязит абыйны шикка төшермибезме?

— Әле чынлап дәваларга керешкәннәре юк, авыртуны химетеп укол кадыйлар да китәләр.

Ул монысын зарланып әйтмәде, нидер уйлый иде, шул уеннан бер генә җөмлә өзеп безгә өлеш чыгарды.

— Синең чирле икәнеңне байтактан ишеткән идем,— дидем мин, гафу үтенгәндәй итеп.— Лотфулла кайтып сөйләде.

Ике тапкыр килеп киткәнемне әйтергә уңайсызландым...

— Нәбиуллинмы? — диде ул, маңгаен җыерып.— Килеп киткән шул. Дачасына кунакка чакырырга килгән икән. Аның проектын расланнар.

— Әйе,— дидем мин, сөйләшергә сүз чыкканына куанып.— Расладылар. Байтак кына премия дә бирделәр.

Баязит абый миңа табарак борылды, сынагандай карап торды.

— Ничек соң, танышты ңмы проекты белән?

Ваемсыз гына:

— Ярый сыман,— дип ычкындырдым.

— Нәрсәсе ярасын? — диде ул, кинәт калкына төшеп.— Ярамый! Моннан өч ел элек темасын үзем сайлашкан идем, хәзер карасам — исем-акылым китте! Бер яңа нәрсә табалмаган, эзләнмәгән, аннан-моннан фикер җыештырып, корама проект әзерләгән.

Аның кул ишарәсен аңлап, Фоат шундук дымлы тастымалны сузды.

— Каян килсен яңа фикер? — диде ул, яңадан түшәмгә текәлеп.— Тук яшь хәзер Нәбиуллин. Аны берни борчымый, кузгатмый. Барыбыз да аны «сабыр» дип килдек. Сабырлык белән янәшә ялкаулык та оя типкәнен беребез дә күрмәгән.

Ул иреннәрен тастымал белән каплап тагын беравык тавышсыз ятты. Мин сүз әйтергә түгел, уйларга да шүрләп басып тора идем.

— Кем ул Лотфулла Нәбиуллин?.. Талант... Табигать талантны биргән үзенә. Ләкин талант тик бүгенге көнгә генә ярашып яши башласа, бүгенге көне белән канәгать булса, бу аның соңы, һәлакәте. Талант иясенең идеаллары бүгенге көн обывательләренең таләпләре белән тәңгәл килә алмый. Һич! Талант алданрак күрергә тиеш, ераграк, тирәнрәк карарга. Башкалардан аның аермасы да шунда. Талант халыкта бер-ике була. Ә обывательләр июнь аендагы яр бакалары төсле бакылдашып утыралар!.. Талант — барыннан да элек, туймас күңел! Ул эзләнә, аның йөрәгенә май оемый, аның йөрәгендә туктаусыз канәгатьсезлек уты дөрли... Шул ук вакытта талант бик ансат кына җайлаша да ала һәм талант булудан туктый, үлә.

Менә нәрсәләр уйлап ята икән бу абзыкай!

Болар Фоат өчен дә ятрак яңгырады, ахрысы, ул тын тартырга да куркынып аның аяк очын саклый.

Баязит абый туктагандыр дисәм, юк икән, һаман сөйләвендә дәвам итте.:

— Кергән безгә... Тик шунда ГИДУВка кагылып чыкмады... Гөлсәйрә апаңнан сорадым. Лотфулламы, дим... Нәбиуллинмы, дим... Лотфулла, ди... Дачасына алып барасы, яртыны уртага куеп, бер-беребезнең аркасын кагып утырасы... Мәнсезлеге дисәң, андый мәнсез түгел ул... Бу аның идеаллары бетүе, тормыш принцибы яки принципсызлыгымы, шайтан белсен... Кулында көчең бармы — син абзый!.. Юк икән, ата казың күкәй саламы. Очраганда урамның икенче ягына чыга. Кайбер талантларның сыек җилдә дә арзанлы шәм кебек сүнгәннәрен күрдек, шөкер... Начар ис белән кара сөрем генә торып калды алардан.

— Сине болай каты ята дип уйламагандыр,— дидем мин, Лотфулладан бигрәк үземне акларга теләп.— Керми калмас иде...

— Анысын үзе белер... Тик менә проекты... Кемнәрдер раслаган бит шуны, премия биргәннәр...

Аның гына шундый үтергеч сүзләр әйтергә хакы бар дип сызланды күңелем... Гайшә Хәлиловна әйткәнчә, «Баязит абый — Ленин гвардиясе солдаты...» Ул беркайчан эштән туймады, дөньяның арзанлы кызыкларына алданмады, сатылмады, сатып алырга тырышмады. Без бәйләнештә булган производстволарның берсендә дә Баязит Гарифуллинның кулы тимәгән почмак юк, аны беләләр, телгә алалар, сагыналар. Чин ягыннан артык зурга күтәрелмәгән икән, аның чиннарга бер чакта да исе китмәде. Намуслы, саф булу чиннар белән дә бирелми торган асыл сыйфат түгелмени?!.

Ул кинәт йөткеренде, чәчәде, күзләрен йомды. Фоат тастымалны алып, аның иреннәренә япты, мин нишләргә дә белмичә, ишек катына йөгердем, ярдәм эзләгәндәй, зал якка карадым, анда берәү дә күренмәде. Бәхеткә каршы, чигәләремә тук-тук бәреп торган йөткерү озакка сузылмады, Баязит абый, хәл җыеп, күкрәген көчсез куллары белән уып яткан арада мин: «Ни турында сөйләшсәк, аның өчен җиңелрәк булыр икән?» дип баш ваттым. Эш, институт турында сүз кузгалуның яхшылыкка алып бармавын күрдек, җитәр.

Гомер буе зирәклек үрнәге итеп санаган кешемә: «Яле, юкка кайгырма, ташла, терелерсең, адәм токымы чирсез торамы бу заманда?» дип, бала-чага сүзе сөйләп утырасым килмәде.

Ул тынычланып, мин кергәндәге хәленә кайткач, саубуллашып китәргә талпындым, ул калкынмыйча ым кагып мине туктатты. Бераздан аның сулышы тигезләнде, ул иреннәрен дымлы тастымал белән чылатты.

— Сәгыйть, яңалык әйтмим, исәңә генә төшерәм. Талантлар йоклаганда талантсызлар бәйрәм итә... Алар әрсез дә булалар, бүгенге көн өчен нәрсә кирәклеген тизрәк тә элдереп алалар... Элек булса син Лотфуллага каршы ядрә кебек атылып чыгар идең... Димәк, син дә билне биргәнсең... мин — радикулиткамы-чорткамы, ә син әллә нәрсәгә!..

Урындыкка утырып, дымлы учымны теземә ышкыдым, күңелле хәбәр ишеткәндәге кебек авызымны ердым...

Ул коры гына:

— Өйдәгеләр ни хәлдә? — дип сорады.

— Сәлам әйтеп калдылар.

Бусы хак иде.

— Балалар ничек?

— Малайлар әйбәт!.. Өчесе өч яктан дөньяны пыр туздыралар. Әле ярый, үзебезгә посып калырга дүртенче якны калдырганбыз дип, әнкәсе белән куанабыз.

Бу минем сыналган коралым, бу җөмләне байтак кешеләргә ычкындырганым бар, ләкин Баязит абыйның аңа исе китмәде.

Аның һәр хәрәкәтен сагалап, бәләкәй генә боерыгын үтәргә дә әзер булып Баязит абыйның аяк очында тугры Фоат басып торды. Мин аларның улларын да, кызларын да беләм, Фоатны берчакта да очратканым булмады. Гөлсәйрә апаның берәр туганыдыр инде, шуның чалымнары бар.

Нигә Баязит абыйның аяк очында мин түгел, ул басып тора? Мәҗлесләрдә, бәйрәмнәрдә аның түрендә утырган башкалар кайда?

Фоат урынында булсам, мин нишләр идем?

Әле шушы биш-ун минутта кыенсынганны, Баязит абый янында, Фоат сымак, берни сиздермичә, авырсынмыйча, хәтта бераз елмаеп, сөйләшенгән һәр җитди сүзне уен-көлкегә борып тора алыр идеңме?

Әллә аны әнә шул тугрылыгы өчен иң авыр, иң кадерле, чамасыз озын минутларны кыскартырга дип чакырып китергәннәрме?

О, сөекледәрен, якыннарын, өметләрен соңгы юлга әзерләүче кешеләрнең күңелләре никадәр бай булырга тиеш!.. Якыннарының соңгы күз карашын, соңгы сулышын, соңгы тырпылдавын үзенә алып калучыларның күңелләре нихәтле киң булырга тиеш...

Әллә мин үтә чыккан күремсез, тар күңелле бәндәме?..

— Дарулар табып булмый,— диде кинәт Баязит абый.— Исән чакта күп нәрсә җитешми, ис китми ул чакта. Авыруның дөньясы башка, фәлсәфәсе дә бүтән. Бәләкәй генә бер җире килмәсә дә рәнҗетә...

Ни теләмәсәм дә, «бирешмә, чир кунак түгел, килер дә китәр» дигән тоссыз сүзләр белән аны юатырга керештем. Фоатның йөзе тагын да яктыра төште, ул да:

— Чирләмәгәч, терелмәгәч, бу дөнья нигә ярый! — дип көйләп куйды. Мин канатланып китеп кояшның унбер еллык циклы турында, шушы даими әйләнешнең табигатькә китергән афәтләре, циклоннар, тайфуннар турында, аның кеше организмына ясаган бәла-казалары турында барыбыз белгәнне дә кабатлап чыкты. Ул күзләрен йомып йокымсырагандай итте, Фоат белән без бер-беребезгә караштык. Мин урынымнан кузгалдым, аяк очларыма басып ишеккә таба атладым.

— Китмә,— диде ул, күзләрен ачмыйча гына.

Мин тып-тын гына көтеп утырдым.

— Йокламыйм мин,— диде ул.— Уйланып ятам. Уйлар өчен вакытымның шушы кадәр мул булганы юк иде. Нигә чакырдылар икән дип курыктыңмы?.. Юк, үлмим әле мин. Аннары физик үлем куркыгмый да. Анысы табигый нәрсә. Иҗат кешеләрен, гомумән, эш кешесен өч төрле үлем көтә дигәннәр акыллылар. Беренчеләрнең үзләре исән чакта ук эшләре үлә... Икенчеләрнең эшләре үзләре белән үлә... Өченчеләрнең исә, үзләре үлсә дә, эшләре кала, хезмәтләре яши, чәчәк ата. Мин шушыларның кайсысына керәм инде?

Аптыраштa калдым. Ак диярге дә белмим, кара диярге дә уңайсыз. Ул исә, «я, я, әйтеп кара» дип, мине кыюландыра.

— Әгәр сезнең яшьтә, сезнең кебек авырып ятканда, янымда үзем төслерәк кеше утырса, мин бик канәгать булыр идем. Без бит синең шәкертләрен. Гариф та, Шәриф тә...

— Үзегезне мактау булдымы бу? — диде ул, көлемсерн төшеп.

— Нигә, рас түгелмени?

Бераз тын тордык.

— Син теге проектыңа яңадан әйләнеп кайтырга ризалык бирдеңме?..

Сикереп тордым.

— Утыр, утыр...

— Яңадан чакырганнары юк, Баязит абый.

Дәшми. Ләкин мин хәзер беләм инде, ул йокымсырамый, ул тын гына уйлана. Аның уйларының үзәгендә үлем дә, үзе дә түгел, мин!.. Аның борчылуы мин. Аның кайгысы мин. Ни ди ул миңа? Минем аша дөнья белән хушлашамы? Башкарып чыгалмаган эшләрен васыять итәме?

Кичке эңгер бүлмәләргә кереп тулды. Кичке эңгердә тәрәзә каршысында уйнаган балаларның тавышлары аермачык, аерата тантаналы, аерата дулкынландырып ишетелеп тора. Сирәк-сирәк кына Гөлсәйрә апа кереп хәл белеп чыга. Фоат залда, диванда журналлар актара. Миңа ул Баязит абыйга да, миңа да кайнар чәй ясап кертте. Чәйдән соң мин аны йоклыйдыр дип белеп кузгала башладым. Ул бер генә сүз әйтте:

— Китмә!

Өстәлдәге лампаны кабызгач, ул хәлләнеп китте, авыр гына кымшанып, уң ягынарак ятты.

— Икеле-микеле йөренүеңне сизенәм, Сәгыйть... Сукыр түгел, колак та ишетә... Турысын әйтәм, ошамый миңа болар берсе дә. Үгетнәсихәтне сөймим, беләсең, әмма әйтми калырга да ярамый. Без — дуслар синең белән. Безне эш берләштерде, хезмәт дус ясады. Бу исә иң бөек бердәмлек. Туганлык, дуслык эш аркасында килгәндә моңа сөенергә генә кирәк. Бу дуслык — мәңгелек. Мәңгелекне олыларга кирәк... Кеше гомеренең бәһасен, кирәклеген, файдасын бары кылган эшләре белән генә билгели ала. Ә син кырык яшеңдә койрыкны сырткa салмакчы буласың. Дан теләдеңме? Килмәдеме?.. Миңа миңа житмеш яшьтә дә дан килмәде. Нигә ул? Нәрсәгә?.. Җир шарын өч кит күтәреп тора дип ышанган заманалар булган. Ләкин җир шарын галәмдә күзгә күренми торган бердәм көч тотып тора... Тереклекне дә

шулай ук... «Остаз, остаз» дия идең син... Хәзер дә шулай дигән кебек булдың. Куркак шәкертләрнең остазы булуны зур мәртәбә дип санныйсыңмы?.. Икеләнүләр була, һәркемнең башыннан кичә андый хәлләр. Инде беттем дип уйлыйсың, моннан ары бер эш тә кыра алмам дип уйлыйсың, куркынып калган чаклар да аз булмый. Җиңәсең, җиңеләсең, төрлесе була. Отмады дип лотерея билетын усалланып ертма. Откан чагың да булыр!.. Ләкин үзең тоткан юлга турылыклы булырга кирәк. Дөньяда хыянәттән дә әшәке нәрсә юк. Иптәшләреңә хыянәт, халкыңа хыянәт, идеяләреңә хыянәт, эш-хезмәтеңә хыянәт... Хыянәт — турыдан-туры сатылу гына түгел ул. Хыянәтләрнең күбесе кеше күңелләрендә тынлыкта, яшеренлектә эшләнә... Синең яңа проектың... Мин аңа һаман ышанам... Нинди икеләнеп тору ди ул?! Автозавод бит ул мәңгелек... Берәүләр Бастилияне алганнар... Берәүләр Төньяк Котыпны ачканнар... Берәүләр Магнитканы төзегән... Бу кешеләр барысы да Мәңгелеккә кул тидергәннәр, Мәңгелекнең утыннан йөрәкләренә очкын төшергәннәр... Миннән сиңа сүз шул: бар, алын, эшлә, җиң!.. Васыять дисеңме моны, карт иптәшнең сүзе дисеңме, үзеңчә ата. Ләкин тормыш кануннары кушканча яшә. Тормыш җиңеп яшәргә куша!.. Инде бик яратсаң, остаз сүзе итеп кабул кыл!

Без бер-беребезгә карашабыз. Ул яткан, мин басып торам.

Фоат кай арададыр аның аяк очына барып житкән. Сүзне ул алды:

— Баязит абый, миңа Төркиягә барырга тәкъдим ясадылар. Экскаваторым белән бергә. Бер елга. Безнекеләр анда алюминий заводы салалар икән.

Баязит абый тагын елмайгандай итте:

— Шулаймыни, Фоат? Бик кызыклы сәфәр булачак. Бар, эшләп кайт. Тагын кемнәрне җибәрәләр? Сезнең тресттан ничә кеше?

— Әле тәгаен белмим. Миңа өзеп әйттеләр: документларыңны әзерли башла, без сиңа ышанабыз, диделәр.

— Әйе, син егет кеше. Монголиядә дә бер ел эшләп кайттың бит... Бер ел...

Мин Баязит абыйлардан кара төндә генә чыгып киттем.

## 7

Институтта хәбәр таралды:

— Сәгыйтьнең проектын янадан гыйльми советка куялар!

— Сәгыйть яңа группа җыя башлаган!

Кем тарата дыр андый хәбәрне, минем әле төпле бер фикергә килгәнем юк. Гали Кадыйров белән көн дә шул хакта утырып сөйләшәбез.

— Мин Баязит абый янына барганнан соң бу турыда бик нык уйлана башладым... Теге вакытта проектка каршы чыгып ялгышмадыммы икән дим. Гайшә Хәлиловнага да Баязит абый әйтеп кайтарган... Шуннан соң директор министрлыкка хат язып җибәрде...

Бу арада көннәрнең, сәгатьләрнең исәбе буталды. Хатыным әйтмәсә, шимбә икәнен онытып та җибәргән идем.

— Син бүген дә бакчага бармыйсыңмыни?.. Бигрәк тиз үзгәрәсең тагын, бер караганда талпан күп кадалып ятасың, икенче караганда куып җибәреп тә булмый. Күзге эшләр тулып ята, бүген барып кунсаң, иртәгә балалар белән мин дә килеп җитәр идем...

Анда да мин артык ашыкмадым, кәгазьләремне караштырдым, кайсыберләрен үзем белән алдым, дачага төш авышканда гына барып җиттем.

Эшкә кулым бармады. Бакчаны бер әйләнеп кердем дә чәй кайнатып эчтем. Белеш балыкчыларның кайтыр вакытларын чамалап Идел

буена төшсәм, минем көймә койрыгында бер кыз утыра. Рузалия ич бу!..

— Сәгыйть абый!

— Син нишләп утырасың монда?

— Сезне көтәм.

— Каян килеп чыктың?

— Минем бер тапкыр да көймәгә утырып караганым юк бит, Сәгыйть абый. Мин иртәнге биштәге поезд белән үк килгән идем инде!

— Шул гомердән бирлеме, һай, балакай!.. Алайса, мин хәзер киләм. Синең карының ачтыр әле!..

Пиджак, чалбар кесәләремә шыплап алма тутырдым да кармаклярымны күтәреп су буена йөгердем. Яр буендагы тимер шкафтан моторымны, кирәк-яракларымны бушатып көймәгә ташыдым. Рузалия бер адым да калмыйча миңа ияреп йөрде.

— Шәп икән сезнең монда, Сәгыйть абый!..

Моторым тыңлаулы, бер-ике сызуга гүли дә башлады. Рузалия минем янга койрыкка утырмакчы иде дә, күлмәгеңне сакла, монда коры түгел дип, утыртмадым.

Суны җиңел генә ярып, Иделгә кереп киттек.

Гадәттә мин туктый торган урынны алганнар иде, көймәләр арасыннан бушрак урын сайлап, якорьларымны төшердем. Бауларны тартып, көймәне агымга аркылы куйдым; балыкларны чакырырга җимле капчыкларны суга батыргач, кармак җепләрен сүттем.

— Миңа хәзер рәхәтләнеп кара, кызыкай.

— Нәрсәне карыйм, Сәгыйть абый?

— Күңелең ни тели — шуны.

Ул шатланып ризалашты, мин балыкка артык комсыз булмасам да, җепләремә текәлдем.

— Сәгыйть абый, сез монда гел киләсезме?

— Син шуны тикшерергә килдеңме?

Ул оялып кызарынды.

— Юк ла...

Мин суга иелеп алмалар юдым, берничәсен, иң матурларын Рузалиягә бирдем.

— Сыйлан!.. Җәе чыкканда киләбез инде.

— Ялыкмыйсызмы?

— Чынын әйтимме, ялганынмы?

— Чынын, чынын, Сәгыйть абый,— дип кычкырды ул.— Алмагыз нинди тәмле, сусыл. Үзегезнекеме?

— Мин шушында гына чын-чынлап ял итә алам да. Кара, бу бит минем автономиям. Чикләрем бар, алар кагылгысыз. Без, балыкчылар, бер-беребезне хөрмәт итә беләбез. Монда минем дөньям, шөгылем, мавыгуым, гыйшкым, әгәр беләсең килсә, барысы да шушында. Сугышлар, кырылышлар, ямьсезлекләр турында мин монда берни ишетмим, табигать колагыма ял бирә. Миңа шушы ачык зәңгәр күктән, шушы агып барган көмеш таңкалардан тыш мин мелт-мелт итеп утырган кармак җепләрен генә күрәм. Бу җепләр исә башка дөнья белән — балыклар патшалыгы белән ике арадагы телефоным. Мин аларга күчтәнәчләр алып киләм, тәмле боткалар, иске ипиләр, киндер мае салам, солы бүрттерәм, кып-кызыл диетик суалчаннар алам. Алар сыйланалар да арадан бер корбанны билгелиләр. Шул бичара акрын гына килә дә телефоннан шалтырата: «Әй, мин килдем, йоклама!»

Рузалия, беренче күрешкәндәге төсле, очына-очына озак итеп көлде.

— Дөньядан качып киләсез, алайса,— диде ул җитдиләнеп.

— Качарсың бик,— дидем мин көлемсерәп.— Дөнья качышлы уйнаганны яратмый.

Зур пароходлар кырыбыздан гына узып китә, аларның дулкыннарында без каен бәллүдәге бала кебек тирбәләбез. Балык кына чиртми. Тирә-яктагы балыкчылар якорьларын күтәрә башладылар, аларның садокларында ялтыр-йолтыр корбаннар елтыраша.

Бу арадагы йокысызлык үзен сиздерде, күз кабакларым салынып йомылдылар, көймә төбенә сузылып яттым.

— Йоклыйсызмы? — диде Рузалия.— Йоклагыз, чиртсә, үзем алырмын.

— Алырсың,— дидем мин, күз кабакларымны ачмыйча гына. Рузалия белән бүгенге Сәгыйть булып түгел, әле моннан бер-ике атна элек кенә яшәп яткан кеше булып сөйләшәсем килә иде.

— Минә уйлашыйк,— дидем мин.— Сөйләшик...

— Сөйләшик, Сәгыйть абый!..

— Адәм баласы дөньяга килә. Үсә. Яхшы белән яманны аера белми. Минем төпчек улым, Вьетнам җирен таптаучы солдатны күрсәтсәләр дә, «әнә, әйбәт абый» дип карап утыра. Әле һәр очраган бала аңа дус, күзенә күренгән һәр кеше — аңа иптәш. Урамдагы малайлар белән ул уйный ала, уенчыгын уртаклаша. Тора-бара аның зәвыгы үзгәрә. Ул, ниһаять, үз-үзен таба башлый. Иптәшләр сайлаганга талымчанлык күрсәтә. Берәүләр белән уйный, башкаларга әйләнеп тә карамый. Сугышып та ала, димәк, үзенең мин-минлеген даулый. Үпкәләргә, әләкләргә, үчегергә, үртәшергә өйрәнә. Болар барысы да аның үз-үзен табулары. Сайлана, нәтиҗәдә берәүләрне алга чыгара, икенчеләрне кага. Үскән саен ул үзен тирәнрәк ача бара, дөньяга карашы, таләпләре, әхлак-мораль нормалары билгеләнә, камилләшә. Яши кеше, һаман яши, яшәгән саен аның янындагы кешеләр азаялар. Тора-бара шундый дәрәҗәгә килеп җитә, фикер уртаклашыр өчен җан дуслары таба алмый башлый!.. Чөнки аның таләпләренә җавап бирерлек, аның нәзберек күңелен канәгатьләндерерлек кешеләр аңа очрамый! Берәүләр сердәш итеп язучыларны, шагыйрьләрне сайлыйлар, музыкага табыналар, икенчеләре динне, өченчеләре аракыны. Берәүләр тилереп марка җыя, шырпы кабындагы чуар сурәтләр белән мавыга. Болар барысы да кешенең нәни чактагы, аның асылына салынган киң бәйләнешләрне юксыну авазы. Кеше үз ишләре белән аралашырга тели, шул ук вакытта арадашлыкны ялгыз башы, җәмгыять күзеннән качып эшли. Гомеренең азагында япа-ялгыз калган кешеләр дә бар. Болары инде бәхетсезләр... Христианнар, католиклар монастырьларга кача торган булганнар. Мөселманнарда да ул нәрсә бар. Дәрвишләрфәләннәр. Моның асылында бер кыртыйлык яки алла исеменә гомерене корбан итәргә әзер тору гына ятмый лабаса!.. Әнә шул, капитализмның котылгысыз җимеше булган бәхетсезләр өчен, тора-бара тәмам ялгыз калган бичаралар өчен дә уйлап чыгарылган ул хөҗрәләр!.. Көлмә, көлмә, Рузалия!

— Сәгыйть абый, сез шундыйларның берсеме? Бу көймә — хөҗрәме?!

Аның күзләрендә хәйләкәр утлар жемелдәде.

— Юк, балам!.. Бу көймә хөҗрә түгел түгелен...

— Сез мине сыныйсызмы?

— Мин үземне сыныйм. Син бу көймәгә очраклы килеп кунган күбәләк кенә. Очып китәрсең дә янадан кунмассың. Мин үзем белән үзем сөйләшеп ятам...

— Куркыныч,— диде ул кинәт.

— Безнең өскә пароход киләме әллә?

— Юк. Уйларыгыз куркыныч.

— Минем сине чак кына куркытасым килде.

— Ә мин бәхетле! — диде ул, куаныч белән.— Быел язын мин ак күбәләк күрдем. Тәрәзәмнән очып керде. Апрель ахырында ук. Тәрә-

зәмне ачып пыяласын юа идем, ап-ак күбәләк... Ә язын ак күбәләк күрсәң, елың бәхетле була! Сары күбәләк күрсәң, ел буе кайгырасың. Дөрес ул, Сәгыйть абый. Миңа быел гел шатлык кына килеп тора.

— Бәхетле булу әйбәт...

Ул куанып миңа таба иелде:

— Сез дә бәхетле ич!

— Ә син каян беләсең?

— Белмичә... Бик яхшы беләм... Гайфи абый белән сөйләшүегезне мин һәрвакыт тыңлап тора идем. Ай, ачуланмыйсызмы мине, Сәгыйть абый?

— Әллә ниләр сөйләшмәгәнбездер әле,— дидем мин, торып утырып.

Гайфи белән очрашулар, сөйләшүләр миңа бик күптән узган вакыйгалар кебек тоела иде. Рузалия аларны әле кичә генә ишеткән кебек кабынып сөйли башлады.

— Бусын әйтмәм дә дигән идем, хәзер сөйлим инде барыбер. Камилә апа сезне бик ярата иде. Сез чыгып киткәч, «Нигә анык кебек була алмыйсың?» — дип, гел абыйны тирги иде. Абыем кан кардәшем булса да, Камилә апам җан кардәшем бит минем. Сагынам мин аны...

Кинәт ул чәчрәп кузгалды:

— Чиртә!

— Кайсысы?

— Уртадагысы. Кызыл резинагыз селкенеп-селкенеп торды.

— Дулкын уйнаткандыр аны, Рузалия.

Кармак сабын күтәреп карадым, җепне өскә саудым, чирткән икән, суалчанны йомдырып сызган. Балык килә башлады дигән сүз... Суалчан саплап җепләремне төшерсәм дә, дикъкатем балыкта түгел иде, кулымны баш астына куеп, чалкан яттым. Көн чак кына суыта башлады... Җил чыкты...

Нәрсә дип үчеклим инде мин бу кызны?.. Үчеклимме, әллә юаныч эзлимме?..

Рузалия тагын кычкырды. «Әнә!» Бу юлы балыкчылык инстинкты өстенлек алды, сикереп тә тордым, ярты килолы корбанны тартып та чыгардым. Рузалия балыкны бик кызганды:

— И-и, мескенем, ничек тырпылдый. Хәтта кычкырып куйды. Идел белән саубуллашуымы анысы?

— Белмим, бәлки, безгә сәлам бирүедер...

Шәфәкъ батканын абайламый да калдык. Идел өстеннән көймәләр берәм-берәм агып бетте, без ашыкмадык. Үзем ясаган шушы бәләкәй дөньяда татулык, үзара хөрмәт, эчкерсезлек хөкем сөрә иде, миңа тын, рәхәт иде. Җил көчәйде, көймә кабыргаларын шап та шоп дулкын кыйнарга тотынды. Иң соңгыларның берсе булып кузгалдык. Барабыз.

Бөтен мазаларым тегендә — хәзер куе кучкыл томан белән өртелгән ярда калган иде. Хәзер, белә торып, шул ярга ашыгабыз. Бакча карамаган өчен хатыннан нык кына эләгәчәк миңа!..

— Башың әйләнмиме? — дип кычкырдым мин Рузалиягә.

— Юк!

— Ярга чыккач күрерсең әле. Идел сихерләп озата, әмма соңыннан җир белән күк бергә тоташып зәңгәрләнеп ага. Төшләрнең дә зәңгәрләре генә керер моннан соң...

Яр буена тезелешкән утларга моңаеп карадым:

— Менә кайтып та җитәбез! — дип кычкырдым.

— Шулай тизме? — диде кыз кайгырып.— Сәгыйть абый, туктагыз инде, мин аз гына ишеп карыйм.

Буйсындым. Рузалия кулларын төкереклэп ишкәкләргә тотынды, әмма көймә артык зур, авыр, дулкыннар көчле, җил аяусыз, кыз бөтенләй тәҗрибәсез иде. Без бер урында атынып, чайкалып тора бирдек,

аннан жил көймәне куе камышлыкка куа башлады. Камышлыкта мылтык тавышлары яңгырады.
— Аучылар,— дидем мин.— Үрдәк аталар.
— Чак кына ишим инде, Сәгыйть абый. Өйрәнә башладыммы азрак?
— Башладың, башладың,— дидем мин, ана көч биреп.— Ишкәкләреңне артык тирән батырма, бер жайга гына сал да каерып жибәр.
Ул тәмам арып, тирләп пешкәч кенә моторны кабыздым, тиз үк кайтып та життек. Шунда Идел култыгында гына балыкларны чистартып алдым.
— Ничек соң? Азрак күңелең почмакландымы? — дип сорадым, өйгә кайтып житәрәк.
— Әллә ничегрәк,— диде ул.— Көткәнчә үк түгел.
— Киләчәктән гел-гел зурны көтеп гадәтләнгәнгә ул.
Минем үчегеп маташуым ап-ачык булса да, кыз мөмкин кадәр йомшаграк жавап бирергә тырышты:
— Сез мине өф-өф итеп яшәүче унсигезенче гасыр туташы дип саныйсыз, ахры, Сәгыйть абый. Мин киләчәктән көтеп кенә тормыйм, кулымнан килгәнчә, үз көчемне дә файдага жигү турында хыялланам.
Тәмам караңгыланды. Балыкны бик һәйбәтләп куырып ашагач, мин Рузалияне станциягә озата киттем.
Барыр арабыз ун минутлык юл.
Бер жир буе да китмәдек, Рузалиянең башы әйләнә башлады. Ул авызын кулъяулыгы белән томалап, бер читкәрәк чыкты да ялварып:
— Зинһар, килми торыгыз, Сәгыйть абый,— дип кычкырды.
Поездга кадәр вакыт бар иде әле, сабыр гына аның ах-ух килгәнен көтеп тордым.
— Уздымы?
— Баш әйләнә. Авам, авам дип кенә тора.
— Поездда тагын да начаррак булмагае, кайтыйк без өйгә! Кайнар чәй эчәрсең, ял итәрсең.
Ул баш тартты.
— Уңайсыз, Сәгыйть абый. Белә калса, сезгә болай да хатыныгыздан эләгәчәк. Сез барыгыз, кайтыгыз.
— Ә син?
— Чак кына утырып торам. Станция әнә генә ич!
Кызны житәкләп тимер юл аркылы чыгардым. Шпал, май исеннән аның кәефе тагын да начарлана төште. Минем йокым килә иде. Рузалиядән качырып кына иснәштергәләдем. Салкынча, тар тыкрык аша узып, соры-кара урман янына барып чыктык. Урман белән буш кыр арасыннан салынган шома сукмактан атладык.
— Куркыныч,— диде кыз, мине култыклап алып.
— Урманмы? Кырмы?
Як-ягыма шигәеп карадым.
— Сезнең сүзсезлек куркыныч. Минем хакта әйбәт уйламыйсыз төсле.
— Синең әйбәт уйлатасың киләме?
— Бик.
Көз булса да һавалар жылы торыр, ахрысы, уң ягыбыздагы сазламыкта сирәк-сирәк бакалар кычкырып куя.
— Азрак утырып торабызмы, Сәгыйть абый?
— Синең баш һаман зырылдыймы?
— Глобус кебек!
Жир жылы, без сөялеп утырган телем-телем кабыклы имән кәүсәсе дә жып-жылы.
Икәү утырабыз.
Мин һәм ул.

Кичә бу вакытта мин Баязит абыйларда идем.

Нинди сәбәпләр аркасында мин монда? Рузалиянең ихтыярына буйсынып йөрим түгелме? Ни тели ул? Ни көтә миннән? Нигә шатлана?

Мин аңа шатлык та, өмет тә бирә торган кеше түгел ләбаса.

Без утырган җирдән дым исе, пәжегән яфрак исе килә иде. Кыз да шул турыда уйлый икән:

— Нинди татлы ис, әрем исе килә,— диде ул сөенеп.— Әрем себерке белән авылда өй идәннәрен себереп чыгара торган идек!..

Мин эндәшмәдем.

— Сәгыйть абый, сез йокламыйсызмы?

— Киресенчә, мин уйланам.

— Тормыш турында Гайфи абыйга әйткән сүзләрегезне хәтерлисезме?

— Кем хәтерләп бетергән аларны, балакай?

— Ул сезнең иманыгыз түгел идемени?

— Син безне сөйләнә торган чакта очраткансың бит!.. Сүзләр канатлы чакта күргәнсең... Хәзер без андый түгел.

— Болай дигән идегез...— Ул тезләрен кочаклап җайлап утырды.— Без ялгыз-ялгыз беребез дә генийлар түгел, шаккаттырырлык эшкә көчебез дә җитеп бетмәс. Әмма бер теләктә, бер юнәлештә тотынсак, дөньяны әйләндереп салачакбыз... Англиядә худка киткән пар машинасы феодализмны чәнчелдерде. Хәзер бөтен дөнья күләмендә бара торган фән-техника революциясе безнең терекләккә, аңга, яшәешкә, гореф-гадәтләргә, танып-белү методларына никадәрле үзгәреш кертер, монысын бераү дә анык кына әйтеп бирә алмый. Әмма җирдә тормыш нык үзгәрәчәк!.. Без бер агым булып шул революцияне тизләтергә тиешлеләр. Җир өстендә күп илләрдә яшәп килгән хәерчелекне, ачлыкны, наданлыкны, раса дошманлыгын хәл итү безнең буынның асыл бурычы... Шулай дигән идегезме?

— Тукта-тукта, син боларны каяндыр укып-ятлап сөйләмисеңме?

Рузалия дә үпкәли белә икән, тавышы нык кына үзгәрде:

— Чат сезнең сүзләр, Сәгыйть абый. Рәтен, җөмләләрен бутасам да, сезнең сүзләр. Көндәлек дәфтәремә язып та куйганмын мин аларны.

— Шулай да булсын ди...

— Ә менә сезнең тормышыгыз, бүгенге көнегез башкалар тормышыннан ни белән аерыла? Әгиләрегез, бабаларыгыз тормышыннан нәрсәсе үзгә?..

Агач араларында тыгызланган кара тынлыкны бимазалап кемнәрдер шатыр-шотыр агач сындыралар. Бераздан бездән ерак та түгел калкулык өстендә учак тергезеп җибәрделәр. Минем әти «ут кабызыгыз» дими, «ут тамызыгыз» дип сөйләшә иде. Нигә алай әйтә иде икән ул?..

Әтиләр, ата-бабалар...

— Син мине иман агачына тәрәдең, Рузалия...

Кызның сүзләрен һич тә уенга борырга теләмәсәм дә, бу сүзләрем үзеннән-үзе килеп чыкты, урынсыз, ясалма яңгырады.

— Оят булса да сөйлим инде, Сәгыйть абый. Ул вакытта минем арттан бер егет йөри иде. Өйләнеп, тормыш корырга иде нияте. Мин дә каршы түгел идем сыман... Үз абыең өендә яшәсәң дә, тар җиргә тана башы дигәндәй, читен лә, үзегез беләсез. Кеше почмагында торганыгыз бардыр, түренә сыйсаң да, күңеленә сыймыйсың. Сез дә бит мина рәтләп сүз кушмый идегез, бармы мин дөньяда, юкмы. Гайфи абыйның бер җиһазы гынамы, сезнең өчен барыбер иде... Шуннан, теге егет «яратам», ди. Өйләнәм, ди. Мин, барам, дим. Әзерләнеп йөргән

заман... Шуннан сез яңа проектка тотындыгыз да безгә килеп йөри башладыгыз. Аңарчы мин сезне белми идем әле...

Ике битем кызыша ук башлады...

— Бер киләсез, ике, эшлисез, төннәр буе үт сүнми. Җырлап та аласыз, Камилә апа гитара уйный. Ә мин кухняда кичләр буе тыңлап утырам!.. Тоттым да теге егетнең тәкъдимен кире кактым. Әнием белә иде инде, ул пыр туза, туйга дип сарык симерткән. Иптәш кызларымны әйтәсезме, барысы шаккаттылар. Егет, ихлас, начар кеше түгел иде. Эчми, тартуы бар иде барын. Киенә дә белә, кулыннан эш тә килә, төскә-биткә дә төшеп калганнардан түгел... Тик бер ягы бар: сезнең кебек сөйли белми иде ул, дәртләндерә белми иде. Аның уе бик гади, ап-ачык: икәүдән-икәү генә яшәү, квартира, балалар...

Рузалиянең йомшак тавышына ияреп мин үткән көннәргә, үземнең алтын чагыма әйләнеп кайттым...

— Сезнең сүзләр минем йөрәгемне бөтенләйгә урап алдылар. Сезнең киләчәккә өндәвегез мине ул егеттән ерагайтты. Минем тиле күңел шул сүзләрне көткән булып чыкты... Гайфи абыйдан сорашып-белешеп кенә торам... Кайчан килә, кайсы сәгатьтә... Эштән өйгә очам гына! Егетем борын салындырып универмаг ишеген саклап тора. Эш, дус кызлар онытылып торды. Бары сез кирәк, сезнең тавыш, сезнең сүзләрегез генә кирәк. Почмакта китап укып утырган булам, үзем тыңлаам, үзем дә сезнең бәхәсләрнең уртасында кебек... Сез тынасыз, кәгазь кыштырдавын, карандаш йөгергәнен ишетәм... Рәхәт минутлар!.. Егетем бик каты үпкәләде, ишлисең, яраткандыр шул!.. Ул чагында минем күзгә башка берәү күренми иде... Әле ярый, әлегрәк кияүгә чыгып куймаганмын дип шатлана идем... Югыйсә, сезне очрата алмас идем, дөньяда мин яшәгәннән үзгә тормыш барын белми калыр идем... Кияүгә чыгам дип укуны ташлаган идем, документларымны тагын мәктәпкә илтеп бирдем. Сезнең кебек инженер буласым, заводлар, цехлар төзүдә катнашасым килде. Минем тилемсәләнеп йөрүемне бер Камилә апа гына белде.

— Ә Гайфи?

— Бәлки, ул да шигәйгәндер. Бер көн бик нык салып кайтты. Камилә апа ачулана, мин пыр туздырам!.. Сезнең проектны расламаганнар икән! Әмма сез янадан эшкә керешкәнсез!.. Сезнең хакта дөрес уйлаганмын икән дип, әй, шатланам, әй, куанам! Гайфи абый да эчүдән тыелды. Ике тапкыр шулай булды. Инде җиңәсез, инде җилнедавылны кичәсез дип йөргәндә, группагыз таралды... Шул көнне без өй эчебез белән сезне көттек. Тик сез килмәдегез... Сезгә бик нык үпкәләдем мин, Сәгыйть абый! Гайфи абый шуннан ныгытып эчә башлады... Ничек инде, шундый чакта, шундый кичерешләрдән соң иптәшне ташлап китмәк кирәк? Мин сезне бик озак көттем, бик озак, ихлас...

— Нигә? — дидем мин тиле кеше сыман.

— Сезнең үз авызыгыздан барын да ишетәсем килгән иде. Ташламагыз Гайфи абыйны дип үтенәсем килгән иде. Шуннан Баязит абыйларга кердем... Баязит абый сезне... хыянәтче дип атады... Үз-үзенә хыянәт итте ул егет, диде.

Мин кычкырып җибәрдем:

— Җитте, Рузалия! Җитәр, булды.

— Сез миңа үпкәләдегезме?

— Түгел, сиңа түгел!

— Баязит абыйгамы?

— Аңа да түгел!..

— Минем күңел бик төште... Әнкәй авылда минем, танкодромда йорт кына өлгерсен, мин бит кооперативта, йорт салып ятабыз, әнкәйне монда алдырам, институтка укырга керәм... Сезне бүгенге сыман

итеп күрү мине бик ямансулата... Язын ак күбәләк күргән идем мин. Ә хәзер бик ямансу... Әллә җылыйсым да килә инде...

Мин аның кайнар иңбашларын кочакладым, ул карышмады, кулын минем җилкәгә салды. Кулы нык аның, көчле. Станциягә килеп туктаганын күрмәдем дә, ишетмәдем дә, каршыбыздан гына елан төсле елкылдап, җемелдәп узып китте.

— Кичке соңгы поезд, Рузалия. Хәзер төнге уникедә генә киләчәк.

— Ә миңа хәзер барыбер,— диде ул, исе китмичә генә.— Хәзер инде кайчан китсә дә барыбер... Мин теге егетне генә кызганам. Ярата иде бит ул мине. Ә сез, Сәгыйть абый, гадәттән тыш кешеләр булалар дип ышандырып киттегез дә мине алдадыгыз... Сез Гайфи абыйны калдырып, көймә дип аталган хөҗрәгә бикләнгәнсез икән...

Бая кызыша башлаган битләрем сызланып яналар, йокы качты, уңайсызланам да, читенсенәм дә. Аның әрләү сүзләрендә тугры хөкем, дусларча кисәтү ишеттем. Иң гаҗәбе: бая гына кәпәренеп килгән һавалы Сәгыйть хәзер авыз ачарга да куркып утыра.

Җиргә йөз белән капландым. Чыннан да, җирдән әрем исе, тәмлетатлы көз исе, житлеккәнлек, өлгергәнлек исе килә. Башымны күтәреп карыйм, тау кабыргасында биек-биек кара-кучкыл наратлар. Зират ташлары кебек сирәк-сирәк тезелешеп утыралар алар. Караңгылык уртасында, матур кызның кара күлмәк түшендәге асылташ кебек ялтырап, нәни генә учак яна, аның тирәсендә кара күләгәләр кыймылдады...

— Сезне ярattым мин, Сәгыйть абый! Үзегезне дә, идеалларыгызны да, тормышыгызны да. Тик сез шуларның кайсысына хыянәт иттегез икән?.. Әллә миңа дамы?

Аның кулы мине эзләп тапты, бар көченә кысты, аннан кинәт тартып алды. Без икебез дә аягүрә бастык, минем битемне аның кайнар иреннәре көйдерде.

— Сау бул, Сәгыйть абыем!..

## 8

Иртәнге биштәге поезд белән мин Казанга кайттым. Туп-туры Баязит абыйларга юнәлдем. Ул мине сорау белән каршы алды:

— Группа тупларга керешәсеңме?

— Уйланам,— дидем мин шат кына.

— Озак уйланасың. Эх, тазалыгым булса, мин дә синең группага керер идем.

— Сез житәкләсәгез икән ул группаны!

— Юк инде, Сәгыйть... Чират синдә. Көч сездә. Сезнең буын үзенә төшкәнне хәл итәргә тиешле. Без дә сынатмаска тырышырбыз...

Аскы иренемне тешләп, Баязит абый белән саубуллаштым.

— Көч сизелә әле, Баязит абый,— дидем мин, аның кулын кысып.

— Урал егетенең кулы бит,— диде ул. Баязит абый Урал татарлары токымыннан булуы белән азрак кына мактанырга ярата иде.— Онытма, кергәләп йөр!..

Агачлар саргаеп, ямьсезләнде. Алар кышны көтәләр. Урамга чыккач, гадәтемчә, бераз туктап хәл җыйдым.

Гайфи янына керергәме? Тагын Рузалияне очратырмынмы? Нигә яшь кызны вәсвәсәләндереп маташырга? Безнең алыш-бирешебез юк. Без бер юлга чыгып та, «а» һәм «б» пунктларыннан төрле вакытта кузгалган, гомер буе очрашмаска тиешле юлчылар. Имән төбендә уздырган кич ул бер очраклы эпизод кына... Параллель сызыклар да кайчакта кисешәләр бит!..

Мин бик күптәннән юлга чыгып, байтак җир китәргә өлгердем, әнә

гомер тавының түбәсен күреп торам. Ә ул тауның теге ягында еш-еш атлап югарыга менеп бара...

Каян бу газаплы уйлар әйләнеп кайттылар әле? Баязит абый уларга жыенмый, ул яшәргә тели. Бәлки, бирешмәс?.. Ул яшәсә, мин яшим. Мин яшәсәм, ул да яши булып чыга түгелме?.. Рузалия дә яшәячәк, укыячак. Гомер, тереклек, хезмәт тоташ чылбыр булып сузылганда гына бәрәкәтле, өметле һәм нигезле була, кем дә булса аның бер божрасын өзә икән, бу Жир шарын һәлакәткә китерәчәк.

Сугышлар, диктаторлар, фашизм — тереклекнең үсеш юлындагы күпме асыл божраларны өзеп ташламадылар... Димәк, диктаторлар, сугышлар үсеш тарихының йомшак буынлы божраларын эзләп таба алганнар, чылбыр нык, таза божралардан гына тормаган. Нигә әле без, егерменче гасырның егерме сигезенче елында туганнар, йомшак божра булырга тиешбез?

Ватаныбыз бар, жиребез бар, илебез бар. Өлкәннәребез бар, улларыбыз үсә...

Без монарчы матур яшәмәдекмени?

Тарихның гел караңгы яклары гына безнең көннәргә сызылып калмады, хак. Без эгоистлар да түгел, үзебез күргән-кичергәннәр белән берәүне дә әркетергә жыенмыйбыз, Ләкин без кичергәннәр — безнең белән. Баязит абый яшәргә житү өчен безгә тагын утыз ел яшәргә кирәк. Утыз елдан без егерменче гасырның ишеген ябарбыз.

Утыз ел.

Яшь арабыз шактый булса да, Баязит абый белән иңне иңгә куеп эшләдек. Тормыш, яшәү, мәхәббәт һәм нәфрәт хакындагы сүзләребез уртак булды. Димәк, сүз генә түгел, мәхәббәтне-нәфрәтне аклау да уртак булган. Нәфрәт-мәхәббәт теге яки бу буынның монополиясе генә түгел ич, нигә без Рузалия белән уртаклык таба белмәдек икән?

Эстафетаны тапшырырга минем зирәклегем, елгырлыгым, акылым житеп бетмәгән булып чыкты. «Яраттым» дигән сүзне ишетүгә мин бөтенләй шүрләп төштем... Ә үзем төнге поезд киткәнче керфеккә керфек какмадым...

Әгәр Рузалия безнең кырык яшьлекләр белән егерме яшьлекләрне берләштерергә тиешле божра булса?.. Мин аны ычкындырдыммы? Тота алмадыммы? Табигатьнең ышанычын акламадыммы?..

Аның мәхәббәте саф, аның мәхәббәте изге максатына, яхшыга, зурлыкка талпыну гына түгелмени?..

Алайса, икеләнергә һич тә ярамый. Икеләнү шул ук курку ич ул!.. Гайфи янына керергә, Рузалиядән дә качмаска! Саумы, Гайфи! Саумы, Рузалия!.. Әйдәгез бергә! Хәлдән килгәнче, егылганчы бергә!.. Кил, Рузалия, безгә иптәш, юлдаш, ризыкташ бул, инженер-конструктор булам дисең ич, әйдә, киләчәкне бергә бүлешик!

Ишекне миңа Гайфи ачты. Борын астында гына калдырып мыек жибәргән. Ябыккан, болай да арык кешенең яңаклары карындык кебек юкарып, эчкә суырылып кергән. Авызында беләк буе папирос. Куанып кулын сузды.

— Бу синме соң? — диде ул гаҗәпләнеп.

— Танымыйсыңмы?

— Әллә тагын. Үз-үзеңә охшый башлагансың.

— Шаяртасың, кәефең әйбәт дигән сүз.

— Кая ди ул.— Гайфи башын чайкады.— Кәеф яхшыдан түгел!

— Яле, баш бирмә начар кәефкә!

— Син һаман да шул җырны җырлыйсың,— диде ул, миңе кызганып.

— Ашыкма, Гайфи, җырның төрлесен җырлап карадык.

Көлеп куйганмындыр, ахры, Гайфи әлекке күк итеп:

— Нигә көләсең, тиле? — диде.

— Синнән көләм. Дөнья синең талантыңа, көчеңә, эшеңә мохтаж чакта «кәеф начар» дип авыз күтәреп утыр инде.
— Кем мохтаҗ ди, тиле!
— Талантлы кеше син, Гайфи. Кайт институтка.
— Кем алсын мине?
— Мин алам.
Гайфинең болай да нәни башы тагын да кечерәеп калды, күзе шакмакланды.
— Син?!
— Безнең группаны яңадан оештырырга рөхсәт итәләр. Чаллы автозаводы базабыз булачак. Гайшә Хәлиловна кешеләр туплау хокукын миңа бирде. Гали Кадыйров та безгә катнашырга риза. Лотфулланы да чакырабыз. Иөрмәсен йокымсырап.
Ул тәмәкесен атып бәреп нидер эзләнә башлады
— Ни житми сиңа?
— Иөз грамм гына кабарсың инде.
— Ярамый.
— Миңа да ярамый, тиле. Тик шуны әйт, алырлармы мине эшкә? Булган инде ахмак чаклар, искә төшерергә оят.
— Ахмак чаклар күп булды,— дидем мин.
— Алмаслар мине.
— Мә бишне!
Ул минем кулга чытырдап ябышты.
Урамга без икәү чыктык. Гайфинең күңеле нечкәрде, аңа карап мин дулкынландым, тагын кемнәрне үзебезгә алабыз дип фикер уртаклашабыз, куанышабыз...
— Сеңелең Рузалияне дә эшкә җигәргә кирәк!.. Укуын читтән торып укыр.
Гайфи миңа бармак янады:
— Мине дары мичкәсе өстенә утыртырга чамалыйсың инде?..
Менә сиңа мә, иплэп кенә вак яңгыр ява башлаган. Плащ-мазар да алмаган идек, баскыч төбендә ышыкланып торабыз. Яшь ханымнар, буялган яңакларын, каш-күзләрен сумкалары белән юештән саклап, чапы-чапы безнең яннан йөгереп уздылар.
— Ява,— диде Гайфи.— Көз житте, тиле.
Аның тавышында сагыш аһәңе түгел, табигатьнең кодрәте белән мактану ишетелде. Аларның йорт алларына дәү зәңгәр автобус килеп туктады. Автобус ишеге ачылды, эчтән көлгән, чыркылдаган тавышлар килде. Менә жиргә бер кыз сикерде, аның артыннан биш-алтысы берьюлы шыбырдап коелдылар.
— Гайфи абый! — дип кычкырып җибәрде Рузалия. Алдан сикереп төшкән борчаклы яулыклы кыз ул икән.— Сәгыйть абый да монда!..
— Нәрсә кычкырасың, тиле?
— Без Югары Осланга, совхозга алма җыярга китеп барабыз. Барыбер тик утырасың, мин әйтәм, әллә безгә иярәсеңме?
Гайфи миңа карап алды.
— Бар, бар, якшәмбе ич бүген! Туйганчы алма сосып кайтырсың.
— Ә син?
Рузалия әле миңа, әле Гайфигә карый.
— Мин дә барам!
Кызлар, безнең барасыбызны белгәч, куанычларыннан сикерешәләр, көләләр...
Һәм менә без, Гайфи белән икәү, егермеләп кыз арасына утырып, аларның шук тавышларына елмаеп колак сала-сала, совхоз алмасын жыярга китеп барабыз...

1969—1971

## Сибгат Хәким

### Үлгәннәргә хәтта моң кирәк

●

Сезгә эндәшми мин кемгә
Эндәшим, әянкеләр?
Җитте минем дә сезнең күк
Картайдым дияр көннәр.
Кубәйде миндә дә тутлар
Сездәге тутлар кебек,
Ул тутлар учакта сүнеп
Бетмәгән утлар кебек.
Кайда ул биргә шаулаган,
Бергә ашкынган көннәр,
Кимедәге әянкеләр,
Сезгә баш ияр кемнәр?

●

Фермада яз. Туып тора бар да,
Яшәртә яз, язның бер имә.
Телефоннан сөйләшергә кайчак
Вакыт тапмый ферма мөдире.
Тышында яз, ферма эчендә яз,
Менә кайда язын бәйрәмнәр;
Телефонда бәрән тавышлары,
Трубкага керә бәрәннәр.
Тавышлары ачы, склероздан
Чыңлаган күк чыңлый карт башың,
Кинәт алар тынып кала шунда,
Киереп ачкач ферма капкасын.

●

Тугайда көтү. Тугайда
Яшь бер мари — көтүче,
Көтүче бер үк вакытта
Туган якның күкесе.
Ятам, ял итәм, күзәтәм
Болын, зәңгәр күкне дә,

Мари урманы түреннән
Хәбәр салган күкегә
Кайтара җавап көтүче,
Сәлам ягъни күкедән;
Калын мари урманнарын
Мин дә синең күк беләм.
Болында тугай, тугайда
Йөри утлап көтүләр,
Серле урман теле белән
Сөйләшәләр күкеләр.

●

Сугышты... Каты күңелле
Дөнья шактый йомшады,
Немецлар яттан укыйлар
Хәзер безнең Мусаны.
Берлинда февраль, анда да
Бездәге күк кар оча,
Укыйлар, аерым сүзләр тик
Дотлар кебек карыша.
Сүзләрне әйләнеп, читләп
Телемнән алалар күк,
Укыйлар, шигырь юллары
Тегелгән яралар күк...

●

Зур бу дөнья, гаҗәп киң бу дөнья,
Узар әле анда күп давыл,
Һич охшамас ләкин дөм караңгы,
Ташлап чыккан иске йортка ул.
Зур бу дөнья, гаҗәп киң бу дөнья,
Давыл җиңәр көче бар аның,
Сукмакларда һич өзелмәс кеше,
Үлән басмас ишек алларын.
Зур бу дөнья, гаҗәп киң бу дөнья,
Җылы хәбәр китер, хат калдыр,
Өйдән өйгә, илдән илгә ашык,
Соңга калма, ашык, шатландыр.

## Дугадан соң

*Төзәтелгән вариант*

Дугадан соң чирек гасыр. Дуга.
Белгородка кабат кул бирдем,
Тәрәзәмне ачтым, мәңгелек ут
Карап чыкты эчен номерның,
Карап чыкты бөтен почмакларын,
Янәсе кем яши?
Ут: таныйм...
Мин дә таныйм, солдатларның таныш
Йөзен күрдем шушы утта мин.

Чайкала ут, бәргәләнә, сугыла,
Тынып кала кинәт. Җил тына...
Тагын уйный, кисәк-кисәк булып
Солдатларның җаны йолкына.
Кылган уйный утта, сагыш уйный,
Йокы керми, чөнки юк тынгы,
Зур кытыршы теле белән шул ут
Ялап алды бөтен йокымны.
Бүлмәм эче якты, тышта якты,
Син әз генә калкыт башыңны,
Тәрәзәдән суырып алыр төсле
Солдатларым. Харьков таш юлы.
Таң алдында, юл чатында, утта
Күреп алып үзен Исламның,
Кычкырамын соңгы тапкыр шунда:
Очрашмасак, Ислам, исән бул!
Казан егете, Казан ломовое,
Һаман да яшь, яшәр еллары...
Тавышы утны калтыратып чыкты,
Тәрәзәләр минем зыңлады.
Номерда ут, мәңгелек ут, якты,
Утлар белән хәзер очрашам,
Янам бергә, ул солдатлар белән
Янсаң да җәл түгел, ичмасам.

## Карловы Вары шигырьләре

●

Туган җиргә рәхмәт, мәңге рәхмәт,
Ләззәт алдым күпме чишмәдән!
Тагын нинди яңа бер чыганак
Калды икән авыз итмәгән?
Бар Карловы Вары, ләкин ерак,
Юлы авыр... Кирәк чыдамак,
Гете эчкән чыганактан эчәм,
Кайда да бер безнең чыганак.

●

Монда син ят, телсез, өнсез, монда
Бернәрсәгә синең хакың юк,
Сукмак-юллар, таулар Гетеныкы,
Монда Гете итә хакимлек.
Карловы Вары парадныйларыннан
Кыймый атлый безнең аяклар,
Баш өстендә — ишек өсләрендә
Әйтерсең лә сүрә-аятьләр:
«Моннан Гете кереп-чыгып йөргән»,
Уңда, сулда, җирдә, күктә ул...
Вакытлыча түгел, бу якларга,
Бу җиһанга килгән күпкә ул.

•

Тошенмәгән кешеләр арасында,
Еракларда, читтә телемнән,
Мин кирәксез; аерылган да җаным
Туган җирдән — үзенең тәненнән,
Бер бушлыкта эшсез әйләнә күк,
Авырлыгын тоймыйм гәүдәнең!..
Бер ай читтә... Үкси, сыза күңел,
Урын тапмый, шундый бәндәмен.

•

Чех җирендә чехлар, словаклар...
Горурлыктан бәхәс чыкканда:
Сездә Фучик булса, бездә — Җәлил,
Иң зур дәлил — Җәлил чехларга.
Кая гына, нинди төбәкләргә
Барып керми безнең бу җырлар,
Тукайны мин запастарак тотам,
Каплау өчен кирәк козырьлар.

•

Тоям артта бөек Идел барын,
Тоям артта Ватан, чик барын,
Телләреннән Фучик тавышын тыңлап
Арасында йөрим чехларның.
Телләреннән миңа рәхәт, шат тел,
Үзләренә тагы рәхәттер,
Яратамын: горур булсын халык,
Тик булмасын гына тәкәббер.
Азат халык...
Тауларына карыйм,
Күрә алмам килер җәйсез дип.
Кешеләрнең... хәтта тауларның да
Йөзләренә чыккан бәйсезлек.
Файдасы күп кайнар суларының,
Шифасы күп, эчтең — газап юк!
Саулык кирәк, сәламәтлек кирәк,
Барыннан да бигрәк — азатлык!

•

Чикләр аша көнбатышка узам,
Күренешләрнең зурын-вагын да
Терки күңел, төрле халыкларның
Музыкасы яңгырый вагонда.
Тиле уйлар килә шунда башка,
Тәрәзәмне ныклап ябам да
Күзләремне йомам, күзем бәйләп,
Җибәрсәләр мине ялангa,

Табармынмы үз җиремне?
Табам!
Ориентирга оста җайлаштым!
Иделемә мин чыгармын барып
Көй-моңнары буйлап Сәйдәшнең.

●

Урны анык түрдә, югарыда,
Баш иям дә тынам эчемнән,
Зур заллардан орган тавышлары
Ишетелә томан эченнән.
Миңа гармун, гармун җитми читтә,
Юлларыма ятар таң нуры,
Яңгырасын иде Европаның
Уртасында татар гармуны.
Яңгырасын иде бер минутка
Европада «Арча», «Сарман»нар,
Түзмәс, торыр татар егетләре,
Сугышларда башын салганнар.
Түзмәс, торыр татар егетләре,
Аларнымы туфрак, кар каплар!
Ияреләр шул гармунга алар
Германия һәм Польша, Карпаттан...
Күрүгендә «Кара урман» шаулый,
Юллар авыр, юллар бормалы,
Сикәлтәле, үз язмышы кебек
Бу татарның бөтен моңнары.
Азат итә, сугыша, һәлак була
Батырларча типкән мең йөрәк,
Алар һаман шул гармунны сагына,
Үлгәннәргә хәтта моң кирәк.

1971—1972

## Мөдәррис Әгъләмов

### Каурый

Алтын каләм белән язганнар да
Мәңгелеккә җирдә калмыйлар...
Коелган соң нинди канатлардан
Мәңгелек җыр язган каурыйлар?

Ул каурыйны койган каз булган,
Табучылар барыбер аз булган.

### Таулар күп ул...

*Мостай ага Кәримгә*

Азиягә чыгам синең аша,
Европага кайтам синең аша.
Таулар күп ул, аларга да кыен,
Берсе белән берсе тоташмаса.

Җилләр ашый аны, еллар ашый,—
Җир йөзендә ялгыз калу яман.
Күрәсем бар сезнең иранңәрне,
Азиягә таба үтеп барам.

Көтә кебек мине Шәйхзадә,
Юлым илтә сыман Акмуллага.
Өлкәннәргә «ага» диләр бездә —
Хөрмәт сүзе. Гомер дә бит ага.

Кая ага, ничек, кемнәр белән,
Әллә ялгыз барып кушыламы?
Ага, ага, дибез... ага торгач,
Балык була күрмик чит судагы.

Борын-борын заманнардан Шәрык
Россиягә узган Казан аша...
...Таулар күп ул, аларга да кыен,
Берсе белән берсе тоташмаса.

●

Үзәннәрдә чәчәк бәйрәмнәре,
Йөрәгемдә сагыш бәйләмнәре.
Офыклардан ары бу киңлекләр,
Бу киңлекләр — безнең мөмкинлекләр.
Тамырларда яшь кан сулык-сулык,
Күкрәгемдә сәер бер моңсулык.

Аргамаклар кешни каударланып,
Йөгереп чыгам әллә каян танып,
Тыңлап багам... Тояк тавышлары
Тынып калган инде, киткән ары —
Нигә соңга калып сискәндерә
Еллар шаулап узып киткәч кенә.

Кинәт бөтенесен җиргә бәреп,
Соңга калган өчен өзгәләнеп
Каршы алам чәчәк бәйрәмнәрен,
Өзеп ташлыйм сагыш бәйләмнәрен —
Офыклардан ары бу киңлекләр...
Ул киңлекләр — безнең мөмкинлекләр.

## Бар иде заманнар

Бар иде заманнар,
        чыгасың болынга.
Ярсу бар йөрәктә,
        чалгы бар кулыңда.
Бар иде каерып,
        каерып чабулар,
Эш беткәч, кыз-кыркын
        артыннан чабулар.

Төн буе сүнмичә
        яндылар учаклар,
Теләсәң учак бар,
        сөйгәнгә — кочаклар.

Шатланып елады,
        елады бөтнекләр...
Яшьлеген югалтып
        елады бик күпләр.

Өелә өемнәр,
        куела кибәннәр...
Куенда кош кебек
        талпына сөйгәннәр.

Бар иде тартыну,
        картлардан куркулар.
Печәннәр өелде,
        калыкты курпылар.
Ике җан бер булып
        болыннан кайтулар,

Авылның башыннан
башлана, һәй, туйлар!
Егетләр түгел дип
кем безне яманлар,
Калыкты курпылар...
Бар иде заманнар!..

●

Без дигәнчә генә барса икән,
Булса икән без дигәнчә генә,
Тимерченең чүкечедәй, сиңа
Килеп төшә тормыш, яньчә генә —
Барса икән без дигәнчә генә.

Шагыйрь шигырь язып йөрмәс иде,
Зур хирург, табип булыр иде,
Яруын да ярыр, ә кем тегәр?
Яручыны табып булыр иде —
Һәркем шулай табип булыр иде.

Әгәр шулай хөкем итә калсаң,
Юләргә дә мөмкин әйләнергә,
«Ник бу агач кире үсә?» — диеп,
Табигатькә мөмкин бәйләнергә —
Даһига да мөмкин әйләнергә.

Бәлки, әллә кемнәр чит ноктада
Гомерләрен юкка үткәрәдер,
Кычкырырга кирәк, бәлки, аның
Чикләвеге чынлап юкәдәдер —
Ә ул читтән эзләп үткәрәдер.

...Сез дигәнчә генә булса икән,
Барса икән сез дигәнчә генә...
Тимерченең чүкечедәй, бер көн
Килеп төшә вакыт, яньчә генә —
Барысы була ул дигәнчә генә.

## Матчага элгән сиЛә

Әнидән башланып киткән
Туган тел, туган илем —
Халкымда булган сәяхлек
Канымда булса минем,
ул шуңардан...

Буй җитеп, яуларга китеп
Кире кайтмаса бала,
Аналар өйдә, бишекләр
Чормада ятим кала,
чормада...

Законы каты сугышның:
«Матчага бишек асма!»
Өй юган саен бишекне
Юа иде дә Әсма,
уйлана иде:

«Ир-егет өчен ятимлек
Бер килми калмый,
Килә.
Баласыз, ятим калмасын
Аналар гына менә,
аналар гына...»

Ә бүген кышкы бураннар
Котырган чакта шашып,
Бала күтәргән яшь ана
Керде дә тып-тын басып,
керде дә...

Бары тик барыр ягына
Бураннар бүлгән юлын.
Чормадан кузгалдың, бишек,
Беткәндер күптән җылың,
беткәндер...

Оета бугай бишекне
Баланың җылы пары.
Бала йоклаган, тик Әсма
Сизми дә гүя аны,
тирбәтә...

Идел-йорттан Берлингача
Сузылган киңлек, ишет!
Ил исән булса, беркайчан
Чормада ятмас бишек,
ил исән-сау булса!

...Тирбәлә бишек, моңлы җыр,
Моңлы җыр агыла өйгә...
Сыкранып аваз бирә дә
Матчага элгән силә,
тирбәлә.

## Аз да түгел

И фәрештә, мин мөкиббән,
Ымыңны сиздер генә,
Аз да түгел, күп тә түгел,
Бары бер мизгел генә.

Суырып үпсәм дә сулмассың,
Тор разый булып кына...
Аз да түгел, күп тә түгел,
Бары бер минут кына.

Назланулар әүвәлгедән
Калган бер гадәт кенә,
Аз да түгел, күп тә түгел,
Бары бер сәгать кенә.

Әнкәңне кунакка җибәр,
Теләсәң кемгә генә,
Аз да түгел, күп тә түгел,
Бары бер көнгә генә.

Дөнья буйлап җитәкләшеп
Барасы иде менә,
Аз да түгел, күп тә түгел,
Бары бер гомер генә.

## Учак урыннары

Болыннарда калган
Учак урыннары,
Атларымны эзләп
Йөри идем бары...
Учак урыннары,
учак урыннары...

Һәр кишәрлек саен
Алар төрле якта,
Яңа иңеп төшкән
Кабер кебек ята,—
Алар төрле якта,
алар төрле якта...

Болында көз көне
Шул кадәр күп алар,
Сонгми күк алар,
Орадур күк алар,—
Шул кадәр күп алар,
шул кадәр күп алар.

Җир шарына таңгәл
Болын шундый чуар...
Монда синең Болгар,
Монда синең Суар,—
Болын шундый чуар,
болын шундый чуар.

Учак урынына
Тишелмәгән курпы,—
Минем яшь йөрәгем
Урыныннан купты:
Тишелмәгән курпы,
тишелмәгән курпы...

Нәфрәт кисәгедәй
Тешен кыскан кисәү,
Сонгмилар калка,
Калка әллә ничәү —
Тешен кыскан кисәү,
тешен кыскан кисәү...

Көз көне яланда
Учак урыннары,
Атларымны туплап
Йөри идем бары —
Учак урыннары,
учак урыннары...

1970

## Рәисә Ишморатова

# МИЛИЦИЯ ЛЕЙТЕНАНТЫ

ПОВЕСТЬ

### 1



Фәһимәнең йокысы качкан иде. Күзләрен караңгы түшәмгә төбәп, кулын баш астына куйган килеш, энесе Салихны уйлап ятты. Әле кайчан гына энисе итәгенә тагылып йөргән малай бит. Инде менә егет булып килә. Начар да укымый үзе. Тик соңгы вакытта аның әллә нинди малайлар белән дуслашып китүе, бер дә юкка карышып, энисенә хәтта кычкыргалап куюы Фәһимәне борчый иде. «Жиңги боза, жиңги узындыра».— дип уйлады ул һәм, авыр гына бер көрсенеп алгач, икенче ягына әйләнеп ятты. Йокы барыбер кермәде. Инде аның күз алдына Зөлфәт килеп басты. Озын кара керфекләр. Кискен дә, серле дә итеп карый торган акыллы күзләр. Милиция формасы берәүгә дә ул хәтле килешмидер. Икәү генә булганда ул һәрвакыт кызыл читле фуражкасын салып кулына тота да елмаеп кына Фәһимәгә карап тора. Бүген ул моңарчы әйтелмәгән сүз әйтте:

— Әйдә, Фәһимә, язылышыйк...

Фәһимә дәшмәде, аны курку биләп алган иде.

Әгәр тагын уңмаса, тагын аерылырга туры килсә?..

Ул гашыйк булып кияүгә чыкты. Беренче ире Дамир да аңа: «Бик-бик яратам»,— ди торган иде. Ә үзләре өйләнешеп ярты ел да тормадылар, аерылыштылар. Әгәр Зөлфәткә чыгып та шулай булса?

Кайнар күз яше иреннәренә агып төште.

Яшьли ятим калып, ата-ана иркәсеннән мәхрүм үскәнгәме, ул Дамирның иркәләп әйткән һәр сүзенә эреп китә иде. Дамир аңардан биш яшькә олы, ул инде институт тәмамлап эшли башлаган, ә Фәһимә укый гына иде әле. Дамир аны укуы беткән сәгатьләрдә институтка килеп каршы ала, озатып куя... Ай, ул бәхетле минутлар!.. «Кара аны, Фәһимә, берәр егет белән институт ишегеннән чыкканыңны күрсәм, үзеңә үпкәлә»,— ди торган иде. Бу сүзләр Фәһимәгә бик ошый иде. Көнли, димәк, ярата.

Туйны зур итеп уздырдылар. Кунаклар күп булды. Моңа кадәр, әйтик, театрда-мазарда Дамирның эчкәләгәнен белсә дә, Фәһимә аңа сүз әйтми — гомумән, әһәмият бирми иде. Ә менә туй көнне исергәнче эчте Дамир.

— Бәхет, мәхәббәт шәрабен эчәм, дуслар! Мин бәхетле, мин шәһәрдә иң матур кызны алдым. Ул хәзер минеке генә! — дип, әллә нинди сүзләр сөйләп бетерде.

Аһ, уйламаска иде ул көннәрне, онытырга иде барысын да! Тик хәтер дигәнең сине тыңлыймыни? Шул көннәр искә төшкән саен, әрнүдән йөрәк кысыла, күзгә яшь килеп тыгыла...

Беренче төннән соң Дамир, уянып киткәч, ак мендәргә озын кара чәчләрен тузгытып, янында яткан хатынына карады да:

— Үтер, валлаһи, берни хәтерләмим,— диде.— Кайчан яттым соң мин? Син дә, ичмасам, «эчмә» димәгәнсең...

Фәһимә оятыннан бөрешеп калды, күзләрен чытырдатып йомды, иренә җавап кайтармас өчен чәчен йомарлап авызын томалады. Дамир аны кысып кочаклап алды, ләкин бу — наз да түгел, иркә дә түгел, бу — тәташ газап, интегү генә иде: Дамир уйнапмы, чынлапмы, сүзен тагын кабатлады:

— Чынлап та хәтерләмим: минем белән йокладыңмы соң син? — диде.

Ләкин иң коточкычы берничә айдан соң булды. Бер төнне ул Фәһимәне иркәләп, чәчләреннән сыйпый-сыйпый, әкрен генә сорады:

— Фәһимә, әйт әле, назлым: син нимә... миңа кадәр башка егет белән... булмадыңмы?

Фәһимәнең йөрәгенә пычак кададылармыни!

Дамир гафу үтенеп тә карады, уйнап кына әйттем дип юатырга да теләде. Тик Фәһимә мондый кимсетүне күтәрә алмады, кинәт авырып больницага керде. Явыз телләр:

— Матур егет килешмәде кызыйга. Атасыз-анасыз бер ятим шундый шәп егетне эләктерсен әле!..— диделәр.

Биш кенә ай торды Фәһимә Дамир белән. Аз гына да яратмыйча, газапланып торды.

Фәһимә бу хакта бер кешегә дә сөйләмәде: аның, бердәнбер абыйсыннан башка, якын кешесе дә юк иде. Ләкин абыйсына да бу хәлләрне сөйли алмый иде ул. Шулай да бер көнне абыйсы эшли торган җиргә барды да үксеп елап җибәрде.

— Абый бәгырем, кире сезгә кайтыймсана. Яши алмыйм мин ул Дамир белән. Яратмыйм мин аны... Ул матур да, акчасын да күп ала. Нигә аның акчасы, үзе кеше булмагач...

Әниләре, үлгән чакта, Заһитка васыять итеп әйтеп калдырды: «Балакаем, бердәнбер сеңелең Фәһимәне ташлама, тәрбиялә, әнисе-этисе юклыкны, ятимлекне сизмәсен. Укытып, үстереп, адәм рәтле кешегә кияүгә бир, яме»,— диде.

Заһит үтә дә якын итеп сеңелесенең күзләренә карап торды да:

— Үзең хәл ит, туганым. Телисең икән, хәзер үк машина чакыртам да өйгә алып кайтам,— диде.

Шул ук кичне, киемнәрен генә салган чемоданын кулына тотып, Фәһимә абыйлары өенә кайтты, унбиш ел йоклаган караватына капланып, онытылып бер елады да ничектер тынычланып йокыга китте.

Ул йоклады, ә җиңгәсе Мөршидә үзен-үзе кая куярга белмәде:

— Үләм, билләһи, үләм! Хурлыгымнан кая барыйм? Уңган-булган нинди егетне ташлап кайтты бит...

Уйлар шул урында бүленде: коридордан ишек ачылганы ишетелде. Фәһимә урыныннан сикереп торды да коридорга чыкты. Салих аңа бармак селекте. Дәшмә, янәсе, әниләрне уятасың. Тик өйдә әле берәү дә йокламаган иде, шунда ук Салихның әнисе Мөршидә килеп чыкты.

— Кайда йөрдең, малай актыгы, ә? Кара инде син аны, сәгать бер тулган бит! — дип тавыш куптарды.

Салих, берни дә әйтми, ваннага кереп китте. Аның йөзе ап-ак, куллары калтырый иде. Ул үзенең бу хәлен әнисенә сиздермәс өчен краннан су агызып, битен юа башлады. Аның артыннан ук әнисе килеп керде.

— Әллә эчкән дә инде? Эчкән шул, эчкән! Кара инде син аны, уналты яшьлек малай, тугызынчы класс укучысы, эчеп кайткан! — Ул улының битенә чалтыратып сугып җибәрде.— Әйт, кайда булдың? Әйт, адәм актыгы!

Озын таза гәүдәсен туры гына тотып, Заһит та килеп чыкты. Ул ваннадагы хәлгә бераз карап торды да тыныч тавыш белән:

— Ягез әле, барыгыз да урыннарыгызга кереп ятыгыз. Төн уртасында нинди тавыш ди ул? Күршеләрдән яхшы түгел: беләсез бит, стена аша сулаган да ишетелеп тора. Ә Салих белән иртәгә сөйләшербез.— диде. Хатынын култыклап, йокы бүлмәсенә алып кереп китте. Фәһимә дә, бераз энесенә карап торгач, түзә алмады:

— Буш баш та инде син, Салих, ә! Төннәр буе йөргәнче — китап карар идең, ичмасам! Уку башланырга бер генә атна калып бара, әле синең китапларың да җитеп бетми.— диде.

— Җиткән, бар да җиткән.—диде Салих, Фәһимәгә кулын селтәп.— Бар, әнә, бүлмәңә кер дә йокы симерт. Синең шикелле тол калгач, мин дә өйдә генә утырырмын.

## 2

Лейтенант Шәкүров төнге унбердә участогын әйләнеп кайтты. Бүгенгә ул-бу юк. Шөкер. Ялгызлыктан файдаланып, өстәл лампасы яктысында эшләнеп бетмәгән документларын күздән кичерә башлады. Күңеле тыныч иде. Ләкин озак та үтмәде, чырае качкан кыз җитәкләп килеп кергән милиция лейтенантын күргәч, ялт итеп аягүрә басты, йөзе капыл үзгәреп китте: димәк, алар участогында ниндидер бер күңелсез хәл булган.

Лейтенант Мәрдәнов аңа берничә сүз белән генә вакыйганы аңлатып бирде.

Унбиш яшьлек Гөлинә Галләмова иптәш кызларына телевизор карарга барган. Мавыгып, вакытның соң икәнен онытып җибәргән. Аны ике квартал узганчы иптәш кызы озата килгән. Үзе генә калгач, кемдер артыннан килеп кочаклаган да авызын томалаган. Якындагы капка эченә өстери башлаганнар. Шуннан башка берниндн сорауга да җавап бирәсе килмәде кызның. Тик башының бик нык авырта башлавын һәм Зөлфәттән тизрәк өйгә озатып куюын гына үтенде...

Шәкүров, телефонны алып, уголовный розыск инспекторын чакырды.

Участок ишеге төбенә выжылдап милиция машинасы килеп туктады. Һәм алар, бүлекчәдән килүче оператив группа кешеләре белән, вакыйга булган җиргә киттеләр. Таң атканчы әйләнә-тирәне тикшереп чыктылар. Шул тирәдә яшәүче кешеләр белән сөйләштеләр, ләкин күңел тынычланырлык өмет күренмәде: җинаятьчеләр суга баткандай юкка чыккан иде.

## 3

Фәһимә соң гына торды. Өйдәгеләр инде чәй эчеп, һәркем үз эшенә тотынган. Җиңгәсе кухняда савыт-саба юып йөри, ә абыйсы түр диванга арка терәп утырган да, каршысына бастырып, Салихны тирги иде.

— Нигә теленне йоттың, ә? Кичә бик гайрәтле идең бит, я, кайда булдың, кемнәр белән йөрдең?..

Салих әйтерсең лә аның сүзләрен ишетми, башын игән дә сүзсез калган. Уналты яшенә җитеп, әнисенең аңа сукканы юк иде. Бүген беренче мәртәбә яңагына сукты, әтисе беренче мәртәбә алдына бастырып допрос ала. Оят та, хурлык та. Аның колагы уттай яна, чалбар кесәсенә тыккан куллары калтырый.

— Әти алдында ничек торасың, ә? Ал кулыңны тиз генә! Инде җавап бир!..

Юк, әтисенә җавап бирми котылып булмаячак. Тик нәрсә дияргә? Әйе, иң яхшысы — дөресен сөйләргә, киңәш сорарга... Ул, әтисенең күзләренә туры карый алмыйча:

— Ну, Тәлгат белән, Галим белән булдым,— диде.

— Тәлгатен беләм, ә Галиме кем?..

— Ну...

— «Ну»сыз гына сөйлә!

— Заводта эшли, слесарь.

— Кайсы заводта, фамилиясе кем?

— Заводын да, фамилиясен дә белмим. Исеме Галим.

Заһит диваннан сикереп торып, Салихның борын төбендә бармак уйнатып алды.

— Әгәр дә син моннан ары да фамилиясез малайлар белән йөреп, өйгә аз гына да эчеп кайтсаң, мин сине утлы табага бастырырмын. Бел аны!

Ул бераз тынычланырга теләп, тәрәзә янына килеп басты, тәмәке кабызды. Ул, ата буларак, улы белән башта ирләрчә сабыр гына сөйләшеп утырырга, соңгы көннәрдә улының холкында һәм үз-үзен тотышында булган үзгәрешләрнең сәбәбенә төшенергә ниятләгән иде. күңеленнән хәтта үтемле генә сүзләр дә әзерләп куйган иде. Ләкин улының үзе каршында кулын кесәсенә тыгып, салынкы гына карап торуына йөрәге түзмәде — ачуы өскә бәреп чыкты. Ул суырылып бетмәгән тәмәке төпчеген тәрәзә төбендәге гөл төбенә төртте дә, яңадан улына борылып:

— Хәзергә шул: өйдә утырасың. Беркая да чыкмыйсың! — диде.— Аннары хатынына дәште: — Ишеттеңме, Мөршидә? Кара аны, өч көн беркая да чыгарасы булма!

Салих җинел сулап куйды: димәк, шуның белән җил-давыл узып китте.

Кулын сөртә-сөртә әнисе кухня яктан килеп керде. Ул инде барысын да: кичә кызулыгы белән улының яңагына сугуын да, төне буе газапланып, йоклый алмый ятуын да оныткан иде. «Нинди сылу булып үсеп җитте бит, балакаем!» дип, улының сузылып үсеп килгән буена, дулкынланып торган кара чәчләренә сокланып карап торды да йомшак кына итеп аркасыннан этәрде:

— Бар, гафу үтен. Әтием, моннан соң беркайчан да сезнең рөхсәтегездән башка йөрмәм, соңгысы булыр, диген...

Салих әнисенә үпкәләп карап алды да, әтисе кереп киткән бүлмә ишек төбенә килеп:

— Ну, әти... гафу ит мине. Ну... моннан соң, мин соңга калып кайтмам,— диде. Борылып, Фәһимәгә телен күрсәтте дә, шкафтан калын гына бер китап алып, аякларын бөкләп диванга утырды.

Мөршидә кухняга чыгып, һәр ялдагыча, көндезге ашны пешерә башлады. Фәһимә идәннәрне юып чыгарды. Ләкин барыбер кичә кузгалган күңелен тынычландыра алмады. Зөлфәт бүген аңардан җавап көтә. Ни кылырга, ни җавап бирергә? Абыйсы риза да булсын ди. Әмма җингәсе риза булмаячак. Әллә аның ризалыгын сорап та тормаскамы? Юк, җиңгәсе чын күңеленнән Фәһимәгә бәхет тели бит. Аның

ризалыгыннан башка килешми... Ул, эшләре беткәч, кыяр-кыймас кына жингәсенең жилкәсеннән кочып алды да:

— Жиңги, әйдә әле, бүлмәгә керик әле, сүзем бар,— диде.

Мөршидә аның күзләренә сыный төшеп карады. Бик чәчрәп китмичә генә, Фәһимә артыннан бүлмәсенә кереп, урындыкка утырды.

— Милиционерың турында булса, жанкисәгем, баштан ук әйтәм: тыңламыйм да, сөйләмә дә.

— Жиңги,— диде Фәһимә, ялварып,— тыңла инде сүземне, селтәмә кулларыңны. Син бит минем әнием урынына калган кеше. Син дә киңәш бирмәгәч, кемнән сорыйм, кем белән сөйләшим?! Жиңги, мин Зөлфәтне яратам...

— Куй, ишетәсем дә килми шуны.

— Жиңги жаным, аңла: аның күңеле матур.

— Ачып карадыңмы әллә? Үзең дә инде — тапкансың, билләһи! Шул матурлыгың, шул укымышың белән, адәм көлкесе! Егет булуына кызыктыңмы әллә? Син үзең дә кызларга биргесез. Мин сиңа үзем менә дигән доктор белән таныштырам. Үзе тол, үзе бала-чагасыз...

— Кирәкми миңа доктор. Мин Зөлфәтне яратам.

— Алайса, үзеңә кара! — диде Мөршидә, урыныннан торып.— Абыең белән киңәш. Ә мин — каршы. Минем рөхсәтемнән башка чыгасың икән, туеңа да бармыйм, өеңә дә аяк атлап кермим.

— Жиңги, син ни сөйлисең? — дип кычкырып жибәргәнен сизми дә калды Фәһимә.

Ишектән Заһит башы күренде.

— Нәрсә бар монда? Нигә кычкырышасыз? Инде сезне яңакларга кирәкме? Бүген ял көне, берәр яры йөрергә чыгып керербезме дисәм — монда күз яше, нервы...

— Сөйләш әнә сеңелең белән,— диде Мөршидә.— Милиционерга кияүгә чыгам, ди. Мин риза түгел, дим.

— Ник?

— Мин бит аның бәхетле булуын телим. Ирдән иргә йөрү һөнәрмени ул?..— диде Мөршидә һәм сулкылдап елап та жибәрде.— Берсеннән кайт, икенчесеннән кайт. Кеше ни әйтер? Жиңги тәрбиясе, абый тәрбиясе шулай инде ул, диярләрме?

— Тукта әле, Мөршидә, нигә син алай Фәһимәне, кияүгә чыкмас борын, аера да башладың? Кайдан килә мондый начар уй синең башыңа? — Аның йөзе бер агарды, бер кызарды.— Нигә әле син тумаган тананың тиресен туныйсың?

Телефон шалтырады. Кечкенә генә бүлмәдә өч кеше. Телефон трубкасын берсе дә алырга кыймады. Ләкин телефон, аларның өйдә булуларын белеп, бертуктаусыз шалтырый бирде. Ахырда Фәһимә аңга килеп, йөгереп барып трубканы алды. Телефонда Зөлфәт Мәрдәнов иде.

## 4

Зөлфәт эштән соң, сөйләшкәнчә, туп-туры бакчага китте. Ашыга-ашыга барды. Күңеле тыныч түгел, йөрәге ашкынып тибә иде. Нинди жавап алып килер икән Фәһимә?.. Кире какса, әнигә ни диярмен? Мине тиң күрмәде, кимсенде диярменме? Әни дә: «Әйттем бит!» — диячәк...

Зөлфәт бакча читендәге ялгыз эскәмиягә килеп утырды. Озак утырды. Инде өметен өзә башлаганда, бакча капкасыннан кызу-кызу атлап кереп килгән хатын-кызны күрде. Зөлфәт аяк өсте басты.

Фәһимә аңардан бер-ике адым арырак туктады. Аның жавабы әзер иде. Ләкин ничек итеп Зөлфәтне рәнжетми генә әйтергә соң?.. Ул

бармакларын авырткапчы кысты, чәчен рәтләгәндәй итеп, башын иеп уйланып калды. Тукта, андый җавап бирергә аның ни хакы бар? Җиңгәсе рөхсәт итмәгән өчен генә, Зөлфәтнең милициядә эшләгәне өчен генә мәхәббәтеннән ваз кичәргә тиешмени ул?.. Юк, юк! Тагын бер уйларга кирәк. Җиде кат үлчә, бер тапкыр кис, дигәннәр.

— Беләсеңме, Зөлфәт...

Зөлфәт аңа төбәлде. Йөрәге кысылып килде. Фәһимәнең үз тавышы түгел иде бу — ят тавыш иде. Менә ул хәзер аның йөзенә бәреп... юк, бәрмәс, җайлап-көйләп кенә әйтер. Кавышмыйк, дияр. Инде ничә ай буена зарыгып көткән сүзне бүген, ә бәлки мәңге ишетә алмас күк тоелды аңа. Ул Фәһимәдән күзен алмый көтте. Озын кара керфекләре арасыннан очкын сибеп, елмаеп карый торган зур коңгырт күзләре бүген боек иде аның.

— Беләсеңме, Зөлфәт...

Нәкъ шул вакыт болар янышнан шаулаша-шаулаша бер төркем яшьләр узып китте. Алар арасында Салих та бар иде. Фәһимә аны күрү белән урыныннан ук сикереп торды.

— Салих! Кил әле монда.

Салих, иптәшләреннән аерылып, теләр-теләмәс кенә апасы янына килде.

— Нәрсә?

— Кая барасың әле болай? — диде Фәһимә.

— Өйгә кайтам,— диде Салих, апасы янында басып торган Зөлфәткә текәп кенә карап алды.

— Әле кайда булдың?

— Су кердек. Көймәдә йөрдек.

Фәһимә гаҗәпләнеп башын селкеде, шелтә белән энесенә карады да, кулыннан тотып, бер читкәрәк алып китте.

— Иртә белән әтиең сиңа нәрсә диде? Кем рөхсәте белән өйдән чыктың? Әтиеңнән рөхсәт сорадыңмыни?

— Әни җибәрде лә мине. «Әтиең кайтканчы өйдә бул», диде.— Аннан бераз Фәһимәгә елмаеп карап торды да, күзен кысып, Зөлфәткә ымлады: — Шулмыни инде теге, әни яратмый торган милиционерың?

— Бар, тизрәк өйгә кайт...

Салих калынаеп килгән тавыш белән:

— Малайлар, көтегез мине! — диде дә иптәшләре артыннан йөгерде.

Зөлфәт сискәнеп китте. Ирексездән Салих киткән якка бер-ике адым атлап куйды.

— Зөлфәт, ни булды сиңа? — Фәһимә аның кулыннан алды.— Ник кинәт дулкынландың?

— Юк, Фәһимә, болай гына...— Зөлфәт яңагын сыйпап торды.— Кинәт тешем сулкып китте.

— Әйдә, бераз йөреп килик,— диде аңа Фәһимә.— Йөрегәч, бәлки, басылыр.

— Әйдә, алайса...— Ул Фәһимәне култыклап алды. Алар әкрен генә бакча буйлап йөрделәр. Зөлфәтнең уйларын кичәге вакыйга биләп алды: таныш тавыш... Кичә шул бит: «Йөгерегез!» — дип кычкырды.— Шул үзе, шул...

Фәһимә аның кинәт сүзсез калуын аңлап җиткерә алмыйча:

— Ярый, Зөлфәт, мин кайтыйм инде, суыта да башлады,— диде.

Башка чак булса, Зөлфәт аны, тагын бераз гына торыйк инде дип, туктатып та калган булыр иде, ләкин бүген каршы килмәде. Фәһимә белән барыбер рәтле-башлы сөйләшә алмаячак иде. Ул аңа иркәләп карады да:

— Алайса, сөйләшүне иртәгә калдырыйк, яме? Нәкъ шушы урында, шушы ук сәгатьтә. Вәгъдәме?..— диде.

— Вәгъдә,— диде Фәһимә сүлпән генә.

Зөлфәт аның инбашыннан йомшак кына итеп кочып алды да, нәрсәдер әйтергә теләп, авызын ачты. Ләкин әйтергә теләгән бик изге, бик кыйммәтле сүзләрен әйтә алмады. Капма-каршы ике уй,— берсе кичәге җинаять, икенчесе мәхәббәт,— икесе бергә, бер минутта аның башына төшеп, бер-берсенә юл куймадылар. Икесе дә бик мөһим иде, берсе аның хезмәте, икенчесе — киләчәк тормышы... Ул тизрәк Фәһимәне озатып куярга да, таркалган уйларын туплап, тиз генә бер чара күрергә ашыкты.

Гадәтенчә, Фәһимәне өйләренә кадәр озатып куйды.

— Менә килеп тә җиттек, сине көтәләрдер инде. Энегез кайтып: «Апаны бер милиционер белән күрдем», дигәндер инде.

— Кайтмагандыр әле ул.

— Нишләп? Әллә соңлап йөри торган гадәте дә бармы?

— Төрлечә була. Егет кисәге бит.

— Ничәнче класста укый әле ул?

— Быел унынчы класста укыячак.

— У, егет икән шул!..

Ул башкача сорашмады, артык кызыксынуын сиздерүнең кирәге юк иде.

Зөлфәт участогына кайтып, үз бүлмәсенә керде дә, өстәл лампасын кабызып, урындыгына килеп утырды һәм, гадәтенчә, иягенә таянып, кичәге хәлне башыннан азагына хәтле күз алдына китерде. Колак төбендә генә «Йөгерегез!» дигән тавыш тора иде. Әйе, «Йөгерегез» дип кычкырды да үзе капкага кереп китте. Бөе шул. Өстенә нәрсә кигән иде соң әле ул? Тавышы да шул... Ләкин ничек итеп тыныч кына тикшерергә? Әгәр, белер-белмәс көе, энееннән шикләнүемне Фәһимә сизенсә,— бетте, урамнарыннан да узма! Ул әле хәзер дә сизенде булса кирәк: сүзне кайту ягына борды. Нишләргә? Ул, торып, бүлмә буйлап йөренә башлады. Озак кына тәрәзәдән карап торды. Кичә, йокламаганлыктан, башы авырайган, фикерләрен туплый алыр хәлдә түгел иде.

РӘИСӘ ИШМОРАТОВА ◆ МИЛИЦИЯ ЛЕЙТЕНАНТЫ ◆

5

Маһруй әби көч-хәл белән өйләренә кайтып керде дә, шәлен дә салмыйча, диванга килеп утырды. Бик кыенлык белән генә читеген салып, аягын диванга ук күтәреп куйды.

— Әй авыр да соң бу картлык көннәре,— дип үз-үзенә сөйләнә башлады.— Күр инде, һич көтмәгәндә, нинди хәлләр килеп чыкты бит. Көненә ничә мәртәбә менеп-төшеп йөрим лабаса шул дүртенче катларга. И раббем, киленнең саулыгын бир, ходаем! Ул сау чакта оҗмахта яшим икән, оҗмахта. Бар да әзер — пешкән дә төшкән...

Улы Арслан бер генә атна элек Кырымга ялга китте. Килене: «Үз бакчабыз бар, ел саен курортларда акча туздырып йөреп булмас, без монда улым, кайнанам белән бакчада гына ял итәрбез» дип калган иде дә, булмады. Арсланы китеп өч көн дә үтмәде, аягын сындырып больницага керде. Менә шулай Маһруй әби килененә ашарга илтергә дип больницага барган җиреннән арып-талып кайтып кергән иде.

Каты итеп шалтыраган телефон тавышы аны сискәндереп җибәрде. Ул, үзенчә җәһәт кенә торырга теләп, «хәзер, хәзер, барам» дип, диваннан кузгалганчы телефон шалтыравыннан туктады. Әби трубканы колагына куеп, «әллү, әллү» дип эндәшкәләде дә, «ярар, кирәгем булса, тагын шалтыратырсың әле», дип, кухняга кереп чәй куярга җыенды. Телефон тагын шалтырады. «Хәзер, хәзер, әлми тор!..»

Ул тагын кабаланып трубканы алды, тагын бераү дә эндәшмәде. Әби трубканы элгәч, тиз-тиз генә чәй кайнатып, җиләкләп, вареньелап кына чәй эчәргә утырган иде, ишектәге звонок зыңлап шалтырап куйды.

«Әй, рәхмәт төшкере, кем дә булса бер бәхетле тамагы килә, бигрәк мактап йөри икән»,— дип, ишекне барып ачты. Анда муеннарына тимер-томыр аскан яшь кенә ике егет басып тора иде.

— Исәнмесез, әби. Кирәргә ярыймы? Без телефон станциясеннән, телефоныгызны тикшерәбез.

— Керегез, улым, керегез. Әй, рәхмәт төшкерләре! Әллә нәрсә булган телефунга, үзе шалтырый, үзе сөйләшми. Күрәсең, ватылгандыр. Әнә, карагыз, тикшерегез үзен, узыгыз түр якка.

Егетләр ишек төбендә аякларын һәйбәтләп сөрттеләр дә түргә уздылар, җәһәт кенә аппаратны сүтеп ташладылар, аннары: «Станция, станция! Мине ишетәсезме? Әйе, тикшердек, булды, төзәттек. Отлично эшли. Да, да!..» — диештеләр дә чыгарга ишек төбенә килделәр.

— Булды, әби. Телефоныгыз отлично эшли хәзер, төзәттек! — диде берсе. Аннан бүлмәгә күз йөртеп алды.— Әллә, әби, бер үзең генә шундый зур квартирада торасың инде?

Әби тезепме тезеп китте. Улының курсртта, килененең булнистә, оныгы Тәлгатнең Казанка буендагы бакчаларында кунып-төнеп ятуын сөйләп бирде. Егетләргә савыт тутырып алма китерде. Кесәләренә кәнбагыш салды. Аркаларыннан сөя-сөя, мең төрле матур теләкләр телители, ишектән озатып калды.

Ләкин әби сервант өстендәге вазадан ике егерме бишлекне шушы ике чибәр егетнең алып китүен белмәде.

Бер сәгатьлек киңәшмәдә башлыкларының яңа күрсәтмәләре, планнары белән танышканнан соң, Зөлфәт Мәрдәнов үз участогына юл тотты. Салих белән сөйләшергә, малайның кылын тартып карарга кирәк. Әллә башта Фәһимәдән сорашыргамы? Андый уйны башына да кертергә куркып, эченнән һаман «юк, моның булуы мөмкин түгел» дип кабатласа да, шикләнүдән арына алмады. Нигә соң әле ул бу хакта Шәкүров белән сөйләшми? Шәкүров Фәһимәләр гаиләсен яхшы белә ич. Фәһимә белән Зөлфәт арасындагы дуслыкны да белә. Аннары ул Мәрдәновтан өлкәнрәк, тәҗрибәсе дә күбрәк. Әйе, хәзер үк аны күреп сөйләшергә кирәк.

Мәрдәнов адымын кызулатып Шәкүров участогы ягына бара торган автобус тукталышына китте.

Биш катлы йорттан берсе кулына кечкенә чемодан, икенчесе муенына телефон чыбыклары ураган ике егет ашыгып килеп чыктылар. Каршыларына очраган бер хатынга бәрелеп, кулындагы сумкасын чак төшермичә, кире якка китеп бардылар. Зөлфәт тукталып калды.

«Нигә шул кадәр ашыга бу егетләр, ханым кешене бәреп ега яздылар, гафу да үтенүне кирәк тапмадылар. Кайсы телефон станциясендә шундый тәртипсез кешеләр эшли икән?»

Егетләр бик тиз күздән югалды. Шулай да чандыр гәүдәле, чәчен «подгоршок» алдырган кечерәк башлысын Зөлфәт хәтерләп калырга өлгерде.

Ул егетләр чыккан егерме икенче йорт янына килде. Бу йорт аның участогына керә иде. Монда торучы һәрбер семьяны яхшы белә ул. Эче пошып китте аның: әллә нинди сизенү, шикләнү туды күңелендә. Кемнәрдә телефон? Барлыгы җиде. Әһә! Бу подъездда инженер Бадамшиннарда гына бар. Ул үзе ялда, хатыны больницада, әби бер үзе... Лейтенант Мәрдәнов ике атлыйсын бер атлап, дүртенче катка менеп китте.

Мәһруй әби авызына китергән чынаягын кире куеп, аксый-аксый ишекне килеп ачты. Зөлфәтне күргәч, шатлыгыннан нишләргә дә белмәде.

— Әйдүк, улым, әйдүк, күптән күргәнем дә юк үзеңне! Әйдә уз,

утыр, бер үзем күңелсезләнеп чәй эчеп утыра идем әле. Ни хәлләрдә яшисен?

— Әкрен генә яшәп ятабыз, әбкәй. Тиз генә телефон шалтыратырга кирәк иде дә, менә кердем инде сезне борчып...

— Шалтырат, шалтырат, улым. Әле яңа гына төзәтеп чыгып киттеләр. Ике егет килгән иде, минут эчендә телефон эшли башлады.

Зөлфәт телефоннан номер җыйнады.

— Ислам абый, синме бу? Китми тор әле, яме. Хәзер мин синең янга барам.— Ул трубканы куймый гына тагын номер җыйнады. Ремонт бюросыннан нинди заказ белән ... телефон төзәтергә җибәрүләрен сораштырды. Ремонт бюросыннан бүген андый заказ булганы юк, дип җавап бирделәр. Зөлфәт трубканы кулына тоткан килеш бераз уйланып торды да, Маһруй әбине хәвеф-хафага төшермәс өчен, аңардан артык берни дә сораштырмыйча, әби ясап куйган бер чынаяк чәйне эчеп, тыныч кына саубуллашып чыгып китте. Подъезд төбендә тукталып, телефонлы бүтән квартираларны да исенә төшереп чыкты. Бәлки әле, аларга да кергәннәрдер?..

Тиктомалдан гына берәр квартирга килеп керү Зөлфәт өчен дә, өй хуҗалары өчен дә көтелмәгән хәл түгел иде. Бу участокта ике ел эшләү дәверендә ул үн меңгә якын кешене белеп бетерә язган иде. Ул аларның хәл-әхвәлләре белән кызыксынып тора, кайвакыт өйләренә дә кереп чыккалый. Кешеләр дә аны ихтирам итә. Өйләрен бикләп курортка-мазарга киткән чакларында аңа әйтеп китүне тиеш табалар. Хәзер дә аның берничә минут эчендә җиде квартирга сугылып чыгуы бер дә гаҗәп тоелмады. Ул кайберләренә кереп телефоннан шалтыратты, кайберләреннән әлеге егетләрне сораштырды. Егетләр башка квартирларга кермәгән иде.

Шәкүров участогына барып кергәндә, Ислам бер ир кеше белән сөйләшеп утыра иде. Ул ым белән генә Зөлфәтнең утыруын үтенде.

— Менә шул, туганкай,— диде Шәкүров янына килгән ир кеше, Зөлфәткә игътибар да итмичә.— Озын сүзнең кыскасы, табып бирегез миңа ул сволочьларны! Җитәр, ике көн үзды! Сез монда булмәгездә тыныч кына утырган арада, алар инде тагын берәр кызга бәйләнеп өлгергәннәрдер. Кызым-бичарам, ике көн инде, урамга чыгу түгел, тәрәзәдән карарга да курка. Гомерлеккә шулай нервный булып калса?..

— Гаеп үзегездә дә бар, абзый кеше,— диде Шәкүров.— Унбиш яшьлек кыз баланы нигә сез төнге уникегә кадәр йөртәсез? Укучы балага режим кирәклекне белмисезмени? Ул сәгать унда өйдә булырга тиеш...

— Аклану эзләмәгез, лейтенант,— дип, әлеге ир тагын кызып китте.— Каян чыккан ул закон? Төнге уннан соң өйдән чыкма, имеш. Ниндидер паразитлардан куркып, барасы җиреңә барма, имеш. Баланың каникулы, рәхәтләнеп йөреп калсын. Менә уку башлангач, кусаң да, өйдән чыгарып булмый аларны. Үзебезнең телевизор ватылган чакка туры килүен дә әйт син аның! Ә шимбә көнне, яхшы тапшыру була дип, кызы да буынга төште. Төпчек бит, каршы килмәдек. Аны кем шулай соң кайтыр дип уйлаган...— Ул бик авырлык белән генә кузгалды. Зөлфәт аның бер аягында протез икәнен шәйләп алды да, ярдәм итмәкче булып, урыныннан торды.

— Зарар юк, үзем дә ярыйсы кыймылдыйм әле мин,— диде ир.— Озак утырып торсам гына оеша башлый.— Аннары кесәсеннән папирос алып кабызды.— Сволочьлар, күрсеннәр иде алар без күргән нужа-хәсрәтләрне! Шулар дөньяда рәхәт яшәсен, укысын, рәхәтләнеп үз җиребездә йөрсен дип, унтугыз яшемдә аяксыз калдым мин. Ә алар синең газиз баланны мыскыл итмәкче... Тоткач та миңа хәбәр итегез, барып бик каты итеп битләренә төкерәм, шунсыз җаным тынычланмаячак.

Ул, аягы белән дә, таягы белән дә шак-шок басып, ишек катына килде, сау булыгыз дип тә әйтмичә чыгып китте.

Милиция лейтенантлары — Мәрдәнов белән Шәкүров беравык сүзсез утырдылар. Шәкүровның бит урталары кызарып, маңгаена тир бәреп чыккан иде.

— Суга баттылармыни! Эзләренә һич төшеп булмый. Ике тәүлек узды бит инде...

— Ислам абый, минем сиңа бер киңәшем бар.

Шәкүров өстәл кырыена төшеп калган тәмәке көлен кәгазь кисәге белән себереп алды да, тәрәзә янына барып, форточканы ачты.

— Тыңлыйм, Мәрдәнов.

Зөлфәт әлеге ир сүзләреннән бик дулкынланып, тагы да борчыла төшкән иде. Калтырар дәрәҗәгә җитеп, Шәкүровка Фәһимә энесе Салихтан шикләнүен сөйләп бирде. Шәкүров кинәт тынып калып, өстәле янына барып утырды. Аның юантык гәүдәсе кечерәеп киткәндәй булды, әле яше кырыкка да җитмәгән булуына карамастан, чаллана башлаган кара чәчләрен сыпыргалап алды да, Зөлфәтнең йөзенә күтәрелеп карамыйча гына, бераз үпкә катыш тавыш белән әйтте:

— Ялгышасың, Зөлфәт, бик нык ялгышасың! Мин ул семьяны синнән әйбәтрәк беләм. Ә син Фәһимәне генә беләсең, синең әле бер кайчан да аларда булганың юк, Заһит абый белән сөйләшеп утырганың юк. Киңәш итеп әйтәм: тиз көндә үзләренә кереп, Заһит абый белән таныш. Ул үз гомерендә беркемгә начарлык эшләмәгән, кешегә һаман яхшылык кына теләгән, кешеләрнең әйбәт яшәвенә ихлас шатлана торган кеше. Чын мәгънәсендә коммунист ул. Җитмәсә тагын, булачак хатыныңның абыйсы. Ташла юк-бар уеңны... Бу — минем участок, һәм мин әйтәм: ул семьяда җинаятьче үсүне мин башыма да китерә алмыйм.

— Тәмам аптырадым инде,— диде Мәрдәнов.— Әллә кичтән ишетелгән тавыш шулай колакта яңгырап калган, хәтерләтә бит шуны. Ул малайның: «Туктагыз, мине көтеп торыгыз» диюе булды, бөтен тәнемне электр тогы суктымыни!..

Ислам Шәкүров, тагын урыныннан торып, гадәтенчә, кызу-кызу йөренеп алды.

— Әгәр чыннан да син уйлаганча булса, Зөлфәт, эшләр харап. Мин ничәмә еллар юкны бушка аударып йөргән булып чыгам.

Лейтенант Шәкүров хезмәттәше Мәрдәновның үз эшенә һәрвакыт житди һәм зур җаваплылык белән караганын яхшы белә, шул ук вакытта ул аның искиткеч кешелеклелеге белән тыныч холкын да күреп тора иде. Фәһимәсе өчен утка-суга ташланырга әзер йөргән бер вакытта, аның туганына үзе ышанмаган яланы ягу түгел, гаепләре күренеп торган кешеләр белән дә ул иплән кенә, такт белән генә эш итәргә тырыша иде. Шуның өчен Шәкүров иптәшенең шикләнүләрен игътибарсыз калдырмады. Алар озак кына сөйләшеп-киңәшеп утырдылар да, икесе бер фикергә килеп, конкрет план корып аерылыштылар. Алар моңарчы, гадәттә, һәр көн иртән район милиция идарәсендә генә күрешә торган булсалар, моннан ары, бу җинаятьнең очына чыкканчы, бергә эшләргә булдылар.

Инде төш вакыты да узып бара иде. Зөлфәт кайсы ашханәгә керим дип уйларга да өлгермәде, Фәһимәнең тагын егерме минуттан көндезге аш сәгате бетүен исенә төшереп, аңа шалтыратырга дип үз участогына ашыкты.

## 6

Фәһимә беренче каттагы кечкенә лабораториягә керде дә ишеген бикләп үк куйды. Монда көн буе рәхәтләнеп эшләргә була: тыныч та, салкынча да. Аның хәзер эшенең иң күп, иң җаваплы көннәре — ми-

нимумнарын тапшырып, диссертациясен яза торган чак. Эш күп, ләкин ул шул кадәр дәртләнеп, бирелеп эшли. Мондый минутларда ул арунын нәрсә икәнен дә белми. Төрле төстәге сыекчалар тулган мензуркалардагы анализларны, үзе тапкан химик составларны журналга язып утырган чаклардан да бәхетле минутлар юктыр, мөгаен. Әле бала чакта, җиде классны тәмамламас борын ук, фармацевтлар техникумына керәм, дип нинди өзгәләнде бит ул. Төрле авыруларны дәвалый торган даруларны үз кулың белән ясау иң җаваплы, иң кызыклы эш булып күренә иде аңа. Ләкин җиңгәсе авызын да ачтырмады.— Әнкәйнең васыяте шулай, сине югары белем алганчы укытырга кушты.

Белем алырга сәләте дә, теләге дә зур булган Фәһимә карышып тормады, укыды. Химия-технология институтын тәмамлагач, аны зур бер завод каршындагы лабораториягә эшкә калдырдылар.

Фәһимә урындыкка утырган килеш, башын артка ташлап, уйга калды.

— Их, тыныч кына, бер нәрсә өчен дә борчылмый гына эшлисе иде. Ун сәгать, унбиш сәгать буена лабораториядән чыкмый эшләргә дә риза ул. Тик менә эчен пошыра, йөрәген әрнетә торган сүзләр ишетү күңелен төшерә, кәефен ала аның.

«Әй, Салих энекәем... Тол хатын дип үртисең. Мин аны үзем теләп алганмыни? Үземчә тормыш корып, яраткан кешем белән яшисем килмимени минем? Ә ул җиңгигә ни кирәк? Ул бит Зөлфәтне бөтенләй белми: күргәне дә, сөйләшкәне дә юк, ә үзе бик җәелеп, үзенә-үзе ышанып, кешеләрне дә ышандырырлык итеп, аның данын сата. Милиционерыңа артык ышанасың, имеш, авызың бер пешкәч, салкын суны да өреп кабарга кирәк, имеш».

Фәһимә ярты елга якын Зөлфәт белән таныш, дус булган, аның белән бергә уздырган минутларын күз алдына китереп, уйланып утырды. Зөлфәтнең аңа беркайчан да хәтер калырлык сүз әйткәнен яки саксыз кыланганын хәтерләми. Аның колагында кинәт җиңгәсенең ярым шаяртып әйткән сүзләре яңгырап киткәндәй булды.

— Егетләр алар өйләнгәнче хатыннар белән йөрергә ярата, өйләнергә булса, кыз кирәк аларга...

Фәһимә урыныннан сикереп торды да, кулына ике мензурка һәм калын журналын алып, ишеккә ташланды. Бу сүзләрдән качып китмәкче иде бугай, ләкин күңел түрендәге уйлары аны кире урындыкка утыртты.

«Юк! Зөлфәт намуслы егет. Әй, нәрсә дип әле мин акланып торам? Үз акылым, үз фикерем юкмыни минем? Яратам мин аны. Яратам! Яратам!.. Минем бу изге хисемә тыкшынырга кемнең хакы бар?»

Төрле төстәге сыекчалар салынган мензуркалар, яшел, зәңгәр, кызыл төсләр бергә кушылып, тәрәзәдән төшкән кояш нурларында уйнаудан өстәл өстендә гаҗәеп бер матурлык пәйда булды. Халык көнкүреше өчен, яшәү өчен кирәкле бу матдәләр үзләренең нәтиҗә-җимешләрен шундый матур итеп бирерләрме? Кайчакларда тышкы матурлык алдаучан да була бит...

«Зөлфәтем, ышандыр мине!.. Синең белән бергә атлап барыр сукмагым бәхетле була алырмы...»

## 7

Гражданнар кабул итү сәгате узып бара иде инде. Каршысына утырган олы яшьтәге ханым белән сөйләшеп бетергәндә генә телефон шалтырады.

— Тыңлыйм,— диде Мәрдәнов.

Телефонда Шәкүров иде.

— Әле яңа гына дружинник Габитов шалтыратты. «Безнең егет»

икенче берәү белән синең участок каршында басып тора икән. Тәрәзәңнән кара әле, китеп өлгермәделәрме икән?..

— Рәхмәт, Ислам абый.

Зөлфәт трубканы элде дә, өстәл янында утырган апага, бер генә минутка дип, урам як тәрәзәгә килде. Каршы якта яшел агач ябалдашы астында ак күлмәк, соры чалбар кигән Салих басып тора. Кулын кесәсенә тыккан, гамьсез, һич нәрсәгә исе китми. Зөлфәт кинәт Фәһимәсен күргәндәй булды. Салихның кай ягыдыр Фәһимәгә охшаган иде. Ә иптәше кайда? Ислам абый икәү диде бит...

Өстәл янында утырган ханым:

— Ярар, алайса, мин китим, сез әйткәнчә, иртәгә гариза язып килермен,— дип, урыныннан торды.

Бу ханым күршесеннән зарланып килгән иде. Өч гаиләгә бер кухня, ди. Бер күршем белән бик тату, ди, ә менә икенчесе, алла үзе сакласын, кабереңә якын булмасын, шундый әшәке телле хатын, ди. Ханым сөйләнә-сөйләнә чыккан ишектән зифа буйлы, ак күлмәкле үсмер егет килеп керде.

— Мөмкинме, Зөлфәт абый?

— Әйдә, Тәлгать, узып кара,— диде Мәрдәнов, Маһруй әбинең оныгын баштанаяк күздән үткәреп.— Я, хәлләрең ничек? Әниең янына больницага барасыңмы?

Тәлгать маңгай астыннан гына Зөлфәткә карап тын гына тора бирде. Нидер әйтер сүзе дә бар шикелле.

— Сөйләп җибәр, ни йомыш? — диде Мәрдәнов.

— Ни... сез бүген безгә кереп чыккансыз икән...

— Кергән идем шул.

— Әби өйдән илле сум акча югалткан, базардан алма сатып җыйган акча иде... Шуны миннән таптыра, син генә алгансың, ди. Мин алырга булгач, базардан ук алып кайтмаган булыр идем. Өйгә керүче дә юк... Кая киткән, белмим, аптырадым...

Зөлфәтнең күз алдына шундук бая Тәлгатьләр өеннән чыккан ике егет килеп басты.

— Я, лейтенант абый, нәрсә әйтәсез? Югыйсә, әби, әниеңә әйтәм, ди... Мин алмаган акчаны ничек табыйм ди хәзер.

«Димәк, әби теге ике «монтерның» керүе турында Тәлгатькә әйтмәгән,— дип уйлады Зөлфәт.— Оныткан, күрәсең. Карчык кеше шул, склероз барын да оныттырадыр». Мәрдәнов үзе дә ул егетләр турында Тәлгатькә әйтүне кирәк тапмады. Ул сөйләгәннәрне бер кәгазьгә әйбәтләп язып куйды да урыныннан торды:

— Ярый, борчылма, Тәлгать, акчаңны табарбыз,— диде.

Тәлгать чыгып китү белән үк тәрәзә янына килде. Агач төбендә басып торган Салих Тәлгатьне каршы алды. Аннары алар сөйләшә-сөйләшә китеп бардылар.

Якындагы кафе алдында тәмәке тартып торган егерме яшьләр чамасындагы егет — дружинник Габитов та алар артыннан атлады. Кабул итү сәгате беткән иде, Мәрдәнов үзе дә, тиз генә бер карарга килеп, урамга чыкты һәм, Салихларны күздән югалтмаска тырышып, артларыннан китте.

Салих гамьсез адымнар белән генә атлый, ул бер нәрсә дә уйламый кебек, ә Тәлгать башын аска игән дә очраган кешеләргә күтәрелеп тә карамыйча бара. Аның бик нык эче поша булса кирәк. Ә алар артыннан күз яздырмый барган Мәрдәнов җиргә түгел, әнәгә баскандай, тигезсез адымнар белән атлый. Ул яшүсмерләрнең бозык юлга керә башлаганнарын белсә, һәрвакыт борчыла. Ә бу юлы? Эш дәверендә әле аның мондый авыр хәлгә очраганы юк иде. Үзенә иң якын кешеннең энесен, бәлки, тиз көндә булачак якын туганыңны, җинаятьче түгелме дип күзәтеп йөр инде! Намуска тия бу, җанны мәсхәрәли.

Әллә, чыннан да, ялгышамы сон? Әнә Шәкүров әйтә бит, кулымны кисмәгә бирәм, син ялгышасың, ди. Ә шулай да үзе дә икеләнде. Шулай булмаса, иң әйбәт дружинныгы саналган Габитовны бирер идемени? Габитов бүген иртәдән бирле Салих артыннан күзәткән, ләкин һичбер шикләнерлек сәбәп тапмаган...

Егетләр киң проспект читендәге эскәмиягә барып утырдылар. Биш минут чамасы узгач, Габитов та, кулына газета тотып, алар янына килеп утырды. Зөлфәт исә шуннан ерак түгел, каршыдарак торган автомат телефон будкасына керде дә Салих белән Тәлгатне дикъкатьләп күзәтә башлады. Юк, тыныч түгел иде егетләр. Бер-берсенә ачуланалар идеме, үпкә катыш бәхәс итәләр идеме? Шул чак алар янына яшь кенә бер егет белән нык кына бизәнгән, җилкәсе аша кызыл сумка аскан җирән чәчле бер кызый килеп туктады. Алар кул биреп күрештеләр. Зөлфәткә дә инде, шалтыраткан булып, озак тору мөмкин түгел иде. Җитмәсә, автомат ишеге төбенә бер-ике кеше дә килеп басты. Ул чыкты да, блокнотыннан яңа номер эзләгән булып, Салихларны күзәтүен дәвам иттерде. Ул арада әлеге егет белән кыз китеп тә барды. Зөлфәт үз күзләренә үзе ышанмады. Егете — иртәнге якта өстенә иске туҗурка, муенына тимер чыбык төргәге асып, Маһруй әбиләр подъездыннан атылып-бәрелеп чыкканнарның берсе иде. Аның өс-башы танымаслык булып үзгәргән, ләкин пөхтә итеп «подгоршок» алынган чәче, кечкенә түгәрәк башы Зөлфәтнең хәтеренә сеңеп калган иде. Зөлфәт алар артыннан баруны кирәк тапмады. Егетнең кем икәнлеген Тәлгаттән дә белеп булачак иде.

Менә Салих белән Тәлгат тә, урыннарыннан торып, икесе ике якка китеп бардылар. Зөлфәт уенча, алар хәзер бер кая да бармыйча, өйләренә кайтып китәргә тиеш. Шуның өчен дә, эскәмиядә утырып калган Габитовка, урыныннан кузгалма дип, кулы белән ишарә ясады да юл аша аның янына чыкты.

Габитов аңа Салих белән Тәлгатнең, икәү генә утырганда, урланган акча турында гына сөйләшеп утыруларын, ә инде бу егет белән кызның (егете Коля исемле икән) Галим исемле бер иптәшләренең туган көненә бергәләшеп барабыз дип, боларны да чакырып китүен әйтте.

— Тәлгат: «Бәлки барырбыз», дисә дә, Салих: «Галим белән башка беркайчан да очрашырга теләмим», дип әйтте,— диде Габитов.

Зөлфәт инде Салихның шикле кешеләр белән бәйләнешкә керә башлавына шикләнмәде. Аңа бик кыен булып китте. Берничә көннән, ә бәлки, берничә сәгатьтән, Салихны алар милиция идарәсенә алып киләрләр, шунсыз булмас. Шәкүровка шалтыратырга да әйтергә кирәк. Миннән булмый, миннән башка гына... Юк, башта Фәһимәгә шалтыратыйм. Ул хәзер, мөгаен, өенә кайтып җиткәндер. Әгәр кинога чакырсам?.. Шунда барсын да сөйләшербез...

Зөлфәт бөтен көчен җыйнап трубкага үрелде. Ләкин шул хәлендә тукталып калды. Иртәгә Галимнең туган көне. Тәлгат барырга риза. Димәк... Ул үз участогындагы күзәтү астында тора торган, эчәргә яратучы кешеләрнең барсының да исем-фамилияләрен хәтеренә төшереп чыкты. Юк, Галим дигәне юк алар арасында, бәлки, бу — кушаматыдыр? Бәлки, аны Ислам абый беләдер? Ул Шәкүровка шалтыратыр өчен кире будкага керде.

— Хәерле кич, Ислам абый! Нинди яңалыклар бар?

— Габитов минем янда утыра. Вакытың булса кил.

— Пөгердем.

Ләкин Галим исемле шикләнерлек кеше Шәкүров участогында да юк булып чыкты.

— Анысын иртәгә иртәнге летучка вакытында районның барлык участокларыннан тикшереп алырга да була,— диде Шәкүров. Аннары Мәрдәновның күзенә текәлеп карап торды да:

— Мина Габитов яңа мәгълүматлар бирде. Шикләнүләреннең дөрес булуы ихтимал...— диде.

Мәрданов маңгаена кинәт бәреп чыккан тирен кулъяулыгы белән сөртеп алды.

— Нишлисең бит? Салих та адәм баласы! Димәк, ялгышкан, дөресрәге: әти-әниләре, шул ук Фәһимә дә ялгышкан булып чыга. Кай урындадыр, кай вакыттадыр игътибарлары җитмәгән. Ә Салих шуннан файдаланган...

Лейтенант Шәкүровның муен тамырлары бүртеп китте, ике күзен дә сөрем томалагандай булды, биш көн буена сузылган бу күңелсез вакыйга аның нервысын байтак сүткән иде. Әгәр чыннан да үзенең бик хөрмәт итеп йөргән Заһит абыйсының бердәнбер малае җинаять юлына баскан булса?.. Ул әлегә кадәр лейтенант Мәрдановның шикләнүләренә ышанмаса яки ышанырга да теләмәсә, бүген инде Зөлфәт: «Тәлгатләр өеннән акчаны Коля урлаган, ә Коля Салихның да, Тәлгатнең дә дусты» дип кырт кисеп әйткәч, Габитов та яңа материаллар өстәгәч, ышанмый булдыра алмады. Ул, ни Заһит абыйсын, ни үзен якларлык сүз таба алмыйча:

— Мин сиңа ихластан әйтәм, Зөлфәт, бу очракта Салих ялгышлык эшләсә дә, бу аның беренче ялгышуы. Әлегә кадәр аңардан шикләнерлек хәл булмады. Беләм бит мин үз участогым кешеләрен,— диде.

## 8

Мөршидә белән Заһит институтның беренче курсыннан башлап бергә укыдылар. Биш ел буе якын дус, сокланырлык иптәш булып йөрделәр. Яхшы мөнәсәбәтләр бара-тора мәхәббәткә әверелеп, аларны мәңгегә бәйләде. Эшләвен дә икесе бер заводта эшли башладылар.

Яшь хатынның дөньяда иң бәхетле көне кайсы дисәләр, Мөршидә, мөгаен, балага узган көнем, дияр иде. Беренче кабат, оялып кына, үзенең йөкле икәнен әйткәч, Заһит, чиксез шатланып, хатынын озак итеп кочып торды. Әкрен генә колагына пышылдады:

— Кем булыр икән: кызмы, улмы? Исемен ничек кушарбыз икән?..

Шул көннән башлап алар дөньяда өчәү яши башладылар: өчәү эшкә бардылар, өчәү кире кайттылар. Заһит Мөршидәнең һәр хәрәкәтен, һәр адымын күзәтеп, саклап кына йөрде. Теләгән бер нәрсәсен ашатты ул Мөршидәгә. «Улыбыз я кызыбыз өчен кирәк бит», диде.

Ләкин, көннәр узган саен, аларның бу чиксез бәхетен кара күңелсезлек каплап алды. Һич уйламаганда, төн уртасында, Мөршидә авырып китте. Врач чакырдылар. Тик врачлар килеп җиткәнче, ул дүрт ай ярым гына әлек яралган үле ир бала тапкан иде инде. Заһит кинәт картаеп китте. Мөршидә җылады да җылады. Мондый хәлнең кабатлану ихтималын ишеткәч, бөтенләй һушсыз булды.

Икенче баласын ул зур газаплар белән җиде айга кадәр күтәрде. Ләкин больницага баланы саклап калу өчен ятарга барган көнне тагын да баланың карында ук үлгәнлеге билгеле булды. Мөршидәнең ата-анасы да, туганнары да моннан соң газапланып авырга узып йөрмәскә киңәш бирделәр. Заһит та:

— Бөтенләй баласыз яшәгән кешеләр дә бар. Әле бит минем сеңелем — Фәһимә бар. Ул кияүгә чыгар, аның бәбәе булыр. Шул бәбәйне багарбыз. Моннан соң балага узу турында уйлама да, борчылма да,— диде.

Мөршидә барыбер моңа риза булмады. Ул врачлар киңәшен тотты. Нык дәваланды һәм өченче тапкыр да шундый фаҗигане кичермәс өчен, алдан ничәдер ай баланы саклап больницада ятты. Һәм врач-

ларның зур ярдәме белән өченче бала булып Салих туды. Өч килолы малай түгел, дөньяга аңлатып булмый торган бер илаһи көч туды. Гаиләгә якты көн, якты төн булып беренче өйләнгән көннәрендәге зур бәхет, кайнар мәхәббәт кире кайтты. Шуның белән бергә борчуы да килде. Салихның әз генә температурасы күтәрелсә дә, Заһит белән Мөршидә кая барырга урын тапмыйлар — балага карап үзләре авырый, балага карап үзләре сызлана иде. Әби-бабайлар, туганнарының телендә Салихтан башка нәрсә булмады да.

Бик авыр булса да, Мөршидә бала хакына яраткан эшен ташлады, өйрәнгән коллективыннан аерылды. Бөтен тормышын баласына бирде. Салих уку яшенә җиткәнче, шулай өйдә утырды. Баланы ничек тәрбия итәргә кирәклеген Мөршидә дә, Заһит та бик яхшы белә, ләкин күп вакытта ул кагыйдә ничектер онытыла иде. Мөршидә, барлык эшне дә үзе эшләп, бар нәрсәне үзе әзерләп, Салихның иренчәк булып үсүенә төп сәбәпче булды.

Алтынчы класста укыган чакта класс җитәкчесе Мөршидәгә:

— Салих сәләтле укучы, ләкин актив түгел. Кушсаң эшли, кушмасаң, үзе башлап бер нәрсәне дә эшли белми,— дигән иде.

Мөршидә ул вакытта укытучыга үпкәлисе итте. Ә Заһит авыр сулап:

— Нигә аңа үпкәлисең? Салихны шулай итеп үзебез үстердек. Хәзер менә шуның нәтиҗәсен үзебез күрәбез. Без бит аның сәламәтлеген генә кайгырттык, бик каты яраттык. Инде хәзер күздән ычкындырмаска кирәк,— дигән иде.

Сигезенче класларда укыган чакта Салих бик нык үзгәреп китте. Әнисенең артык дәрәҗәдә кайгыртуы хәзер аның ачуын гына китерә иде. Хәзер ул еш кына:

— Әллә мин баламы, әни? Нәрсә һаман мине бала урынына күреп тикшереп торасың? — ди башлады.

Мөршидә аның үзе сайлаган малайлар белән генә дус булып йөрүен тели иде. Ә Салих әнисенә Макаренко китапларын укырга киңәш бирде. Балаларны төрле бала белән аралашудан тыймаска кирәк; мондый аралашу аларның характерлары формалашу өчен зарур нәрсә дигән сүзләрен әнисенә укып күрсәтте. Заһит, инде улының үсеп җиткәнен күреп, Мөршидәгә:

— Үзенә юл куярга кирәк, үзе теләгән иптәшләре белән йөрсен, аралашсын; аңа инде унбиш яшь тулды, хәзер аның үз характеры, тормышка үз карашы булырга тиеш,— диде. Ләкин Мөршидә аның саен:

— Мин кем белән дуслашырга кушсам, Салих шулар белән генә йөрер! Аңа иң һәйбәт малай — Тәлгат. Әти-әниләре дә яхшы кеше, йөрсеннәр бергә. Тәлгат белән көнып-төнеп ятса да, сүзем юк,— дип үзенекен тәкърарлады.

## 9

Тәлгат Галим белән кызык кына танышты. Шулай бер көнне Бауман урамыннан кызу гына барганда, аны-моны уйлап та тормыйча, йөгереп кенә каршы яктагы кибеткә чыкты. Чыкты, ләкин шунда ук аны милиционер туктатты, кулын козырегына куеп:

— Егет кеше, күрсәтелмәгән җирдән урам аша чыгарга ярамаганны белә торгансыздыр. Нигә тәртип бозасыз? — дип фамилиясен, кайсы мәктәптә укуын сорый башлады.

Тәлгат, нәрсә дияргә дә белмичә, кызарынып басып торды. Башын түбән иган килеш, кызу-кызу кесәләрен актара башлады, ә кесәдә бер тиен дә акча юк икән. Шул чак, боларга игътибар итеп, озын гына

буйлы, ачык чырайлы, ялан баш бер егет бер-ике минут эчендә җыйналып өлгергән халык арасыннан килеп чыкты да көр тавыш белән:

— Менә миндә бар, юк акчаңны эзләмә, мәгез,— дип, милиционерга бер сум акча сузды. Тәлгат бу рәхимле егеткә күзләрен тутырып карады да, бер сүз дә әйтми, янадан күзләрен җиргә текәде. Ә милиционер егет сузган акчаны кире этәреп:

— Мәшәкатьләнмәгез, гражданин, сезнең ярдәм кирәкми монда, юлыгызда булыгыз,— диде. Шунда ук җыйналган халыкка карап: — Иптәшләр, берни дә булганы юк, таралышыгыз, таралышыгыз. Бар, егет, син дә юлыңда бул, кара аны, тагын икенче кабат йөри белми йөрсәң, болай гына котылмассың, колагыңнан тотармын да мәктәпкә, илтәшләрең, укытучыларың янына ук алып барырмын,— дип, Тәлгатне шелтәләп озатып җибәрде.

Тәлгат, башын түбән иеп, китеп барды. Ул ара да булмады, кемдер берәү аның җиңеннән килеп тартты:

— Я, ничек, ычкындыңмы?

Бу баягы егет иде.

— Ычкындым... Кесәдә акча булса, берни түгел иде дә, түләп киткән булыр идем, болай уңайсызрак килеп чыкты.

Алар сөйләшә-сөйләшә бергә киттеләр.

— Укучы малайлардан штраф түләтми алар,— диде Тәлгатнең яңа танышы. Әнә нәрсә ди бит: мәктәбеңә хәбәр итәм, ди. Итәр дә. Аңа нәрсә? Тик минем яклаганны күргәч кенә тынып калды. Беләм мин аларны! — Ул Тәлгатнең җилкәсенә кулын салды: — Әйдә, милициядән котылу шатлыгыннан киногa керәбез!..

— Рәхмәт. Күрдең бит, акчам юк. Бу яхшылыгың өчен сине мин үзем киногa алып керергә тиеш.— Ул кинәт кенә: — Әйдә, безгә, өйдә акча бар минем,— дип, яңа танышына карады.

— Пустяк. Бу юлы булмаса, икенче юлы син алып керерсең... Әйдә, таныш булыйк.— Ул шәм шикелле шома кулын Тәлгаткә сузды: — Мин Галим исемле булам, заводта слесарь.

Тәлгат аңар ихтирам белән күтәрелеп карады. Ул бит үзе дә унны тәмамлагач заводта токарь булып эшкә керү турында хыяллана. Ә кичләрен университеткамы анда, кая да булса математика факультетына керү өчен хәзерлек курсында укырмын дип уйлый.

Алар кинога керделәр. Су эчтеләр, мороженое ашадылар һәм шул көннән бирле алар еш кына очрашып, дус булып йөри башладылар. Тәлгатнең әти-әнисе дачада чакта — алар шәһәрдә, ә әтиләре шәһәрдә чакта — алар дачада булды.

Көннәр шулай үтә торды. Тәлгатнең әтисе курортка китеп, әнисе больницага кергәч, дачада Тәлгат бер үзе калды. Бакча эшенең очкырые юк иде. Менә шундый авыр чакта Галим, синең өчен эштән отпуска алдым дип, Тәлгаткә ярдәм итә башлады. Унөч төп алмагачның алмалары кызарып пешеп утыра. Кая куеп бетерер хәл дә юк. Галим нәкъ әнә шуларны урнаштырырга ярдәм итте дә инде. Көн саен таңнан торып, иң эре алмаларны гына җыеп кәрзингә сала иде дә базарга илтеп сата иде. Тәлгаткә күренеп йөрергә кушмады, мәктәп укучысына базарда алма сатып йөрү килешми, диде. Хәер, ул үзе дә алма сатып утырмады, сөйләшеп куйган кешесенә файда калырлык итеп тапшыра иде дә кайта иде. Аның үзенә дә кәрзин башына файда тия барды. Ә калганын Тәлгаткә кайтарып бирде. Кичләрен алар кинога баралар, шул акчага мороженое ашыйлар, кайчагында сыра, я җинелчә генә — кызлар эчә торганын гына — вино да эчкәләп куялар иде. Юк, исерерлек, кешегә сизелерлек түгел, әз-мәз генә. Бу компаниядән Тәлгатнең дусты Салих та читтә калмады. Аларга Галимнең күренеп торган тыйнаклыгы, тырышлыгы ошый, әмма алар аның төрмәдә утырып чыкканын белмиләр иде.

Ә бер көнне алар өчәүләшеп Тәлгатләр дачасында кичкә кадәр карта уйнадылар. «Сухое» дип аталган ун гына градуслы вино эчтеләр. Бераз кызмача хәлгә килеп, күңелләнеп алгач, Галим җәзалы уен тапты:

— Әйдәгез, бер кызык эшлибез! — диде.— Мин карта. Сез минем оста уйнаганымны беләсез. Икәүләшеп уйнасагыз да, бишәү уйнасагыз да, мине дурак калдыра алмыйсыз.

— Икәү бергә уйнасакмы? Без сине айн момент калдырабыз! — диде Тәлгат, масаеп.

Аның сүзен Салих эләктереп алды.

— Алайса,— диде Галим,— әйдәгез, бәхәсләшәбез: әгәр дурак калдырсагыз, сез миңа теләсә нинди җәза бирә аласыз.

— Бәхәс! — диделәр берьюлы Тәлгат белән Салих.— Ләкин баштан ук нинди җәза икәнен сөйләшеп куябыз.

— Теләсәгез нишләтегез,— диде Галим, бер дә исе китми генә.— Сез мине барыбер дурак калдыра алмыйсыз. Сезнең кебек чибәр егетләр белән байтак уйнаганым бар минем.— Ул аларны юри кыздыра иде.— Әгәр мине отсагызмы, егетләр?.. Туктагыз әле, бу уенны берәр стакан вино эчмичә башлап булмый. Ягез әле, сезнең җиңү өчен берәрне күтәрик әле!

Салих белән Тәлгат бер-берсенә караштылар: күпкә китә бит, Салихның өенә дә кайтасы бар.

— Борчылма, дус,— диде аңа Галим.— Без сине Тәлгат белән озатып куябыз.

Уен башланды.

Иреннәре кипкән саен вино белән чылатып тордылар.

— Әгәр отсагыз, беләсезме, нинди җәза бирәсез миңа? — диде Галим, хәйләкәр генә елмаеп.

— Казанканы төн уртасында йөзеп чыгасың,— диештеләр Салих белән Тәлгат...

— Шул да булдымы җәза!.. Казанканы түгел, Иделен дә эһ тә итми йөзеп чыгам мин... Телисезме, сезнең күз алдыгызда беренче очраган кызны менә шунда нәртеп алып киләм... Беләсезме, нәрсә? Мин суны да, урманны да яратам, тик менә кызларны яраткан кадәр бер нәрсәне дә ярата алмыйм. Сез әле белмисез, ни әйтсәң дә, малайлар шул әле сез — борын астыгыз кипмәгән!

— Безнеңме кипмәгән! Ха! Унҗиденче яшьтә кайбер егетләр өйләнеп тә куя,— диде Салих, башын күтәрә төшеп.

— Шулай булгач, әйдәгез, бәхәсләшик. Әгәр отсагыз, бүген юлда очраган беренче кыз минеке. Теләсәгез — сезгә дә табам.

Галим кызлар турында сөйләп, тәҗрибәсез үсмерләрне тәмам шаштырды.

Ике-өч шешә вино бушагач, барсы да шактый кызгач, Галим чынлапмы-юриме, дурак булып калды — бер генә дә түгел, рәттән өч мәртәбә.

— Молодцы! — диде ул, башын кашып.— Тәки оттыгыз. Инде җәзагызны теләсә кайчан, теләсә нинди җирдә үтим.

Алар шәһәргә менеп киттеләр. Автобустан төшкәч, Галим егетләрне култыклап алды. Вакыт соң иде инде.

— Авызыгыздан аракы исе килә, аякларыгыз да бик үк туры баса алмый, әйдәгез, айныганчы бераз урамда йөрик. Әнә, читкәрәк китеп утырып торырга да була,— дип, Галим егетләрне караңгырак бер урамга борып алып кереп китте. Ләкин аларга озак йөрергә туры килмәде. Чаттан йөгерә-йөгерә бер кызкай килеп чыкты. Аны күргән Галим:

— Әнә, бирим дигән колына — чыгарып куяр юлына! Карагыз аны, югалып калмагыз...— диде.

Салих айнып киткәндәй булды, ул кинәт Галимнең кулына килеп тотынды.

— Юк, мин бу эшкә катнашмыйм. Әйдә, киттек, Тәлгат!

— Их, чүпрәк! Кайчаннан бирле дус булып йөрисен, ә үзең? Мин сине куркак куян дип уйламаган идем. Әле житмәсә, карта уйнаган була. Ә карта уенында сүзне утәми калу — хыянәт.

Тәлгат тә бөтенләй бер нәрсә аңламый Галимгә карап тора иде. Галим аларның икесен дә, өстерәп диярлек, капка эченә алып кереп китте. Калганы бик тиз эшләнде. Кыз шул капка яныннан үтеп барганда гына, Галим атылып чыгып, аны үзләре янына тартып алды, шундый ук тизлек белән кызның авызын учы белән каплады.

— Әйдә, тот култыгыннан, әнә шунда гына барабыз... Ә син арттан күзәтеп бар.

Галим белән Тәлгат кызны култыклап күрше капкага таба киттеләр. Нәрсә булганын рәтләп аңлап та өлгерә алмаган Салих арттарак калды. Минут эчендә аның башыннан мең төрле уй узды. Әллә хәзер үк барып, кулларыннан ул кызны йолкып алыргамы? Әллә «коткарыгыз» дип кычкырыргамы? Ләкин эчелгән аракы Салихның акылын томалап ихтыярын алган иде. Уйлары буталчык иде. Һәм ул, артларыннан кеше килгәнен күргәч, үзе дә сизмәстән, «йөгерегез!» дип кычкырды да, коты очып, җан-фәрманга чабып китте.

## 10

Инде менә үз-үзенә урын таба алмый борчыла, өзгәләнә Салих. Кесәсенә кулын тыга да тәрәзә каршысына килеп уйланып басып тора; я кулына китап алып, укырга итеп карый. Ләкин китаптагы сүзләр башына керми, күзләре хәрефләргә текәлгән булса да, уйлары әллә кайда йөри. Олыгаеп, җитдиләнеп китте ул бу көннәрне. Әнисе белән этисенә илтифатлы булып, Фәһимә апасына да хәтер калырлык сүзләр әйтүдән тыелып кала. Әнисе, кинәт шулай җитдиләнеп киткән улына карап, шатланып бетә алмый, ә Заһит бер дә исе китми генә:

— Шулай булырга тиеш тә: балалыктан егетлек чорына күчә торган авырлыкны кичерә малай. Кискен борылыш аның организмында. Төне буе урамда йөрүдән дә тәм тапмый башлагандыр,— ди.

Ләкин, ни атасы, ни анасы улларының ни уйлаганын, вакыты-вакыты белән куркынып, кемнәндер, каядыр качып котылырга теләгән минутларын сизмәделәр. Ә Салих борчыла иде, Тәлгаткә дә үпкәсен әйтеп, ачуланып алды. Ә Тәлгат Галимне яклады:

— Юкны сөйләмә, Галим — яхшы егет. Заводта начар кешеләр эшләми... Ул исерек иде, шаярды гына...

— Шаярды? Шаяргач кына, нигә ул кызның авызын томалады, каядыр алып китәргә теләде...

— Эчмәскә кирәк иде безгә,— диде Тәлгат.— Эчмәгән булсак, син үзең дә бәхәскә катнашып, Галимгә ияреп китмәс идең. Барыбыз да гаепле монда...

Бүген Салих, Тәлгат белән аерылышкач, йөгерә-йөгерә өенә кайтты да түземсезләнеп Фәһимә апасын көтә башлады. Аның белән киңәшергә кирәк. Әтиләренә белдерми генә. Ә Фәһимә апасы милиционеры белән сөйләшер.

Фәһимә кайтып өс-башын да алмаштырырга өлгермәде, бүлмә ишеген шакып Салих килеп керде. Фәһимә энесенең моңсу күзләреннән күңелсез бер хәл булганын сизеп алды.

Салих, ишек яңагына сөялеп, бер сүз дә дәшми басып торгач, кинәт:

— Апа, алып бар әле мине иртәгә Зөлфәт абый янына,— диде.

Фәһимә Салихның бу сүзләреннән кычкырып көлеп җибәрде. Ләкин энесенең, бер дә шаярмыйча, туп-туры итеп күзләренә карап торуын күргәч, үзе дә җентекләп Салихка карап чыкты.

— Йомышын бар идеме әллә, үскәнем?

Салих бер генә секундка каушап калды, йөрәге еш-еш тибә башлады, ул куркынып китте — үз сүзләреннән үзе курыкты. Башына кинәт әллә нинди хәсрәтле уйлар тулды. «Кем соң ул Зөлфәт?» Шул ук милиционер. Барсын да сөйләтеп бетерер дә, барыңны бергә җыйнап, төрмәгә утыртып куяр. Үземне генә гаепләсә бер хәл, бу бит иптәшләрне сату була. Юк, юк, ашыкмаска кирәк.

Фәһимә аның иңбашыннан килеп кочты:

— Нигә кирәк сиңа Зөлфәт абыең?

— Болай гына,— диде Салих, авызын кыйшайтып.— Җизни белән ныгытып танышасы килгән иде.

## 11

Төнге вакыйгадан соң Галим, өйләренә кайтып, әнисен кисәтеп куйды. Телефоннан шалтыратсалар — ул өйдә юк. Ишек шакыгач, коридорда аяк тавышы ишетелгән саен, үзен алырга киләләр, дип куркып ятты. «Барсын да участок милиционерына барып сөйлим» дип, ничәдер мәртәбә урамга да чыкты, ләкин йөрәге җитмәде. Үзенә күпме ярдәм иткән, лагерьдан соң эшкә урнаштырган кеше капитан Симагин янына, мондый хәлдән соң, баруы да оят! Тәлгат белән Салих милициягә барып, барсын да сөйләгәннәрдер инде. Күз алдына төрмәнең шыксыз караңгы биналары килеп, җанны өшетә... Әйе, әйе, әгәр алар куркак булмасалар, гадел егет булсалар, алар икенче көнне үк милициягә барырга тиешләр иде. Галим бит аларны «сөйләмәгез» дип кисәтмәде...

Ни өчен соң ул һаман үз-үзен тыя алмый, ни өчен аракы эчүдән туктый алмый, ни өчен бозык егетләр, бозык кызлар аны күбрәк тарта? Нигә ул һаман кемгәдер ачу саклый, кемнедер кыйныйсы килә, ватасы, җимерәсе килә? Үз әнисе белән үги әтисенең аны читкә этәргәне өченме? Аларга ачу итәм дип, ни өчен ул үзен хурлыкка, һәлакәткә төшерә? Үз-үзенә хуҗа булса, заводтагы яшьләр, институттагы студентлар кебек, кешечә матур хыяллар белән канатланып яши алмас идемени?

Әнә ашыгып-кабаланып әнисе кайтып керде. Ул гел шулай ашыгып йөри. Әллә ниткән ыгы-зыгылы кеше аның әнисе. Бу, мөгаен, ирен югалту куркуыннандыр. Ярата ул ирен, балаларыннан артык ярата. Юкса, Галимнең энесе Камилне авылда асрар идемени? Үги әти курортка китте. Ул ике путевка алган иде. Галимнең әнисе:

— Үзең генә бар инде,— дип, курорттан баш тартты.

— Улым дисең инде? Да, аңлыйм, аңлыйм,— диде ире, мыскыллырак тавыш белән.— Ләкин, бел, син гомер буе төрмә сандугачын саклап утыра алмаячаксың.

— Битәрләмәче шул балалар белән! Әле дә мәхәббәтебез хакына ничә еллар буе балаларымнан ваз кичеп яшим, шуның миңа газап икәнен күрмисеңмени? Үләр идем дә, вакытсыз үлеп тә булмый бит...— дип үксеп елап җибәрде.

Ире аны юатмады. Һашиянең кайчандыр тулы, түм-түгәрәк булган, хәзер инде ябыгып калган иңсәләренә, елаган чакта бик ямьсезләнеп киткән иреннәренә, нервыдан кызыллы-күкле таплар чыккан йөзенә карап торды да, нәфрәтләнеп, читкә борылды. Бу күренеш аның байтактан бирле Һашиягә карата күңеленең салкыная баруын көчәйтте. Ул ясалма бер тавыш белән:

— Бу көннең киләсен мин алдан ук белә идем. Син беренче иреңне дә, ике балаң бар өстенә, һичбер кызганусыз ташладың, ә мине ташлау — чүп тә булмаячак сиңа,— диде.

Иртәгәсен ул курортка китте. Һашия үзеннән җиде яшькә кече булган, әле яңа куәтләнеп, көчәеп килгән иреннән үлеп көнләшә иде. Яратуы көчәя барган саен, иренең читләшә баруын күреп, газабыннан бөтенләй ябыгып, картаеп китте. Ул авылда беренче иренең туганнарында яшәп яткан кече улы Камилне бөтенләй оныткан иде. Галимне дә чын аналар мәхәббәте белән яратмый, өстәвенә, ул аңардан курка да иде. Шул ук вакытта җәмәгатьчелек фикере, иптәшләре, туганнары фикере белән дә аз булса да исәпләшми булмый. Аннары ул, әгәр ире ташласа, ялгызлыкка дучар булып каласын да, шул ике баланың ярдәме кирәк булачагын да белә иде. Ичмасам, картаймыш көнемдә улларым, оныкларым белән яшәрмен дип, үз күңелен үзе юаткан чаклары да була иде.

Һашия, кайтып керү белән, сумкасыннан бер төргәк алды да:

— Галим, кил әле бире,— дип, йомшак кына итеп улына эндәште.

Галим иренеп кенә әнисе янына килде.

— Киеп кара әле, улым, коңгырт төс сиңа килешә микән? Әгәр ошатмасаң, кибеткә барып икенче төскә алмаштырып кайтырмын,— дип, целлофан пакетка салынган нейлон күлмәкне улына сузды.

Галим күлмәкне кулына алмый гына карады да:

— Минем күлмәкләрем бар бит инде, әни. Нигә юкка акча туздырып йөрисең? — диде.

— Иртәгә туган көнең бит, улым: егерме тула!

— Рәхмәт, исеңә төшергәнең өчен,— диде Галим, әнисе яныннан читкә китеп.

Туган көн! Кирәкме соң аны билгеләп үтү!.. Юк, үткәрергә туры киләчәк. Аның иптәшләре әллә кайчаннан бирле җыйналып йөриләр инде. Бу — сөйләнгән, килешенгән. Моннан баш тарту — иптәшләрне санга сукмауның да иң начары булачак. Коля моннан бер атна элек үк инде, туган көнеңне уздырырга кирәк, кызлар да көтә дип, аның алма саткannan калган акчасын кырып-себереп алган иде. Коляның да, башка иптәшләренең дә характерларын яхшы белә Галим. Алар каты бәгырьле. Ике сөйләп тормыйлар...

Галим кухня ишеге аша әнисенең йөзенә карап тора башлады. Әнисе, инде кырыгы тулса да, әле һаман да матурлыгын җуймаган, тик ябыккан гына. Элек күрсәң иде аның матурлыгын! Аның зәп-зәңгәр күзләренә Галимнең һаман карап кына торасы килә иде. Аннары ул көзге алдына барып, үзенең йөзенә карады. Аңа кешеләр һәрвакыт: «Әнисенә охшаган, бик матур егет булыр»,— диләр иде. Юк, нинди матурлык булсын бу йөздә? Егерме тулган егет, имеш! Чырае, авыру кешеләрнеке сыман, сап-сары, әнә чигә буйлап чәче дә агара башлаган, бераздан ап-ак чәчле бабай да булыр әле. Ул заводта үзе белән эшләгән егетләрне күз алдына китерде. Иртәгә шимбә көн. Алёша аны үзләренең компаниясе белән Мари урманына походка чакырды. Әллә шулар белән китәргәме? Әшнәләренең сасы бүлмәсендә тәмәке исе иснәп утырганчы... Ул баядан бирле чалбар кесәсендәге конвертны капшый иде. Әле кичә генә мәктәптә бергә укыган Евгений Тарасовтан килгән хат иде ул. Евгений аны Омскига үзе янына эшкә чакырган. Әллә шуның янына китәргәме? Колялар, Фәруклар аның артыннан ияреп бармас әле, тотарга да китәргә!..

Бу минуттагы хыяллары матур һәм өметле иде Галимнең. Шундый җаваплы адымны атлар өчен ныклы ихтыяр көче кирәк иде аңа. Ә Галимнең бармы соң ихтыяр көче? Юк, юк, юк! Булса, җил кайдан иссә шунда бөгелмәс иде. Бик кечкенә генә күңелсезлек тә аның өметен сындыра, әз генә шатлык та аны канатландырып җибәрә. Шатлык?..

Тукта. Нинди шатлык көтә иде соң әле аны? Ә-ә-ә, туган көне... Иртәгә туган көне бит. Камил дә кайтырга тиеш, дигән иде әнисе. Әллә заводтан бер-ике иптәшен чакырып, өйдә генә үткәрергәме? Әйе, әйе! Иң яхшысы — өйдә уздыру. Ул кухняга әнисе янына чыкты.

— Әни,— диде ул,— әйдә, минем туган көнемне үзебездә генә уздырыйк. Иптәшләрем дә килер.

«Иптәшләрем» дигәннән әнисенең йөзе каралып китте.

— Иптәшләрең?! Кемнәр соң алар синең «иптәшләрең»? Безнең өйгә китерергә ярыймы соң аларны? Болай-болай кыланып биеп, кыйммәтле келәмнәрне таптап бетермәсләрме? Келәмнәрне җыеп куярбыз микәнни? Мебельләр дә безнең, үзең күрәсең...

Галимнең ике кулы хәлсезләнеп гәүдәсе буйлап салынып төште. Аннан акрын гына атлап бүлмәсенә керде дә мендәренә йөзтүбән ятты.

Һашия ханым аның артыннан керде.

— Улым, син үпкәләмә. Үзең уйлап кара әле...

Галим урыныннан сикереп торды да чөйдән ялт иттереп пиджагын алып җилкәсенә салды. Бу минутта аның кыяфәте усал, күз карашларында бөтен нәрсәгә нәфрәт яна иде. Шулай да үзен-үзе тыеп:

— Борчылма, әни... Затлы мебелеңне бозмам, үзеңне дә борчымам,— диде дә йөгереп диярлек чыгып китте.

## 12

Лейтенант Мәрданов төнге өчтә генә эшеннән кайткан булса да, йоклый алмады, борчылып, уфылдап ятты. Эшләр өсле-өсле килеп өелде аңа бу көннәрне. Тәртип бозучылар күп булды. Аның өчен ни авыры гаиләдәге низагларны тикшереп йөрү иде. Лесгафт урамында торучы Шәмсия исемле хатын, ничә көн рәттән килеп, елый-елый иреннән зарлана. Көне-төне эчә, эчеп кайткач кыйный, балаларымның инде коты чыгып бетте, зинһар өчен ярдәм итегез: я төрмәгә ябыгыз, я шәһәрдән үк куып җибәрегез, дип ялвара. Кичә лейтенант Мәрданов шул хатынның ирен участокка чакырды:

— Әгәр эчүегезне туктатмасагыз, гаиләгезне һаман борчысагыз, мин сезне судка бирәм,— диде аңа Зөлфәт.

Ир, башкача эчмим, зинһар гафу итегез дигән булып, өенә дә кайтып киткән иде. Бер сәгать тә узмады, шау-гөр килеп, дулап, хатыны килеп керде.

— Өч бала атасын судка биреп, төрмәгә утыртырга сезнең ни хакыгыз бар? Эшләгән акчасын алып кайта, аның акчасы булмаса, мин балаларымны ничек туйдырыйм? Ир белән хатын арасына тыгылып, дөнья бутап йөрисез, мин бит сезгә куркытыгыз гына дип әйттем! — дип, теләнә ни килсә, шуның белән лейтенантны тиргәп чыгып китте.

Зөлфәт үзен-үзе хөрмәт итә белмәгән бу хатынга нәрсә диярга дә белми аптырап калды. Әллә хурланудан, әллә шул коточкыч сүзләрне тыңлап торганга бите ут кебек яна башлады. Хәзер дә шул ямьсез вакыйга күңелен тырнап, кәефен тәмам бозып җибәрде. Көненә ничәшәр мәртәбә әнә шундый кешеләрдән үпкә, ачу сүзләре ишетә ул. Ә кайчакта үзләрен бәладән, күңелсез хәлләрдән коткарып калдырганы өчен рәхмәтләр әйтеп, кунакка чакырырга килгән игътибарлы кешеләрнең хәтере калмаслык сәбәпләр табып, кунактан баш тартырга да туры килә аңа. Бу кварталда җиде җинаятьнең иксе ачылмый калган. Бер атнадан халык алдында чираттагы отчет җыелышы була, шуңарга әзерләнергә кирәк.

Тәлгатләр өеннән югалган илле сум акчаны кем урлаганы инде ачык: моны Тәлгатнең дус булып йөргән иптәшләре алган. Телефон

станциясендә ул ике егетнең эшләмәве дә мәгълүм, димәк, акчаны кире кайтару юлы гына кала. Әлеге Салихларга бәйле вакыйга тулысынча лейтенант Шәкүров участогына кагылса да, җинаятьне ачу Зөлфәткә бәйле иде. Фәһимә белән көрешмәгәнгә дә ике тәүлек узып китте. Дөрес, моңарчы да алар көн саен күрешеп тормыйлар иде. Күрешми торган көннәр кайвакытта атнага да сузыла иде, ләкин алар көн саен телефон аша бер-берсенең хәлләрен белешеп торалар иде. Бу арада эш белән чабып, шалтырата да алмады. Дөресрәге, Салих эше белән бәйле булу аны шалтыратудан тыеп тора иде.

Зөлфәт үзенең эшен-профессиясен уйлый башлады. Авыр да, үзенчәлекле дә аның профессиясе, никадәр яшерен эшләр эшләнә анда. Кайберәүләрен кайчак үзеңнән дә яшереп йөрисең. Андый вакытларны, тәүлекләр буе эш артыннан йөреп, өеңә дә кайта алмыйсың, кайткач та әле семьяң белән уртаклаша алмаган сүзләр күп була. Ә эчеңдә күпме уй, күпме борчу! «Шундый инде менә син, Зөлфәт»,— диде ул үз-үзенә. Ә менә шундый булуыңны синең тормыш иптәшең — хатының аңлармы?! Ул күз алдына Фәһимәне китереп бастырды да, аның күзләренә озак кына карап торгандай итеп:

«Фәһимә акыллым, аңларсыңмы син мине? Бәхетле була алырсыңмы син минем белән? — дип, күңеленнән аның белән сөйләшә башлады.— Мин бит сине яратам, өзелеп яратам! Сиңа энә очы кадәр дә күңелсезлек китермәс өчен барын да эшләргә әзермен. Тик син дә минем авыр, бик җаваплы хезмәтемнең үзенчәлекләрен аңларга тырыш, акыллым. Миңа кыен булган чакларда түземле бул, кыю бул, сыгылып төшмә. Көләч йөзеңне беркайчан да караңгылык томаламасын. Акыллы күзләреңә, нурлы йөзеңә карап, алардан көч алып яшәсәм, синең саф мәхәббәтеңә лаеклы булсам, юлымда нинди генә авырлыклар, кыенлыклар очраса да, минем өчен алар җиңел булып тоелыр...»

Сәгать иртәнге җиде тулып килә иде инде. Зөлфәт, авыр, йокысыз төннән соң башы каткан хәлдә, ваннага кереп салкын душ коенды. Минут эчендә бөтен арыганлыгы бетеп, башы җиңеләеп китте: әйтерсең лә бик тыныч кына сигез сәгать йокы йоклаган иде. Соры костюм, эчтән ап-ак нейлон күлмәк киеп, көзге алдында чәчен тараган арада, Камилә апа өстәлгә йомырка тәбәсе китереп куйды.

— Нигә кузгалдың инде, әни? Син уянмасын өчен песи кебек кенә йөреп маташам бит.

— И балакаем, бу квартираларда песи кебек йөргәннәр дә ишетелеп тора шул,— диде әнисе.— Үзең дә төне буе йокламый яттың, син йокламаган чакта мин ничек йоклап ята алам? — дип сөйләнә-сөйләнә, улы каршысына килеп утырды.— Синең белән тәмләп чәй эчеп калсам, җаннарыма дәва була, улым, көне буе ашамый-эчми дә йөри алам,— дип, Зөлфәткә дә, үзенә дә алтын путаллы чынаякка чәй ясап куйды.

Сагыну, ярату хисләреннән мөлдерәмә тулган әнисенә Зөлфәт нинди сүз әйтергә дә белмәде. Акча алган саен, ул аңа тәмле күчтәнәчләр, матур-матур бүләкләр күтәреп кайта, әнисенең шул бүләкләрне шатлана-шатлана караганын күреп, үзе дә балалар кебек шатлана иде. Бик күңелле, бик рәхәт аларның тормышлары. Тик ана кеше көне буе,— юк, күп вакытта ярты төнгә кадәр,— улын көтеп өйдә ялгыз утыра. Сөйләшергә кешесе юк. Зөлфәт әнисен кызганып куйды. Әйе, тизрәк Фәһимә белән аңлашырга кирәк. Тизрәк, тизрәк... Әгәр... «сиңа кияүгә чыкмыйм» дисә!.. Күтәрә алырмы Зөлфәт бу кайгыны? Фәһимәдән башка беркем дә кирәкми иң аңа.

Әнисе иркенләбрәк чәен эчеп бетерсен дип, вакыты бик аз булса да, Зөлфәт стакандагы чәен болгатып утырды. Әнисе бер чынаяк эчкәч туйса да, каршысында улы утыргач, тагын бер чынаяк ясап алып, әкренләп эчеп утыра бирде.

Маһруй әби Зөлфәтнең шул кадәр иртә килеп керүенә бераз гаҗәпләнсә дә, шатлыгын яшерә алмый, аксый-туксый аның каршысына килде.

— Әй, рәхмәт төшкере, кайдан гына килеп чыгасы иттең? Уз әле, уз, балам. Бик аптырап тора идем... Менә мондарак утыр әле, бераз киңәшеп алыйк.

Зөлфәт Маһруй әбинең җайлап кына диванга утырганын көтеп торды да, өстәл янындагы урындыкны тартып, каршысына утырды. Өй тулы алма исе: диван астында кып-кызыл булып пешкән әнис алмалары таралып ята иде.

— Алмагыз күп булган икән, әбкәй.

— Сөйләмә инде, балакаем, артык күп булды, бер дә кирәкмәгәнгә күп булды. Тәлгатем алҗып бетте, өйгә дә кайтара, базарга да илтеп сата, иптәшләренә дә тарата. Әле дә әнә бер кәрзин алып кайтты да базарга дип йөгерде, бу алмаларны гына сатам да, иптәш малайның туган көне, шуңа бүләк алырга барам, ди. Бик куркам, улым, иптәшләре күбәйде. Әнисенә дә әйтергә куркам: авырый бит, дәвасы дәва булмавы бар. Алмасы аның чәнчелеп китсен, әнисе дә шулай ди, тирә-күршеләргә бирегез, ди. Тәлгатебез алай-болай акча белән уйный башламасын дип куркам. Кичә дә кайтмады, кунып калды. Әллә, улым, әтисенә телеграмма җибәрик микән, кайтсын микән әллә? Курортка икенче барыр иде әле.

Зөлфәт әйләнә-тирәгә күз йөртте. Чыннан да, эшләр четрекле. Нишләргә? Өченче көн үк әби янына килеп, рәтләбрәк сөйләшеп утырырга кирәк булган. Һаман шул оператив эшчеләргә хас булган житдилек, тапкырлык житеп бетми шул миңа дип, үз-үзен битәрләп алды. Җинаятьчене тотудан бигрәк, җинаятен булдырмау чарасын күрү бит безнең төп бурыч. Зөлфәт житди бер карарга килеп, урыныннан торды да:

— Әбкәй, шалтыратсам, рөхсәт итәсеңме?

— Рөхсәт, балам, рөхсәт, сорап та торма.

Зөлфәт телефон янына килеп номер җыйнады.

— Саша, сәлам дускай! Ял итәсеңме? Бик үтенәм синнән, вакыт табып минем янга килче... Әйе, хәзер үк. Зинһар. Рәхмәт.— Ул Сашага адресын әйтте. Тагын, тагын шалтыратып, өч-дүрт кешене үз янына чакырды. Аннан ул кире Маһруй әби янына килде.

— Хәзергә, әбкәй, Арслан абыйга телеграмма сугып, аны борчымыйк. Син тыныч кына өйдә тор, килененң янына да барып кайт. Тик аңа бер сүз дә әйтмә. Тыныч кына дәвалансын. Мондагы эшне мин үзем җайлармын. Тәлгат өчен дә борчылма, ул акылсыз малай түгел,— дип, әбине тәмам тынычландырып, чакырган егетләрен каршы алырга чыгып китте. Ярты сәгать эчендә дүрт егет җыелып та бетте. Сафа дигәне заводта слесарь, Саша да заводта эшли. Калган икесе студент. Авыл хуҗалыгы институтында укыйлар. Алар Маһруй әбиләр йорты каршындагы эскәмиягә барып утырдылар. Ул арада бишенчесе дә килеп житте. Анысы да заводтан иде.

Егетләрнең шулай тиз арада җыелып өлгерүләреннән бик канәгать булган Зөлфәт аларга хәзер нәрсә эшләргә кирәклеген аңлатты. Ике төркем булып аерылыштылар. Зөлфәт үзе, Сафа белән Сашаны ияртеп, шәһәр үзәгендә урнашкан колхоз базарына китте.

Базар. Нинди генә яшелчә, нинди генә хуш исле җиләк-җимеш юк монда. Грузин, әрмән йөземнәре, мандариннары белән бергәттән, үзебездә үскән, береннән-бере яхшы сортлы алма, яшелчә белән базар тулган. Күзгә муллык. Сатучысының да, алучысының да исәбе-хисабы юк. Лейтенант Мәрдәнов, юлдашлары белән базарны аркылыдан-буйга

йөреп чыкты; һәр алма сатучыны карап, барлап үтте. Ләкин Тәлгат тә, Салих та күренмәде. Инде дә эзләүнең мәгънәсе юк иде. Иптәшләренең вакытлары бик санаулы икәнен белеп, Зөлфәт кайту юлына юнәлде. Су эчеп чыгарга дип базар чатындагы кафега керделәр. Берәр кружка сыра алып, сөйләшә-сөйләшә, эчә генә башлаганнар иде, Зөлфәтнең күзе залның түрендәге өстәл янында тыныч кына сыра эчеп утырган дүрт егеткә төште. Алар арасыннан Тәлгат белән Коляны танып алды. Шунда ук, мөмкин кадәр алар күзенә чалынмаска тырышып, аларга арты белән борылды да иптәшләренә ымлады. Алар бик тиз аңлашып, тиз-тиз генә кафедан чыктылар да, өчесе өч якка китеп, өч урынга бастылар.

Егетләр дә озак көттермәде, йөзләре кызарып, күңелләре күтәрелеп килеп тә чыктылар. Көлешә-көлешә, якындагы автоматка килделәр. Тәлгат будканың эченә кереп, телефоннан шалтыратты, калган өчесе, бер-берсенә мәгънәле генә карашып, кызу-кызу сөйләшеп алдылар. Өстенә соңгы мода белән тегелгән яхшы костюм, ачык зәңгәр күлмәк кигән ак чырайлы Галимне дә, көннең җылы булуына карамастан, өстенә болоньи плащ кигән курнос борынлы, юантык гәүдәле, яшькә барсыннан да олырак күренгән Фәрукны да Зөлфәт танымады. Тәлгат телефоннан сөйләшкәч, иптәшләре янына чыгып, нәрсәдер әйтте. Шуннан соң алар тиз-тиз генә киңәшеп, Тәлгат белән Коля бер якка, ә теге ике егет икенче якка китеп бардылар. Алар артыннан Саша белән Сафа, Тәлгатләр артыннан Мәрдәнов үзе китте. Тәлгат белән Коля бик кызу атлап бер квартал үттеләр дә троллейбуска утырдылар. Зөлфәт тә, аларның эзен яздырмас өчен, артыннан килгән бер «Волга»ны туктатып, шоферга троллейбус артыннан барырга кушты.

## 14

Ял көнне, һәрвакыттагыча, Салихның әтисе-әнисе, Фәһимә апасы — дүртесе бергә иртәнге чәйгә утырдылар. Заһит бүгенге планнарын сөйләп бирде.

— Чәйдән соң бер-ике сәгать өй эшләрен караштырыйк та елга портына китәрбез. Бүген анда «Муса Җәлил» теплоходын каршы алырга халык бик күп төшәчәк. Кыскасы, бик күңелле вакыйгага булачак,— диде.

Мөршидә белән Фәһимә берсүзсез риза булды. Тик Салих кына:

— Үзегез генә барыгыз, сезгә ияреп йөрергә мин инде бала түгел. Тагын ике көннән уку башлана, үзем теләгәнчә йөреп каласым килә,— дип кырт кисте.

— Ягъни мәсәлән, ничек инде ул үзең теләгәнчә? — Улының шундый тупас җавап кайтаруына әтисенең бераз ачуы килде.

— Ну, кая барасым килсә, шунда барам...— дип, Салих сүзендә нык торды.

— Син инде җәй буе үзең теләгәнчә йөрдең, шул да җитмәдемени? — диде әнисе, үз итеп.

— Бу өйдә без синең белән ике ир кеше. Бәлки, мин сиңа компаньон була алырмын? — диде Заһит, улының күзләренә сынап карап.

— Ярар инде, вакланма,— диде аңа Мөршидә.— Иөри икән, йөри бирсен. Ни кызык бар аңа безнең белән?..

Нәкъ шул вакыт телефон шалтырады. Салих кызу гына килеп трубканы алды.

— Ярар, хәзер,— дип, ике генә сүз әйтте дә трубканы элде.— Тәлгат шалтырата, чат башында мине көтеп тора, мин киттем,— диде дә йөгереп чыгып китте.

Заһит бер Мөршидәгә, бер улы чыгып киткән ишеккә карап баш селкеп торды да тәрәзәне ачып урамга күз салды. Ләкин анда Салих күренми иде. Ул бик нык үртәлеп:

— Тагын берәр кабат малай алдында миңа кисәтү ясасаң, мин сиңа үпкәләячәкмен,— диде.

— Соң биг инде, картым, баланың һәр адымын санап утырып булмый. Соңгы көннәрс бит, йөреп калсын инде үзе теләгәнчәрәк.

— Иртәгә уларга жыенмый торгандыр бит? — диде Заһит кырыс кына.— Бүген аның сөйләшүендә дә, күз карауларында да бөтенләй яңа галәмәт чагылып китте. Мөстәкыйль тормышының беренче көннәре әле башлана гына. Сөйләшеп куйыйк: моннан ары Салихны ул әле бала гына дип, бер нәрсә дә аңламый торган сабыйга исәпләмә. Ул инде егет кеше. Ләкин бу әле бар нәрсәне дә үзе хәл итәргә тиеш дигән сүз түгел. Бу яшендә без аңа карата аеруча сак булырга тиеш. Мин моны үземнең малай чагымнан беләм. Безнең киңәштән башка яшәү әле аңа авыр. Аннан шуны да аңла: эти сөйләгән сүзләр беркайчан да вак булмый.

Ул, тыныч кына чәй эчеп утыруыннан туктаган сеңелесенә дә, кулын өстәлгә куеп, иягенә таянып утырган хатынына да карамыйча, залдан чыгып китте.

Мөршидә авыр сулап куйды. Аннары пышылдап кына Фәһимәгә әйтте:

— Заһитның картаюы бу: һәрбер сүзгә бәйләнә, үпкәли башлады.

— Минемчә, абый дөрес әйтте, җиңги, ачуланырга ашыкма аны,— диде Фәһимә.

## 15

Тәлгат белән Коля Салихны Галимнең туган көненә чакыра килгәннәр иде. Кич сәгать җиделәрдә бер квартирада яшьләр җыйнала икән, бар да таныш-белеш, үз кешеләр, эшче яшьләр, ди.

— Бармыйм,— диде Салих.

— Галим үпкәләр, малай,— диде Тәлгат.— Ул бит, беләсең, эшче кеше, сез минем белән дусляшырга теләмисез, интеллигентлар дип ачулана башлар. Аннары күпме бергә йөреп, болай капыл гына өзеп тә булмый бит инде.

— Миңа әниләр рөхсәт итми.

— Мөршидә апа белән үзем сөйләшәм, алайса,— диде Тәлгат.

Әлегә кадәр сүзгә катышмый торган Коля Салихка кулын селтәде дә:

— Нәрсә ялынасың, ялынма шуңа. Подумаешь! Мамкин сынок. Әнисеннән рөхсәт сорарга дисәң — кирәге юк. Куркак ич ул, саран. Өч сум акча кызгана.

Салих кесәсеннән өч сум акча чыгарып Коляга сузды.

— Мәгез! Акча кызганудан түгел, минем тик...— Ләкин ул соңгы сүзен әйтеп бетермәде. Кинәт аның башына кызыклы бер уй килде. «Барырга! Кемнәр икән Галимнең дуслары? Гомумән, кем икән Галим үзе? Бүгенгә Зөлфәт абый белән сөйләшми торам, ә иртәгә барсын берьюлы сөйләрмен...»

— Ярар, барам,— диде ул.— Кая барырга? Әйтегез.

— Сәгать җидегә Ирек мәйданы почмагындагы кибет янына кил, шунда без сине каршы алырбыз,— диде Коля.— Ә акчаңны бир, без хәзер Тәлгат белән калган кирәк-яракларны алырга барабыз.

Салих акчасын бирде дә өенә китте. Уйлана-уйлана кайтты ул. Кызык бер вакыйгага очрап шикелле тоела иде аңа. Тизрәк кич житсен иде. Фәһимә апасы мактап бетерә алмый торган милиционеры да

сизенмәгән бер җинаять эзенә төшәр сыман иде ул. Бик начар эшли милиционерлар. Безне тотарга да уйламадылар. Сыбызгы сызгырткан булдылар, чаптылар, йөгерештеләр. Ә икенче көнне бар да онытылды. Ярый әле, бәхеткә, милиционеры килеп чыкты. Әгәр килеп чыкмаган булсалар. Галим теге кызыкайны нишләткән булыр иде? Аның шушы уйдан да коты очып китте. «Шулай да милиционерлар начар эшли. Әни белеп әйтә: милиционерлар алар үзләре хулиганнар белән дус булып йөриләр, ди. Әнә Тәлгатнең әниннән илле сум акча урлаганнар бит. Өйгә Зөлфәт абыйдан башка кеше кермәгән. Кем белә... Шулай да үзләренә бер караклар компаниясе тотып бирсәм, и кызык та булыр иде!» Шулай хыяллана-хыяллана, Салих өенә кереп китте.

Ләкин ул үзен лейтенант Мәрдәнов күзәтеп торганын башына да китермәде.

Лейтенант Мәрдәнов, Тәлгат белән Коля күздән югалганчы, баскан урыныннан кузгалмады. Салих та өенә кереп киткәч, телефон будкасына кереп, Шәкүровка шалтыратты. Шәкүров, алдан сөйләшкәнчә, аның шалтыратканын көтеп утыра иде.

— Иптәшләр шалтыратты, барасы өйләренең адресларын билгеле. Сәгать җиденче яртыларга облава. Барыбыз да шунда булабыз,— диде Шәкүров.

## 16

— Таныш булыгыз, минем яңа дусларым Салих белән Тәлгат,— диде Галим, кунакларны өйдәгеләр янына алып барып.

Өстәл янындагылар, Колядан башкалары, аягүрә басып, алар белән кул биреп күрештеләр. Кайсы Жанна, кайсы Ниночка, кайсы Сережа дип кулын сузды.

Салих белән Тәлгат уңайсыз гына бер читкә утырып, тирә-юньгә күз йөртеп чыктылар. «Дөрес килдекме соң без монда?» дигәндәй, бер-берсенә карашып куйдылар.

Бүлмә тынчу. Тәмәке исе, аракы исе, стеналарның күгәрек исе — барысы бергә кушылган. Тырпайган чәчле, бизәлгән битле кызлар, аларның чытлыкланып күрешүләре, шушы искә кушылгандай, күзләрне китерә. Фарук дигәне, тышкы кыяфәте белән ыспай гына булса да, Галим сөйләгәнчә, завод эшчесенә бер дә охшамаган. Күзендә ниндидер мәкер, кыланышында дорфалык бар. Аның Коля белән ымлап сөйләшүе Коляга карата да шик тудырды егетләрдә. Салих Тәлгатнең колагына иелде:

— Озак утырмыйк, Тәлгат. Мин монда буылам,— диде.

Галим магнитофон уйната башлады. Жаннеталар, Ниночкалар музыка тавышына, урыннарында утырган килеш, иңсәләрен сикертеп, аякларын тыпырдатырга керештеләр. Ә малайлар, иреннәрен очлайтып, береннән-бере калышмаска тырышып, сызгыра-сызгыра аларга кушылдылар.

Галим:

— Дуслар, музыка уйный торсын, әйдәгез, башкалар килеп җиткәнче, табын әзерли торабыз,— диде.

Кызлар тиз генә төрле-төрле таплар тамган клеенка өстеннән, заманында ак төстә булып, хәзер инде саргаеп беткән ашъяулык җәеп куйдылар. Алар бу өй белән таныш булса кирәк, үзләрен хуҗаларча тотып, Галим белән бергә табын әзерләп ташладылар. Башта бик ярлы гына күренгән өстәл кинәт тулып китте. Ак һәм кара ипи янына кәбестәсе, кыяры, колбасасы, консервасы куелды. Алар янына дүрт-биш баш шешә «ак баш» белән ике-өч шешә кызылы да менеп утырды.

— Чем богат, тем и рад. Сез инде — үз кешеләр, гаеп итмәгез,— диде Галим.

Ул арада өйгә тагын ике егет белән ике кыз килеп керде. Кызлар күз явынны алырдай чибәр иде. Аларны бик ачык чырай белән каршы алдылар. Кочаклаштылар, гөрләштеләр. Яңа кунаклар кесәләреннән эчемлек чыгарып өстәлгә куйгач, табын тагын да тулып китте. Мәҗлес тәҗанлана төште. Яңа килгән кунаклар Салих белән Тәлгаткә ошадылар. Алар тыйнак, мөлаем чырайлы кебек иде.

Коля Галимнең егерме яше тулу хөрмәтенә кунакларга рюмка күтәрергә тәкъдим итте. Салих Тәлгатнең янтыгына терсәге белән төртеп куйды. Бу аның «эчмә» дигән сүзе иде. Башкалар зур гына рюмкага салган аракыларын төбенә кадәр эчеп җибәрделәр. Салих белән Тәлгат авыз да тидермичә куйгач, Салих янында утырган зур кара күзле кыз боларга елмаеп карап әйтте:

— Болай ярамый, егетләр! Галимне хөрмәт итсәгез, беренче рюмканы гына булса да эчегез,— диде. Аннан Галимгә дәште: — Галимчик, синең яңа дусларың эчми, алай прилично түгел, хотя бы беренчесен эчсеннәр,— диде.

Шушы компанияне оештырып, төрлесен төрле һөнәргә өйрәтеп торучы Фәрук янә барлык рюмкаларга аракы салып чыкты да:

— Я, я, кыстатмагыз, эчегез! Без инде, күрәсез, икенче рюмканы күтәрәбез,— дип, Салих белән Тәлгаткә карады.

— Без эчмибез, безгә эчәргә ярамый, әтиләребез ачулана,— диде Салих, монда килгәненә ихластан үкенеп.

— А! Сез бик сабый икән шул әле! — диде Фәрук бер төрле мыскыл белән.— Кая барганыгызны да, күпме эчкәнегезне дә әтиләрегез белән киңәшеп йөргәч, булмады, безнең компания кешеләре түгел сез... Әнә Жанна белән Ниночка — кызлар, шулай да алар әти-әниләренә кая, кемнәргә баруларын әйтеп йөрмиләр. Чөнки алар да, без дә — инде самостоятельный кешеләр. Әтиләр безнең кебек чакта революция ясаганнар, кулларына мылтык тотып сугышканнар, ә без ата-ана рөхсәтеннән башка иптәшләребез янына кунакка да бара алмыйбыз, бер рюмка аракы эчәргә дә куркабыз! Позор! Позор! — диде дә кулындагы бер бәләкәй стаканның тамчысын да калдырмыйча эчеп бетерде. Башкалар да калышмады. Галим Салих белән Тәлгатнең ике арасына утырып:

— Яла якмагыз минем дусларга, алар да самостоятельный. Тәмәке дә тарта, аракы да эчә, кызлар да кочалар!..— диде дә Салихның колагына гына пышылдады: — Янында утырган кызга да игътибар ит азрак, мәмәй булма, ул үзе бит сине сайлап утырды. Чибәр кыз, имансыз! Унөченче мәктәптә укый.

Салих кызга карап алды да башын түбән иде. Ул бу минутта хәзер үк моннан чыгып китү турында уйлана иде. Шулай да, кыстый торгач, алар берәр рюмка кызыл вино эчтеләр. Алар артыннан инде тагын берне эчеп куйганнарын үзләре дә сизми калды. Кызыл винога ак аракы кушып биргәннәр икән, бик тиз башларына китеп өлгерде.

— Әй, музыка!

Радиолада пластинкалар бере артыннан бере алмашынып торган шикелле, Салихны да әле бер кыз, әле икенче кыз биергә чакырып кына торды. Кызларның һәркайсы бик оста һәм җиңел итеп твист бии. Салих та, аякларын чалыш-чолыш басып булса да, биергә тырыша, ләкин ул башкалар кебек бии алмый, шуңардан оялып, читкә китеп утырды да Тәлгатнең бер кыз белән бик оста биюен сокланып карап тора башлады. Кинәт аңа күңелле, бик күңелле булып китте, бер дә куркыр эш юк ич монда, ә ул күне буе эч пошыргыч уйларга бирелеп йөргән була.

Фәрук Галимне читкә чакырып алды да нидер әйтте. Аннары Салих белән Тәлгат янына аракы тулы стопка күтәреп килде:

— Ярый, дуслар, соңгысын күтәрәм. Сезнең белән дуслашу хөрмәтенә! Миңа китәргә вакыт. Сезгә уңыш телим, мәктәпне тәмамлагач, безнең заводка эшкә килегез,— диде.

Салих белән Тәлгат тулы стопкаларны өстәлгә куйдылар да:

— Безгә дә китәргә вакыт, бергә китик,— дип, урыннарыннан кузгалдылар.

— Юк, юк, сез утырыгыз, барыгыз да бергә китәрсез,— диде Фәрук һәм бик кызу чыгып китте. Салих аның тышкы якган шалтыратып ишекне бикләгәнен ишетте.

— Ач ишекне, Галим,— дип, Салих Галим янына килде.

— Миндә ачкыч юк. Ул безне иртән ачып чыгарачак.

— Алдама...— Салих ышанмады.— Бир икенче ачкычны.

— Я инде, селәгәй булма, егет бул! — дип, Коля аны бер читкә этеп җибәрде.— Беребез дә китмибез. Таң атканчы утырабыз, күңел ачабыз.

Шактый исерә башлаган Тәлгат аның Салихны этеп җибәргәнен күргәч:

— Нигә син аны этәсең? Үзең чакырып алып килдең, үзең этәсең! Ач ишекне, Галим. Без китәбез,— диде.

Коля, йөзенә ачу чыгарып, аның каршысына килеп басты.

— Әйттеләр бит бүген моннан китмибез дип! Дуслыкка хыянәт итәргә уйлыйсызмы? Ике рюмка эчмәделәр, боламыкка әйләнделәр.

— Безме боламык? Ах, син, шундый сүзләр белән хурлар өчен чакырып китердеңме? Салих, давай-ка...— Тәлгат Коляны яныннан бәреп җибәрде дә Галим каршысына килеп басты.

— Ач, Галим, ишекне, югыйсә...

— Югыйсә, нәрсә? — диде дә соңгарып килгән чибәр егетләрнең берсе Тәлгатнең тез астына типте. Тәлгат, буынсыз калып, сыгылып төште.

Фәрук чыгып киткәннән бирле, Галим идән уртасында баскан да, бер сүз дә әйтмичә, шушы ямьсез күренешне күзәтә иде. Бүтән көннәрне дә башына бер килеп, бер китеп йөргән уйлар хәзер, нәкъ шушы минутта, аны берьюлы бәтереп алдылар. Кем кемне кыйный? Нигә?.. Минем туган көндә ни өчен сугышалар? Колагында Фәрукның киткәндә әйткән сүзләре яңгырады: «Бу малайларны җибәрмә, кызлар белән төн уздырсыннар, ә иртәгә үзләре үк безне эзләп килерләр. Безнең полкта ишәю булыр». Нинди ишәю? Минем шикелләрме? Фәрук белән минем сыман төрмәдән кайтып, бер эштән икенче эшкә күчеп, буталып йөрүчеләрме? Мин дә шулай башладым бит. Тәлгат белән Салих шикелле, берни белмичә, аңламыйча, билгесез кешеләр компаниясенә эләгеп, кызлар белән гулять иттем, эчтем, урладым...

Бүлмә эче кинәт икегә аерылды. Бер якта Фәруклар, икенче якта Тәлгатләр.

Галим, үзе дә сизмәстән, кычкырып җибәрде:

— Нигә минем дуска суктың, ә? — Чибәр егетнең бугазыннан алды: — Бетерәм! — Бар көченә кизәнеп сугып җибәрде. Бүлмәдә тавыш купты, чырылдап кызлар кычкырган, урындыклар ауган, савыт-саба ватылган тавыш ишетелде. Кемдер, ерткыч җанвар кебек, арттан Галимнең өстенә сикереп капланды. Котырышып, әүмәкләшеп, рәхимсез рәвештә сугыша башладылар.

Монын азагы ни белән бетәр иде, кинәт ишек ачылып китте. Өйгә милиция лейтенантлары Мәрдәнов, Шәкүров, дружиначы Саша, тагын биш-алты егет килеп керде.

Бүлмә эче кинәт тып-тын булып калды. Әле генә ярсынып сугышкан егетләр, хәйран булып, канаган битләрен, борыннарын сөртәләр, милициянең бикле ишектән ничек килеп керүен аңламый торалар иде. Беренче булып Коля аңына килде.

— Ни хакыгыз бар кеше квартирасына рөхсәтсез керергә? Без ял итәбез, иптәшебезнең туган көнен уздырабыз,— дип, алгарак чыгып басты.

Галим хәлсезләнеп урындыкка утырды. Аның тәненә салкын су койдылармыни. Ишек төбендә үзе яши торган урамның участок капитаны Симагин басып тора иде. Ул Галимгә карап башын селкеп куйды. Салих, Зөлфәт абыйсына күтәрелеп карарга да оялып, тәрәзә янына арты белән басты. Ә Тәлгат, иң якын кешесен күргәндәй, шатлык очкыны белән Зөлфәткә текәлде.

— Җыеныгыз! — диде Шәкүров каты тавыш белән.— Сезне машина көтә.

— Бу — башбаштаклык. Законсызлык! — диде Коля әкрен, әмма усал итеп.— Без моны болай гына калдырмабыз.

— Разберемся,— диде лейтенант Мәрдәнов.

Машина җилдерә генә. Алты егет, дүрт кыз тыныч күңел белән, ачык тәрәзә аша шәһәр өстенә, матур табигатькә сокланып барыр урынга, караңгы машина эчендә селкенә-селкенә баралар. Сикәлтәле юлларны узганда, бер-берсенә башлары, я гәүдәләре бәрелеп, сискәнеп куялар. Әле генә бергә эчеп, бергә биеп-җырлап утырган кешеләр — хәзер бер-берсенә ят, берсеннән-берсе чирканып, бер-берсенә күтәрелеп тә карыйсылары килми бара. Тизрәк машина туктасын да, якты дөнья йөзен күрсеннәр иде. Һәркайсы, башын түбән иеп, үзен акларга сәбәп эзли.

Коля машинаның иң түренә утырган да башын килешсез генә пиджак якасы эченә яшергән. Җансыз бер гәүдә кебек, бөтен нәрсәне онытып, уйга чумган. «Аракы эчеп утырган өчен дә, туган көн уздырган өчен дә кешене гаепләргә бер кемнең дә хакы юк. Галим чакырды, мин килдем. Башкасын белмим, Галимне генә беләм». «Ә Галимне каян беләсең?» «Узган кыш ресторанда таныштык, шуннан башкасын белмим». «Ә Тәлгатләр өеннән урлаган илле сум?» Тәлгат үзе ул турыда бер мәртәбә дә сөйләмәде бит. Димәк, карчык әби үзе каядыр куйган да оныткан дип уйлыйдыр. Милиция идарәсендә, һичшиксез: «Кайда эшлисең?» дип сораячаклар. Сорасалар, «эшкә урнаштырыгыз» дип, үзләрен кысып алырга кирәк. Ә Галим белән бер булып Тәлгатләр бакчасыннан алма сатып йөрүне зур гаепкә алмаячаклар. «Салих белән Тәлгатне дә үз юлыгызга тарткансыз»,— дип гаеп итә башласалар? Алар эт түгел котыртканга иярергә!

Хурланудан Салихның бите уттай яна. Ул битен, колакларын тотып карый, бар җире дә ут кебек. «Сәгать ничә бар икән хәзер? Әнидән дә, әтидән дә курыкмыйм: ачуланып көтеп торсалар да, кайтып күзләренә күренгәч, барысын да, барысын да онытачаклар. Тик менә Фәһимә апа күзенә ничек күренермен? Зөлфәт абыйдан да бик оят. «Энеңне тәрбия итә белмәгәнсең, бергә үскәнсез бит» дип, мөгаен, Фәһимә апага әйтер инде. Фәһимә апа болай да, бер сүз әйтсәң, кыпкызыл булып кызара, күзеннән яшьләре чыгам-чыгам дип кенә тора. Бүлмәсенә бикләнеп елар инде. Нигә ул шулай бик тиз елый? Әллә әнисе булмагангамы? Аның күзләре шундый матур, коңгырт, юк, кара... Керфекләре дә озын... Исән-сау өйгә кайтсам, «тол хатын» дип тә үртәмәс идем үзен. Әтиеннең эшләгән җиренә язарлар инде, начар малай үстергәнсез, диярләр... Мәктәпкә язсалар, комсомолдан чыгарып куюлары бар...»

Тәлгатнең күзеннән туктаусыз яшь ага. «Галимне бит мин чын дус күреп, ышанып йөрдем. Эшче егетләр алар саф күңелле, кешелекле була, дигән була әти. Шулмы инде кешелеклелек?! Туган көнем дип чакырды, ә үзләре үртәп сугыша башладылар...: Ярый әле, милиция килеп керде... Миннән никадәр акча алдылар. Табын әзерләргә, имеш, акча алгач та түләрбез, имеш. Колясы да, бурычка дип, аягыма ботин-

кам юк дип, кырык сум алды... Минем бу машинада кайтканны әби белсә, йөрәге ярылып үләр...»

Бу минутта иң авыр хәлгә калган кеше, әлбәттә, Галим иде. Ул ике кулы белән башын тоткан да, гадәтенчә, аскы иренен нык итеп тешләгән. Үләсе килә иде аның бу минутта. Машинага утыртканда аларны өсләренә ап-ак күлмәк, матур костюмнар кигән биш-алты егет озатып калды. Алар дружиначылар, җәмәгать вәкилләре. Яшьләре белән дә Галимнән олы түгел, хәтта аңардан яшьрәкләре дә бар. Тәртип саклап йөриләр. Ә Галим инде мөнә ничә ел тәртип бозып йөри. Капитан Симагинның кечкенә генә соры күзләре белән шелтәләп тә, кызганып та Галимгә карап куюы аны бөтенләй үтерде. Галим төрмәдән кайткач, ничә мәртәбәләр үзенең участогына чакырып, озак-озак аның белән сөйләшеп утырды. Ничә мәртәбәләр кайгыртып өенә килде. Аны эшкә урнаштырды, кичке мәктәпкә керергә ярдәм итте. Ә Галим аңар: «Төзәләм, башкача эчмим...» дип вәгъдәләр бирде. Ә үзе Симагин бер айга отпускага киткән арада нинди эшәкелекләр эшләде.

Күз алдына суд залы килеп басты. Алгы эскәмиядә чәчләре агарган әнисе утыра. Судьяның тавышы: «Төрмә, төрмә!» ди. Юк, юк!.. Елап, егылып үтенер Галим: «Төрмәгә япмагыз, мин төзәлермен, мин гаебемне аңладым, үкенәм!» — дияр. Моннан ары Коля, Фәрук кебек эшәке егетләр — ресторан ябалаклары белән бөтенләй аралашмас. Характеристикага нәрсә дип язарлар икән? «Без аны белмибез, ул әле бездә эшли генә башлады». Цех башлыгы аны ярата иде. Егетләр белән сөйләшер дә, порукага алыйк, дияр. Их, шулай булса, ул көненә өчәр норма эшләргә дә риза булыр иде!.. Ул машинаның стеналарына елышты. Урамдагы тавышны ишетергә теләгәндәй стенага колагын куйды. Урамнан аларны берәмләп машинага кертеп торучы яшь кенә егетләрнең йөзләре күренә, көлүләре ишетелә кебек тоелды аңа. Юк, көлмиләр, аларның да йөзләре кырыс, борчулы. Берсе хәтта, уф дип, тирән сулап та куйды түгелме? Әллә Галимнәрне кызгандымы? Әллә нәфрәтләндеме?.. «Юк, моннан ары болай яшәп булмый. Тик утыртмасыннар гына иде... Моның өчен нишләргә тиеш соң ул? Кылган гаепләрне ничек йоларга? Башны менә шушы стенага бәрергәме?.. Каты итеп, ә?.. Юк, моннан ары болай булмый. Сорау алганда барысын да яшермичә сөйләп бирергә кирәк. Теге кыз турында да. Тәлгатьләрне гаепләмәскә. Барысы да минем аркада булды. Барысына мин гаепле...»

Аның башы кысып-кысып авырта, аркасы манма тиргә батты. «Котылу юк мина. Әгәр арттан кеше килмәсә, ул көнне ни булып бетәр иде... Фу, уйлавы да куркыныч. Ярый әле, арттан кеше килгән, ул, мөгаен, милиционер булгандыр, свисток сызгыртты бит...»

Галим ишек шалтырап ачылганга сискәнеп китте.

— Выходи! — диде милиционерның рәхимсез тавышы.

## 17

Йокысызлыктан күзләре кызарган һәм бик арыган булсалар да, үзләрен нык тоткан тыныч кыяфәтле милиция кешеләре каршыларына утырган егет һәм кызлардан — исем-фамилияләреннән алып бу компаниягә ничек эләгүләренә кадәр — барысын бәйнә-бәйнә сорашып, кәгазьгә язып баралар.

Ике тәрәзәсе дә урамга караган зур гына бүлмәдә лейтенант Шәкүров Салих белән сөйләшеп утыра. Салих бик нык каушаудан кайбер сүзләрен әйтә дә алмый, тотлыгып тора. Җебеп киткән борынын әледән-әле тартып куя, кульяулык алыр өчен кесәсенә тыгыла да туктап кала, тагын борынын тарта башлый. Ул Галим белән кайчан һәм ничек

танышып китүеннән башлап, бүгенге көнгә кадәр булганнарның барын да дөрес итеп сөйләп бирде. Бер генә атна элек, карта уенында бәхәсләшеп, беренче очраган кызны алып китәргә теләүләрен дә, бер дә яшермичә, Шәкүровның соравын да көтмичә, үзе сөйли башлады. Шәкүров тиз генә Мәрдәновны чакырып кертте. Лейтенант тәрәзә янына барып басты да, игътибар белән Салихның йөзенә караган килеш, аның сөйләвен тыңлап торды.

— Мәсьәлә ачык, иптәш Мәрдәнов,— диде ахырда авыр сулап Шәкүров. Салихның атасы-анасы хакына, чын күңеленнән мондый хәлнең булмавын, хәтта бу мәсьәләдә коллегасының ялгышуын теләгән иде ул. Ләкин... Аның йөзе карангыланып, ямьсезләнеп китте. Күкрәге бер төшеп, бер калкып, еш-еш сулу алганы сизелеп тора иде. Ачуына, алдануына түзешә алмыйча, караеп, өстәл яныннан чыкты.

— Заһит абый улы шундый хәлгә төшәр дип кем уйлаган?! Инде нишләргә? — дип ялварып диярлек Мәрдәновка карады.

— Анысын үзең хәл ит инде,— дип, Зөлфәт ишек янына килде.— Малайларның әти-әниләре хафададыр, хәзер Тәлгат белән сөйләшеп бетерәм дә, өйләренә озатырга кирәк. Теге Ниночка дигән кызны да... Кеше көлкесе, нибары уналты яшь икән әле аңа, ә үзенә егерме биш, утыз диярсең! — дип сөйләнә-сөйләнә, икенче бүлмәгә чыгып китте. Анда аның үз участогы егете Тәлгат утыра иде. Тәлгат тә барысын да дөрес итеп сөйләде. Тик Гөлинә турында гына бер сүз дә әйтмәде. Зөлфәт аңа төрле яктан китереп сорау биреп карады. Тәлгат барыбер яшерде. Аның саен Мәрдәнов Тәлгатнең характерын аңлый барды.

«Күңеле бик үк саф түгел моның,— дип уйлады ул.— Эшләгән җинаятен тыныч кына яшереп утыра бела. Әбисе дә, әнисе дә: «Беркатлы, бик гади, бар кешегә дә бик нык ышана»,— диләр иде. Кешегә ышану яхшы сыйфат, әлбәттә. Кешегә ышанырга кирәк. Гади булуы да начар түгел. Әмма гаебен танымаска да өйрәнгән инде бу. Кеше ялгышып куя, җинаять тә эшли, тик шуны соңыннан үзе аңлап, үзе үк төзәтергә тиеш! Шул чакны гына ул җәмгыятькә файдалы кеше була ала. Ә аңламаса, я аңлап та, менә бу егет шикелле, үз гаебен үзе яшерсә, ул чагында — булмый. Киләчәге зур күңелсезлек, хәтта фаҗига белән тәмамланачак. Башта укытучылары белән, әтисе-әнисе кайткач алар белән сөйләшергә кирәк...

Зөлфәт узган шимбәдә төнен аларның, Галим һәм Салих белән бергәләшеп, Гөлинә исемле кызга һөҗүм итү вакыйгасын үзе сөйләп биргәч, Тәлгат куркуыннан калтыранып төште. Сүзен әйтә алмас хәлгә килде.

— Дөрес, әйе... мин бит... ни бит... Зөлфәт абый... Гафу итегез. Мин Галимне кызгандым. Ул бит... ни бит... Ул яхшы егет. Тик ул бәхетсез. Аның бер кеме дә юк. Ул миңа үз тормышын сөйләп күрсәтте инде. Сез Галимне төрмәдән чыккан дисез; менә анысын ул безгә әйтмәде... Инде тагын төрмәгә эләксә, бөтенләй начар була бит!..

Бу сүзләргә ышанмый ярамый иде. Боларын Тәлгат эчкерсез әйтте. Зөлфәткә ул шундук якынаеп китте.

— Кешеләрне кызганып кына аларга ярдәм итеп булмый,— диде лейтенант Мәрдәнов.— Син, уналты яшьлек егет, иптәшеңнең җинаятькә адым ясаганын күргәнсең, ә аңа, тукта, ярамый, дияргә көч таба алмагансың. Бу инде, Тәлгат, синең ихтыяр көчең юклыгын, үз-үзеңне хөрмәт итмәвеңне, шулай ук куркаклыгыңны күрсәтә.

— Мин бит... Галим өчен... Әйтегез әле, аны нишләтерләр инде хәзер? Кабат төрмәме?..

— Анысын халык суды хәл итәр,— диде Мәрдәнов.

Ишектән дежурный сержант керде:

— Иптәш лейтенант, бүлекчәгә китерелгән кешеләр арасында өч

Рәсүл Ишморатова ◆ милиция лейтенанты ◆

үсмер егет һәм бер кыз мәктәп яшендә. Аларны өйләренә озатып куяр өчен машина һәм кеше бирикме? — диде.

— Бирегез,— диде лейтенант Мәрданов, сержант чыгып киткәч, Тәлгат ягына борылды.— Кабаттан без мондый рәвештә очрашмабыз дип уйлыйм. Сүз әле бетмәде. Иртәгә Мәһруй әби янына кереп чыгасым бар. Акчагызны кем алганын әйтергә кирәк. Аны монтёр булып телефон төзәтергә кергән егет — синең «дустың» Коля алган.

Тәлгат тәмам аптырап, бетеп, коелып төште.

## 18

Таң атып килә. Көнчыгыш ягыннан искән җил саргая башлаган яфрак исләрен, кин Иделнең су салкынын тын гына йоклап яткан шәһәр урамнарына тарата. Сүнеп бетмәгән йолдызлар, зәңгәр күк йөзендә үзләре генә хуҗа булып, тоныкланып җемелди. Алар да озакламый сүнәр. Офык тирәсендә ал пәрдә хасил булыр. Кешеләрнең күңеленә үзенең җылы, якты нурларын сибеп кояш чыгар.

Биш катлы зур йортның өченче катындагы өч тәрәзәсеннән дә урамга электр яктысы сибелгән. Башка өйләрдә ут юк. Әллә инде болар шундый салкынча иртәдә тәрәзәләрен үк ачып куйганнармы? Бәлки эсседер? Әллә кунак җыйганнар, я туй булганмы?

Бу — Фәһимә. Гәүдәсен яртылаш урамга чыгарып, тәрәзәдән карый. Төн буе өзгәләнеп Салихны көтте алар.

Башына сулы сөлге урап, Мөршидә караватта ауный.

Заһит бертуктаусыз ишекле-түрле йөреп тора.

Кинәт Фәһимә бүлмәсеннән «ай!» дигән тавыш ишетелде. Заһит бүлмәгә ташланды. Сеңелесенең йөзе агарып киткән иде.

— Абый җаным, анда...— Ул әйтеп бетерә алмады, кулы белән тәрәзәгә күрсәтте.

Заһит тәрәзәгә йөгереп килде.

Подъезд төбенә милиция машинасы килеп туктаган. Бер милиционер машинадан кемнедер чыкканын көтеп басып тора.

— Нәрсә бу?.. Кем бу?..

Машинадан Салих чыкты да, милиционер белән рәттән басып, үзләренең подъездына таба атлады.

— Улым...— дип, әти кеше стенага таянды. Аның башы әйләнеп китте, стена белән бергә идән такталары җиргә упты, бар нәрсәнең асты өскә килде.

Ишектә звонок шалтырады.

Ялан аяк, төнге күлмәктән, Мөршидә атылып килеп чыкты. Фәһимә аның юлын бүлде, култыгыннан тотып, кире бүлмәсенә алып керде. Звонок кабатланды.

Ишектән башта Салих, аннан милиция сержанты керде. Заһит та, Фәһимә дә, өнсез калып, бер Салихка, бер сержантка карап каттылар. Сержант житез хәрәкәт белән уң кулын козырегына куеп:

— Шушы повестканы тапшырырга рөхсәт итегез,— дип, Заһитка сарырак төстәге кәгазь сузды. Аннан тагын кулын фуражкасына куеп: — Сау булыгыз,— дип, житез генә чыгып та китте.

Заһит, кәгазьне тоткан килеш, ишек янында басып калды. Аннан көч-хәл белән генә залга керде. Аңарга каршы, өстенә халатын кия-кия, Мөршидә бүлмәдән чыкты.

— Нәрсә булган? Ни бар?..

— Әнә улыңны кадерләп кенә милиция сержанты китереп куйды,— диде Заһит, үзе кәнәфигә утырып, кулындагы кәгазьгә текәлде:

«30 август, 11 сәгать 30 минутта 12 нче участокка, лейтенант Шәкүров янына килергә.»

Заһит, калтыранган кулы белән повестканы кесәсенә салып, улына карады.

— Я, сөйлә, нинди хәбәрләр белән безне сөендерергә уйлыйсың?

— Сөйләмәсен, бер нәрсә дә сөйләмәсен! — дип килеп кушылды Мөршидә.— Әнә каеш ал да, ичмасам, шуның белән тиресен туна. Бу нинди әшәкелек, төне буе өйгә кайтмый йөрү! Сәгать унда кайтам, диден бит. Яхшылыкның, иркәләгәннең кадерен белми башладың, бөтенләй узындың!..

Дүртесе дүрт җиргә басып, алар озак кына тын тордылар. Тәрәзәдән өйгә таң нуры сирпелде. Төн буе керфек какмаган булсалар да, йокы качкан — йокы кайгысы түгел иде.

Салих, бер нәрсәне дә яшермичә, аларга башыннан узганнарны сөйләп бирде.

Ата белән ана гамьсез яшәүләренә, бердәнбер улларының айдан артык вакыт җинаять сукмагында йөргәнлегеннән бер хәбәрсез булуларына шаккатып, гаҗиз булып, өнсез утырдылар. Күңелсез дә, оят та иде.

Иртәгә Заһит нинди йөз белән участокка барыр? Әле бит белеп булмый, Салихны нинди җәза көтә?

Шомлы тынлыкны Мөршидә бозды.

— Фәһимә акыллым, иртәгә иртүк Зөлфәтеңә бар да Салих турында әйт: ул безнең участок милиционеры Шәкүров белән сөйләшсен, ичмасам. Абыеңның эш урынына, мәктәбенә дә житкерсәләр — хурлык бит, валлаһи!.. Зөлфәтне кешелекле, һәйбәт кеше дисең бит, күрсәтсен менә шундый вакытта кешелеген...

Заһит, ни әйтергә белми гаҗиз булып:

— Ни сөйлисең син, Мөршидә, акылыңа кил! — диде.— Салих исән-сау кайтты. Безгә хәзер шунысы мөһим. Минемчә, барын да күреп, аңлап кайткан. Әгәр менә бүген төнне лейтенант Мәрданов, безнең шикелле, эш сәгате бету белән тыныч кына өенә кайтып йоклап ятса, бәлки, малаеңны бүтән күрмәгән дә булыр идең...

## 19

Инде бу якшәмбене ял итәрмен, Фәһимә белән бергәләп бакчаларда йөрермен дип уйлап куйса да, Мәрданов түзмәде, сәгать уннар тирәсендә милиция участогына килеп утырды.

Эче поша, күңеле тыныч түгел иде.

«Бала тәрбиясендә кайсыдыр бер звенода өзеклек бар. Югыйсә, нәрсә инде бу? Ун ел буе укытабыз, пионер вәгъдәләре, комсомол антлары алабыз. Павел Морозов, Олег Кошевойларны гел тукып торабыз. Ә Галим урамда йөри. Ә Фәрук белән Коля үсмер егетләргә укытучылардан көчлерәк йогынты ясый алалар. Нилектән? Эш юк үсмерләргә, гел вәгазь тыңлап тору туйдыра. Бала табигате шөгыль таләп итә. Фәруклар, Галимнәр үсмерләрне моңарчы күрелмәгән яңа вакыйгалар белән мавыктырып алып китәләр. Ә Галим үзе ник урамда? Нилектән ул җинаять юлына баскан?»

Лейтенант Мәрданов, тәҗрибәле өлкән иптәше капитан Симагин белән бергәләп, Галимнең тормыш юлын өйрәнеп чыкты, сорау алган чакта катнашты.

Үзе өчен ул менә нәрсә ачыклады.

Галимнең әтисе юаш холыклы булган. Завод директорының урынбасары. Унбиш ел гомер иткән беренче хатынын бала тапмаган өчен аерып җибәргән. Кырык яшендә унтугыз яшьлек чибәр кыз Һашиягә өйләнгән. Яхшы квартира, мебель, завод машинасы Һашияне бәхетле итә. Ул иренә ике малай — Галим һәм Камилне бүләк итә. Еллар уза,

Галимнең этисе картая, Һашия чибәрләнеп тула. Галимнең этисен инфаркт түшәк өстенә егып сала. Ул вакытыннан алда пенсиягә чыга. Чәче коела. Һашиягә күңелсез, ире белән сөйләшер сүзе юк, көннәр буе кайдадыр югалып йөри һәм, ниһаять, үзеннән яшьрәк бер инженерга кияүгә чыгып, баласын авыру иренә калдырып, китеп бара. Галимнең этисе кайгыдан эчә башлый, семья таркала, тәртип тә, тәрбия дә бетә...

Галим үз көнен үзе күрә башлый.

Акчаң булмаса, акча бирә торган, бер кайда да эшләми, матур итеп күңел ача белә торган дуслар табыла.

Дөнья гел кәеф-сафадан гына тормас бит. Унсигез яшендә Галим Рахманов суд эскәмиясенә эләгә. Гастрономда бер хатынның сумкасыннан акча урлаганга аны өч елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Амнистия белән бер елдан котыла. Капитан Симагин — милиция идарәсендә бүлек начальнигы — аны заводка урнаштыра. Бар да җайланды кебек, юк икән шул: ул өйдә югында әнисе яшь ире белән аларның иркен квартирына кайтып утырган. Үги ата калын кара кашлары астыннан аңа усал итеп карап йөри. Әнисе Һашия, ирсез калудан коты алынып, гел үги ата җаеннан гына тора.

Галимгә тагын көн юк.

Ул кайдадыр читтә, бүтән кешеләр белән күңел бушлыгын тутырырга тиеш...

...Мәрдәнов уйларына күмелеп утырганда ишектән дружинник Саша Алексеев килеп керде. Гадәтенчә пөхтә киемле, әле генә парикмахердан чыккан: чәчләреннән җиңелчә одеколон исе бәреп тора.

— Төне буе йокламадым, иптәш Мәрдәнов,— диде ул, Зөлфәт каршына утырып.

Мәрдәнов аның ябыгып киткән аксыл чыраена карады.

— Мин дә йокламадым. Белмим, безнең берәребез йоклады микән? Бик соң кайтылды бит, таң аткан иде инде. Душ алдым да, бер стакан куе чәй эчеп, урамга чыктым. Бераз йөргәч, килеп утырдым әле менә...— Аннан Сашага карап алды: — Ә нигә килеп утырдым, үзем дә белмим...

— Мин дә синең янына эч пошканнан килдем,— дип, Саша тагын көрсенеп куйды.— Бер уйласам, җәмгыятькә файда китерәм: тәртип урнаштырып йөрим. Хулиганнар куам, исерекләрне милициягә китерәм. Ә бит, икенче уйласаң, просто чепуха, туйдырды бу хәл. Чынлап әйтәм, туйдырды! Кичә бит көнем исерекләр артыннан йөреп узды. Хатын ачулана: вакытыңны әрәм итәсең, ди. Беткән башлар артыннан чапканчы ял көнендә, ичмасам, театрга барсак, җан азыгы алыр идек, ди. Ә никадәр нервы бозыла? Шундый матур егетләр, кызлар... Хурлык, билләһи! Этә-төртә машинага төйисең. Айнытып чыгарасың. Очы-кырые буламы моның, юкмы? Нәрсә җитми ул кабахәтләргә? Киемнәрен кара син аларның! Нейлон да капрон, йон да ефәк... Ашаганнары бал да май. Ни өчен кешеләрнең тынычлыгын бозып йөри алар? Кадерле минутларны урлыйлар? Кайчакта, инде башкача дружинник булып йөрмим дип, дежурга да чыкмый калам. Иртән уянсаң — яңа хәбәр: кемнеңдер бүреген салдырганнар, эштән кайтып килә торган кызны җәберләгәннәр. Чыдап булмый, тагын дежурга килеп, төннәр буе шулар артыннан чабасың.

Сашаның үпкә сүзләре күп иде. Заводның алдынгы эшчесе, әйбәт гаилә башлыгы, заводта да, өендә дә мәшәкать җитәрлек аңа. Үзенең ике кызы, бер малае бар. Ул менә шулар белән үткәрәсе вакытын эт койрыгына тагып йөри. Саша күңеленә җыелганны ярсып, әрнешеп сөйләде-сөйләде дә кинәттән генә бик кискен нәтиҗә ясап куйды:

— Артык гуманный кыланабыз. Аяусыз булырга, көрәшнең яңа методларын табарга кирәк.

— Ягъни? — диде Мәрдәнов, ачыкларга теләп.
— Кайсыдыр бер яңа шәһәрдә участокларга овчарка биргәннәр.
— Соң?!.— диде Мәрдәнов, гаҗәпләнеп.
— Соң, шул инде, төне буе унбиш-егерме дружинник телен чыгарып, шәһәр буйлап чабып йөрми, участок уполномоченные, овчарка эте һәм аның хуҗасы үз участокларын бик тыныч кына әйләнеп чыгалар. Төннең берендә капка-койма буйларында эшсез өелеп торган салагаларга бер генә сүз әйтәләр: «Балакайлар, өйгә кайтырга вакыт».
— Кайталармы?
— Хикмәт шунда да шул: әйтү белән кайтып китәләр.
— Ник?
— Эт бик гадел хайван, кушканны үти бел. Гуманист булып кыланмый. Ату нәрсә килеп чыга: ниндидер бер хулиган кисәге бөтен урамның тынычлыгын алып йөри, ә син аңа замечание дә ясама, дөньяда юк сүз белән ул сине мыскыл итәчәк. Аңа юл ачык хәзер, кешене түгел, овчарканы мыскыл итсен.
— Юк, бу — бердәнбер чара түгел.
— Кем әйтә бердәнбер чара дип?! Мин моны кирәкле чараларның бер звеносы дип карыйм. Ә менә шул яңа шәһәрдә, беләсең килсә, кичләрен тәртип урнашкан, эшче халык милициягә рәхмәт әйтеп хатлар яза,— дип, ярсынып-кайнарланып сөйләде-сөйләде дә Саша, саубуллашып кайтып китте.
Ул киткәч, лейтенант Мәрдәнов ледерин тышлы көндәлек дәфтәре белән киңәшеп, күңелендә туган уйларын шул дәфтәренә язып утырды.
Бераздан аңа полковник Борһанов шалтыратты. Хәл-әхвәлен сорашты. Кичәге эшләре белән танышуын әйтте.
— Ничек соң? — диде Мәрдәнов, сабырсызланып.
— Нигезләвең әйбәт. Миңа ошады. Берничә үсмерне бозык йогынтысыннан аерып алуың бигрәк тә яхшы. Хәзер шуларны күзәтү астыннан ычкындырмаска кирәк.
— Ычкындырмабыз, иптәш полковник. Киңәшегез өчен рәхмәт.
— Иртәгә миңа кереп чыгарсыз. Иркенләбрәк сөйләшербез. Хәзергә шул! Туктале, нишләп сез ял көнне участокта утырасыз, иптәш лейтенант?
— Бераз эшләрем бар иде, иптәш полковник.
— Хәзер үк участоктан чыгып кит! Ничәнче ял инде эшләп утырасың, йокы күрмисең!
— Слушаюсь, иптәш полковник.
Борһанов трубканы элде. Лейтенант Мәрдәнов трубканы бераз кулында тотып торды да көлеп җибәрде. «Ял ит,— ди, ә үзе ял көне дип тормаган, кабинетына килеп, минем материаллар белән танышып чыккан».
Аның күңеле күтәрелеп китте. Дәфтәрен өстәл тартмасына бикләде дә, плащын, йолдызлы фуражкасын киеп, урамга чыкты. Сабыр да, рәхәт тә бер тойгы белән:
«Бәлки әле Фәһимәне дә очратырмын»,— дип уйлады.

1970—1971

## Фәнис Яруллин

### Кеше

Көчле дә син, көчсез дә син,
Кеше дигән бөек зат.
Ачып кына карап булмый,
Күңелең — хикмәтле йозак.

Йолдызларга менәсең син,
Галәмнәрне гизәсең.
Ә үзең бөтен галәмнән
Серлерәк бит, сизәмсең.

Йөз диңгезне кичәсең син,
Йөз диңгездә батмыйсың.
Ә кайчакта бер баткактан
Чыгар әмәл тапмыйсың...

Йөз кайгыга түзәсең дә
Бер кайгыдан авасың.
Белмисең син, белмисең син
Үз көчеңнең чамасын...

### Һәйкәл булып

Безнең авыл — шактый зур авыл,
Урамнары яшел үләнле.
Өч йөз йорты аның үзара
Сөйләшә күк күргән-белгәнне.
Ә сөйләшер сүзләр күп алар,
Күңелләргә бары син кагыл.
Имәндәй йөз ирен югалткан
Бер сугышта бары бер авыл.
Өч йөз йортның уртак кайгысын
Бергә кушып һәйкәл салынган.
Кояш чыга безгә һәр көнне
Әнә шушы һәйкәл ягыннан.
Ә кичләрен һәр көн урамда
Җыр канатын җәя як-якка:
Күңел ачкан чакта балалары
Сакта тора кебек аталары.
Һәйкәл булып карап еракка...

## Бер мизгелгә

Язгы елга бозын каерып аткан кебек,
Җитез юрга йөгән салып чапкан кебек,
Кара болыт яңгыр булып аккан кебек
Бер бушанып калсаң иде борчулардан:
Күз алдыңнан китсен иде язмышың да,
Йөрәгеңне кимермәсен ялгышың да,
Һичбер төрле уй калдырмый бу көндәлә
Бушанасы килә, дуслар, бер мизгелгә.

## Төсләр өләшәм

Бер чишмә бар безнең бакчабыз артында.
Яратабыз аны суы бик салкынга.
Кояшлы көннәрдә чишмәгә төшәм мин.
Юамын битемне, суларын эчәм мин.
Шаярам, чәчрәтәм, басам да ак ташка.
Учыма салып бөркимен кояшка.
Бөркегән суларым гөлт итеп кабына.
Күк йөзе күп төрле төсләрдә чагыла.
Алы бар, сарысы, кызылы, зәңгәре...
Чишмәдә икән лә дөньяның бар яме.
Ал төсне сайлыймын алмалар манарга.
Зәңгәрен алмыймын — калдырам таңнарга.
Сарысын өләшәм бодайга, арышка.
Яшелен бирәмен судагы камышка.
Төсләрнең ниндиен тели соң җаныгыз?
Кызганмыйм берсен дә: килегез, алыгыз!

## Аптырыйм

Янәшәмдә өч күрше,
Бик охшаш бу өчесе:

— Үләм! — диеп кычкырсаң да,
Ишетмидер һичберсе.
Хатын белән әрләшсәк
Хәтта пышылдап кына,
Өч күрше дә ишетә —
Өч баш була ишектә.

●

Тора торгач хатын һәм ир
Була диләр икесе бер.
Мин дә, дуслар, ышанамын
Бу сүзләрнең хаклыгына.
Әкрен-әкрен югалам мин,
Калып бара хатын гына.

## Рашат Низамиев

### Привалда

Пилоткамда — поход тузаннары,
Ике битем буйлап тир ага.
Шушы хәлдә, сабый бала сыман,
Карап торам менә дөньяга.

Курыкмагыз, урман чәчкәләре,
Таптап узар диеп итектән.
Бер утырып яшел печән исен
Сулый алсам, миңа шул җиткән.

...Хәлләремне аңлыйлардыр кебек
Күпне күргән кырлар, урманнар,—
Бармакларым минем канга түгел,
Каен җиләгенә буялган.

### Кич

Китеп бара менә түгәрәк көн
Мәшәкатен төяп сыртына.
Шундый мизгел урап ала хисне —
Әйтерсең лә матур җыр тына.

Көтү кайткан, урам тынган инде,
Көн кызуы беткән сүрелеп.
Рәшәткәгә кунган тузан гына
Язмышыннан ята сүгенеп.

Вакыт белән тарткалаша кояш,
Таулар түбәсенә таянып.
Шушы җирне ташлап китү аңа
Бик аяныч кебек, аяныч!

Җиле качкан, өрми этләре дә,
Уйга баткан чагы дөньяның.
Топольләргә хәтле тынып калган,
Карт философ кебек уйланып.

**Нигъмәт Ихсанов**

# ДАВЫЛДА

хикәя

Ерак диңгез буендагы Саскылах поселогыннан шомлы радиограмма килде: «Жылы киемнәре булмау сәбәпле берничә аучының кул-аягы өшеде. Берсе, давылга эләгеп, өйгә кайтмады. Эзлибез».

Райпотребсоюз председателе, үзенең ярдәмчесе Шамил Исмәгыйловны чакыртып, радиограмманы укып күрсәтте дә:

— Хәзер үк Саскылахка барып, андагы эшләрне тикшереп кайтырга кирәк. Шунда беррәттән кешеләр өшү мәсьәләсен дә ачыкларсыз. Квартал бетәргә нибары бер ай вакыт калды. Саскылахтан тиренең җүнләп килгәне юк, сыйфаты да әллә ни түгел,— диде.

— Аяк-кул өшетү сирәк була торган хәл инде ул... Эшләп бетермәгән кәгазьләр бар иде бит, минә син, ә... Барырга кирәк булгач, нишлисең инде,— дип, Исмәгыйлов ризасыз гына сөйләнеп куйды.

— Кәгазь качмас. Кешеләрнең хәлен ачыклап кайтырга кирәк,— диде председатель.

— Мин әле мондагы күп нәрсәне белеп бетермим, Тихон Егорович, гафу итегез: безнең болан белән эттән башка транспортыбыз да юктыр әле,— диде Исмәгыйлов. Ул моны барасы юлының шактый ерак булуын күздә тотып әйтте.

— Кызганычка каршы, юк шул. Болан да этләр генә...

Исмәгыйлов райпотребсоюзда яңарак кына эшли башлаган иде әле. Эшне ничектер җайга салырга кирәк дип борчылып йөри иде. Шуңа күрә председательнең бу тәкъдиме бер уйлаганда урынлы да булды кебек...

Ә менә хатыны Наилә аның тота-каба дигәндәй ашыгыч кына ерак юлга чыгарга җыенуын өнәп бетермәде.

— Килеп җылынып җитмәгән — әллә кая җәһәннәм астына җибәрәләр. Үзең атлыгып торасыңдыр әле,— диде.

— Шулай кирәк, җаным. Эшем шундый бит. Аннары, ул тирәләрнең табигатен дә, кешеләрне дә күреп кайтырмын,— диде Исмәгыйлов, хатынын юаткан сыман.

— Алайса, җылырак киен,— диде хатыны, йомшый төшеп.— Менә боларны ки,— дип, иренә дәү киез итекләр белән толып китереп бирде.

Ишек төбенә пар болан җиккән нарта килеп туктады. Өстенә башлыклы болан туны, аягына камус[1] кигән каюр[2] килеп керде. Аның башында бала башлыгына охшашлы бүрек, кулларында уч төбе ярыклы бияләй — барысы болан тиресеннән.

Каюр өйгә килеп керү белән:

— Исәнмесез, иптәш Исмәгыйлов! — дип шаулап исәнләште дә: — Боланнар әзер, юлга чыгарга мөмкин,— диде.

— Яхшы,— диде Исмәгыйлов, киенә башлап.

Каюр, идәндәге толып, итекләрне күргәч, кычкырып көлеп җибәрде. Табак бите тагы да җәелә төшкән сыман булды, чем-кара күзләре кысык кына булып җелтерәп тора башлады.

— Ә-әй, иптәш Исмәгыйлов, мондый итек белән тундрада юлга чыгалармыни? Тагы бу толыпны да кисәгез, тирән карда атлый да алмассыз!..

— Менә бит. Әйттемме мин сиңа, ә? — диде Шамил хатынына.

Хатын:

— Мин бит ни...— дип, ык-мык итә башлаган иде дә, каюрның капчыктан мех киемнәр чыгара башлавын күргәч, тынып калды.

— Мәгез, менә боларны киегез. Бик әйбәт булыр,— диде каюр Тит.

Шамил киенеп бетеп, башына бүрек кенә киясе калгач, Наилә, елмая-көлә, аның бүрек бавын бәйләште.

— Менә хәзер син чын котып аучысы булдың инде, Шамил. Мылтыгың гына юк.

— О! Мылтык бар, патрон да җитәрлек! — диде Тит.

Кар өстенә саргылт төс иңдереп, ерактагы офыктан беренче кояш нурлары күренде. Боланнар бик җитез бара, нарта артында кар тузаны бөтерелеп кала.

Тундрадагы кар яланнарының иге-чиге юктыр кебек. Ара-тирә генә куаклыклар, төркем-төркем кәрлә наратлар очраштыргалый. Аларның ботаклары кар авырлыгыннан сыгылып төшкән, кояшта ялтырап-ялтырап китәләр. Ап-ак кар сахрасында бу агачлар диңгез уртасындагы көймә төсле генә күренәләр. Күк йөзе чалт аяз — иксез-чиксез тундраны зәңгәр гөмбәз белән каплап куйган шикелле.

Исмәгыйлов авыз эченнән генә нindидер көй көйләп барды-барды да кинәт тынып калды. Янында таныш түгел якут кешесе булгач, татарча җырлап баруны яхшысынмады.

— Җыр тыңларга яратам мин. Ник туктадыгыз? — диде каюр.

— Минем туган як җырлары ул, Тит дускай, сезнең тундрага килешеп бетмәс бит.

Тит боланнарны шул ук тизлек белән чаптыра биреп, озын колгасы белән әле уңга, әле сулга таба юл күрсәтә-күрсәтә, аларны куаклыклар арасыннан уздырды.

— Безнең котып ягында да яхшы җырларыбыз күп, әкиятләребез, дастаннарыбыз бар.

Шулай дигәннән соң, Тит якутча җыр сузарга кереште. Ул җырлап бетергәч, Исмәгыйлов:

— Ни турында җырладың? — дип сорады.

— Баһадир Олонхе турындагы атаклы җыр бу,— диде каюр.

Якутлар матур җырлый икән. Мондагы табигатьнең үзеннән туган шикелле, җырларында беркадәр кырыслык та, моң-сагыш та бар.

Сөйләшеп бара торгач, вакыт узганы сизелмәде дә. Боланнар акрынрак бара башлады. Кәрлә урман, куаклар сирәгәя-сирәгәя,

[1] Камус — болан тиресеннән теккән аяк киеме.
[2] Каюр — юл йөртүче.

бөтенләй күренмәс булды. Хәзер инде алда урыны-урыны белән иңкү, урыны-урыны белән калку, ялангач кар сахрасы гына иде.

Кай арададыр күк йөзен болыт каплап өлгергән. Боланнар да акрын бара. Каюр ара-тирә озын колгасы белән аларның сыртларына төрткәләп ала. Тит боланнарның ачыккан, өшәнгән иканлекләрен, колга белән куып кына барып булмаслыгын белә.

— Тит-Арыга барып җитә алмабыз, ахры: боланнар арыды, бу тирәдә азык барын да сизә башладылар. Кунарга туры килер,— диде каюр.

— Ялан кыр уртасындамы? — дип гаҗәпләнеп сорады Исмәгыйлов.

— О! Аның бер куркынычы да юк. Палатка корып куябыз, юртадан да әйбәтрәк булачак.

— Ничек итеп, каян алып?

— Безнең бөтен әйбер бар. Әнә артта тимер мич, безнең аста гына утын. Әнә, күрәсезме, күктә аллы-гөлле бөҗралар пәйда була. Төньяк балкышы диләр аны. Озакламый давыл буласын белгертә,— диде Тит.

Исмәгыйлов башын күтәреп офык ягына күз салды: анда, чыннан да, аллы-гөлле төсләргә кереп балкып торган катлы-катлы бөҗралар хасил булган. Аларның балкуы отыры көчәя бара, шәүләләре инде кар өстендә чагыла башлаган иде. Исмәгыйлов үз гомерендә беренче тапкыр күргән бу могҗизадан күзен ала алмыйча, сокланып карап торды.

Аллы-гөлле төсләрен балкытып уйнаган шул могҗиза яктысында боланнар мөгезендәге бәс һәм сыртларына оешып каткан борчак-борчак боз кисәкләре дә екияттәгечә энҗе бөртекләредәй булып тоелды.

Боланнар, буран буласын сизенеп, башларын бутыйлар, әледән-әле туктыйлар. Каюр кашларын җыергалап:

— Таён белән очрашырга туры килмәгәе,— дип куйды.

— Кем ул? — дип сорады Исмәгыйлов.

— Таён — хуҗа дигән сүз. Сезнеңчә әйтсәк — давыл була.

Шул вакытта Тит, Исмәгыйловка терсәге белән төртеп, читкә таба күрсәтте:

— Әнә килеп тә җитә инде. Күрәсезме — әнә анда өерелә-өерелә кар күтәрелә. «Таён» ул. Койрыгы шактый озын булыр, ахры.

Шулай дигәч, Тит тимер очлы кыскарак таяк алып, нартаның табан тоташтырмалары арасына карга батырды да тезгенне тартты. Боланнар шундук башлары белән нартага таба борылдылар.

Тит юлдашына:

— Аркагыз белән борылыгыз, бияләй бауларыгызны киегез, югыйсә, җил очыртып алып китәр,— дип әйтеп кенә өлгерде — кар өермәсе бөтерелеп битләргә китереп бәрде. Тирә-юньне буран каплап китте.

Исмәгыйлов җылы кухлянкасына төренә төште, башлыкның йөз ягындагы тар гына ярыктан мышнап сулу ала башлады. Җил, аны нартадан төртеп төшерердәй булып, аркасына басып-басып этә. Берни күрерлек, берни ишетерлек түгел. Әллә нинди тавышлар белән сызгырып-улап кар өермәләре генә котырына. Вакыт-вакыт нарта урыныннан кубып китәр төсле тоела. Җил, шакаткыч бер кодрәт иясенә әйләнеп, тоташ кар ташкынын куып тора иде.

Җилнең көче йомшарган араларда, Тит, юатырга тырышкандай, юлдашын аркасыннан каккалап ала иде.

Шулай да Исмәгыйловның эченә курку төшә бара. Әйтерсең җил аларны куптарып алган да һавадан очыртып бара. Исмәгыйлов алга таба бөгелгән дә шул килеш утыра бирә. Каюрга эндәшеп карады,

тик үз тавышын үзе дә ишетмәде. Үзләрен кар астында күмелеп калган кебек хис итте. «Бетүебез шушыдыр, күрәсең!» — дип уйлады.

Җил бераз йомшый төшкән арада, авыр-авыр сулап:

— Тит! Нишлибез? Харап булабыз бит! — дип кычкырды.

— Бик әйбәт! Буран арттан бәрә бит! — дип җавап кайтарды каюр, берни булмаган кебек.

«Исе дә китми. Бик зур батырлык бит бу!» — дип уйланды Исмәгыйлов һәм үзе дә бераз тынычлана төште.

Кар давылы сәгатьтән артык котырынды. Шуннан соң җилнең көче йомшап, кинәт басылып та китте. Күктә, болытлар арасыннан, ай килеп чыкты. Сыек кына ай яктысында тез тиңентен карга батып басып торган боланнар күренде. Нарта күренми — калган бөтен нәрсәне кар күмеп киткән иде.

Исмәгыйлов өс-башындагы карларны каккалады да башлыгын ача төшеп, тирә-ягына күз салды. Алар Тит белән бил тиңентен кар эчендә утыралар. Алда тоташ бер стена булып соргылт-кара болыт китеп бара, болыт артыннан күк аязып килә иде.

Каюр ком шикелле каты кар эченнән тиз генә чыкты да, Исмәгыйловны да торгызышкач, җиңел сулагандай әйтеп куйды:

— Ярый, зыянлы булмады. Тизрәк азыклы урынга барып җитәргә кирәк. Күп булса биш чакрым ара калгандыр. Шунда җиткәч, палатка корырбыз,— диде.

Исмәгыйлов әле Титка, әле өсләрендәге карларны кагынып селкенгәли башлаган боланнарга карап:

— Бер чакрым да бара алмаслар алар хәзер! — дип әйтеп куйды.

— Баралар! Хәзер алар туңганнар, ул урынны да беләләр. Бик әйбәт барачаклар. Аннары, яңадан да давыл булуы ихтимал. «Таен»ның энекәшләре дә булмагае: койрыгы бик озын иде,— диде Тит, колгасын күтәрә башлап.

Нарта уңлы-суллы авышкалап кузгалып китте. Калкулык түбәсенә менделәр. Җил андагы карны бөтенләй себереп алып киткән иде. Тит, карлырак җирләрне сайлап, боланнарны әле уңга, әле сулга боргалады.

«Бу якларда халыкка тормыш итүе авырдыр, салкынына да, бураннарына да түзеп яшиләр. Шулай да һәркемгә туган ягы газиз. Нинди булса да башкага алыштырмыйлар»,— дип уйланды Исмәгыйлов.

Үр түбән боланнар сикереп чаба башладылар, аннары бераздан — каюр нартадан җиргә сикереп төшүгә — шып туптадылар.

— Җитәр, шушында кунарбыз,— дип, Тит юлдашына кирәк тоттырды.

Исмәгыйлов урын әзерләп кар көрәгән арада, каюр, җыелган палатканы сүтеп, терәкләр какты һәм палатканы корып, бауларын тарттыра башлагач, кисәк кенә каты җил китереп бәрде.

— Тизрәк бул! Менә бу ыргакларны эләктер, югыйсә, эш харап! — дип кычкырды Тит.

Исмәгыйлов ыргакка үрелергә өлгермәде — көчле җил аны каты кар өстеннән шудырып алып китте. Бер мизгелдә ул Титның кул болгавын гына күреп калды, аннары бөтен тирә-ягын тоташ кар пәрдәсе, караңгылык каплап алды. Исмәгыйлов кул-аяклары белән каты карга ябышырга тырышып карады, чокыр сыман җиргә башын төртеп, давыл узганын көтәргә кирәк дип уйлады. Әмма көчәйгәннән-көчәя барган давыл өермәләре аны нартадан читкә таба шудырып бара иде. Исмәгыйлов нишләргә дә белмәде, йөрәгенә шом, курку төште, бу мәхшәр давылы аны үлемгә таба өстери кебек тоел-

ды. Һәм ул ярдәмгә чакырып ачыргаланган тавыш белән кычкыра башлады. Иәрәге күкрәк читлегеннән чыгарга җитешеп тибә, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә, бите-башы шыбыр тиргә баткан, битенә сарган кар бөртекләре эреп, муенына агып төшә иде. Давыл аның бер кулындагы бияләен дә йолкып алып китте.

Каюрның ярдәмгә килүеннән өмет өзеп, хәлсезләнеп, шуышып барганда Исмәгыйлов каты бер нәрсәгә орынып киткәнен тойды һәм шундук ике куллап әлеге әйбергә ябышты: кар астыннан чыгып торган таш кисәге иде бу. Исмәгыйлов бөтен көче белән шуңа ябышты. Җил йомшабрак киткән араларда карга чокыр кебек нәрсә казып азапланды. Сыенырлык булгач, шунда башын төртте. Аның ялангач кулы туңып, берни тоймас хәлгә килгән. Колак төбендә, бөтен җир өстен себереп алып китәрдәй булып, давыл ажгыра иде.

Бераздан җил тыйлыга төште, ул да түгел, давыл кинәт тынып калды. Җир өстен ай яктыртты. Ләкин Исмәгыйлов поскан җиреннән чыгарга ашыкмады, әлеге мәхшәр давылының яңадан кузгалуыннан курыкты, кайдадыр еракта дөп-дөп иттереп ике тапкыр мылтык аттылар. «Тит булырга тиеш! Миңа сигнал бирүе»,— дип, Исмәгыйлов, сөенеп, үзалдына сөйләнеп куйды һәм таш артыннан торып, кулын селкә-селкә:

— А-ау! Тит! Мин монда!..— дип кычкырды.

Давыл котырынган чакта Исмәгыйловны таба алмаслыгын белеп, Тит нарта янынннан китмәгән, үзен бау белән нартага бәйләп куйган иде. Менә хәзер ул юлдашын эзли китте. Давылның юнәлеше буенча чамалап, Исмәгыйловның эзенә басып диярлек барды һәм аны үзләре туктаган төштән шактый еракта эзләп тапты.

— Искәрмичәрәк килсәгез, менә шулай да була ул, иптәш Исмәгыйлов,— диде Тит, аны күргәч.

Исән калуына чиксез сөенгән Исмәгыйлов, сүзләрен көчкә оештырып:

— Бик зур рәхмәт сиңа, Тит. Мине үлемнән коткардың,— диде. Башын күтәреп күккә карагач, анда тагын кара болыт килгәнен күрде...

Алар яңадан палатка корырга керештеләр: бау очына бәйләнгән тимер чөйләрне җиргә кактылар, уртага терәк утыртып, палатканы корганнар һәм кырыена кар өеп кенә өлгергәннәр иде — яңадан каты җил китереп бәрде.

Тит, биленә бау бәйләп, бер очын Исмәгыйловка тоттырды да шуышып диярлек нарта янына барды, нартаны палатка ишеге төбенә тартып китереп, андагы бөтен әйберне палатка эченә кертте һәм юеш битләрен бияләе белән сөртә-сөртә:

— Инде куркасы юк. Давыл дулый бирсен. Менә хәзер тимер мичне ягып җибәрәбез, палатка эче мунча булачак,— диде.

Җил катырак бәргән саен палатка терәкләре шыгырдап-сыгылып китә, брезенты киерелеп тартыла. Исмәгыйлов куркынып шунда карана. Палатка менә-менә авып китәр кебек тоела аңа.

— Хәзер аны ат белән дә кузгата алмассың,— диде Тит, мичкә чәйнек куеп.

Гаҗәпләнерлек тә шул! Тышта ажгырып-сызгырып кар давылы котырына, ә монда палатка эче торган саен җылына бара. Бүрек, башлыкларны салып куйдылар. Хәзер инде алар чәй эчеп утыралар.

Исмәгыйлов туңып өши язган кулын болан мае сөртеп бәйләп куйды.

— Давыл кузгалганчы туктарга булмый идеме? — дип сорады ул, бая кичергәннәрен исенә төшереп.

— И агай, очраган бер җирдә туктый башласаң, ике көндә дә барып җитә алмассың. Әгәр мин алай йөрсәм, балаларымны ач кал-

дырам бит. Кешеләр дә көләр үземнән. Аннары, ул Таенның хикмәтләрен белеп тә бетермәссең: кайвакыт читләтеп, канат очы белән генә сыйпап китә. Менә шуннан бел син аны,— диде Тит, чәй чөмерә-чөмерә.

Ашап-эчеп алгач, Тит, биленә бау бәйләп, икенче очын Исмәгыйловка тоттырды да боланнар муенына кыңгырау тагып керде. Шуннан соң чишенеп, йокы капчыгы эченә керде һәм гырылдап йоклап та китте.

Каюрдан күреп, Исмәгыйлов та чишенде, йокы капчыгына кереп ятты. Тик байтак вакыт күзенә йокы төшмәде. Башында төрле уйлар чуалды. Бүген давылда кичергәннәрен исенә төшерде, хатынын, балаларын күз алдына китерде.

Ул йокыдан уянганда каюр палаткада юк иде. Тимер мичтә шарт-шорт утын яна иде. Бераздан чәйнек капкачы шалтыраганы, тышта кыңгырау чыңлаганы ишетелде.

Тамагын кыргалап, палаткага Тит килеп керде, ишек төбенә ап-ак төлке ташлады да:

— Тозакта берничә көн яткан булырга тиеш. Аучысы авырып киткәндер. Алмасаң — бүреләр ашар. Пунктка тапшырырбыз. Анда кем тозагы икәнен беләләрдер,— диде.

Иртән көн аяз, салкын иде. Тагын бер тундра полосасын узгеннан соң каюр:

— Тит-Арыга җитеп киләбез,— диде.

Исмәгыйлов, офыкка таба текәлеп-текәлеп караса да, поселокка охшашлы нәрсә күрмәде.

Шул вакыт Тит нартадан ялт кына сикереп төште дә тезгенне тартты.

— Ни булды?

— Күрәсезме — карда бүре эзе! Яңа гына узганнар: бүген төнлә йөргәннәрдер. Берәр каза ясамый калмаганнардыр: тук икәнлекләре күренеп тора. Әнә, ничек эре-эре сикереп барганнар! — диде Тит, күзләрен елт-елт йөртеп.

Бүреләрнең монда төньякта болан хуҗалыгына зур зарар китерүләре турында Исмәгыйловның ишеткәне бар иде инде.

— Әнә! Әнә берсе сикереп-сикереп чаба. Мин аны хәзер!.. — дип, каюр тиз генә мылтыгын алды да гөрселдәтеп атып җибәрде.

Бүре, сөрлегеп китеп, борыны белән карга төртелде, ләкин шундук сикереп торды да тагы йөгерә башлады.

— Тимәде!..— диде Тит, кулын селкеп. Һәм мылтыгын нартага кире куйганда: — Алар боланнарны буудан бигрәк, куркытып качырып бетерәләр. Аннары тундрадан эзләп кара син аларны — бик ерак китәләр, хәтта бөтенләй юкка да чыгалар...— дип сөйләнде.

Исмәгыйлов, Титны тыңлый-тыңлый, тирә-юньгә каранды. Боланнар үрне менүгә, алда ике кеше күренде. Алар да өсләренә болан тиресеннән теккән җылы тун, аякларына камус кигәннәр, чаңгылары да бар, иңнәренә мылтык асканнар иде.

Каюр боланнарны туп-туры аларга таба юнәлтте.

— Көтүчеләрдер, боланнарын эзлиләрдер,— диде Тит.

Чыннан да көтүчеләр булып чыкты. Әйтүләренә караганда, бүреләр җиде боланны буганнар. Егермеләбе көтүдән аерылып киткән. Шуларны эзләп йөрүләре икән.

Тит, аларның хәленә кергән кебек:

— Ай-ай! — дип башын чайкап куйды, аннары: — Ярхан сырты янында бүре эзләре күп, шул тирәдән эзләп карагыз,— дип киңәш итте.

Көтүчеләр, Титның киңәшенә күңелләре булып, Ярханга таба китеп бардылар.

Болытлар ертыгыннан, кылчык сыман нурлары белән күзне камаштырып, кояш килеп чыкты. Тит боланнарны уңга борды.

— Әнә теге озын мачтаны күрәсеңме? — диде ул, колгасын сузып. Тит-Ары радиостанциясе ул.

Исмәгыйлов та мачтаны күрде. Озакламый кара төртке сыман нәрсәләр дә шәйләнә башлады: болары яртылаш карга күмелгән йортлар икән. Бераз баргач, морҗалардан чыккан төтеннәр дә күренде.

Кызыл флаг эленгән бер йорт янына боланнарны китереп туктаткач, Тит:

— Килеп җиттек, иптәш Исмәгыйлов. Моннан ары этләр белән илтерләр, күп ара калмады,— диде һәм башлыгын төзәтебрәк киде дә: — Хатыныңа хат язасыңмы? — дип сорады.

Исмәгыйлов ашыкмый гына нартадан төште. Аның Титтан аерыласы килми иде. Шулай да, уйлана торгач, каюрның үз эше бар, минем — үз эшем, дигән нәтиҗәгә килде. Титка рәхмәт әйткәч, өйдә чакта юлга уйный-көлә генә дигәндәй җыенуларын хәтерләп, әйтте:

— Хатынны бик куркытма инде син анда. Бик әйбәт барып җитте, диген.

Исмәгыйлов Тит-Арыда ике көн булды. Аучыларны җыеп сөйләште, мондагы хәлләр белән танышты,ниләр җитмәвен, нәрсәләр кирәк икәнлеген белеште.

Байтак кына аучыларның юл йөрергә ни этләре, ни боланнары юк, чаңгы белән көненә утызар чакрым җир йөриләр, аннары дарыядрә кебек иң кирәк нәрсәләрне дә вакытында җибәрмиләр икән. Бер аучы шуны әйтте:

— Ичмасам, кургаш дигән нәрсәне җитәрлек итеп бирсеннәр иде. Ядрәне без үзебез ясыйбыз. Үзебез койган әйбәтрәк,— диде.

Исмәгыйлов, хәлне әйтеп, районга радиограмма сукты. Тиреләрне район базасына озатканчы складта ничек саклау, базага җибәргән чакта ничек төяү турында күрсәтмәләр биргәннән соң, иң аргы пунктка — Саскылахка юл тотты.

Хәзер инде ул болан түгел, тугыз эт җигелгән нартага утырып бара. Алдагы эт башлык булып санала икән. Шунысы кызык: башка этләр юлда барганда гына түгел, туктагач та башлыкны тыңлыйлар икән. Тегесе бер ырылдауга, башкалары шундук койрыкларын кысып, аның күзенә генә карап торалар.

Каюрдан үзгә буларак, эт йөртүченең кулында озын колга түгел, чыбыркы икән. Борылырга кирәк булса, сүз белән генә әйтә: «төк-төк» дисә — уңга, «цок-цок» дисә, сулга була.

Эт йөртүче Семён — таза гына егет — бик аз сүзле якут булып чыкты. Өстәвенә, русча белүе дә чамалы икән, Исмәгыйлов исә якутча бөтенләй белми әле. Шул сәбәпле, бу юлы шактый күңелсез иде аңа.

Бу тирәләрдә инде тундра үзгәрәк. Әледән-әле яссы-җәлпәк ташлар очрый. Кайберләре шактый зур булып, кар астыннан кыя таш сыман калкып торалар. Таш күбрәк төшләрдә аучылар алардан куыш сыман нәрсәләр корып куйганнар: таш араларын тире белән каплап, түбәсен япканнар да юрта шикеллерәк бер нәрсә килеп чыккан.

Шундый куышларның берсендә төн кунарга да туры килде. «Йортның» хуҗасын күреп, сөйләшә башлагач, Исмәгыйловның аңа исе китте. Чал сакаллы бер карт иде ул. Аның инде оныкларын багып, мич янында гына утыра торган чагы, ул әле һаман ауга йөри, җәнлек ата икән. Русча әйбәт белүенә дә исең китәр: бик дөрес, бик төзек итеп сөйли, тыңлап утыруы бер рәхәт.

— Революциягә кадәр без монда ау айларында гына килә идек, ә хәзер бөтенләйгә шушында торып яшибез,— ди.— Бала-чага мәктәптә укый, бер өлеше — Тит-Арыда, бер өлеше — Күсүрдә,— ди.— Авырсак, фельдшер килеп карый. Кызыл чум[1] аша газета-журнал-лар алдырабыз. Фактория безгә бөтен кирәк-яракны биреп тора. Кыскасы, без бик канәгать. Элекке замандагы кебек түгел,— ди.— Элек, тире налогын түләмәсәң, кыйныйлар да иде. Менә шуның эзе,— дип, карт битендәге җөйне күрсәтте.— Начальник камчысы белән суккан иде.— Шуннан соң ул дәртләнебрәк китеп: — Язга менә радио кертәселәр. Аннары безнең тормыш тагы да күңеллерәк булачак,— диде.

Иртән соң гына тордылар. Исмәгыйлов урамга чыкты. Кояш нурында кар өсте күзне камаштырып җемелди иде.

Семен этләрне ашата, нарта бер читтә тора иде. Исмәгыйлов бу хәлгә беркадәр гаҗәпләнде, чөнки Семен гел ашыга торган иде, ә бүген вакытында аны уятмаган да, хәтта этләрне дә җигеп куймаган.

— Кузгалырга кирәк, Семен,— диде Исмәгыйлов.

— Кузгалу кирәкми: зур давыл буласы,— дип җавап бирде егет.

— Нинди давыл? Әнә бит көн нинди, чалт иткән кояш. Саскылахка бүген аучыларның җыелышын җыярбыз дип хәбәр иткән идек бит. Халык көтәр-көтәр дә таралыр, аннары яңадан җыеп йөрербезме? Ара әллә ни ерак түгел — утыз чакрым гына.

Семен, каршы килергә кыймыйча, этләрне җигәргә кереште.

Кузгалырга әзерләнеп беткәч, таш «йорт»тан хуҗа карт чыкты. Һавага күз салып алды да Семенга:

— Этләрне кызганма, бик каты ку. Давыл кузгалмагае. Бу тирәләрдә гел ялан җир, тотыныр-сыеныр урын юк, диңгезгә хәтле очыртып алып китәр,— диде.

Аннары, акыл өйрәткән бер төс белән, якутча нидер әйтте. Семен бер сүз дә җавап кайтармады, ярар-ярар дигән шикелле баш кына каккалады.

Картның бу сүзләреннән соң, Исмәгыйлов икеләнә башласа да, кире чигенәсе итмәде, шүрләде дип уйлаулары бар.

Саскылахка барып җитәргә инде биш чакрым чамасы гына ара калгандыр. Кояш болытлар артына кереп качканга да байтак вакыт инде. Сул кулда, әллә ни ерак та түгел, диңгез култыгының зәңгәр бозлары күренә, ә диңгез үзе бераз арырак иде.

Беренче тапкыр очрагандагы кебек, давыл бу юлы да кинәт башланды. Этләр беркадәр ара нартаны җилгә каршы тартып бардылар да, кинәт давылга артлары белән борылып, җиргә яттылар.

— Нартага яхшылап тотын, юкса, җил диңгезгә алып китәр үзеңне,— диде Семен, кулы белән диңгез ягына ишарәләп.

Шуннан соң ул нартадан төште дә чыбыркысы белән этләрне торгызырга кереште. Исмәгыйлов, давылга аркасы белән борылып, әйбәтләп нартага тотынды.

Тирә-юньне сызгырып-улап торган кар өермәләре басып китте. Алда Семенның этләргә кычкырганы, этләрнең чиный-чиный өрүләре ишетелә. Нарта әле кисәк тартылып китә, әле бөтенләй туктап кала. Исмәгыйлов борылып алга карауга, битенә, күзләренә энә очыдай чеметтереп, каты кар килеп бәрелде, һәм ул Семенны да, этләрне дә күрә алмады.

---

[1] Кызыл чум — кызыл почмак.

Давыл сәгатьтән артык дәвам итте. Тик Исмәгыйлов бу юлы инде элеккесендәге кебек курыкмады. «Үтеп китәр. Тегесеннән исән калдык, бусы да шуннан артык булмас»,— дип уйланды ул.

Бераздан этләр дәррәү өрергә тотындылар, нарта җилдертеп тау түбән төшә башлады. Семен йөгереп барышлый нартага ауды да:

— Яхшы! Озакламый этләр сине дә, мине дә коткара,— дип кычкырды.

Чыннан да, бераздан читтәрәк эт өргәне ишетелде, һәм аннары нарта бер йорт янына килеп туктады.

Саскылахның кырый бер йорты иде бу.

Бераз вакыттан соң Исмәгыйлов белән Семен бүлмәдә җылы мич янында утыралар иде инде.

Саскылахта нибарысы утызлап йорт бар, халкы ау белән генә көн күрә икән.

Моннан бер көн элек аягы-кулы өшегән аучыны табып поселокка алып кайтканнар. Исмәгыйлов, фельдшер белән киңәшкәннән соң, махсус нарта җиктереп, авыруны район больницасына озаттырды.

Райпотребсоюз председателенең: «Менә үз күзегез белән күреп ышанырсыз, тундра җирләрендә бу йомшак алтынны бик авырлык белән табалар» дигән сүзләрен Исмәгыйлов тагын бер тапкыр исенә төшерде.

Ерак сәфәрдән кайтып күрешкәч тә, Тихон Егорович аңардан:

— Я, ничек булды? — дип сорады.

— Бик яхшы! — диде Исмәгыйлов.— Барысын да үз күзең белән күрми торып, эшне дә дөрес оештырып булмый, кешеләрне дә җитәкли алмыйсың.

— Хикмәт тә шунда шул,— диде председатель.

— Кеше түгел — алтын алар! Хәйлә, алдау дигән нәрсәнең әсәре дә юк аларда. Намуслы, тырыш, кыю кешеләр. Ә сез аларның нинди сабыр булуларын, үз эшләрен яратуларын күрсәгез икән...

Исмәгыйловның дәртләнеп сөйләргә керешүен күреп, Тихон Егорович елмаеп куйды һәм аны сөендерергә теләгәндәй:

— Сез больницага китерткән аучының кул-аяклары исән, баш бармагын гына кистеләр,— диде.

**Барлас Камалов**

КамАЗ көндәлеге

# УЛ ҺАМАН СОЛДАТ



Өстәлдәге анкеталарның берсенә күзем төшү белән, хәтеремә Һади Такташның «Киләчәккә хатлар»ындагы юллар килде.

> **«...Матур кызның йөзенә караудан да**
> **Элек анкетасы карала».**

Юк, мин анкета аясенең кем баласы булуын белергә теләмәдем. Чыннан да бит, шагыйрь алдан күреп әйткәнчә, безнең «чорда, шиксез, социаль чыгыш

> **Зур бер нәрсә итеп каралмас.**
> **Кемнең кемнән тууы, атасының**
> **Кем булуы гаеп саналмас...»**

Хәер, ул чыгышы белән дә әллә кем түгел икән. Бу турыда алдарак сүз булыр. Мине хәзергә кәгазьдәге сорауларга җавап язган кешенең бүләкләре хакындагы мәгълүматлар игътибарымны җәлеп итте. Анда документ теле белән бик кыска итеп: «Ленин ордены, «Почет билгесе» ордены, ике Кызыл Йолдыз ордены, III дәрәҗә Дан ордены, 7 медаль» дип язылган иде.

Шугарны укыгач:

— Оһо! — дигәнемне сизми дә калдым. СССР Махсус монтаж эшләре министрлыгының Кама автомобиль заводы төзү буенча Баш идарәсе парткомы секретаре Лерон Курамшин, ниндидер кәгазьләр актаруыннан бүленеп, миңа карады.

— Шәпме? — диде ул, күңелле елмаеп.— Бездә мондый кешеләр аз түгел, иптәш...

Партком секретаре үз подразделениеләрендәге кадрлар белән горурлануын яшерергә теләми иде.

— Танышырга мөмкинме бу анкета белән?

— Сезгә, журналистларга, мөмкин. Танышыгыз. Аннары бая сөйләшкәннәргә үзегез ук йомгак ясарсыз... Дәүләтнең күпме акчасын тотып, инженер дипломы алгач, станокка баскан эшчене дә мактыйсыз сез кайчак. Янәсе, күрегез! Безнең гади эшчебез дә нинди! Бу, йомшак кына әйткәндә, җитди түгел. Ә менә гади эшчедән, әүвәлгерәк еллардагыча әйтсәк, кара эшчедән инженер булган кешене күккә чөеп зурласаң да җирендә. Ул инде кадр, үз эшенең бөтен баскычларын энәсеннән җебенә кадәр биш бармагы төсле белгән оста...

Моңа кадәр кеше белән танышуымны анкетадан башлаганым юк иде. Хәерле булсын, партком секретаре үзе рөхсәт биргәч, мин бу кәгазьгә язылган белешмәләрне йотлыгып укырга керештем. Ә соңрак Зөфәрнең үзе белән дә таныштым.

Зөфәр Садретдинов — алда аталган министрлыкның КамАЗ корылышындагы Баш идарәсенең начальнигы — уртачадан аз гына калкурак буйлы, гәүдәгә таза гына кеше икән. Күзләре гел көлеп тора.

Гадәттә без, очерк геройларыбызның тыйнаклыгына басым ясарга теләп, үзе турында бик саран сөйли, күбрәк иптәшләре, коллектив хакында фикер әйтергә тырыша, дип язабыз. Зәфәр Садретдинов андый түгел. Кыю монтажчылар хакында бик күп матур сүзләр әйтү белән бергә, үзе турында да, семьясы хакында да, сугышта күргәннәрен дә җәелеп китеп сөйли, рәхим итеп тыңла гына! Әмма мин-минлек юк инде, шапырыну юк, үзен алгы планга куярга тырышу юк. Күпне күргән ирләрчә, төпле итеп, нигезле итеп, еллар узганнан соң байтак нәрсәне ер-яңача анализлап, бәя куеп сөйли ул. Турысын әйтим, аның белән очрашкан саен, мин күңелемә киртләп үрдым: мондый иптәшләр белән әңгәмә корырга килгәндә, мин әйтәм, журналист алдан ук әзерлек күрергә тиеш. Югыйсә, төп башына утырып калуың да ихтимал. Техника яңалыклары белән атнаныкын-атнага танышып баралар. Агымдагы политикада кыйблалары бик туры. Синең сорауларың беткәч, акрынлап-җайлап кына әдәбиятсәнгать яңалыкларын сораштыра башлыйлар. Бик мөмкин, сине капшап караудан да түгелдер мондый хәл. Очрашкан икәнбез, мин дә белешкәләп калыйм әле, диюдәндер. Тик, ничек кенә булмасын, татар әдәбиятыннан һәм Академия театрының спектакльләреннән, фәлән яшь композиторның тәүгән әсәреннән башланган әңгәмә рус әдәбияты һәм сәнгатенә күчә, ул да түгел, инженер иптәш чит ил әдәбияты яңалыклары хакында сүз кузгата, Ля Скала театрының атаклы җырчысы репертуарындагы җырларны мактый һәм туксан яшь тулу уңае белән зур күргәзмә оештырган Пабло Пикассоның хезмәт дәртенә соклана. Шахмат буенча дөнья чемпионы титулы өчен булачак көрәшнең нәтиҗәләрен күрәзәлек итә башлый.

Әңгәмә куерып китеп, сәгатьләр үткәнен дә искәрмибез. Тәзелеш колачы, көн саен баш калкыта торган кыенлыклар һәм алардан арына бару хакында байтак сүз алып баргач, мин сорауларның Зәфәр Садретдиновның үзенә генә карагаңнарын бирергә тырышам.

— Сез минем анкета белән таныш бит инде,— диде ул һәм рәхәтләнеп көлеп куйды.— Аңа нәрсә генә өстәрмен икән? Анкетадан тыш та байтак сайрадым бугай...

Әйе, мин анкета белән җентекләп таныштым. Анда язылганнарга таянып һәм Зәфәр үзе сөйләгәннәрдән дә чыгып, кайбер нәрсәләрне укучыга да әйтә алам.

Зәфәр Садретдинов — тумышы белән Башкортстаннан, ярлы татар семьясында 1924 елда дөньяга килгән. Туган авылы — Каридел районында. Байкыбаш дип атыйлар аны. Зур авыл, матур авыл. Заманында район үзәге дә булып торган.

Газиз әнкәсе янына, туган-тумача, кардәш-ыру һәм, гомумән, авылдашлары янына хәзер дә эзне суытмый ул, еш кайта.

— Шунсыз тора алмыйм,— ди идарә начальнигы.— Аннары бит туган авыл хакында Габдулла Тукаебыз ничегрәк дигән әле? — Зафәр бер тынга гына күзләрен йомгандай итә. Сизәм, шигырь юлларын хәтерләргә тели.

> **«Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,**
> **Билгесездер кая ташлар бу тәкъдирем;**
> **Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,**
> **Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем»,—**

дип укыгач, миңа карый. Дөрес укыдыммы, янәсе. Мин «Әйе!» дип ым кагам.

Ә бу дөньяда күргәннәре байтак аның!

Садретдин агай Зәфәр бик яшь чагында дөнья куя. Әнисе Саимә апа, дүрт баланы канат астына җыеп, тол кала. Ул чагында Зәфәрдән яисә сеңелесе Хәлләдән ни өметләнәсең әле, хәтта олы балалар дигәннәре Тәслимә белән Нәфисәдән дә һич ни көтәр җай юк. Өстәвенә, еллары нинди иде бит!

Кыскасы, Зәфәр җидееллыкны гына туган авылда тәмамлый. Аннары туган-тумачалары янына Можга шәһәренә күчеп китәләр. Тәрәзәләрне аркылы-торкылы кадаклап, ишеккә йозак элеп, төп нигездән аерылуларның ни икәнен үз башына төшкәч кеше генә аңлыйдыр. Китәләр, китми хәлләре юк. Кыз балалар, ачыксалар-тилмерсәләр дә, әниләренең күзләренә карауга, тып-тын калалар, ә менә гаиләдә бердәнбер ир бала — Зәфәр, тамырларында ир заты каны йөгергәнгәдер шул инде, тизрәк ачыга, ашый башласа да колагы селкенеп тора, кыстатырга исәбе юк. Уйный-уйный да Саимә түти каршына йөгереп керә.

— Әнкәй, аш тиз пешәме инде? Бик тә карыным ачты,— ди.

— Аш кичкә инде, улкаем, кичкә,— ди бүтән җавап таба алмаган әнисе.— Барыбыз бергә утырып ашарбыз, балам...

Можгада да чәчеп-игеп, урып-сугып куймаганнар инде. Алай да өлкән кызлар эшли башлагач, алай гына да түгел, Зөфәр үзе дә Сюгинск пыяла заводына өйрәнчек булып кергәч, өс-баш әллә ни бөтәймәсә дә, тамак туярлык акча керә башлый, «Тук кешенең уе бар, уе барның җае бар» дигәннәр борынгыда. Зөфәр дә килер көннәре турында уйлана. Пыялачы һөнәрен үз итә алмагач, бу эшкә җаны ятмагач, тракторчы булырга карар кыла. Тәгаен генә әздереп әйтә алмаса да, хәтерендә: туган авылының чирәмле урамына беренче киртләч эзләр салган трактор артыннан ул да, кыска балаклы штан кигән Зөфәр дә, таң калып чапкан иде. «Шәп машина икән! — диешкәннәр иде авыл малайлары.— Алдыннан тартучы, артыннан төртүче юк, элдертә генә. Җитмәсә, сабан сөрә, ди әле ул. Ашаганы-эчкәне керосин, ди. Вәт әкәмәт!»

Семьялары белән Свердловск өлкәсенең Озерск леспромхозына күчеп килгәч, корыч айгырны үзе иярләшә инде ул. Тракторы гөрләп эшләгәндә куанычы эченә сыймый иде. Урман эше гомер-гомергә иң авыр хезмәт саналган, тик авырлыклардан сыкрамады Зөфәр. Ул үзенең семья терәгенә әверелүеннән башы күккә тиярдәй булып йөрде. Егет хыяллары тыелгысыз, киләчәккә өметләре салават күпередәй матур иде. Ләкин чалт аяз көннәрнең берсендә, мең тугыз йөз кырык беренче елның егерме икенче июнендә, кояшны болыт каплагандай булды. Гитлерчылар өере туган илебезгә басып керде.

Зөфәр шомлы хәбәрне кайтып әйткәч, түрдә чәйләп утырган Саимә апа авызындагы ризыгын чәйнәп йота алмый торды.

— Илгә-көнгә афәт инде бу, улкаем! Асыл ир-егетләр башына купкан зилзилә! Һай, муены астына килгере шул герман этләрнең! Без белгән гомердә генә дә икенче кат яу кузгаталар бит мәлгуньнәр! Инде ни хәлләр итәрбез, балакаем?!

Ни хәлләр итәсен Зөфәр дә анык кына күз алдына китерә алмый иде. Шул кадәресе иртәгесен үк ачыкланды: әзмәвердәй агайларны сугышка алдылар. Бер смена урынына икене эшләргә туры килде. Эш артты, ә яңа техника кайтуы кимеде. Тракторлар берәм-берәм сафтан чыга торды. Ямарга-ялгарга, тизәтергә һәм урман чыгаруның бермә-бер арткан планын һичсүзсез үтәргә кирәк иде. Зөфәр Садретдинов һәм аның яшьтәшләре, ирләрен алмаштырган хатыннар көнне төнгә ялгап тырыштылар. Сырт сынса да сынатмаска, авыз тулы кан булса да төкермәскә, дошманга сер бирмәскә кирәк иде. Бөтенесе фронт өчен, барсы да җиңү өчен эшләнде.

Беравыктан, 1942 елның җәендә, Зөфәр тракторы белән дә, әнисе һәм туганнары белән дә саубуллашты. Ул фронтка — ут эченә китте. Яшь егетне танкка утырттылар. Взвод командиры машинасында радист-укчы иде ул...

Сугыш биографиясе бай аның. Орденнары һәм медальләре шуның шаһите. Һәммәсен бәйнә-бәйнә сөйли китсәң, үзе бер китап булыр иде.

Сугыш юлы урау. Рейхстаг өстенә Җиңү байрагы кадагач та Зөфәр сафта кала әле. Германиядәге безнең гаскәрләр группасында хезмәт итә. Свердловск өлкәсенә ул 1947 елда гына кайтты.

Җиңеп кайткан гвардия сержантын урман хуҗалыгында сагынып каршыладылар. Аны урман хуҗалыгы эшчеләре профсоюзының җирле комитеты председателе итеп, ә берничә айдан район комитеты председателе итеп сайладылар. Коллектив белән эшләүнең җаваплылыгын да, мәгънәсен-тәмен дә Зөфәр Садретдинов шунда тоя башлагандыр. Җитәкче работникка хас сыйфатлар аның характерында әнә шул елларда бөреләнгәндер.

Еллар үтә торды. Зөфәр Садретдинов леспромхозның транспорт бүлеге мөдире булып та, начальник урынбасары булып та эшләде. Склад мөдире булган чаклары да, базага җитәкчелек иткән вакытлары да булды. Тик аны бер нәрсә борчый килде — белеме үстерәсе бар.

Шуннан соң ул, әнисеннән хәер-фатиха алып, Куйбышев өлкәсенең Ставрополь шәһәренә китте. Кичке мәктәпкә кереп укыды, өлгергәнлек аттестаты алды һәм Куйбышев индустриаль институтының кичке бүлегенә укырга керде.

Тормышның үз законы, үз таләпләре бар. Дөнья куып күп вакыт узды, ә Зөфәрнең парлы тормыш корганы юк бит әле. Көннәрнең берендә Юрий Книпович белән (шәп дус, хәзер Тольяттида төзелеш трестының баш инженеры) парлап йөргән ика

чибәрне очраттылар алар. Сүзгә кесәгә керәсе юк, егетләр чибәр. Кызлар да сер бирә торган түгелләр. Очрашып киткән беренче көндә үк алар якын танышлар булып киттеләр. Тора-бара Саратов кызы, финансистка Надя (хәзер инде Надежда Васильевна) Зөфәрнең рухи канатына әверелде.

Өйләнү — өйле булудан алынган сүздер. Ә Зөфәр Садретдиновның ул вакытта торак шартлары мактанырлык түгел иде әле.

— Тулай торактан китәргә кирәк иде,— ди ул, үткәннәрне искә төшереп.— Квартира юк. Ак мунча сатып алдым. Бер ел мунчада яшәдек. Үз дигәнең белән куыш та җәннәт диләр дә соң... Җәннәт булмаса да, гаилә рәхәтен әйтеп бетерәсеңме?!.

Инде хәзер өлкән кызым Ирина Куйбышев политехника институтының студенткасы, ә кечесе Лариса урта мәктәптә укырлык булгач, ул көннәр кайдадыр еракта калган төсле тоела...

Аның анкетасындагы кайбер язганнарны укыгач, бер мәлгә сәерсенеп калган идем: Куйбышев индустриаль институтының электротехника факультетын тәмамлап, инженер-энергетик булган егет, 1957 елда Куйбышевгидростройның промышленность районы начальнигы булып эшләгән җиреннән кинәт мастер булып эшли башлаган. Сәбәп нәрсәдә? Әллә үз эше буенча ышанычны акламаганмы? Юк, алай түгел икән. Үгетләүләренә, кыстауларына карамастан, институтта өйрәнгән үз һөнәре буенча эшләргә керешә ул. Әйе, хезмәт хакы да ким, персональ машина да юк, колач та элеккечә түгел. Әмма эш анда гына түгел бит: үз белгечлегең буенча эшнең иң нечкә серләренә төшенергә кирәк.

Башта мастер, аннан прораб, тагын берникадәр вакыт үтүгә өлкән прораб, ә 1960 елдан башлап РСФСР Төзелеш министрлыгының 426 нчы УНРында баш инженер... 1967 елдан исә Зөфәр Садретдинов Волга автозаводы төзү буенча Баш идарәнең баш инженеры һәм аннары начальнигы... Гади бер чагыштыру кулланып әйткәндә, төзелеш генералы дигән сүз инде бу. Мәшәкать муеннан, авырлыклар берничә ирьиңенә дә чакка килерлек. Моннан тыш җәмәгать эшләре дә күп көч таләп итә. Зөфәр Садретдиновны ике чакырылыш рәттән хезмәт ияләре депутатларының Тольятти шәһәр Советына депутат итеп сайлыйлар, шулай ук дүрт ел буена ул партиянең шәһәр комитеты члены булып тора. Сигезенче бишьеллыктагы эшчәнлегенә бәя биреп, хөкүмәтебез аны илебезнең иң югары бүләге — Ленин ордены белән бүләкли.

Тәэүче халкының бер генә урында тормаганын беләбез. Тугызынчы бишьеллык Зөфәрне Кама ярларына, автогигант корырга чакырды. 1971 елны аны СССР Махсус монтаж эшләре министрлыгының КамАЗны төзү буенча Баш идарәсе начальнигы итеп билгеләделәр. Чаллыда ул зур дәрт, олы теләк белән эшкә керешә. Алны-ялны белми эшли. Оештыру чоры аерата катлаулы булды. Хәзер ул җитәкли торган монтажчылар гвардиясе автогигант корудагы төп эшләрне башкара. Чын-чынлап гвардия! КамАЗ төзелешенә тартылган оешмаларны санап чыгарга гына да түземлек кирәк: Стальконструкция тресты идарәсе, мәсәлән, двигательләр заводында һәм пресс-рам заводында металл конструкцияләрне монтажлый. Криворожстальконструкция тресты идарәсе, әйтик, тимерчелек заводында шундый эшләрне башкара. Главнефтьмонтажның җиденче тресты автомобиль җыю заводында технологик металл конструкцияләрне, трубаларны һәм җиһазларны монтажлый, коммуникацион эстакадалар кора. Главэлектромонтажның, Главсантехмонтажның һәм Главпромвентиляциянең ничәмә-ничә оешмасы эшли бирәдә! Ялыктырмый гына әйткәндә, Баш идарә карамагындагы монтажчылар кулы тимәгән бер генә участок та юк.

— Күчеп йөрү туйдырмыймы? — дип сорадым мин идарә начальнигыннан.

— Юк. Киресенчә, бер генә урында озак яшәү миңа күңелсез тоела. Мин, мәсәлән, ВАЗның беренче чираты төзелеп беткәч, заводта кала ала идем. Алай да үлчәп карадым, болай да фикерләп бактым да үз-үземә әйттем, юк, мин әйтәм, характерың андый түгел. Солдат холкыдыр инде...

Шулай дигәч, мин уйлап куйдым: әйе, Зөфәр Садретдинов төзелеш генералы һәм запастагы сержант, солдат кеше. Ләкин солдат дөнәнең икенче бер мәгънәсе, тагын да тирәнрәк аңлашыла торганы бар әле. Ул — партия солдаты.

**Валентина Гудкова**

# ПРОФЕССОР МӨШТӘРИ ҺӘМ АНЫҢ МӘКТӘБЕ

**1929** ел.

Аның биш елдан бирле Казанда булганы юк иде. Үзгәргән Казан! Университет бөтенләй башка тормыш белән яши, ул чын Совет вузына әверелгән. Таныш урамнарда яңа институтлар барлыкка килгән: химия-технология институты, төзелеш институты. Якын арада тагын бер институт — авиация институты ачылырга тиеш. Әйе, математикларга эш җитәрлек. Ә Хәмит гади математик кына түгел, инде фәннәр кандидаты, атаклы академик Сергей Алексеевич Чаплыгин шәкерте!

Яшь галим Хәмит Мөштәрине Казан коммуналь төзелеш институтында теоретик механика кафедрасы мөдире итеп профессор эшенә билгеләделәр.

Беренче лекция. Менә аудиториягә озын буйлы, ябык гәүдәле, төз борыны өстенә күзлек атландырып куйган яңа укытучы керде дә, студентларга кырыс итеп караш ташлаганнан соң, артык сүз куертып тормастан, лекциясен укырга кереште.

Кара тактага бер-бер артлы формулалар төшә торды, лектор аларга аңлатма бирә барды. Студентларга тагын күз ташлаган иде — акбур тоткан кулы ярты юлда туктальп калды: бер генә студент та лекцияне язып бармый...

Студентлык елларыңны онытырга да өлгердеңме әллә син, Хәмит!.. Үзең дә конспект язып барырга өлгерә алмый күпме интектең. Әйе, студентларга конспект алып бару күнекмәләрен дә өйрәтергә кирәк...

...Югары белемгә ия булу өчен бик зур кыенлыклар кичәргә туры килде Хәмиткә. 1918 елның март ае иде. Казандагы икенче ирләр гимназиясе укучысы Хәмит Мөштәри чыгарылыш классыннан укуын ташларга мәҗбүр булды.

Авылда укытучы булып эшләүче әтисе Мозаффар ага Мөштәри улына: «Яңа мәктәп ачтык,— дип хат язган.— Парталарны үзебез ясадык... Тик менә математика белән физиканы укытыр кеше юк».

Ә Хәмит гимназияне бетергәч, университетта укырга уйлаган иде. Хәзер ярлы балалары өчен дә белем алу юллары ачык. Нишлисең, иң якын кешең — әтиең чакыргач, кайтмый булмый.

Директор егетне озак үгетләп тормады, аның үзенә дә Мозаффар агайдан хат килгән икән.

— Әйе, балаларга белем бирергә кирәк,— диде.— Имтиханнарны җәй көне экстерн тәртиптә тапшырырсың.

Иделнең текә ярлы буйлап киткәч, Тәтештән ерак түгел, Келәнче дигән авыл урнашкан. Исеме җисеменә бик туры килә бу авылның: каралып беткән салам түбәле кыйшайган өйләр, җимерек каралтылар, коймалар. Әмма чабаталы бала-чага яңача укытыла торган мәктәпләре белән горурлана. Үзләре ясаган парталарда язарга-сызар-

гә уңай. Яраткан укытучылары Мозаффар ага Мәштәринең дәресләрен бирелеп тыңлыйлар. Классларда салкын — утын юк. Әмма укучылар зарланмый, күшеккән кулларын өреп җылыталар да тагын кәгазь, карандашка тотыналар. Ләкин Мозаффар аганың физика, математика фәннәреннән белеме сайрак. Гомер буе ул татар теле, татар әдәбияты, рус теле дәресләре алып барган. Менә улы Хәмит кайтып укытырга керешсә...



Ә Хәмит өчен әти сүзе — закон. Әтисе аны приют каршындагы мәктәптә укытты, артыннан йөреп, казна хисабына Казан гимназиясенә урнаштырды. Әтисенә ярдәм кирәк икән, ничек кайтмасын ул!..

Шулай итеп, Хәмит үзе урамда малайлар белән кузна уйнап йөрер вакыттан мәктәптә балалар укытырга керешә.

Шулай да гимназияне тәмамларга, университетта белем алуны дәвам иттеверга кирәк иде.

Хәмитне бөтен авыл малайлары озатып калды. Әтисе пристаньга кадәр килде.

...Университетта Хәмит Мәштәринең өлгергәнлек аттестатына карап та тормадылар: 16 яшь тулган һәркемне алалар икән. Беренче лекциягә ул элгә алмады, чөнки аудиториягә керерлек тә түгел, хәтта идәнгә дә утырышканнар иде. Физика-математика факультетында гына да бер мең ике йөз кеше укырга теләп, ә медицина факультетында ун меңнән артык.

Өч айдан аудиторияләр бушап калды. Өч класс белеме булганнар дифференциаль тигезләмәләрне ничек аңлый алсыннар!.. Икенче курска физика-математика факультетында бары тик утыз гына кеше күчте.

Бер заман аудиторияләрдә калын пыялалы күзлек кигән, ябык гәүдәле, җитди карашлы студент күренми башлады. Берничә көн үзды, атна узды — ул юк та юк.

Хәмит университетта уку белән бергә эшли дә: Яңа бистәдәге мәктәпләрнең берсендә физика, математика дәресләре алып бара иде. Ялсыз-нисез күп эшләп хәлсезләнү өстенә, ул салкын да тидерде.

Аны больницага салдылар.

Казанның атаклы врачлары Вишневский, Земницкий, Чебоксаров, консилиумга җыелгач, Мәштәригә туп-туры әйттеләр:

— Сезне, егет, бары тик эссе климатлы көньяк һавасы гына коткара ала,— диделәр.— Ташкентка китегез!

Әйтергә генә җиңел. Ташкент әллә кайда, дөнья читендә диярлек иде ул заман өчен. Урта Азиягә юл да ябык — Оренбург тирәләрендә Дутов бандалары башбаштаклык итә. Җитмәсә, Ташкент шәһәрендә туган-тумача да юк, кемгә барып төшәсең!

Шулай да тәвәккәлләде Хәмит.

Ул анда Көнчыгыш халыклары мәгариф институтында укытты, шул ук вакытта үзе дә Ташкент университетында белем алды.

Профессор Всеволод Иванович Романовский — ихтималлык теориясе һәм математик статистика буенча зур белгеч — Хәмит Мәштәринең фәнни тикшеренүгә сәләтен бик тиз күреп алды.

— Тумыштан математик,— дип сөйли иде ул аның турында кафедра галимнәренә. һәм Хәмиткә ничек тә ярдәм күрсәтергә тырыша иде, ял көннәрендә өенә яки дача-

сына чәйгә чакыра, студент белән сөйләшеп утырырга ярата иде. Ә диплом эше өчен француз телендә язылган хезмәтләрне файдалану таләп ителгәч, профессор үзе Мөштәригә тәрҗемә итәргә булышты.

Университетны тәмамлагач, Хәмит Мөштәригә өч елга Германиягә командировка тәкъдим иттеләр. Ә профессор Романовский сәләтле, хезмәт сөючән бу егетне үз кафедрасында калдырырга тели иде,— ул аңа китәргә киңәш бирергә ашыкмады.

— Әлбәттә, чит илдә булу кызыклы,— диде ул Хәмиткә.— Немец телен дә яхшылап өйрәнерсез. Галим кешегә немец телен белү бик кирәк. Әмма өч ел эчендә биредә дә чын галим булып җитешә аласыз...

Ләкин Хәмитнең үз омтылышлары бар иде. Ике ел элек ул үзенең яшьтәше, танылган шагыйрь Һади Такташ белән дуслашты. Хәтта алар бер бүлмәдә яшәделәр.

Төн уртасында да ут сүнми иде алар бүлмәсендә. Маңгаена төшеп торган сары чәчле, зәңгәр күзле шагыйрь төннәр буе дустына яңа шигырьләр укый. Вакыт-вакыт кайнар бәхәсләр куба. Әмма Такташ дустының сүзләренә үпкәләми, чөнки ул белә: Хәмит тә рухы белән шагыйрь. Тик аерма шунда, аның музасы шигърият түгел, математика.

Аларның икесе өчен дә тагын бер нәрсә уртак иде: Хәмит тә, Һади да Ташкентка авыру аркасында килгәннәр. Һади үпкә авыруыннан сихәтләнү өчен килгән булса, Хәмит бөер авыруыннан — нефриттән. Алар икесе дә туган халык арасына — Татарстанга кайтырга хыялланалар иде.

Һәм алар икесе дә Казанга кайттылар. Әмма дуслыклары озак дәвам итә алмады: Һади бик яшьли дөнья куйды...

Ә Хәмит Ташкентта вакытта дәвалануны уйлап та карамады, больницаларга да йөрмәде. Нефрит дигән авыру ничек юкка чыккандыр, ул үзе дә белми. Бер караганда, туйганчы ашаганы да, йоклаганы да булмады диярлек, төнлегенә уннар-ундүртәр сәгать баш күтәрми эшләп утырырга туры килә иде. Мөгаен, менә шундый чиктән тыш киеренкелек авыру зәхмәтен куып чыгаргандыр.

Хәмит Мөштәрине Казанда Мәгариф Халык Комиссариатына Академик Үзәкнең гыйльми секретаре итеп эшкә алдылар. Галимҗан Ибраһимов белән бергәләп алар «Мәгариф» журналын чыгара башладылар.

Әмма Хәмитнең хыялы журналистика түгел иде бит. Ул укуын дәвам иттерергә, инженер-конструктор булырга, самолетлар төзергә, үзе дә очарга теләде.

Мәскәүдә Хәрби-һава Академиясендә аның гаризасын кабул итмәделәр, анда бары тик хәрби командирларны гына алалар иде.

Мөштәри югалып калмады. Ул Хәрби Революцион Совет председателенең үзенә барып җитте.

Михаил Васильевич Фрунзе Хәмитне бүлдермичә тыңлады. Егет Көнчыгыш телләрен яхшы белә икән, үзе — математик. Авиация инженеры булырга тели. Яшь, характеры нык. Мондый егет өчен ташлама ясарга да мөмкин... Һәм ул Мөштәри гаризасына түбәндәге сүзләрне язып куйды:

«Имтиханнарга кертүегезне сорыйм.

**М. Фрунзе».**

Имтиханнарны Хәмит җиңел тапшырды. Мандат комиссиясен дә узды. Әмма врачларның карары катгый иде: күзләре зәгыйфь.

Тагын Мәгариф Халык Комиссариаты. Бу юлы Мәскәүдә.

Надежда Константиновна Крупская аны җитдилеге, аз сүзлелеге, үз-үзенә дә, башкаларга да таләпчәнлеге өчен үз итә иде. Көннәрдән бер көнне Хәмит аңардан үзенең шәхси эше буенча сөйләшергә кабул итүен үтенде. Надежда Константиновна, аны тыңларга әзер икәнлеген белдереп, өстәлдәге кәгазьләрне бер кырыйга этәрде. Мөштәри, ничектер тарсынмыйча, үз тормышын ачыктан-ачык сөйләп бирде. Һәм төп омтылышын да белдерде ул: белемен тагы да үстерәсе иде, укыйсы иде, ә Академиягә күзең начар күрә дип алмадылар.

— Беләсезме,— диде Надежда Константиновна,— университетта аспирантура ачылды. Мин сезне шунда тәкъдим итәр идем...

Математика һәм механика профессоры — Егоров дигән кеше — Мөштәрине күргәч, шаркылдап көләргә кереште:

— Сез, татар башыгыз белән, фәнгә үрмәләргә телисезме? Юк, сез миңа батмыйсыз!

Хәмитнең бирешергә һич исәбе юк иде. Ул, Үзәк аэродинамика институтына барып, академик Сергей Алексеевич Чаплыгин адресын сорашып белде. Аның квартирасы ишек төбен өч көн саклады. Ниһаять, Сергей Алексеевичны очратты.

— Сезгә ни кирәк, егет? — академикның ачулы җыерылган калын кашлары рәхим-шәфкать вәгъдә итми иде.

— Сезнең белән сөйләшергә теләр идем.

Академик җилкәләрен сикертеп куйды, әмма каршы сүз әйтмәде. Сергей Алексеевичның хатыны кунакны аш бүлмәсенә чакырды.

— Сезнең аспирантыгыз буласым килә!

Чаплыгин кулындагы чәнечкесен төшереп җибәрә язды. Сәер егет. Уку елы инде башланды, аның аспирантлары җитәрлек.

— Кемнән укыдыгыз? Ә-ә, профессор Романовский шәкерте. Беләм мин аны. Егоровта булдыгызмы соң?

Хәмит сөйләп биргәч, академикның калын кашлары тагын җыерылды, аннары ул рәхәтләнеп көләргә кереште.

— Димәк, татарлар чүпрәк-чапрак җыючылар гына. Ха-ха-ха! Математика алар өчен түгел...

Чаплыгинның йөзе кинәт җитдиләнде, бу үзсүзле кыю егет кай ягы беләндер аңа ошап куйды.

— Нинди телләрне беләсез?

— Немец телен, француз телен.

— Ә инглиз телен?

— Юк.

— Алайса, булмый. Мин инглиз телен белмәгәнне алмыйм.

Академикның хатыны сәер кунакка теләктәшлек белдереп карап куйды. Тыйнак киенгән. Ябык. Ягымлы. Мөгаен, бик тырыштыр үзе. Ул егетнең чәен яңартты, алдындагы җәймәне рәтләп куйды. Хатынының егеткә карата җылы карашын академик та сизде, университетта укуын, нинди программа буенча дәресләр алуын төпченеп сорашырга кереште. Күзе начар күрү сәбәпле, Академиягә керә алмавын ишеткәч, башын чайкап куйды.

— Ничек яшәрсез соң? Аспирантларга стипендия бик аз бит.

Бу сүзләр инде ризалык билгесе иде. Әмма ул шатлыгын йөзенә чыгармаска тырышты.

Урамга чыккач кына Хәмит нинди әрсез адым ясавын күз алдына китерде. Уңайсызланып куйды. Шундый эшкә күмелгән, арыган, өлкән яшьтәге кеше, академик кадәр академикка кайгы-хәсрәтеңне, тормыш хәлләреңне сөйләп, аның никадәр вакытын ал әле!..

Әмма ни булса булды — ул үз дигәненә иреште!

Чаплыгин, яңа аспирантын сынарга теләгәндәй, аны эш белән күмде. Җитмәсә тагын, инглиз теле! Академик механика буенча бары тик инглиз телендә чыккан китапларны укырга куша иде.

Мәскәүдә ул елларда тормыш авыр иде. Әмма конкурсштагы кыенлыклар Хәмит өчен вак-төяк булып күренде. Ул көндез дә, кичен дә китаптан аерылмады. Тәүлек тә җитми иде.

Ниһаять, имтиханнар җитте. Бер ел эчендә академик шактый картайган кебек тоелды Хәмиткә. Чаплыгин Хәмитне программа буенча инәсеннән җебенә кадәр төпченеп тикшерде. Әлбәттә, ул хаклы иде: фән өлкәсендә ярым-йорты белем белән әллә ни майтарып булмый.

— Әзерлек курсы үттек дисәк тә була хәзер, — диде ул, имтиханнан соң. — Сезне үземдә калдырам. Хәзер инде аспирантура башлана. — Һәм ул, егетне җитәкләп, үзенең бай китапханәсендәге киштәләр янына алып килде.

— Кирәк китапны моннан ала аласыз. Әмма бер шарт белән: урынына куярга һәм бит араларындагы кәгазьләрне югалтмаска!

Хәмит үз колагына үзе ышанмады. Галим үзе өчен иң изге саналган әйберләреннән аңа файдаланырга рөхсәт итә! Ә бит ул аны үтә кырыс кеше дип йөргән иде...

Мештәри академикның эш урынында да, квартирасында да үз кешегә әверелде. Остазының ышанычын ул аклады: кандидатлык диссертациясен срогында яклады. Аңа Мәскәүдә эш тәкъдим иттеләр.

Юк, ул башкалада калмады, туган җиргә аңа якынрак иде...

...Докторлык диссертациясен язуны калдырып торырга туры килде: Хәмит Мөштәригә авиация институтыннан тагын бер кафедра җитәкләүне йөкләделәр. Өстәвенә, институтның директор урынбасары итеп тә куйдылар.

Ике институтта ике кафедра — бер кеше җилкәсенә, әлбәттә, күбрәк иде бу. Өстәвенә, тәҗрибә дә аз. Докторлык диссертациясе өчен җыйналган материал өстәл тартмаларына бикләп куелды, Хәмит Мөштәри укыту эшенә, административ эшкә күмелде.

Авиация институтының беренче чыгарылышы. Яшь инженерларның барысын да диярлек Мәскәү заводлары үзләренә соратып алды. Чкалов, Байдуков, Громов очышлары бөтен дөньяны шаккаттырган еллар иде бу. Дөрес, Хәмит Мөштәри авиация конструкторы була алмады. Әмма бөтен дөньяны таң калдырган самолетларны ясаучы инженерлар аның шәкертләре бит. Теоретик механикадан, сопроматтан башка инженер булып кара син!

1937 елда Мөштәри остазы белән кабат очрашты. Бу юлы ул Мәскәүгә докторлык диссертациясе якларга барды. Сергей Алексеевич, Мөштәри хезмәтен укып чыккач, кулларын җәеп җибәрде:

— Искиткеч бу! — диде академик.— Шундый гади математик ысуллар белән гаять катлаулы техник мәсьәләләрне чишәргә мөмкин, ә!..

Шәкертенең фәндә үз урынын табуы чын галим өчен һәрвакыт куанычлы хәл. Чаплыгинның элекке аспиранты белән горурланырлыгы бар иде.

1938 ел.

Хәмит Мөштәригә өченче кафедраны — химия-технология институтында теоретик механика кафедрасын җитәкләү эше йөкләделәр. Татарлардан беренче математика профессоры исемен алган галимнең оештыручанлык сәләтенә ышаныч зур иде.

Фән дөньясында оештыручылар төрле була. Берәүләр, тышкы эффектка омтылып, үзләрен киң колач белән эшләүче итеп таныткырга тырышалар. Икенче берәүләрнең читтән караганда, эшләре ул кадәр зур да түгел кебек. Нәкъ менә шундыйлар, шаушу куптармыйча, үз эшенә бирелеп, җиренә җиткереп башкарган галимнәр, фәндә тирән эз калдыралар. Хәмит Мөштәри дә оештыручы, ләкин ул тышкы эффект артыннан кумый, аның фәндә үз юнәлеше, үз мәктәбе бар.

Профессор Мөштәрине якыннан белгән кешеләр аның үзенчәлекле төп сыйфаты итеп җаваплылык хисе тоеп эшләвен әйтәләр.

Бу сыйфат аңарда, мөгаен, яшьтән үк, үзен фәнгә багышларга карар кылганнан башлап тәрбияләнгәндер. Ул бер вакытта да үзе өчен фәннең нәрсә бирәсен, нинди уңайлыклар китерәсен уйламый, фәнгә үзе нәрсә бирә алачагын гына уйлый.

Моннан утыз биш еллар элек ул Үзәк аэродинамика институтына командировкага барды. Шунда беренче мәртәбә сүрү теориясе белән якыннан танышты. Ул вакытта бу теориядә япон галимнәре хисаплап чыгарган ике формула хакимлек итә иде. Әмма япон галимнәре исәплап чыгарган нәтиҗәләрдә теоретик яктан ялгышлык табылмаса да, Үзәк аэродинамика институты инженерлары үткәргән экспериментлар бу формулаларга туры килеп җитми иде.

Ниһаять, татар галиме Хәмит Мөштәри үз формуласын тәкъдим итте. Ул бу турыда Үзәк аэродинамика институтының юбилей сессиясендә доклад ясарга тиеш. Сессия ике көннән Зур театр бинасында үткәреләчәк.

Мөштәри үзе куячак мәсьәләләрнең дөреслегенә ышана: кат-кат тикшерелгән, кат-кат тәҗрибәләр үткәрелгән. Шулай да ул үз формуласы нигезендә тагын бер кат эксперимент ясап карарга теләп институтка китә. Экспериментны лаборант ясый.

Нәтиҗә — ул көткәннең киресе!

Докладтан баш тартыргамы?..

— Ашыкма,— ди ул үз-үзенә.— Үзең тикшереп кара!

— Гафу итегез, үзем эшләп карыйм әле,— ди галим, лаборантны үпкәләтмәс өчен йомшак кына итеп.

Инженер гаҗәпләнеп Мөштәригә карап ала да җилкәсен сикертеп куя: ихтыярыгыз, янәсе, нәтиҗә барыбер шундый булачак. Чыннан да, лаборант хаклы икән бит!

— Ашыкма, ашыкма,— дип юата үз-үзен галим,— барысы да дөрес иде бит. Кайдадыр ялгышлык булырга тиеш.

Ялгышлык табыла — үтә гади икән: лаборант прибор тоткасын ике бүлемгә югарырак куйган.

Доклад уңышлы булып чыга. Ә ике елдан академик Чаплыгинга аның докторлык диссертациясе тапшырыла. Исеме бик тыйнак: «Сыгу теориясен гомумиләштерүнең кайбер мөмкинлекләре һәм аларны нык торучанлык мәсьәләләрендә куллану».

...Югары биеклектә, үз артыннан тар ак тасма калдырып, самолет оча, диңгез өстен күбекләндереп линкор йөзә, гаять зур түгәрәк чаңга нефть җыела, бөтен шәһәргә ямь биреп, пыяла һәм бетоннан салынган, түбәсе гөмбәгә охшашлы матур бина тора. Илебезнең тынычлыгын тәэмин итүче күп төрле ракеталар, җирнең ясалма юлдашлары, космик корабльләр...

Казан профессоры Хәмит Мөштәринең аларның һәрберсенә мөнәсәбәте бар.

Кәкре сызыклы сыгу теориясе. Очкычлар да, йөзгечләр дә теге яки бу формадагы сыгу белән тышланган. Самолет өчен дә, корабль өчен дә авырлык күләме төп рольне уйный. Фюзеляж өчен, канатлар өчен тиешле ныклыкны тәэмин итәрлек нинди калынлыкта тышча алынырга тиеш? Менә боларны исәпләп чыгарганда конструктор сыгу теориясе формулаларыннан чыгып эш итә. Зур резервуарлар, металл трубалар ясаганда да, биек башнялар салганда да, ракета техникасында да, космик кораблар төзегәндә дә Мөштәри һәм аның шәкертләре тәкъдим иткән катлаулы теоретик исәпләүләр кулланыла. Алар чыгарган формулалар инженерлар өчен чыгарылган белешмәләргә кертелгән.

Хәмит Мөштәри теоретик галим генә түгел, ул фәнни лабораторияләрдә ирешелгән нәтиҗәләрне практик куллану чараларын да эшли. Шуңа күрә дә аңардан кеше өзелеп тормый: фән-техниканың төрле өлкәләрендә эшләүче инженерлар, галимнәр аның янына киңәшкә киләләр, планнары белән уртаклашалар.

Казанда яңа цирк бинасы салыр алдыннан «Татпроект» вәкилләре — архитекторлар иң элек профессор Хәмит Мөштәри белән киңәштеләр: моңа кадәрле салынган биналар кабатланмасын, залда тамашачы өчен һәряклап уңай булсын!

— Бер атнадан килерсез,— дип озатты аларны профессор. Үзе шунда ук бүлмәсенә фәнни хезмәткәрләрне чакырды: цирк бинасы өчен инженерлык расчетлары әзерләргә!

Фантастик әсәрләрдәге тәлинкә төсле гигант космик корабны хәтерләткән бу бина хәзер һәркемгә таныш. Эчендә аның 2500 урын, манежы һәр яктан да әйбәт күренә, тамашачыга комачаулый торган бер генә багана да, бер генә терәү дә юк. Һәр җирдә — җиңеллек, гүзәллек. Зур тимер-бетон гөмбәз, колонналар да булмагач, нәрсәгә таянып тора соң?

— Моңа ирешү өчен сыгу теориясен белергә кирәк,— ди бу сорауга каршы профессор.

Кыскасы, профессор Хәмит Мөштәри үз эше белән никадәр генә мәшгуль булмасын, киңәш, ярдәм сорап килгән һәркем өчен вакыт таба.

Галимнең һәм ул тәрбияләп үстергән коллективның производство кирәкләренә шундый мөнәсәбәте илебез шәһәрләрендәге фән эшлекләре арасында Казан физика-техника институтының абруен бик нык күтәрде.

Ә бу институт моннан чирек гасыр элек оешкан иде. Университетның элекке геометрия корпусындагы ике бүлмәдә ул чагында сигез өстәл, сигез урындыктан башка берни дә юк иде. Дүрт фәнни секторда бары тик сигез хезмәткәр булып, алар да университетта дәрес алып баралар иде.

— Кадр дисәң кадры, бина дисәң бинасы юк. Дүртенче мәртәбә инде юктан бар ясарга кушалар. Баш тартам бу эштән,— дип уйланды Мөштәри бу юлы.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы президенты, академик А. Е. Арбузов профессорны бүлдерми генә тыңлады.

— Утыз яшьтән директор урынбасары, утыз елга якын югары уку йортларында укытасыз,— диде ул, тыныч кына.— Институт оештыруны сездән башка тагын кемгә тапшырыйк?

Мөштәри башын күтәреп академикка карады. Яшь түгел бит инде ул — алтмыш алты яшь аңар. Ә үзе бер институтны гына түгел, филиалны җитәкли...

— Ышандырдыгыз, Александр Ерминингельдович. Миңа уңыш теләгез...

Ә фәнни хезмәткәрләренә ул:

— Үз бинабыз булганчы өйләрегездә эшләрсез! — диде.

1946 елның 24 гыйнварында стенага приказ эленде: «Шимбә көннәрне көндезге сәгать 2 дән 4 кә кадәр фәнни хезмәткәрләргә эшләнгән эшкә хисап бирү өчен институтка җыелырга».

Институтның кадрлар бүлеге профессор Миропольский квартирасына урнашты. Геология институты директоры үзе Мөштәри янына килде дә:

— Үзем көне буе филиалда, университетта булам, минем бүлмәгә урнашып торыгыз,— диде...

Ул көннәрдән соң инде күп сулар акты. Институтның эше күзгә күренеп яхшырды, күп кенә яңа кадрлар үсеп чыкты.

Михаил Степанович Корнишин институтка лаборант булып килгән иде. Профессор аның сәләтен күреп алды, аерым тема бирде. Озак та үтмәде, кандидатлык диссертациясе барлыкка килде һәм ул доктор булырга теләген белдерде. Җитәкчесе аны хуплады. Ә хәзер физика-математика фәннәре докторы М. С. Корнишин сыгу динамикасы һәм статистикасы лабораториясен җитәкли.

Көннәрнең берендә Иркутск шәһәреннән яшь кенә бер инженер килеп төште.

— Сыгу теориясе буенча монографиягезне укып чыктым,— диде ул профессорго.— Сезгә аспирант булып керергә телим.

Әмма егет белгечлек буенча керү имтиханын уза алмады. Тагын профессорга керде.

— Хәзер алмассыз инде мине?..

Профессор гаҗәпләнүеннән хәтта күзлеген салды. Егетнең җирән бөдрә чәчләре астында озынча йөзе ап-ак булган, ә кыю күзләре очкынланып тора иде.

— Ул хакта нинди сүз булуы мөмкин? Имтиханны бирә алмагансыз бит.

Егет, ике кулы белән дә җирән бөдрәләрен учлап, башын аска иде. Шундый зур теләк, омтылыш булгач, аңардан рәт чыгар кебек тоелды профессорга. Әңгәмә вакытында киң карашлы, тирән фикерле булуын да күрсәткән иде егет.

— Ярар, иртәгә керегез, уйлашырбыз...

Хәзер профессор Сергей Владимирович Прохоров — Йошкар-Олада, политехника институты деканы.

Марат Илһамов та аспирантурага Мөштәригә керергә үзе сорап килә. Утыз биш яшь тулганчы ул докторлык диссертациясе яклый. Профессор аны иң сәләтле шәкертләренең берсе дип саный.

Казан университетында профессор Александр Васильевич Саченков — кафедра мөдире, Илгизәр Терегулов Югары инженерлык-команда училищесында кафедра җитәкли, Корбан Галимов — университет профессоры. Алар барысы да — Хәмит Мөштәри шәкертләре.

Вадим Алексеевич Голенищев-Кутузов та профессорның яраткан фәнни хезмәткәрләреннән берсе. Вадим Алексеевич ике ел эчендә аспирантура бетереп, кандидатлык диссертациясен якларга өлгергән талантлы, шул ук вакытта бик тыйнак егет. Ерак бабасы фельдмаршал Кутузов булуын ул сезгә тиз генә әйтмәс. Моннан унбиш еллар элек Ленинградта Казан соборында бабасы — скульптор Воронихин иҗат иткән һәйкәл — белән беренче очрашканда кичергән хисләрен дә белдермәс, фельдмаршал табуты янында, баш киемен салып, озак кына уйланып торуы турында да сөйләмәс.

Дөрес, аңа гомерендә бер мәртәбә генә булса да туганлык бәйләнешеннән файдаланырга туры килә. Мәскәүгә командировкага килгәч, Кутузов проспектында художник Рубо язган Бородино сугышы панорамасын ачкан вакытка туры килә ул. Команди-

ровка вакыты бетеп килә, билет алырга мөмкин түгел. Администратор ишегә төбендә бик озак таптанып торгач, ниһаять, көч-хәл белән, тыйнаклыгын җиңеп, ишек шакый.

Көтелмәгән бу кунакка, әлбәттә, барысы да бик шат булалар.

Бу турыда яшь физиклар хәзер дә көлеп сөйлиләр әле...

Профессорның эш көне минутына кадәр алдан исәпләнгән. Иртәнге 9 дан көндезге 1 гә кадәр ул — институтта. Һәр хезмәткәр бу вакытта аның янына туп-туры керә ала. Әмма берәү дә аңа юк-бар йомыш белән керми. Аңа кергәндә һәркем белә: Мөштәри йомышны тыңлап кына калмый, бер мәсьәлә буенча кат-кат йөрмәслек итеп, ахырына кадәр хәл итә.

Тыштан кырыс күренсә дә, олы йөрәкле, нечкә күңелле кеше ул Хәмит ага Мөштәри.

Шулай бер көнне институтта бергә эшләүче фәнни хезмәткәр аның дачасына хатыны белән килеп төшә. Бакчадагы искиткеч матур астра чәчәкләрен күреп, «ах» итә әлеге хезмәткәрнең хатыны. Хуҗа кеше моңа игътибар итмәгәндәй сүзне икенчегә бора.

Менә көз җитә. Профессор иртән институтка килгәч, иң элек, әлеге хезмәткәре эшли торган бүлмәгә керә дә пакет суза.

— Чәчелә күрмәсен,— ди.— Астра орлыклары. Хатыныгызга бик ошаган чәчәкләрнеке...

Хәзер физика-техника институтының дүрт бүлегендә, алты зур лабораториясендә 300 дән артык фәнни хезмәткәр эшли. Институт физика һәм математиканың соңгы казанышларына җавап бирерлек җайланмалар белән җиһазландырылган.

Физика-техника институтының һәр бүлеге аерым бер фәнни үзәк диярлек. Радиоспектроскопия бүлеген физика-математика фәннәре докторы, 1944 елда Казанда парамагнит резонансы күренешен ачкан Е. К. Завойский хезмәттәше Б. М. Козырев җитәкли. Түбән температуралар белән эш итә торган криоген лабораториясе дә шушы бүлеккә карый. 1965 елның язында түбән температуралар буенча үткәрелгән Бөтенсоюз конференциясендә академик П. Л. Капица Казан галимнәренең бу өлкәдәге уңышларына зур бәя бирә.

Хәмит Мөштәри халык хуҗалыгы өчен мөһим булган һәр яңалыкны вакытында сизә, күрә белә. Аның тырышлыгы белән булдырылган электрон-хисаплау машинасы Казан өчен генә түгел, Мәскәү институты өчен дә яңалык иде. Күптән түгел бирелә Советлар Союзында беренчеләрдән булып яңа лаборатория — квант акустикасы лабораториясе ачылды.

Профессор Мөштәри, үзе механика буенча белгеч булса да, барлык бүлекләрнең эшенә актив катнаша. Нәкъ менә шуңа күрә дә институтның барлык секторлары да бердәм, дус коллектив булып эшлиләр.

Институт директоры «катып калган» математик кына түгел. Ул, буш вакытлары никадәр аз булса да, әдәбият яңалыклары белән дә даими кызыксына. Матур әдәбият уку яшьлек дусты Һади Такташ, татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов салып калдырган өеткы гына түгелдер, мөгаен. Бу мәсьәләдә улы Даниярның да йогынтысы бардыр. Ә Данияр исә бала чактан математика белән дә, матур әдәбият белән дә дус.

Әтисеннән дә озынрак буйлы, әтисе кебек үк ябык Данияр әтисе кебек үк аз сүзле, әмма үз сүзле егет. Ул бер дә гадәттәге профессор малайларына охшамаган: берниндн эштән дә тартынмый, гаҗәп хезмәт сөючән. Аңа карата чын-чынлап: «Алма агачыннан ерак төшми»,— дип әйтергә була.

Данияр мәктәптә укыган вакытында ук Прагада үткәрелгән математик олимпиадага катнашып, медаль алып кайта. Университет курсын ул дүрт елда үтә. Аннан физика-техника институты турында ишетергә дә теләми.

— Әти шунда директор булгач, миңа анда урын юк,— дип кырт кисә.

Аспирантурага керүдән дә баш тарта. Н. Б. Чеботарев исемендәге фәнни-тикшеренү институтына кече фәнни хезмәткәр булып эшкә урнаша һәм аспирантурасыз гына өч ел эчендә кандидатлык диссертациясе яклый. Егерме биш яшьтән ул инде — өлкән фәнни хезмәткәр.

— Ярый әле миңа кермәдең,— ди аңа әтисе вакыт-вакыт.— Кече хезмәткәр булып бер биш ел гына йөрмәс идең...

Әлбәттә, ул эченнән горурлана улы белән. Башкача ничек булсын! Данияр бала чактан ук кешегә салынырга яратмады, эштән баш тартмады, үзбаш фикер йөртергә, үзбаш эшләргә тырышты. Үзе өчен күп әйбер таләп итмәде, аздан да канәгать булды. Ә китапларны инде ул су урынына эчә. Матур әдәбият белән дә, музыка белән дә, рәсем сәнгате белән дә, спорт белән дә кызыксына.

Профессордан сорыйм:

— Данияр докторлык диссертациясен язамы? — дим.

— Белмим,— ди Хәмит ага.— Ул турыда сорашканым юк. Кандидатлык диссертациясе яклавы турында да газетада чыккан белдерүдән генә укып белдем...

Күптән түгел физика-техника институты яңа урынга күчте. Себер трактында яңа фән шәһәрчеге үсеп чыкты. КФТИның дүрт катлы яңа бинасы химия-технология институты бинасына килеп терәлә. Ә аннан Казан университетының электрон-хисаплау үзәге урнашкан бина башланып китә.

Көн саен иртән ак плитәләр белән тышланган физика-техника институты бинасы янына зәңгәр «Волга» машинасы килеп туктый. Аннан озын буйлы, төз гәүдәле бер ир кеше чыга да шушы бина ишегеннән эчкә уза. Ул — РСФСРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, Ленин ордены кавалеры профессор Хәмит Мозаффар улы Мөштәри.

Профессор үз бүлмәсенә үтә. Иң башта яңа килгән корреспонденцияне актара. Америкадан атаклы механика белгече, Советлар Союзы Фәннәр академиясенең почетлы члены яза. Ул сыгылмалылык теориясенең тарихы буенча монография әзерли икән, Мөштәридән хезмәтләрен җибәрүне үтенгән. Польша, Венгрия, Румыния, Голландия галимнәреннән килгән хатлар... Ә монысы Каһирәдән.

Барысына да җавап язарга кирәк...

Акрын гына ишек шакыган тавыш.

— Керегез...

Нечкә генә мыеклы, озын чәчле, зур күзлек кигән егет кыюсыз гына өстәл янына уза. Кичәге студент икәнлеге әллә кайдан күренеп тора.

— Хәмит ага, мин сездә аспирантурада укырга телим...

**М. ХӘМИТОВ** тәрҗемәсе.

**Альфред Халиков,**
тарих фәннәре докторы

# ДУНАЙ БОЛГАРСТАНЫ — КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ ИЛЕ

Иделдән чагыштырмача шактый еракта, Европаның Балкан ярымутравында, бер ил бар. Бу илне «Болгария» дип, ә анда яшәүчеләрне «болгарлар» дип атап йөртәләр. Беренче ишеткәндә үк безгә бу ике исем ничектер якын һәм үз тоела, күңелдә шундук үткән тарихыбызның гасырлар эчендә күмелеп калган кайбер сәхифәләрен тергезеп җибәрә. Кайчандыр безнең ерак ата-бабаларыбыз да үзләрен «болгарлар» дип, ә туган җирләрен «Болгар иле», «Болгар» дигән исем белән йөрткәннәр бит. Бер-берсеннән шулай еракта яшәгән ике халыкка ничек һәм ни сәбәптән бер үк исем тагылды икән? Дунай болгарлары белән борынгы Идел буе болгарлары һәм аларның соңгы токымнары арасында нинди дә булса уртаклык бармы? Дунай болгарларының борынгы культурасы бу хакта ниләр сөйли? 1971 елның октябрь аенда, болгар коллегаларымның ихтирамлы чакыруы буенча, егерме көн дәвамында бу гүзәл ил һәм аның тарихи истәлекләре белән танышып йөргәндә, менә бигрәк тә әнә шушы мәсьәләләр кызыксындырды. Болгариягә сәяхәтем вакытында алган кайбер тәэсирләремне мин журнал укучылары белән дә уртаклашырга телим.

Безнең самолет 1 октябрьда һавага күтәрелеп, София вакыты белән шул ук көнне сәгать 12 дә Болгария башкаласына килеп төште. Аэродромда мине борынгы болгар казылмалары белгече, күренекле галим, профессор Ст. Ваклинов һәм аның коллегалары — Болгария Халык Республикасы Фәннәр академиясенең археология институты хезмәткәрләре каршы алды. Профессор Ст. Ваклинов күп санлы гыйльми хезмәтләре белән миңа яхшы һәм күптән таныш булса да, моңарчы үзен күреп сөйләшергә туры килгәне юк иде әле. Ул шактый озын буйлы, пөхтә-чандыр гәүдәле, яше белән илләр тирәсендәге бер кеше булып чыкты. Аның биографиясе дә бик кызыклы. 1941 елның 22 июнендә, ягъни фашистлар Германиясе Советлар Союзына мәкерле һөҗүм башлаган көнне, ул Болгария комсомолы сафларына кергән һәм сугыш чорында немецларга каршы халык хәрәкәтендә актив катнашкан. Соңыннан ул Коммунистлар партиясенә алына һәм Социалистик Болгариянең күренекле галиме булып танылa. Аның археология өлкәсендәге эшчәнлегенә мисал итеп монда VIII—IX гасыр борынгы болгар каберлекләренә (Нови-Пазар, Плиска янындагы курган һ. б.) һәм беренче болгар башкаласы Плиска тарихына караган гыйльми хезмәтләрен күрсәтеп үтәргә мөмкин. Хәзерге вакытта ул беренче Болгар патшалыгының мәркәзе Преславны өйрәнү буенча алып барылган киң тикшеренүләргә җитәкчелек итә.

Мин Болгария тарихы белән танышуымны София археология институты һәм аның янындагы археология музееннан башладым. Бу институт һәм музей элекке мәчет

бинасында урнашкан. Болгария дүрт йөз елдан артык Төркия хакимлеге астында яши, шуңа күрә анда бик күп элекке мәчет бинальары сакланып калган. Кайбер мәчетләр, бигрәк тә төрекләр күп яши торган Шумен, Бургасс кебек өлкәләрдәгеләре, хәзерге вакытта да үзләренең төп вазифаларын дәвам иттерәләр.

Археология музеенда Болгария тарихының борынгы чорларына һәм урта гасырларга караган бик кызыклы экспонатлар тупланган. Монда шулай ук Европада иң борынгы саналган неолит, бронза дәверләре игенчелек культурасы материаллары (фәндә ул Каранов культурасы дип йөртелә) һәм борынгы җирле халыклардан Тракия кабиләләре культурасына караган экспонатлар да киң урын алган. Әмма музейның экспонатларга иң бай бүлеге — антик дөнья, әлбәттә. һәм бу бик табигый. Чөнки Балкан ярымутравының хәзер Болгария биләп торган өлеше элекке заманнарда борынгы Грециягә дә, борынгы Римга да чиктәш өлкәләр булган бит. Шуңа күрә монда күп кенә эре антик шәһәрләрнең хәрабәләре сакланып калган (Апполония, Одессос, Адрианополь, Сердика һ. б.) Одессостагы (хәзерге Варна шәһәре) мәһабәт терем калдыклары, Адрианополь һәм Мадарадагы борынгы виллалар, безнең эрага кадәр IV гасырда стеналарына гаҗәеп нәфис рәсемнәр уеп эшләнгән мәшһүр Казанлык төрбәсе — болар һәммәсе дә күңелдә җуелмас тәэсир калдыралар.

Шулай да болгар халкының борынгы тарихына һәм Беренче болгар патшалыгы культурасына багышланган бүлекләр мине күбрәк дулкынландырды. һәм, әйтергә кирәк, бу бүлекләрдәге экспонатлар белән өстән-өстән генә танышу да Балкандагы борынгы болгар кабиләләре культурасы белән Идел буе болгарлары һәм аларның токымы — хәзерге татар халкы культурасы арасында шактый күп охшашлыклар барлыгын күрсәтте. Ләкин бу мәсьәләдә дәлилле киңрәк мәгълумат туплау өчен миңа Болгариянең борынгы культура үзәкләренә сәяхәт ясарга туры килде. Минем сәяхәт Варнадан башланып, ахырда Мадара, Плиска һәм Преслав кебек борынгы болгар шәһәрләре буенча дәвам итте. Варна музее директоры Дм. Димитров, доктор Ж. Выжарова һәм профессор Ст. Ваклинов бу сәяхәттә миңа юлдаш һәм экскурсовод вазифасын үтәп йөрделәр. Шушы уңайлы очрактан файдаланып, мин аларга журнал аша үземнең тирән рәхмәтемне белдерергә телим.

Ә хәзер, әйдәгез, укучы белән бергә, борынгы Болгарстан буенча сәяхәтне тагын бер кат күздән кичереп үтик әле. Аны без Балкан ярымутравына беренче болгар кабиләләренең килеп чыгуы тарихыннан башларбыз.

Бу тарихи вакыйга VII гасырның урталарында була. Кавказ алды һәм Азов буе далаларында борын-борыннан болгар дигән төрки кабиләләр яшәгән. Соңга таба алар Кубрат исемле хан җитәкчелегендә зур кабилә берләшмәсе булып оешалар. Ләкин VII гасыр урталарында бу берләшмә таркала, һәм болгар кабиләләренең бер өлеше, Азов, Кавказ буе далаларын ташлап, Аспарух хан җитәкчелегендә көнбатышка таба юл тота һәм 670 еллар тирәсендә Дунай елгасына килеп чыга, ә 679—681 елларда, Византия императоры Константин IV нең гаскәрен тар-мар итеп, Балкан ярымутравының көньяк өлешен яулап ала. Монда болгарлар җирле славян кабиләләре белән тыгыз бәйләнешкә керәләр һәм озакламый уртак дәүләт берләшмәсе төзиләр. Бу берләшмә тарихта Беренче Болгар патшалыгы исеме белән йөртелә. Аның оешу елы итеп 681 ел, ә нигез салучысы итеп Аспарух хан исәпләнә. Хәзерге көндә болгар халкы шушы беренче болгар дәүләтенең оешуына 1300 ел тулу бәйрәмен билгеләп үтәргә әзерләнә.

Борынгы болгар кабиләләренең Дунай буйларына һәм Балкан ярымутравына күченеп килүләрен археологик тикшеренүләр дә раслый. Алар арасында Нови-Пазар каберлеген тикшерү материаллары аеруча игътибарга лаеклы. Болгариянең беренче башкаласы Плиска шәһәреннән ерак түгел урнашкан бу каберлек VIII гасырга карый. Анда шул чорның гаскәри кешеләре күмелгән булырга тиеш. Аларны кайчакта атлары белән, ә еш кына сугыш кораллары — кылыч, балта, җәя-уклары белән бергә күмгәннәр. Кабер казылмалары арасында шулай ук савыт-саба әйберләре — кувшин, чүлмәк ише нәрсәләр дә еш очрый. Бу савытларга су яки берәр төрле эчемлек салып күмә торган булганнардыр, күрәсең. Нови-Пазардагы кабер табылдыклары һәм мәет күмү йоласы безнең борынгы Идел буе болгарлары каберлекләрен тикшерү нәтиҗәләренә күп яклары белән тәңгәл килә. Аерым алганда, Ульяновск өлкәсенең Кайбела авылы һәм бигрәк тә Татарстанның Зур Тархан авылы янындагы борынгы каберлек-

ләрдән табылган истәлекләр[1] Азов буйларыннан Дунай һәм Идел ярларына күченеп киткән ике төркем болгар кабиләләренең үзара якын һәм кардәш булганлыкларын исбатларга шактый нигезле дәлил була ала.

Әлбәттә, Дунай буена күченеп киткән болгар кабиләләре ыруг-нәсел ягыннан бер бөтен булгандыр дип уйларга ярамый. Чыганакларда, хосусан, Болгар идеиннигы дип йөртелгән язма чыганакта, борынгы Дунай болгарларының төрле-төрле кабилә һәм ыруглардан торганлыгы әйтелә. Аспарух хан үзе, мәсәлән, «Дуло» кабиләсеннән булган икән; чыганакларда шулай ук «Вокил», «Угаин», «Ерми» кебек башка кабилә яки ыруг исемнәре дә телгә алына. Соңгы елларда болгар археологлары (Дм. Димитров, Ж. Выжарова һ. б.) Болгария территориясенең шул ук төньяк-көнчыгыш өлешендә әлеге без сөйли торган чорга кагылышлы бик кызыклы казылма истәлекләр тапканнар. Аларның кайберләре, мәсәлән, 1971 елда Ж. Выжарова тарафыннан Мадара янындагы Кюлевча авылы каберлегендә табылганнары, тулысынча Нови-Пазар каберлеге калдыкларын хәтерләтә, ләкин арада бөтенләй башка типтагы каберлекләр дә бар. Мәсәлән, Варна округының Девня шәһәрчеге янында һәм башка урыннарда табылган каберлекләрне өйрәнү (Дм. Димитров тикшеренүләре) болгар кабиләләренең кайсыларындадыр мәетне яндырып күмү йоласы булганлыгын ачык күрсәтә. Бу факт, бер караганда, әллә ни гаҗәпләндермәскә дә тиеш шикелле, чөнки болгарлар килгәнче Балкан ярымутравының төп халкын тәшкил иткән славян кабиләләре дә мәетне һәрвакыт яндырып күмә торган булганнар бит. Ләкин бу бер үк йола тегеләрдә һәм боларда бөтенләй ике төрле чагыла. Девня каберлеге калдыкларыннан күренгәнчә, анда мәетне бер читтә киеме белән бергә яндырганнар, аннан соң җыелган көлне шул килеш яки махсус таш тартмага салып кечкенә чокыр-кабер төбенә урнаштырганнар да, янәшәсенә балчык савыт һәм ит кисәкләре куеп, өстән туфрак белән күмгәннәр. Славяннар исә бер читтә киемсез яндырылган мәет көлен, гадәттә, балчык тартмага — урнага салып күмгәннәр. Беренче йола Урта Идел һәм Кама буйларында болгарларга кадәр яшәгән һәм тарихта Имәнкискә исеме белән йөртелгән җирле кабиләләрнең мәет күмү йоласына бик охшаш. Татарстанның Лаеш районы Рождество авылы янындагы борынгы зур зират калдыкларын өйрәнү материаллары нәкъ менә шул хакта сөйли. Әмма ул материаллар, әйткәнебезчә, V—VII йөзләргә, ягъни Идел буена болгар кабиләләре күчеп килгәнгә кадәр булган чорга карый. Моңардан исә без шундый нәтиҗә чыгара алабыз: болгарларга кардәш кайбер кабиләләр Идел һәм Кама буйларында, күрәсең, Кубрат берләшмәсе таркалганга кадәр үк яшәгәннәр. Бу факт Татарстан тарихын өйрәнүдә һәм бигрәк тә төрки телдә сөйләшүче җирле халыкларның чыгышын ачыклауда гаять әһәмиятле роль уйнарга мөмкин. Ә инде борынгы Дунай болгарларында мәет күмү йоласының ике төре очравына килсәк, моны язма чыганаклар да раслый. Мәсәлән, X гасыр башында яшәгән күренекле гарәп географы Әл-Масуди, IX гасырның беренче яртысында Византия гаскәрләренә әсир төшеп, Балкан ярымутравын гизеп кайткан Мөслими-әл-Җәрми дигән кешенең сүзләренә таянып, борҗаннар турында (шәрыкта Дунай буе болгарларын борҗаннар дип йөрткәннәр) болай яза: «...алар үлгән кешене тирән кабергә салып күмәләр... Кайсылары исә мәетне яндыралар...»

Борынгы Дунай буе болгар кабиләләре нинди телдә сөйләшкәннәр, аларның көнкүреш һәм культура дәрәҗәләре нинди булган? Кызганычка каршы, бу сорауларга ачык җавап табу кыен. Шулай да Дунай Болгарстаны чорыннан сакланып калган кайбер язма истәлекләр борынгы болгар теле турында беркадәр мәгълүмат бирә шикелле. һәрхәлдә, ул үзенең сүзлек составы белән чуваш теленнән бигрәк хәзерге Казан татарлары теленә якынрак торган булырга тиеш. Әле безнең гасырның башларында ук болгар галимнәре борынгы шәһәр калдыкларын тирәлегендә язулы таш баганалар — колонналар тапканнар. Баганалардагы язулар VIII йөздә һәм IX йөзнең беренче яртысында булган теге яки бу тарихи вакыйга турында сөйлиләр. Тарихи вакыйгаларны таш баганаларга шулай язып, теркәп калдыру төрки кабиләләрнең борынборыннан килгән тотрыклы бер традициясе ул. Бу традиция Төрек каганаты хаганнарына да, Идел буе болгарларына да хас күренеш, шулай ук ул үлгән кешеләрнең

[1] Бу хакта кара: В. Ф. Генинг, А. Х. Халиков. Ранние болгары на Волге. М., 1964. (Рус телендә.)

каберләренә язулы таш кую йоласы рәвешендә Идел буе болгарларының турыдан-туры варислары булган Казан татарларында да гасырлар буена сакланып килгән.

Дунай буе болгар колонналарының күпчелеге Омуртаг хан (814—831) һәм аның варисы Маламир хан (831—836) заманында куелган. Ләкин арада элегрәк чорга караганнары да бар. Шундыйлардан Тервел хан (702—718), Кормисош хан (740—756) колонналарын күрсәтергә мөмкин. Бу багана язуларында иң еш очрый торган сүзләр: ханның дәрәҗә билгесе — «хан ювиги» («ханым-солтаным» мәгънәсендә), башка түрәләрнең дәрәҗә билгеләре — «тархан», «баһатур», «олобоһатур», «баһаин», «боила» һ. б., шунда ук — барлык төрки кабиләләр өчен уртак мәҗүси алла исеме — «тангра» («тәңре»). «Белег» («билге»), «тояга» («таяк»), «каиш» («каеш») һәм башка шуның кебек сүзләр дә борынгы Дунай болгарлары теленнән алынган дип исәпләнелә. Кызганычка каршы, безнең тел галимнәребез бу мөһим мәсьәләгә әлегәчә тиешле игътибар бирмиләр. Ә бит борынгы Дунай болгарлары телен (шулай ук бүгенге болгар телен) татар теле белән тарихи үсештә чагыштырып өйрәнү кызыклы гына нәтиҗәләр бирә алыр һәм Идел буе төрки халыклары этногенезындагы кайбер мәсьәләләрне ачыкларга ярдәм итәр иде. Тел өлкәсендә топонимик эзләнүләр дә бик кызыклы. Берничә мисал гына китереп узыйк. Хәзерге Болгариядә әлегәчә шундый бер традиция саклана: алар сулыкларны капма-каршы кую принцибы буенча я «акка», я «карага» бүлеп йөртәләр («Черна речка» — «Бела речка», «Черна места» — «Бела места», «Черна море» — «Бела море» һ. б.). Шундый ук күренешне без Идел буе болгарларында һәм аларның дәвамнарында очратабыз: «Актай» — «Каратай» («тай», «сай» — «инеш» дигән сүз), «Ак чишмә» — «Кара чишмә», «Ак Идел» — «Кара Идел», «Ак яр» — «Кара яр» һ. б. Борынгы болгар кабиләләре яшәгән торак һәм шәһәр урыннарының, болыннарның Дунай буенда да, Идел-Кама буйларында да, гадәттә, кызларга бәйләнешле исемнәр белән аталып йөрүе дә кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Болгариядә: Девня (борынгы болгар каберлекләре урнашкан шәһәрчек исеме; «Кызлар каласы» дигән мәгънәне аңлата), Девичья гора (Шумен янындагы борынгы шәһәр урыны) һ. б. Татарстанда: «Кызлар каласы», «Кызлар тавы», «Кызлар зираты», «Кызлар уйный торган җир» һ. б. Моны борынгы болгарларда хатын-кызның чагыштырмача шактый зур хөрмәткә ия булуы белән аңлатырга кирәктер, күрәсең. Әлеге гарәп географы Әл-Масуди бу хакта менә болай яза: «Аларда (болгарларда — А. Х.) янә шундый гадәт бардыр: мирас бүлгәндә хатын-кызга ирләргә караганда күбрәк өлеш чыгаралар». Ибне Фазлан да, 922 елда Идел буе болгарлары иленә килгәч, андагы хатын-кызларның мөстәкыйльрәк, ирекләрәк яшәвен күреп гаҗәпләнә.

Дунай буенда Аспарух хан төзегән беренче Болгар дәүләтенең мәркәзе Плиска булган. Болгар язма чыганакларында бу турыда менә болай диелә: «Той Испєрих (Аспарух — А. Х.) създаде велики градове. Той създаде и Плюска град». Болгариянең төньяк-көнчыгыш өлешендә, хәзерге Шумен округының Плиска авылы янында, бу шәһәрнең әле булса җимерекләре саклана. 1899—1900 еллардан башлап монда системалы казу-тикшерү эшләре алып барыла, ә 1937 елдан бирле археология музее эшли. Шәһәр, аның тирәлеге дәүләт карамагына алынып, резерват, ягъни заповедник (истәлекле урын) дип игълан ителгән.

Борынгы Плиска шәһәре Дунай буендагы Провадия үзәненең тигез, урта бер җирендә турыпочмаклык рәвешендәге өч рәт концентрик ныгытма эчендә урнашкан булган. Туфрак өеп эшләнгән тышкы ныгытма-стена 23 кв. м. мәйданны үз эченә алган, ә үзәк ныгытма эчендәге мәйдан $^1/_2$ кв. км га тигез. Тышкы ныгытма буйдан-буйга тирән чокыр — ур белән әйләндереп алынган булган. Әл-Масуди үзенең истәлекләрендә нәкъ менә шундый шәһәр ныгытмаларын күздә тотып яза булса кирәк: «Борҗаннарның өлкәсе (шәһәре ягъни — А. Х.) кәз койма белән әйләндереп алынган; коймага агач тәрәзәләргә охшаш тишекләр тишелгән; бу койма канал кырыйларындагы диварны хәтерләтә. Авылларның андый коймалары юк». Плисканың үзәк ныгытмасы калын таш стенадан гыйбарәт; аның чат-почмакларына түгәрәк манаралар (башнялар), фронталь өлешләренә — биш кырлы, ә чыгып-кереп йөри торган капкаларына ике яклап дүрт кырлы манаралар ясалган булган.

Планировкасы ягыннан Плисканың Рим шәһәрләре белән дә, Византия шәһәрләре белән дә берниндн уртаклыгы юк. Ә менә Идел буе болгар шәһәрләре белән чагыш-

тырганда андый уртаклыкны табарга мөмкин. Плисканың планировкасы бигрәк тә борынгы Болгар (X гасырдан башлап — Бөек Болгар) шәһәре планировкасына охшаган.

Археологлар Плисканың үзәк шәһәрчек өлешендә Омуртаг хан заманында салынган зур таш пулат-сарай хәрабәләрен казып чыгаралар. Алар астында тагын да зуррак икенче бер бинаның да (мәйданы 74 м × 60 м) җимерекләре табыла. Анысын Крум хан заманында төзелгән һәм 811 елда Плисканы сугышып алганда Византия императоры Никифор гаскәрләре тарафыннан җимерелгән сарай калдыклары дип исәплиләр. Сарайларның һәр икесенең дә нигезләре юнып эшкәртелгән эре кисәкле ак таштан, ә стеналары дүрткел формадагы кызыл кирпечтән салынган булган. Крум сарае формасы белән квадратка якын, Омуртаг сарае исә озынча дүртпочмаклыкны хәтерләтә. Соңгысының төньяк урта өлешендә ярым түгәрәк стеналы апсидсыман эчке бүлмәсе булган. Шундыйрак формадагы бүлмә безнең тарафтан 1971 елда борынгы Болгар шәһәре җимерекләрен казыганда зур бер кирпеч бина эчендә табылган иде.

Сарайлар каршында, бераз читтәрәк, мәҗүсиләр храмы булган, болгарлар христиан диненә күчкәч, ул храм чиркәү итеп үзгәртелгән. Шундый типтагы мәҗүсиләр храмнарының хәрабәләре шәһәрнең башка урыннарында да, шулай ук Мадарада һәм Дунай Болгарстанының икенче мәркәзе Преславта да очрый. Тышкы күренешләре белән алар берсе икенчесе эченә кереп урнашкан дүртпочмаклы биналар рәвешендә булганнар.

Үзәк ныгытма — крепость эчендә Кече сарай бинасының калдыклары казып чыгарыла. Бу бина озын җир асты юлы белән Зур сарайга тоташкан булган. Шушында ук чит-читләре таш белән түшәлгән түгәрәк яки дүрткел формадагы бассейннар, мунча бинасы һәм берничә ярдәмче корылма урнашкан. Кече сарайның эчке мәйданы — 568 кв. м.; сарайдан ныгытманың тышкы ягына тагын бер җир асты юлы салынган. Мунча бинасы идән астына кирпечләр өеп ясалган махсус җылыту системасы ярдәмендә җылытылган. Мондый система соңгы вакытларда борынгы Болгар шәһәре урынында тикшерелгән җылыткыч системаларын хәтерләтә. Анда да кирпечтән салынган биналарны шул рәвештә җылыта торган булганнар.

Плисканың эчке шәһәр территориясе суүткәргеч балчык торбалар челтәре белән капланган булган. Монда бары ханнар һәм феодаллар гына яшәгәннәр. Хан сарайларыннан тыш, эчке шәһәрдә боил һәм баһаиннарның торак йортлары, хан гвардиясе һәм гаскәриләр яшәгән казарма җимерекләре казып чыгарыла.

Тышкы шәһәр территориясендә исә торак йортлар азрак очрый. Бу территориянең күп өлеше сугыш атлары өчен көтүлек булып хезмәт иткән, күрәсең. Моны Әл-Масуди да искәртеп үтә. Атлар, ди ул, «ирекле рәвештә болыннарда утлап йөриләр, аларга беркем дә атланып йөрми, бу бары сугыш чорында гына рөхсәт ителә. Әгәр берәрсе дөнья имин чакта атка атланса, аны үтерәләр». Шулай да тышкы шәһәрдә дә болгар урдасының гади кешеләре, һөнәрчеләр өчен аерым бистәләр һәм сәүдәгәрләр өчен кәрвансарайлар булганлыгы күренә. Мәсәлән, шундый кәрвансарайларның берсе эчке шәһәргә алып керә торган үзәк капканың көньягындарак урнашкан булган. Шәһәр халкының бер өлеше киез өйләрдә — тирмәләрдә яшәгәндер дип фараз итәргә мөмкин. Ул тирмәләрнең калдыклары сакланмаган, әлбәттә; ләкин Девня янындагы борынгы Рим шәһәре Адрианопольнең амфитеатры урнашкан урында археологлар кызыклы бер тирмә моделе табып алалар; таштан эшләнгән бу модель үзенең төзелеше, формасы белән бездәге кыргыз һәм башкорт тирмәләрен бик нык хәтерләтә.

Эчке шәһәрдән төньяк-көнчыгышка таба, бер километр чамасы ераклыкта, зур чиркәү хәрабәләре сакланып калган; элек аның урынында мәҗүсиләр храмы булган дип уйланыла. Бу урынга эчке шәһәрдән таш юл сузылган. Чиркәү үзе Византия стилендә — озынча өчпочмак рәвешендә (базилика) төзелгән, һәм катлаулы архитектурасы, зурлыгы белән ул әле дә гаҗәеп бер бина булып күренә. Аны IX гасыр болгар шәһәрләре бергәләшеп салганнардыр, күрәсең, чөнки колонналарның һәрберсенә тегә яки бу шәһәрнең исеме язып калдырылган. Соңгы елларда базиликаның төньяк-көнбатыш чигендә болгар ханнары һәм патшаларының каберлеге табыла. Биш зур таш саркофаг казып чыгарыла; галимнәрнең фикеренчә, аларда Аспарух, Тервел, Крум, Омуртаг һәм Маламир кебек болгар ханнары күмелгән булырга тиеш. Ләкин саркофагларның дүртесе, кызганычка каршы, борынгы заманда ук инде таланган, бары берсеннән генә археологлар затлы кием һәм корал калдыклары табып алалар.

Тышкы шәһәр аръягында, бигрәк тә көньяк юнәлештә, тигез рәтләр булып тезелгән сәер таш кисәкләре очрый. Җиргә вертикаль утыртылган һәм «девташлар» («ватык ташлар») исеме белән йөртелгән бу таш кисәкләрен галимнәр борынгы заманда читтә һәлак булган болгар сугышчылары истәлегенә куелган һәйкәлләр дип уйлыйлар. Плиска янында борынгы зират, каберлек калдыклары да күп. Аларның берсен — Нови-Пазар каберлеген — мин инде телгә алып үткән идем. Аерым курган рәвешендә сакланып калган болгар каберлекләре дә еш очрый. Шундый бер курган әле күптән түгел генә ачып тикшерелгән. Бу курганнарның характерлы үзенчәлеге шунда: мәетләрнең үзәк кабердәгесе дә һәм аның тирә-ягындагылары да яндырып күмелгәннәр. Тагын Әл-Масуди сүзләре искә төшә: «Әгәр борҗаннарда берәр ак сөяк кеше үлсә, алар аның яраннарын һәм хезмәтчеләрен дә җыеп... яндыралар һәм әйтәләр: теге дөньяда янмас өчен аларны без бу дөньяда яндырабыз, диләр».

Плисканың материаль культурасында борынгылык әле шактый нык саклана. Бу бигрәк тә керамикада ачык күренә. Борынгы Дунай болгарларыннан монда ике төр савыт-саба әйберләре сакланып калган. Аларның бер төрен тышкы ягына дулкын-дулкын сызыклы орнамент төшерелгән чүлмәкләр, ә икенче төрен соры яки кызыл төстәге зур күләмле балчык савытлар тәшкил итә. Соңгыларының тышлары шомартылган һәм вертикаль-горизонталь сызыклар ярдәмендә үзенә бер төрле бизәкләр белән капланган. Мондый төрдәге савыт-саба әйберләре Идел буе болгарларына да хас. Сугыш һәм эш кораллары, бизәнү әйберләре формаларында да шундый ук уртаклыкны табарга мөмкин. Ләкин шуның белән бергә, Плисканың материаль культурасында славян кабиләләре һәм Рим-Византия культураларының да тәэсире шактый нык сизелә.

Дунай буе Болгарстанына көнбатыштан дәһшәтле күршесе — Византия, ә төньяктан күчмә халыклар — печенеглар, соңга таба — кыпчаклар һәрвакыт сугыш белән янап торган. Шуңа күрә ул үзенең чикләрен хәрби ныгытмалар ярдәмендә сакларга тырышкан. IX—X гасырларда Дунай елгасының түбәнге уң як яры буйлап дистәләрчә чакрымнарга сузылган туфрак ныгытмалар ясала. Илнең көньяк-көнбатыш чикләрендә дә Византиядән саклану өчен шундый ук ныгытмалар барлыкка килә. Туфрак ныгытмалар янында, гадәттә, зур булмаган крепость калалар төзелгән. Мәркәз шәһәрләрдән аермалы буларак, бу крепость-калалар өчпочмак формасында салынганнар.

Илнең үзәк өлешендә болгар авыллары, шәһәрләр һәм «хан ауллары» — ханнар яши торган мәркәзләр урнашкан булган. Аспарух хан өчен төзелгән Плискадан тыш, мондый мәркәзләргә мисал итеп тагын «Омуртаг хан аулын» күрсәтергә мөмкин. Ул Плиска белән Преслав шәһәрләре арасында, Тича елгасы буенда урнашкан булган. Аның ачылу тарихы болай: XIX йөзнең ахырларында археологлар Чаталар дигән авыл янында язулы бер мәрмәр таш багана — колонна табып алалар. Язуда «хан ювиги Омуртаг»ның болгарча ел исәбе белән сигезенче елда («сигор елем»), ягъни 822 нче елда, «аул» салуы, шунда Плискадан үзенең гарнизонын күчерүе һәм, ниһаять, Тича елгасы аша күпер төзетүе турында әйтелгән була. Чыннан да, мәрмәр багана табылган урыннан ике километр көнбатыштарак әлеге «хан аулы»ның хәрабәләре казып чыгарыла. Формасы белән ул тигез дүртпочмаклык рәвешендә. Тышкы ныгытмасы туфрак өеп эшләнгән һәм тирәли чокыр — ур белән әйләндереп алынган, ә эчкесе — таш; ул 100 м × 112 м мәйданны билән тора. Эчке шәһәрдә таш һәм кирпечтән салынган казарма, мунча, хан сарае кебек биналарның җимерекләре табыла.

Мадара — болгар тарихының икенче бер зур истәлекле урыны. Археология һәм архитектура истәлекләренең бөтен бер комплексын тәшкил иткән Мадара шул ук Шумен округында, Провадия тауларының Плискадан көньяктарак күтәрелеп торган кыялары тирәсендә урнашкан. Хәзерге вакытта бу урын тарих-археология заповеднигы булып исәпләнә, анда махсус салынган бинада музей оештырылган, туристик комплекс булдырылган.

Мадараның тарихи истәлекләре арасында иң атаклысы — текә таш кыя битлегенә, егерме биш метр югарылыкка, рельефлы итеп эшләнгән җайдак сурәте, әлбәттә. Сурәт табигый зурлыкта ясалган һәм ат менгән җайдакның сөңге белән ерткыч арсланга һөҗүм итү моментын тасвирлый. Бераз арттарак аның эте дә бар. Тулаем сурәт җиңү тантанасын аңлата. Рельеф тирәли борынгы грек телендә уеп язылган язулар да шул хакта сөйли. Анда болгарларның Тервел хан (702—718) җитәкчелегендә дошман гаскәрләрен җиңеп, мөстәкыйль дәүләт булып оешулары һәм бу мөстәкыйль-

лекнең Византия тарафыннан танылуы әйтелгән. Әлеге язмаларда Балканда беренче тапкыр «болгар» дигән исем телгә алына. Сүз уңаеннан монда тагын шуны да искәртеп үтәргә кирәк: Балканда бу исем нәкъ бездәгечә — «былгар» (българ) дип әйтелә. Рельефтагы башка язмалар исә Круместа яки Кормисош (740—756), Омуртаг ханнар заманына карый һәм болгарларның шул чордагы яңа җиңүләрен бәян итә.

Гомумән, ат менгән җайдак сурәтен ясау Дунай һәм Идел буе болгарларының һәр ике төркеме өчен дә хас күренеш. Беренчеләрендә ул ташка төшерелгән сурәт рәвешендә (граффити) борынгы Плиска, Преслав табылдыклары буенча яхшы билгеле, ә Идел буе болгарларында аны керамика яки металл асмалар бизәге рәвешендә очратырга мөмкин. Болгарларда шулай ук этка табыну да бик нык таралган булган. Этнең болгарча борынгы атамасы «куче» хәзерге болгар телендә үзгәрешсез саклана, ә Казан татарларында «көчек» формасында әле булса да яшәвен дәвам итә. Идел буендагы борынгы каберлекләрдә (Тархан, Танкеево), шулай ук Нови-Пазар каберлегендә табылган эт сөякләре мәет күмү ритуалында этнең үзенә бер төрле урын тотканлыгын раслап тора. Идел буе болгарлары эт улавын яхшыга юрый торган булганнар — моны без ибне Фазлан язмалары буенча беләбез. Этка табыну йоласы Казанның салынуы турындагы риваятьтә дә чагылып үтә: Казан стеналары астына терелей эт күмеп калдырганнар, имеш. Казан татарларында әле соңгы вакытларгача шундый бер кызыклы гадәт яшәп килгәнлеге билгеле: бала тугач, аңа «көчек күлмәге» кидерә торган булганнар. Аерым ыруг һәм кабиләләрнең килеп чыгышлары кайбер легенда һәм риваятьләрдә эт исеме белән бәйләнештә бирелүе дә игътибарга лаеклы. Ә IX—X гасырларда Урта Идел буе өлкәләрен шәрыкта еш кына «эттән туган печенегләр иле» («ит бечене») дип атап йөрткәннәр, ибне Фазлан исә Идел буе болгарларын печенегча «сакалаблар», ягъни «эттән туган кешеләр» дип атый.

Мадара рельефы тирәсендә археологлар шактый күп санлы культ корылмалары ачалар. Аларның беришесе суга табыну культы белән бәйле, беришесенең эчендә исә зур-зур таш кисәкләре табыла. «Даулташ» дип йөртелгән бу ташларны кыялардан кителеп төшкәндер дип уйлыйлар. Корылмалар үзләре берсе икенчесе эченә кереп урнашкан турыпочмаклыклар рәвешендә булып, Преслав белән Плискадагы борынгы мәҗүсилек храмнарын хәтерләтәләр. Кайберләренең янәшәсендә таш бассейн җимерекләре ята. Бу бассейннарга су тау чишмәләреннән җыела торган булган. Мадараның культ корылмалары төзелешләре белән Бүләрдәге борынгы гыйбадәтханәләрне искә төшерәләр. Бүләрнең изгеләр чишмәсе дип йөртелгән Балынгуз күле янында, ислам дине кабул ителгәнче, ягъни IX гасырда ук, шундый турыпочмаклык рәвешендәге гыйбадәт корылмалары күпләп төзелгән дип уйланыла. Алар, күрәсең, төрки кабиләләрнең уртак мәҗүси алласы Тәңрегә табыну урыны булып хезмәт иткәннәрдер. Моны Мадарада табылган язма истәлекләр дә раслый. Шундый истәлекләрнең берсендә, мәсәлән, IX гасырның беренче яртысында, ягъни христиан диненә күчү алдыннан, болгарларда мәҗүсилек гадәтләренең әле бик нык сакланган булуы әйтелә: «хан ювиги Омуртаг е от бога владетел... направих жертвоприношение на бога Тангри...»

Мадара борынгы болгар тарихының гына түгел, бәлки Рим культурасының да истәлекле урыны санала. Монда II—V йөзләрдә римлеләр төзегән мәһабәт вилла хәрабәләре, V—VI йөзләргә караган торак урыны калдыклары бар. Мәсәлән, Голяма (Олы) могарә дип йөртелгән урында зур склад бинасы һәм торак йорты җимерекләре табыла. Әлеге складта ашлык һәм башка азык-төлек әйберләрен саклау өчен һәрберсе 800 литр сыешлы гаять зур балчык савытлар торган. Ниһаять, Мадара — тау башына салынган һәм таш стена белән әйләндереп алынган кала-крепость ул. Мадара заповедынгына шулай ук XI—XIV йөзләрдә төзелгән берничә чиркәү, шул исәптән таш кыя эченә кертеп эшләнгән монастырь корылмасы да карый. Бу монастырьның хөҗрәләре, чиркәүләре һәм башка биналары һәммәсе дә таш кыя эчендә урнашкан. Шундыйрак типтагы монастырь тагын Варнадан төньяктарак та бар. Аңысы XIII—XIV йөзләрдә төзелгән һәм «Аладжа монастырь» дип йөртелә («аладжа» — алача, чуар дигән мәгънәне аңлата, Гайна татарларында — «алачыбыр»).

864—865 елларда, Борис патша вакытында, Дунай буе болгарлары христиан динен кабул итәләр. Шуннан бераз гына элегрәк Болгариядә ислам динен тарату омтылышы да булып ала. Борис патша янына көнчыгыш болгарларыннан миссионерлар килеп йөри, алар мөселман китаплары алып киләләр, патшаны ислам диненә күчәргә өнди-

ләр. Ләкин бу эш барып чыкмый. Христиан динен кабул итү халыкның бер өлешендә, бигрәк тә борынгы төрки болгар нәселеннән килгән өлешендә, көчле ризасызлык тудыра, алар баш күтәрәләр. Ләкин каршылык тиз бастырыла, фетнәчеләрнең беришесе, күрәсең, җитәкчеләре — боиллар һәм баһаиннар, бөтен гаилә-нәселләре белән бергә Борис патша тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителәләр. Бу фаҗигале вакыйганың эзләре кайбер археологик табылдыкларда да чагылыш таба. Мәсәлән, күптән түгел археолог Димитров Девня шәһәрчеге янында Болгариядә христиан динен кертүнең беренче чорына караган зур бер борынгы каберлекне ачып тикшерә. Иңе 5,7 м, тирәнлеге 3,5 м чамасындагы түгәрәк чокырдан 74 хатын-кыз һәм баланың сөякләре казып чыгарыла. Тикшерүләр аларның анда тереләй ташланганлыгын һәм күбесенең кул-аяклары бәйле булганлыгын күрсәтә. Тагын шунысы характерлы: күпчелек баш сөякләре төзелешендә горизонталь юнәлештә ясалма үзгәреш (деформация) сизелә. Ә баш сөяге формасын шулай ясалма рәвештә үзгәртү борынгы төрки болгарларының бер өлешендә, бигрәк тә ак сөяк ыруглар арасында, тотрыклы бер традиция ул. Андый традицияне без һуннарда һәм һуннар белән аралашып яшәгән кайбер Урал буе кабиләләрендә дә очратабыз (Кушнаренко каберлеге). Димәк, Девня янындагы каберлекне Борис патша террорыннан һәлак булган кешеләр күмелгән гомуми зиратларның берсе булгандыр диярга мөмкин.

Симеон патша заманында (893—927 еллар) Беренче Болгар дәүләтенең үзәге Преславка күчерелә. Шул ук Шумен округында, Плискадан илле километр көньяк-көнбатыштарак, Планин дигән тау сыртының калку итәгендә борынгы Преславның әле булса мәһабәт хәрабәләре ята. Әнә, Балкан капкасы дип аталган тарлавыкка илтүче юл буйлап, борыла-сырыла, туфрак өеп эшләнгән тышкы ныгытманың калдыклары сузыла, ә арырак эчке стена җимерекләре күренә. Бу таш стенаны һәм эчке шәһәрне Симеон патша егерме сигез ел буена төзеткән диләр.

Хәзерге вакытта Преслав — Болгариядәге археологик заповедникларның иң эресе. Музей өчен монда бик шәп бина һәм башка ярдәмче корылмалар төзелгән. Алар һәммәсе дә Болгария Фәннәр академиясе карамагында торалар.

Преславка нигез салыну вакыты төгәл билгеле түгел. Язма истәлекләрдә бу хакта бары: «Симеон създаде градовелики по морето, и великия град Преслав той създаде»,— дип кенә искәртеп үтелә. Шулай да галимнәр аны элекке хан «аулы», бу очракта Крум хан «аулы», урынында салынгандыр дип уйлыйлар. Тарихтан билгеле булганча, Крум хан (803—814) Омуртагның әлгәре һәм IX—X гасыр болгар патшалары династиясенә нигез салучы булып исәпләнә.

Мин Преславта чакта болгар археологлары крепостьның иң борынгы таш стенасын ачу эшенә керештеләр. Бу стена үзенең формасы һәм янәшәсендә урнашкан мунча, казарма биналары белән хан «аулы»лары», аерым алганда, Омуртаг хан «аулы» планировкасына һәм төзелешенә бик охшаган.

Преслав, югарыда телгә алынган Плиска һәм Омуртаг «аулы» кебек үк, ике төп өлештән — тышкы һәм эчке шәһәрләрдән тора. Моннан башка тышкы шәһәр читендә, Тича елгасы аръягында, монастырьлар һәм феодалларның аерым-аерым йортлары урнашкан булган. Тышкы шәһәр үзенең чик сызыклары белән безнең борынгы Биләрне хәтерләтә, ягъни ул да шулай бишпочмаклык формасында төзелгән. Шәһәр тирәли сузылган туфрак ныгытманың гомуми озынлыгы җиде километр. Ә инде Эчке шәһәрне иңе 3,25 м, биеклеге 10 метрлы таш стена әйләндереп алган. Крепостьның чат почмакларында түгәрәк манаралар күтәрелеп торган, ә төньяк һәм көньяк стеналардагы капкалар һәрберсе дүрткел формадагы дүртәр манара белән ныгытылган. Алар 15 метр биеклегендә булганнар. Крепость стенасының яхшырак сакланган көньяк-көнчыгыш өлешендә ташка тырнап ясалган рәсемнәр — ат менгән яки җәяүле кеше, ерткыч хайван сурәтләре һәм һәртөрле язулар күрергә мөмкин. Болар — крепостьны саклаучы эшсез гаскәриләр ясаган рәсемнәр дип уйланыла.

Көньяк стенаның эчке ягына терәп һәрберсе квадрат формадагы унсигез сәүдә йорты салынган булган. X гасырда дошман гаскәре шәһәрне штурмлаганда стена ишелеп, бу йортлар күмелеп кала, шуңа күрә алар эчендәге әйберләрнең күбесе бүгенге көнгә кадәр шул килеш сакланган диярга мөмкин. Археологлар анда төрле бизәнү, көнкүреш әйберләре, савыт-саба ватыклары, үлчәү шикелле нәрсәләр казып чыгарганнар.

Эчке шәһәрдә сарайлар комплексы урнашкан — Зур сарай һәм Кече сарай. Алар ак таштан салынган һәм тышкы күренешләре, архитектуралары белән Плискадагы сарай корылмаларын хәтерләтәләр. Сарайлар янәшәсендә төрле хуҗалык биналары һәм мунчалар булган. Шунысы кызык, Кече сарай эчендә, аның көньякка караган стенасы буенда, Плиска һәм Біләрдәге сарай корылмаларындагыча, ярым түгәрәк формадагы өстәмә бүлмә бар. Ул йокы бүлмәсе хезмәтен үтәгәндер, күрәсең. Аның эче тирмәгә охшатып эшләнгән булган. Преславтагы сарай корылмалары (тарихта алар «сарай ери» исеме белән йөртелә) әле бүгенге көндә дә җуелмас тәэсир көченә ияләр. Аларны төзү өчен эре таш блоклар һәм квадрат рәвешендәге кирпеч кулланылган. Формасы һәм зурлыгы белән (27 ╳ 27 ╳ 4—5 см) бу кирпеч янә Идел буе болгарлары файдаланган кирпечне искә төшерә. Сарайларның стена, түшәмнәре рельефлы итеп төрле архитектура бизәкләре белән бизәлгән булган, ул бизәкләр арасында иң еш очраганы — үсемлек сурәте.

Эчке шәһәр белән янәшә, аның төньяк-көнбатыш тарафында, чиркәүле зур монастырь җимерекләре ята. Бу монастырьның бүлмә иданнәре кайчандыр мозаикалап эшләнгән булган, ә төньяк өлешендәге җир асты төрбәләрендә күп гасырлар буе беренче болгар патриархларының (дин башлыкларының) табутлары саклап тотылган. Тагын да бер чиркәү Эчке шәһәрнең көньягында урнашкан. Анысы «түгәрәк» яки «алтын» чиркәү дип йөртелә һәм борынгы болгар архитектурасының иң гүзәл җәүһәрләреннән санала. Ул 908 елда элеккеге мәҗүсилар гыйбадәтханәсе урынында төзелгән дип уйланыла. Чиркәү гаҗәеп матур рельефлы скульптуралар, күп санлы колонналар, мозаикалар белән бизәлгән, иданнәренә төрле төстәге плитәләр җәелгән; аның түгәрәк түбә — гөмбәзенә алтын йөгертелгән булган.

Гомумән, X гасыр Болгария тарихының «алтын чоры» булып исәпләнә. Бу чорда болгар (гомумславян) язуы туа, шул нигездә әдәбият барлыкка килә, рухи һәм материаль культура формалаша. Дунай буе болгарларының X—XI гасыр материаль культурасы буенча Преслав музеенда гаҗәеп бай материал тупланган. Алар белән якыннан танышкач, без бу культураның катлаулы синтез нигезендә, төгәлрәк әйтсәк, борынгы төрки болгарлары, славян һәм соңгырак дәвердәге Тракия кабиләләре культураларының үзара катлаулы аралашуы, берегүе, аннан соң урта гасырларда иң алдынгы илләрдән саналган Византия культурасының шактый көчле тәэсире нигезендә формалашкан булуын күрәбез. Ләкин бер үк вакытта анда төрки болгарлары культурасының күп кенә үзенчәлекле сыйфатлары да сакланып калган. Идел буе һәм Дунай буе болгарларының X—XII гасыр тарихларына караган археологик материаллар нәкъ менә шул хакта сөйли.

Хан һәм патшалар яшәгән мәркәз шәһәрләрнең планировкаларын гына чагыштырып карыйк. Дунай Болгарстанындагы Плиска, Преслав һәм Омуртаг хан «аулы», зурлыклары ягыннан булсын, эчке һәм тышкы шәһәргә бүленүләре ягыннан булсын, Идел буендагы Біләргә (Бөек шәһәргә), Суарга, хәзерге Пенза өлкәсендә урнашкан Ошель (Ашлы), Юлово (монысы Буртас дигән борынгы мәшһүр болгар шәһәре булгандыр дип уйланыла) шәһәре хәрабәләренә бик якын торалар. Шәһәр тирәли туфрак нигытмалар, ил чикләре буйлап саклану линияләре төзү рәвешендә дә шундый ук охшашлык бар. Бу охшашлык төзү эшендәге кайбер традицияләрдә дә күренә. Дүрткел формадагы кирпеч куллану, биналарны дүртпочмаклык рәвешендә планлаштыру, торак йортларын идән асты җылыткыч системалары ярдәмендә җылыту, кирпеч вагы (хорасан) кушылган известь эремәсе белән ябыштырып эре ак таш блокларыннан стеналар кою, зур биналарның нигез асларын субайлар кагып ныгыту, югары катлау кешеләренең торак йортларына, тирмәгә охшатып, апсидсыман чыгынтылы өстәмә бүлмәләр ясау һәм, ниһаять, гади халык өчен төзелгән өйләрнең турыпочмаклык рәвешендә һәм кирпеч яки таш мичле булуы, ә түшәм-түбәләренең гөмбәз сыман, көймәле итеп ясалуы — болар һәммәсе дә әнә шул уртак традицияләрнең ачык мисаллары булып торалар. Дунай һәм Идел буе болгарларының төзүчелек эшендәге бу югары һәм уртак культурасы аларның Төньяк Кавказ һәм Азов буе далаларында шәһәр-калалар салып яшәгән борынгы бабаларына ук барып тоташадыр, күрәсең. Чыганаклардан күренгәнчә, болгарлар Азов һәм Кавказ тирәләрендә дә Беленджер, Фанагория, Семендер кебек шәһәрләр төзегәннәр бит.

Дунай буе болгарларында керамика сәнгате нигездә славян һәм Рим — Византия традицияләре тәэсирендә формалашкан, әмма анда да Идел буе болгарлары керамикасына хас кайбер үзенчәлекләрне күрергә мөмкин (балчык савытларны бер үк ысул белән ялтырату, аларга кызыл төс бирү; кувшин, миски, зур чүлмәк, хум шикелле бер үк типтагы савытлар җитештерү; аларның тышларына дулкын һәм горизонталь сызыклы бизәкләр төшерү; чүлмәк һәм кәсәләрнең тоткаларын үрдәк борынына охшатып ясау һ. б.). X—XI йөз Дунай буе болгарлары керамикасында шулай ук яшел глазурь йөгертелгән савытлар да еш очрый, ә XII йөздә өске кырыйлары чыгынкылап (ирнәп) эшләнгән зур күләмле савытлар барлыкка килә. Боларның һәммәсе Идел буе болгарларында да бар. Керамика сәнгатендәге бу уртаклык түгәрәк конус формасында ясалган савытларда һәм конус сыман бәләкәй савыт капкачларында да күренә. Ә инде чүлмәкләргә туры һәм дулкынсыман сызыклы бизәкләр төшерү мәсьәләсенә килсәк, борынгы төрки болгарларының бу уртак алымы Дунай буе савыт-саба производствосында X гасырның ахырларына кадәр дәвам итә.

Дунай һәм Идел буенда кулланылышта булган металл савыт-сабалар да формалары һәм бигрәк тә җитештерү ысуллары белән бер-берсенә охшаганнар. Дунай болгарларында очраган агач савыт-саба, йөзек кашы сыман тоткалы көмеш кәсәләр, бронза һәм бакырдан эшләнгән төрле бизәнү әйберләре шулай ук борынгы уртак традицияләренең дәвамлы бер чагылышы булып торалар.

Болгарлар тимердән эш һәм сугыш кораллары ясауда искиткеч оста булганнар. Дунай һәм Идел буе болгарлары бу өлкәдә тимер эшкәртү ысуллары белән генә түгел, бәлки ясаган әйберләренең (сабан төрәннәренең, урак, чалгыларның, агач эшкәртү, тимерчелек коралларының, сугыш балталары һәм кылычларның һ. б.) формалары белән дә бер-берсен кабатлыйлар. Дунай болгарларында табылган борынгы тимер кораллар (Долгополь хәзинәсе) һәм Идел буенда табылганнар (Семеновск хәзинәсе) нәкъ менә шул хакта сөйли. Һәр ике халыкта бер үк төсле цилиндрик тимер йозаклар һәм хайван кыяфәтенә охшатып эшләнгән бронза йозаклар очравы да кызыклы факт. Аерма тик шунда гына: Идел буе болгарлары үзләренең бронза йозакларын юлбарыска, ә Дунай буе болгарлары — капланга охшатып ясаганнар.

Билгеле булганча, күп кенә халыкларда иң тотрыклы этник билге — хатын-кызның бизәнү әйберләре. Бу өлкәдә дә Дунай һәм Идел буе болгарлары арасында кайбер тәңгәллекләр бар (бер үк төрле үрелгән көмеш беләзекләр, бер һәм өч лэйсәнле чигә балдаклары һ. б.). 1971 елда Преславта шундый бизәнү әйберләре салынган таш тартмачык табыла. Ул борынгы бер йортның стена уемына томалап куелган була. Борынгы Дунай болгарларында өч лэйсәнле һәм шуларга өстәп имән чикләвеге яки кукәй сыман ташлар тагылган чигә балдаклары да очрый. Мондый балдаклар Идел буе болгар хатын-кызларының иң специфик бизәнү әйберләре булып саналган.

Ләкин борынгы болгар һөнәрчелегенең һәр ике төркемендә аеруча күзгә ташланган нәрсә — ул да булса сөяктән әйберләр ясау. Болгарлар сөяктән һәм хайван мөгезеннән бик күп төрле әйберләр җитештергәннәр (пычак, камчы сaплары, тараклар, бөтиләр, шахмат фигуралары, комарлы уен сөякләре һ. б.). Ул әйберләр күп очракта үзенчәлекле орнамент белән бизәлгән.

Экономика, дәүләтчелек һәм культура үсешенең үзенчәлекле шартлары нәтиҗәсендә Дунай буе болгарлары да, Идел буе болгарлары да тора-бара, берсе славяннар һәм Тракия кабиләләре белән, ә икенчесе башка төрки һәм угро-фин кабиләләре белән кушылып, үзләренә аерым, мөстәкыйль халык булып оешканнар. Аларның берсе славян телен кабул иткән, ә икенчесе төрки нигезендә үз телен тудырган. Ләкин, шулай булуга да карамастан, алар борынгы бабаларыннан калган уртак элементларны әле бик озак саклаганнар. Алай гына да түгел, бер-берсен белеп, истә тотып яшәгәннәр булса кирәк.

Дунай болгарлары христиан диненә күчеп, тәмам славянлашып беткәннән соң да ике халык арасында элемтә өзелмәгән. 970 еллар тирәсендә, Святослав гаскәрләре белән сугышта Идел буе болгарлары каты җиңелүгә дучар булганнан соң, зур бер төркем мөселман болгарлары Бүләрдән Дунай буйларына, дөресрәге, Паннониягә, күченеп китәләр. Аларны анда Биллу һәм Боксу дигән князьләр алып килә. Соңрак боларга Хәсән дигән кеше җитәкчелегендә тагын бер группа Идел болгарлары килеп кушыла. Күченүчеләрне Паннониядә якты йөз белән, дусларча каршылыйлар һәм

яшәү өчен аларга Дунайның сул як ярыннан җир бүлеп бирәләр. Озакламый бу урында Пешт дигән яңа шәһәр калкып чыга. Соңыннан, XII гасырның ахырларына кадәр, бу урында яшәгән мөселман болгарлары, финанс эшлекләре һәм сәүдәгәрләр буларак, Венгрия тарихында шактый әһәмиятле роль уйнаганнар.

Әбү-Хәмид әл-Гарнати дигән испан гарәбе 1150—1153 елларда, ягъни өч ел буе, әлеге мөселман болгарлары арасында торып кайта. Шунда торганда ул Византия хакимлеге астында интеккән Дунай болгарлары иленә дә барып чыккан булган, күрәсең. Менә нәрсә дип яза Гарнати: «Бу өлкә Бөек Румиядән алып Константиния чикләренә кадәр сузыла. Һәм анда алтын вә көмеш табыла торган таулар бар. Бу ил — иң бай, мул тормышлы мәмләкәтләрнең берседер».

XII гасыр уртасын — Болгария тарихының караңгы, шомлы бер сәхифәсе дияргә мөмкин. Бу чорда Болгария дәүләте алдына Византиянең колониясенә әверелү куркынычы килеп баса, болар өстенә, ил эчендәге болгар феодаллары арасында үзара талаш, ызгышлар да көчәя. Әл-Гарнатиның: «Хәзер күп шәһәрләр җимерелгән, чөнки әмирләр (ягъни, князьләр, боярлар — А. Х.) үзара җир өчен талашалар вә бер-берсенә каршы сугышалар»,— дигән сүзләре нәкъ менә шул күңелсез хәлне күздә тотып әйтелгән булса кирәк.

XII гасыр ахырында Икенче Болгар патшалыгы төзелү Болгариянең авторитетын янә күтәреп җибәрә. Шушы ук чорда көнчыгышта, ерак Идел буенда, икенче бер болгар дәүләте дә яшәвен дәвам итә әле. Әлбәттә, бу ике дәүләтнең хакимдарлары бер-берсе турында хәбәрдар булганнардыр дип уйларга кирәк. Һәрхәлдә, «бай шәһәр, калалары күп булган кодрәтле, шанлы ил — Бөек Болгар патшалыгына» борынгы венгр токымнарын эзләргә дип сәяхәткә җыенган венгр миссионерлары иң элек Ассан Болгариясенә, ягъни «барлык болгар һәм греклар патшасы» дигән титул йөрткән Иоан Асень II Болгариясенә сугылуны кирәк табалар. Бик ихтимал, Идел буе Болгар иленә бару юлын аларга, бәлкем, нәкъ менә шунда өйрәткән булганнардыр.

1236—1242 елларда Көнчыгыш Европа өстенә коточкыч афәт — монголлар урдасы ябырыла. Алар белән тиңсез көрәштә беренчеләрдән булып Идел буе Болгар дәүләте яшәүдән туктый. Тиздән монгол гаскәрләре Дунай Болгариясенә дә барып житәләр. Монгол походлары елъязмачысы — фарсы Рәшид-эд-диннең язуларына карагаңда, 1241—1242 елларда монголлар «башкортларның, мажар һәм сасаннарның (венгр, моравияле, саксониялеләрнең — А. Х.) барлык җирләрен яулап алдылар... һәм җәйне Тиса һәм Туна (Дунай — А. Х.) елгалары буенда уздырдылар». 1243—1244 еллар дәвамында монголлар үзләренең җимергеч походларын яңадан кабатлыйлар һәм Дунай болгарларын ясак түләргә мәҗбүр итәләр. XIV—XV гасырлар чигендә яшәгән мисыр тарихчысы Бәдретдин-әл-Айниның әйтүенчә, болгарлар аларга көн саен «1000 динар акча, ат, бер кол, бер җария һәм ау эте» түләргә тиеш булалар. Шушындый ук язмышка Идел буе болгарлары да дучар ителә.

Шулай итеп, XIII йөзнең икенче яртысыннан XIV йөзнең беренче яртысы беткәнче ике болгар дәүләте дә, мөстәкыйльлекләрен югалтып, монгол һәм Алтын Урда ханнарының ясак түләүчеләре булып кала. Бу чорның гарәп язма чыганакларында (Ибн-Халдун, Әл-Асади, Әл-Омари һәм башкаларның әсәрләре) Алтын Урданың көнбатыштагы биләмәләре Константинопольгә кадәр сузылганлыгы әйтелә. Ә Мисыр энциклопедисты Әл-Калкашандиның (XV йөз башы) язуына караганда, Алтын Урдага ун дәүләт буйсынган булган, шулар арасында: «7) Идел-Чулман буе Болгар иле, мәркәзе Болгар яки Буләрдер; 8) Валахия яки Болгария (Бургал), пайтәхете — Тырново, ягъни Асень патша нәселендәге влах вә болгарлар иле».

Болгар халыклары монгол баскыннарына каршы еш кына баш күтәргәннәр. Шундыйлардан, мәсәлән, Идел буе болгарларының Баян, Җик, Бачман кебек җирле мырзалар җитәкчелегендәге чыгышларны күрсәтеп үтәргә мөмкин. Шундый ук чыгышлар XIII йөзнең 70 нче елларында Идел һәм Дунай буйларында яңадан кабатланган. Монгол-татар ханнары баш күтәрүчеләрне рәхимсез рәвештә бастыра килгән. Сурия гарәбе Ибн-Кесир, мәсәлән, үзенең язмаларында Алтын Урда ханы Беркенең 1263 елда Константинопольгә чиктәш җирләргә буйсындыру походына барып йөрүен һәм «зур бүләкләр, мал-мөлкәт» алгач кына ул җирләрне ташлап китүен әйтеп яза. Ә 1270 елның кышында Берке ханның варисы Менгу-Тимер, мисырлы Әннүвәйри дигән кешенең язуына караганда, Константинополь — Стамбулдан төньяктарак урнашкан өлкәләргә

янәдән талау походына барып килә. Әннувәйри һәм Ибн-Халдун язмаларында тагын бер кызыклы вакыйга да телгә алына: 1300 елда Болгария патшасы (Георгий Тертерий булуы мөмкин) Алтын Урда ханы Ногайның кайсыдыр бер кардәшенә өйләнә. Менә бер вакыт аның янына Ногай ханның Алтын Урдадан качкан улы Җик килеп төшә. Болгар патшасы аны, Җикне, «кулга ала һәм үзенең Тырново дигән крепостена япты-ра, аннары шул хакта Токтуга (Алтын Урда ханына — А. Х.) хәбәр җибәрә».

XIV йөз урталарына таба Алтын Урда ханлыгының таркалу тенденцияләре сизелә башлый. Бу исә, үз чиратында, Алтын Урдага буйсынган илләрнең азатлыкка омтылуларын тагын да көчәйтеп җибәрә. Шушы уңайдан Дунай болгарларының күтәрелеп килә торган Мисыр солтанаты белән дуслык мөнәсәбәте урнаштырырга тырышып йөрүләре аеруча игътибарга лаеклы. Бу хакта Әл-Омари болай яза: «Борын заманда серб һәм болгарлар хак диндә булганнар, ислам дине тотканнар. Хәзерге вакытта исә бу хак динне денсезлек алыштырган, алар тәрегә табынучы гавам котырыгы астында яшиләр. 1330 сәнәдә серб вә болгар падишаһы исеменнән язылган хат илә Мисыр солтаны галиҗәнапларыы каршына алардан илчеләр килеп төште. Серб вә болгар падишаһы үзенең хатында Мисыр солтанына дуслык тәкъдим итәдер һәм аңардан биленә тагып йөрердәй үткен кылыч һәм үз дошманнарын тар-мар итәргә булышырдай байрак бирүен үтенәдер. Солтан падишаһның илчесенә олуг хөрмәт күрсәтте, аны сыйлады һәм аның белән бергә Серб вә Болгар падишаһы өчен ау күренешләрен гәүдәләндергән киемнәр — тиен эчле, тышы Искәндәрия тукымасыннан тегелгән һәм кондыз мехы белән каймаланган тун, алача бүрек, баш-башы чигүле янчык, алтын билбау, алтын каптырмалар, бизәкле үткен кылыч, алтын йөгертелгән сары байрак биреп җибәрде». Сүрияле Фадлалах бин-Мөхәммәт нәкъ шушы ук вакытларда диярлек Мисырга Идел буе болгарларыннан да шундыйрак илчелек килгәнлеген әйтеп яза.

Каһирә хөкүмәте Идел буе болгарларына Балкандагы серб һәм болгарлар өстеннән хакимлек итү хокукы бирүне дә күздә тоткан, күрәсең. Әл-Калкашанди үзенең истәлекләрендә Мисыр белән Шәһре Болгар арасында хат алышулар булуын әйтеп, Идел буе болгар ханын «Әл-булгар (Булгар һәм болгарларның) һәм сербларның падишаһы» дип атый. Бер үк вакытта Дунай болгарларының да Идел буе болгарлары өстеннән хакимлеге танылган. Шунысы характерлы: бу замандагы географик тасвирламаларда Идел һәм Дунай буе болгарларының һәр ике тармагы турында да мәгълүматлар бирелә, алай гына да түгел, алар арасында якын бәйләныш, бөтенлек барлыгы әйтелә. Тик бу ике дәүләтнең уртак патшасы — ханы кем булырга тиешлеге һәм үзәк шәһәре кайда урнашканлыгы гына төгәл күрсәтелми. Баш мәркәз итеп күбрәк Булар (Шәһре Болгар), ә дәүләт башлыгы итеп серб-болгар патшасы китерелә. Бу ике дәүләтне шулай бер бөтен итеп карау, күрәсең, болгар халыкларының борынгы бабалары турындагы истәлекләргә һәм,— иң әһәмиятлесе,— Каһирәнең дәүләт интересларына нигезләнгән булгандыр. Ни дисәң дә, Каһирә аларны үзенең номиналь вассаллары итеп санаган бит һәм алар кушылудан сәүдә һәм башка мәсьәләләрдә үзенә киң мөмкинлекләр ачылыр дип уйлаган.

Бүгенге Дунай болгарлары белән Идел буе халыкларының, беренче чиратта — татар халкының уртак бабалары булган борынгы болгарлар турындагы истәлекләр төрле формада соңрак дәверләрдә дә чагылыш табалар. Бу бигрәк тә этнография, антропология һәм тел материаллары нигезендә ачылырга мөмкин. Озак вакытлар буена күздән төшеп торган бу материалларны тирәнтен өйрәнү уртак бабалары ягыннан кан кардәшләре итеп саналырга хаклы әлеге халыкларның этногенезына һәм урта гасырлардагы тарихына бәйле күп кенә мәсьәләләрне ачыкларга ярдәм итәчәк.

Болгария Халык Республикасына сәяхәтем вакытында алган минем беренче тәэсирләрем менә шушылардан гыйбарәт.

Гөлсем Мөхәммәдова

# КИЕВ ВАКЫЙГАСЫ

## I

**1912** елның көзендә Галимҗан Ибраһимов Киевка китә. Китәр алдыннан ул Казан яшьләренең җитдиләреннән булып, революционер саналып йөргән, ләкин соңыннан провокатор булып чыккан Хәнәфи Кайбышев белән очраша. Кайбышев Ибраһимовтан:

— Ник анда барасың? — дип сорый.

Г. Ибраһимов аңа:

— «Кеше» эзлим! — дип җавап кайтара.

Ул елларны Казанда «кешеләр» табылмый иде микәнни, дигән сорау туарга мөмкин. Бу мәсьәләне аңлау өчен шуны истә тотарга кирәк: 1907 елның июль башларында икенче Дәүләт думасын куу белән башланып киткән караңгы реакция елларында патша хөкүмәте татар җәмгыятенең алдынгы сафларында барган революцион-демократик көчләргә рәхимсез һөҗүм итте. Бу һөҗүм нәтиҗәсендә кайберәүләр халыкның революцион көченә ышанычларын югалтып, элекке «идеалларын» таптап, үз мәнфәгатьләрен генә кайгырту юлына басалар. Ә кайберләре 1905—1906 еллардагы революция чорында үтә кызыл булып, «Җир һәм ирек!» дип кычкырынып йөргән булсалар да, чеп-чи милләтче-пантюркист булып әвереләләр.

Татар җәмәгатьчелегенең Ибраһим Моратов, Гыйният Ризванов һәм башка бик күп алдынгы фикердәге кешеләре төрмәләргә, крепостьларга ябыла, каторгага сөрелә һәм күбесе шунда газап чигеп үлеп кала. Бу авыр язмыштан котылып калганнары революция эшләрен бик яшерен рәвештә генә алып барырга мәҗбүр булалар.

Галимҗан Ибраһимов ул елларда Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов кебек чын большевиклар белән бәйләнешкә керә алмаган булса кирәк. Шунлыктан, үзе әйтмешли, «хакыйкый инсаннарны», «хакыйкый кешеләрне» Казаннан читтә эзләргә мәҗбүр булгандыр. Шуның өстенә, Галимҗан ул чорда Киев мөселман студентлары арасында ниндидер прогрессив хәрәкәт башланганын да белгән булырга тиеш. Киев университетының медицина факультетында укучы Хәлилулла Еникеев ул чакта иң якын дусты, сердәше дип хисаплаган Хәнәфи Кайбышевка болай дип хат яза: «Мин хәзер революционер. Бөтен изелгәннәрнең һәм җәберләнгәннәрнең яклаучысы. Кулыма корал алып, бу әхвәлне җимерергә, бөтен изүчеләрне вә коллыкка төшерүчеләрне үтерергә хәзермен![1]»

Хәнәфи Кайбышев белән Галимҗан Ибраһимов та бик еш очраша, аны якын дусты санап, фикерен уртаклаша. Кайбышев Хәлилулланың хатын Галимҗанга укыткан булуы бик ихтимал. Киевка килгәненең өченче көнендә Галимҗанның Хәлилулла Еникеев квартирына барып чыгуы бу фикерне раслый һәм «революционер» Хәлилулла аркылы ул үзенә кирәк булган «чын кешеләр» белән бәйләнешкә керергә ниятләгән булса кирәк, дип уйларга мөмкинлек бирә.

---

[1] ТАССР ҮДА. Фонд 2. Эш 3612. 16 бит.

Ул елларда Киев янындагы Казатинда укытучы булып эшләгән Каюм Мостакаев Ибраһимовка тамак туйдырырлык кына түгел, хәтта русча уку өчен укытучы елларга да мөмкинлек биргән эш таба. Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимовның Киевка барырга омтылуына материал нигез дә була.

## II

Киевкә барып урнашкан көннәрдә үк Галимҗан үзенең таныш якташларын — Киев университеты студентлары Петр Нестеров белән Николай Андреевны эзләп таба. Алар икесе дә ул заманда студентлар арасындагы революцион хәрәкәтләрдә якыннан катнашып йөргән кешеләр булалар. Шул иптәшләре аркылы Галимҗан «мәңгелек студент» Агаш белән дә танышып ала. Сүз уңаеннан шуны әйтеп үтәргә кирәк: Агашның чын исемен һичкем белми. Һәр җирдә бу кеше энә шул «Агаш» дигән кушамат белән генә телгә алына. Кызганычка каршы, Галимҗан аның кайсы партиядә булганын күрсәтми, тик «югары мәктәп дөньясында революция хәрәкәтен алып бару өчен бар гомеренчә студент фуражкасы, сары төймәле, эполетлы тужурка киеп йөрүне өстенә алган каһарманнарның берсе иде. Нинди генә хәрәкәт булса, Агаш аның үзәгендә. Яшерен «Кызыл хач» аның кулында. Берәү эләксә, берәү сөрелсә, азмы-күпме ярдәм итүне үзенә фарыз дип хис кыла. Һичкемгә ышанмый. Иң кечкенә бер серне дә исереп акылыннан язганда да чыгару ихтималы юк»[1],— дип кенә искәртеп үтә.

Агаш аркылы Галимҗан Лиза исемле поляк кызы белән таныша. Бу кыз, Киев студентлары арасында оештырылган һәм «Организационный совет» дип йөртелә торган берләшмәнең бюросында член буларак, ул чорда югары уку йортларында, бигрәк тә курсисткалар арасында, революцион көчләрне берләштерү юлында актив эшләп йөрүчеләрдән булган.

Ул заманнарда Хәлилулла Еникеев Киев мөселман студентларының «Якташлык оешмасы» члены була. Җитмешләп члены булган бу оешманың кассасында ун мең сум чамасы акчасы да була. Оешманың уставы Киев губернаторы тарафыннан раслanмаган булса да, аны, рәсмиләштерер өчен, Мәгариф министрлыгына тапшыралар. «Якташлык оешмасы», мохтаҗ студентларга матди ярдәм күрсәтүдән башка, үз халкының тарихын, әдәбиятын өйрәнүне һәм халык арасында популяр фәнни брошюралар, милли азатлык юлында эшләүче әзербәйҗан эшлеклеләренең һәм төрек-татар халыкларының демократ язучыларының әсәрләрен бастырып таратуны да максат итеп куя. Киевкә килгәненең беренче көннәреннән үк Галимҗан Ибраһимов Х. Еникеев ярдәме белән бу оешма белән таныша башлый. Шуның өстенә, ул XIX гасырның икенче яртысында Грузиядә булып үткән иҗтимагый хәрәкәтләр турында бер грузин социал-демократы доклад ясый торган түгәрәк утырышларына да йөри. Кызганычка каршы, бу грузин социал-демократының исемен дә, кушаматын да аныклап булмады. Галимҗан аны большевик иде дип кенә әйтеп үтә.

Киевкә килгән чорда Галимҗан Ибраһимовның даирәсе менә шундый һәм, Каюм Мостакаевның әйтүе буенча, ул Киевтәге тормышыннан бик канәгать була.

## III

Бер вакыт Хәлилулла Еникеев белән үзара сөйләшеп утырганда, Г. Ибраһимов аңа:

— Якташ мөселман студентларының үз белемнәрен арттырырга тырышулары, халык арасында аң-белем таратырга омтылулары бик яхшы, кирәкле эш, ләкин безгә мондый эшләр белән генә канәгатьләнеп калу җитми. Яшьләр арасында патша хөкүмәтенә каршы революцион көрәш фикерен уятырга, бу юлда хәзерлек эшләрен башларга вакыт! — ди.

Хәллә Еникеев (Хәлилулла Еникеевне Галимҗан Ибраһимов «Татар студентлары хәрәкәте...» дигән китабында «Хәллә» дип йөртә) бу эштә мөселман студентларының якташлык оешмасыннан файдаланырга кирәк, дигән фикерне әйтә. Бер яктан, ди ул,

---

[1] Галимҗан Ибраһимов. Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә. 1922 ел. Казан. 11 бит.

бу оешманың акчаларыннан революцион эшләр өчен файдаланырга мөмкин булса, икенче яктан, оешма үзе яшерен революцион эшләрне каплап тора торган бик яхшы легаль капкач булыр иде.

Әмма Галимҗан, Агаш, Лиза һәм әлеге большевик грузин Хәлләнең бу тәкъдименә каршы булалар. Якташлык оешмасының составы бик чуар, сәяси яктан җитлекмәгән, тотрыксыз. Шуның өчен оешма әгъзаларын башта сынап, тикшереп карарга кирәк. Тик шуннан соң гына араларыннан тотнаклыларын, иң ышанычлыларын сайлап, әкренәкрен эшне аңлатырга, эшкә җәлеп итә башларга мөмкин, диләр алар.

Ләкин кызу канлы, мавыгучан, сабырсыз Хәллә күзәтеп, сынап утырырга теләми. Якташлык оешмасының бу сөйләшүдән соң булган беренче гомуми җыелышында ук тота да, Галимҗанның һәм башка иптәшләрнең кисәтүенә дә карамастан, халкыбызның якты киләчәге өчен көрәшергә, авыр тормыш тәртипләрен җимереп ташларга чакырып ялкынлы чыгыш ясый.

Хәлләнең бу сүзләрен якташлык әгъзалары алкышлап каршы алалар. Шул ук җыелышта оештыру комиссиясе сайлана. Аның рәисе итеп студент хан Талышинскийны, секретаре итеп курсистка Гөлсем туташ Ахтямованы, әгъзалары итеп Хәлилулла Еникеев, Җәмил бәк Вәзиров һәм, студент булмаса да, Галимҗан Ибраһимовны сайлыйлар.

Патша хөкүмәтенә каршы яшерен сәяси көрәш алып баруны оештырырга тиеш булган бу комиссиянең дөньяга килүе баштан ук һәркемнең күз алдында һәм тиешенчә уйланмаган булуыннан Галимҗан бик шикләнә. Ләкин, ни булса да, инде эш башланган. Ә башланган эшне исә мөмкин булган кадәр нәтиҗәлерәк итеп алып барырга кирәк.

## IV

Оештыру комиссиясенең беренче утырышында ук, бөтен Россия мөселман студентлары белән элемтәгә керергә һәм алар белән берлектә эшләргә кирәк диган карарга киләләр. Шуннан соң оешманың нинди программа буенча эш алып барырга тиешлеге һәм ул программаның проектын төзү мәсьәләсе алга килеп баса. Бу проектны тикшереп, кабул итеп рәсмиләштерер өчен, бөтен Россия мөселман студентларының съездын җыярга һәм ул съездга мөселман дөньясында танылган, атказанган, тәҗрибәле җәмәгать эшлеклеләрен дә чакырырга кирәк булачак дип исәплиләр. Ләкин съездны чакырудан элек башта хәзерлек эшләрен дә күрергә, атап әйткәндә:

1. Студентлар арасында съезд чакыру фикерен тарату өчен, башка шәһәрләрдәге мөселман студентлары белән очрашырга, язышырга;

2. Мөселман студентларының фикер юнәлешләре, тоткан юллары белән танышыр өчен, алар арасында анкета таратырга;

3. Съездда каралачак мәсьәләләрне, съездның составын тәгаенләү, съездның оештыру бюросын сайлау, кирәк булган акчаны ничек, кайдан табу кебек мәсьәләләр турында уйлашу өчен, башка шәһәрләрдәге студентларның вәкилләрен чакырып, Киевта хәзерлек киңәшмәсе үткәрергә кирәк булачак, дигән фикергә киләләр.

Аннары, Россиянең университетлы шәһәрләрендә укучы мөселман студентларына мөрәҗәгать итү өчен, түбәндәге хат текстын язалар: «...Киев шәһәрендәге мөселман студентлары түгәрәгенең гомуми җыелышында кайбер иптәшләр мөселман яшьләренең съездын чакыру инициативасын өстебезгә алу турында тәкъдим ясадылар. Төп максат гомуми дошманыбыз булган рус хөкүмәтенә каршы бердәм көрәшү өчен һәм шулай ук халкыбызның наданлыгын бетерү өчен мөселман яшьләрен оештыру булса, аерым алганда, съездның бурычлары мөселман яшьләренең халкыбызга һәм рус хөкүмәтенә булган мөнәсәбәте белән танышу һәм, кабул ителгән карарларга нисбәтән, югарыда күрсәтелгән дошманнарга каршы көрәшнең программасын һәм тактикасын билгеләүдән гыйбарәт. Бу бурычларны гамәлгә ашырыр өчен, безнең түгәрәк биш кешелек комиссия сайлады. Комиссиянең вазифасы, беренчедән, яшьләр арасында кайда һәм нинди оешмалар барлыгын аныклау, икенчедән, әгәр зур үзәкләрдә, ягъни университетлы шәһәрләрдә мондый оешмалар булмаса, аларны оештыру һәм алар белән элемтә ясап, бергәләп съездның көн тәртибен һәм тиешле шартларын билгеләүдер. Шуның өчен дә, иптәшләр, безнең съезд чакыру мөнәсәбәте белән сайланган

комиссия сезнең мөселман яшьләренең тормышы турында һәм аларның бу идеяга мөнәсәбәтләре турында безгә тәфсилле хәбәр итүегезне һәм, мөмкин булса, яшьләрне оештыру эшен өстегезгә алуыгызны үтенә»[1].

Кызганычка каршы, архив материаллары арасында мөселман яшьләренә таратылырга тиеш булган анкетаның нөсхәсе сакланмаган. Ләкин оештыру комиссиясенең беркетмәләрендә дә, Киев жандармериясенең полиция департаментына биргән хәбәрләрендә дә ул анкета күп мәртәбәләр телгә алына.

Декабрь ахырларында Рождество бәйрәме уңае белән студентлар каникулга тарала башлый. Хәллә дә Уфага — туган иленә кайтып килергә уйлый. Аңа, юл уңаенда Казанга кагылып, Казан яшьләре белән очрашып сөйләшеп килү тапшырыла. 1912 елның 14 декабрендә Хәллә Казанга килеп җитә.

Провокатор Хәнәфи Кайбышев Галимҗанга язган хатында да, Казан жандармериясенә биргән доносында да: «Хәллә Еникеевның Казан татар яшьләре арасында алып барган өндәмәсе нәтиҗә бирмәде һәм ул ниндидер каһәрле бер җир бу Казан, монда яшәүчеләр уянмас йокыга талганнар, аларны һич уятыр хәл юк дип, күңеле кайтып, зарланып Уфага китте»[2] дип яза.

Башта Хәллә үзе дә, өстемә алган вазифаны тиешле дәрәҗәдә үти алмадым, нәтиҗә бик алама, дип борчыла. Ләкин Хәлилулла Еникеевнең тавышы Казан яшьләре арасында югалып калмый. Аның Галимҗанга Казаннан язган хатында менә мондый сүзләр дә бар: «Минем идеям гомуми кызыксыну уятты, ләкин шәхси мәнфәгатьләр иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән өстен тора. Хәзергә шуны гына әйтә алам: монда күпме кеше булса, партияләр дә шул кадәр... Әлегә шуны гына әйтә алам, монда ячейка оештырылды. Бу — уңыш...»[3]

Кыскасы, Хәлилулла Казан яшьләренә үпкәләргә тиеш булмаган, чөнки шул ук провокатор Кайбышевның Галимҗанга язган хатына караганда, Казан яшьләре Хәллә Казанда чакта ук комиссия сайлаганнар, Киев студентларына акча җибәрергә һәм үзләре оешып, устав төзергә карар кылганнар. Димәк, Казан яшьләре дә Киевтә башланган хәрәкәтне яклаганнар, аңа кушылырга теләгәннәр.

## V

Рождество бәйрәменнән соң укулар башлангач, Киев мөселман студентлары башка шәһәрләрдәге студентларның вәкилләре белән очрашып киңәшмә үткәрү өчен хәзерлек башлыйлар. 1913 елның 28 мартында үткәрелгән җыелышта «Съездның йөзе» дигән мәсьәлә карала. Монда Г. Ибраһимов: «Съездда фәкать сәяси мәсьәләләр генә тикшерелергә тиеш»[4],— дигән тәкъдим кертә. Комиссия бу тәкъдимне кабул итә һәм сәяси программаны язу эшен Хәлилулла Еникеев белән Галимҗан Ибраһимовка тапшыра.

Комиссиянең 12 апрелендәге утырышында бу программаның проектын тыңлыйлар. Архивта шул программаның 10 пункттан гыйбарәт булган һәм «Милли үзбилгеләнүнең кирәклеге» дип аталган менә шушы тезислары гына сакланып калган:

«Милли үзбилгеләнүнең кирәклеге.

I. Үзебезнең милли бурычларыбызны без ничек аңлыйбыз?

II. Съездның бурычлары: Россиядәге революцион элементлар белән бергәләп, яшәп килгән стройга каршы көрәш шартларын билгеләү.

III. Шушы шартларга яраклы оешма: оештыру аппар [аты] кирәкме?

1. Аның минимум программасы.

2. Аның максимум программасы.

а) Шушы шартларда ул кирәкме?

IV. Культура-мәгариф эшенә нинди мөнәсәбәттә булырга.

I. Мөстәкыйль нәрсә буларак, ул кирәкме һәм нинди формада.

V. Руханиларга безнең мөнәсәбәт.

---

[1] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 3. Саклау берәмлеге 237. 2—3 битләр.
[2] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 3. Саклау берәмлеге 237. 4—5 битләр.
[3] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 3. Саклау берәмлеге 273. 4 бит.
[4] СССР. ОРУДА. Фонд ДПОО. Язма 1913. Саклау берәмлеге 174, 81 бит.

VI. Думага, сайлау кампаниясенә, аерым алганда, мөселман фракциясенә мөнәсәбәт.

VII. Башка милли агымнарга мөнәсәбәт.

1. Алар белән берләшү кирәкме.

2. Нинди мотивлар буенча һәм нинди формада.

VIII. Шушы шартларда рус революцион партияләре белән берләшү кирәкме.

I. Нинди мотивлар буенча һәм нинди формада.

IX. Тактика мәсьәләләре.

X. Мөселман студентларының бүтән студент оешмаларына мөнәсәбәте.

Бу тезисларны Галимҗан Ибраһимов үзе язган, ә Хәлլә аларны фәкать татарчадан русчага тәрҗемә генә иткән булырга тиеш, диясе килә. Чөнки Хәлләнең Галимҗанга Казаннан язган хатында менә шундый сүзләр бар: «Студент Талышинский белән таныширга тырыш, шулай ук үзеңнең эшкә булган карашыңны үткәрергә тырыш» [1].

Менә бу сүзләр «эшкә булган караш»ның Галимҗанныкы булганын һәм ул карашлар белән Х. Еникеевнең тулысынча килешкәнлеген ачык раслыйлар.

Югарыда китерелгән архив документы Галимҗанның эшкә карашлары нинди булганлыгын бик яхшы күрсәтеп бирә. «Россиядәге революцион элементлар белән бергәләп, яшәп килгән стройга каршы көрәш шартларын билгеләргә кирәк», дип саный ул. Димәк, ул яшәп килгән самодержавие тәртипләренә каршы көрәшкәндә тар милли мәнфәгатьләрне күздә тотып кына түгел, гомум Россия алдында торган зур максатларны күздә тотып һәм бүтән милләтләрнең дә революционерлары белән тыгыз элемтәдә торып, бердәм программа нигезендә эш алып баруны алга сөргән.

Тезисларның бу ноктасыннан карaганда икенче бер мәсьәлә килеп чыга: мөселман яшьләре Россиядәге кайсы революцион элементларга кушылырга тиеш һәм бу юлда мөселман яшьләре өчен аерым бер оештыручы аппарат кирәк булачакмы, юкмы? Тезислар бу сорауга турыдан-туры җавап бирми. Шулай булса да, тентү вакытында жандармерия кулына төшкән кайбер язмалар бу мәсьәләне бераз ачалар. Ул язмалар, әлбәттә, сәяси программаны язарга тапшырылган кешеләр, ягъни Г. Ибраһимов белән Х. Еникеев, тарафыннан язылган булырга тиеш. Башкача уйларга да мөмкин түгел. Архивтагы бер кәгазь кисәгендә шундый язма бар: «Автономияле милләтләрнең федерациясе — милләтләрнең үзара килешеп яшәүләре өчен иң яхшы форма һәм аларның иҗтимагый, фикри һәм әхлакый үсешләре өчен алмаштыргысыз фундамент. Федерация шулай ук экономик тигезлек өчен дә иң яхшы нигез булып тора.

Россиядәге деспотизм бу омтылышны тормышка ашыру юлында киртә булып тора. Безнең төп бурычыбыз — безгә фикердәш булган руслар һәм Россиядә яшәүче башка милләтләр белән бергәләп, бу деспотизмны бәреп төшерү өчен революцион көрәш алып бару» [2].

Күренә ки, Киевтагы мөселман студентларының сәяси программасын төзүчеләр революцион көрәшне бер милләт эчендә генә бикләнеп түгел, бәлки руслар һәм Россиядә яшәүче башка милләтләрнең вәкилләре белән кулга-кул тотынып, алар белән гомуми бер программа нигезендә алып барырга кирәк дип санаганнар.

Ләкин, кызганычка каршы, бу тезисларда мөселман яшьләренең автономияле милләтләр федерациясе өчен көрәштә Россиядәге кайсы революцион партиягә кушылырга теләгәннәре ачыкланмаган. Башка архив материаллары да бу сорауга тулы, ачык җавап бирми. Ләкин шунысы бик ачык: әлеге сәяси программаны төзүчеләр татар җәмгыятенең инде сыйныфларга аерылып җиткәнлеген белеп эш иткәннәр. Моны тезисларның артына язылып куелган сүзләр раслый. Анда: «Милли азатлык эшендә буржуазиянең һәм пролетариатның әһәмияте»,— дип ачыктан-ачык әйтелгән. Шулай ук аерым кәгазьләрдә: «Мөселман эшчеләренең әхвале һәм аларның үзләренә хас хосусиятләре», «Буржуазия белән пролетариат, алпавытлар һәм крестьяннар арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр» [3] дигән юллар да очрый.

Менә болар бөтенесе Киевта яшәгән чорда Галимҗан Ибраһимовның сәяси карашлары, замандашлары әйтмешли, «романтик революционер»лыктан күп алга киткәнен дәлилләп торалар.

---

[1] СССР ОРУДА. Фонд ДПОО. Язма 1913. Саклау берәмлеге 174. 64 бит.
[2] УССР УДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 3151. Икенче кисәк. 349.
[3] УССР УДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 151. Икенче кисәк. 357 бит.

Галимҗан Ибраһимовка Киев җыенында бу сәяси программа буенча сөйләргә мөмкинлек булмаган, чөнки җыен башлану белән жандармерия килеп җитеп, андагы кешеләрнең барысын да кулга алган. Әгәр сөйләргә мөмкинлек булган булса, Галимҗан үзенең сәяси, революцион карашларын тагы да ачыграк аңлаткан булыр иде. Һәрхәлдә, ул әлеге программаның экономика һәм аң-белем тарату мәсьәләләренә багышланган бүлекләрен төзегән Ордубацкий, Алибеков кебек кешеләр артыннан иярмәгән булыр иде.

## VI

Программаның Ордубацкий һәм Алибеков тарафыннан төзелгән һәм аң-белем тарату, экономика мәсьәләләренә багышланган бүлекләрен күздән кичергәч, аларның гадәттән тыш буталчык икәнен күрәсең. Программаның сәяси бүлеге оештыру комиссиясенең утырышында тыңланып, расланганнан соң, бу бүлекләр дә шул сәяси бүлеккә муафыйк итеп язылырга тиеш иде, әлбәттә. Ләкин эш бөтенләй башкача килеп чыга.

Анда «Фән һәм ислам» дигән тезис бар. Хәзер инде Ордубацкий белән Алибеков исламның фән алдында бөтен мәгънәсезлеген, нигезсезлеген ачып бирәчәкләр, дип көтәсең. Ләкин алар мәктәпләрнең программалары, максатлары, бурычлары турында сөйләп китәләр дә: «Моңарга кушымча итеп, мөселманнар, аерым алганда татарлар, өчен иң элек нинди тип мәктәпләр кирәклеген күрсәтергә кирәк. Шуның белән бергә, хәзерге вакытта рус уку йортларында урта белем алу мөмкинлеге бик аз булуын һәм акчаның да аз икәнлеген күз алдында тотарга кирәк. Дини рухлары белән генә түгел, дөньяви белемнәре белән дә югары торган мәгърифәтле муллалар кадры хәзерләү өчен рухани семинарияләр ачу мәсьәләсен куярга кирәк, чөнки муллалар, чыннан да, халык хезмәтчеләре. Аларның бөтен гомерләре надан халык арасында үтә. Моңа полякларның ксендзлары, аларның католик рухани семинарияләре үрнәк була алыр иде[1],— дип куялар.

Ислам динен реформалаштыру, европалаштыру турында хыялланып йөргән Муса Бигиев, Һади һәм Садри Максудовларның карашларыннан бу Ордубацкийларның карашларын һич тә аерып алыр хәл юк!

Шуңа охшаш хәлне программаның экономика бүлегендә дә күрергә мөмкин. Менә бер мисал. Ордубацкий белән Алибеков анда халыкның байлыгын арттыру турында сүз ачалар да, татар халкының экономик хәлен көчәйтергә тиеш булган чаралар итеп, мөселманнар өчен махсус банклар ачу, үзара ярдәм кассалары оештыру, Төркстанда йорт-җир сатып алу хокукын таләп итү кебек нәрсәләрне санап китәләр. Авторларның фикере буенча, бу чаралар мөселманнар арасында сәүдәгәрчелекне, промышленностьне, игенчелекне үстерүдә ярдәм итәргә тиеш булып чыга.

Бу фикерләр, ихтыярсыз, буржуаз милләтчеләрнең сафсаталарын искә төшерәләр. Алар да бит татар җәмгыятенең алдынгы сафында торган элемент фәкать буржуазия генә була ала, чөнки татарлар күбесенчә сәүдәгәрләр, игенчеләр; җитлеккән буржуазиясе булмаган милләт прогрессив була алмый, зәгыйфь, җитлекмәгән буржуазияле милләт — көчле була алмый, шуның өчен татар буржуазиясенең көчен арттырырга кирәк, дип кычкыралар иде.

Дөрес, программаның бу бүлекләре оештыру комиссиясе утырышларында каралмаганнар, тикшерелмәгәннәр. Архив документларында бу турыда бер сүз дә әйтелми. Шуңа күрә бу бүлектә әйтелгән фикерләргә оештыру комиссиясенең бөтен әгъзалары да кушылганнар, бу фикерләрне кабул иткәннәр дияргә нигез юк. Тик бу бүлекләрне язучылар турында, бу кешеләрнең карашы буржуа милләтчеләрнең карашы белән бермә-бер булган икән, дип әйтергә мөмкин.

Программаның бу бүлекләре белән танышканнан соң, чыннан да Кием оешмасының составы бик чуар булганын һәм Галимҗан Ибраһимовның патша хөкүмәтенә каршы революцион көрәш алып бару мәсьәләсен оешма әгъзалары алдында аларны сынамыйча, тикшермичә ачыктан-ачык кую ялгыш булыр, дигән фикере бик хаклы булганына тагын бер тапкыр инанасың.

---

[1] УССР УДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 3551. Икенче кисәк. 351 бит.

Казан губернасының жандармерия идарәсе Киевта мөселман студентларының оешмасы барлыгын 1912 елның декабрендә ук белеп торган. Бу оешма турында доносны беренче булып провокатор «Теоретик» (Хәнәфи Кайбышев) биргән. Ләкин жандармерия ашыкмаган. Ул бу оешманы бөтен гаепләрен фаш итә торган документлар белән тотарга, тамыры белән йолкып ташларга уйлый. Шул ният белән полиция департаменты Казан жандармериясенең белдерүенә нигезләнеп, бөтен Россиядәге жандармерия идарәләренә һәм охранкаларга яшерен күрсәтмәләр, сигналлар бирә башлый. 1913 елның 12 мартында полиция департаментының директоры С. Белецкий үзенең кул астындагы идарәләргә болай дип яза:

«...Полиция департаментында булган мәгълүматларга карагандa, империянең югары уку йортларында укучы мөселман студентлары мөстәкыйль группаларга оеша башладылар. Әйтик, университетлы зур шәһәрләрнең берсендә югары уку йортларында укучы мөселман студентлар инде берләшкәннәр һәм алар арасында тыгыз элемтә булдырылган.

Россиядәге мөселман студентларын берләштерү идеясе соңгылары арасында зур теләктәшлек тапты һәм алар да хәзер өлгергән мәсьәләләрне һәм бергәләп планлы эш алып баруны хәл итү өчен съезд җыю кирәк, дигән фикер уятты... Полиция департаменты сезнең дикъкатегезне шул хәрәкәткә таба юнәлтеп, сезнең күзәтүгезгә тапшырылган район күләмендә бу эшнең ни хәлдә булуын ачыклавыгызны, бу мәсьәлә буенча сезнең үзегездә булган мәгълүматларны эшкәртүегезне һәм аларның нәтиҗәләрен кичектермичә департаментка хәбәр итеп торуыгызны үтенә»[1].

Бу документ полиция департаментының мөселман студентлары хәрәкәтенә зур сәяси әһәмият биргәнен бик ачык күрсәтсә кирәк.

Россиядә яшәүче мөселман студент вәкилләренең җыены 1913 елның 17 апрелендә Киевта үткәрелергә тиеш, дигән хәбәрне алгач, Хәллә Еникеев барган чакта Казанда оештырылган ячейка членнары Киевка кемнәрне җибәрү мәсьәләсен хәл итәр өчен, Хөсәен Ямашевның хатыны Хәдичә Ямашева квартирына җыелалар. Бу турыда Хәнәфи Кайбышев шундук жандармериягә донос ясый: «Киевка чакыру турында сөйләшер өчен,— дип яза ул,— бу елның 14 апрелендә, кич сәгать 7 дән соң 10—15 ләп мөселман студенты теш врачы Хәдичә Ямашеваның квартирына җыелдылар. Җыелышта 1) Фуад Туктаров, 2) Әбүбәкер Имамбаев, 3) Абдерәшит Фәхретдинов, 4) Нурылгаян Байтирәков, 5) Әхмәт Мамлеев, 6) Искәндәр Мөстакыймов, 7) Хәнәфи Кайбышев (озак булмады) һәм хәзергә фамилияләре билгеле булмаган тагы берничә кеше бар иде»[2].

Бу яшерен җыелыш турында охранкага доносны тизрәк җиткерер өчен, Хәнәфи Кайбышев мәҗлестән бик иртә сызган һәм турыдан-туры охранкага чапкан булса кирәк. Доносны алгач ук, җыелыштагыларны эләктерер өчен, ашыгып, охранка полиция җибәрә. Полиция килгәндә ячейка утырышы әле таралмаган була. Андагы кешеләрнең һәммәсенең исем-фамилияләрен язып алалар. Квартира хуҗасы Хәдичә Ямашевага 500 сум, башкаларга йөзәр-йөз иллешәр сум штраф салалар.

Ул кичтәге ячейка утырышында, әле Хәнәфи Кайбышев чыгып киткәнче үк, Киевка вәкил итеп кемнәрне җибәрү мәсьәләсе хәл кылынган булган. Әлбәттә, провокатор үзенең доносында бу турыда да әйтми калмаган: «Утырышта катнашучыларның фикере бүленде: кайберләре (Кайбышев, Туктаров, Фәхретдинов) съезд чакыру һич тә кирәкми, аннан файда булмаячак, бу — вакытны бушка әрәм итү генә булачак, диделәр. Ә башкалары делегат җибәрү кирәклеген алга сөрделәр. Соңгы фикер җиңде. Делегат итеп, хәзерге вакытта буш булган (бу ел ул университет студенты булып исәпләнми) һәм акыллы гына егет — Имамбаев Әбүбәкерне сайладылар, аңа

---

[1] СССРның баш архив идарәсе. Фонд ДПОО. Язма 1913. Саклау берәмлеге 174. 1 бит.

[2] СССРның баш архив идарәсе. Фонд ДПОО. Язма 1913. Саклау берәмлеге 32. Бүлек 28 лБ. 27 бит.

вәкиллек хокукы һәм юл кирәк-яраклары бирделәр. 15 апрельдә ул Киевкә китәчәк...» [1] — дип язган ул.

Монда бер аңлашылмаучылык килеп чыга. Икенче бер провокатор — Төхфәтулла Мамлеев (бусы охранка тирәсендә «Житель» дигән кушамат астында йөри) Киевка казакъ егете Кадыйров китте дип жандармериягә хәбәр бирә. Казан жандармериясе Кадыйров белән Имамбаевның кем икәнлекләрен тикшерү-ачыклау чараларына керешә һәм, Казаннан вәкил булып киткән казакъ студентының буен-сынын күрсәтеп, тиз генә Киевкә шифр белән язылган телеграмма суга.

Киев жандармериясенең агентлары Имамбаевны поездда ук каршылап алалар һәм, артыннан күзәтеп, аны җыелыш булачак квартирга чаклы озатып куялар.

Имамбаев килгәнгә кадәр дә Киев охранкасы үзенә мәгълүм булган мөселман студентларын бик нык күзәтеп тора. Шул күзәтүнең нәтиҗәләре турында Киев жандармериясенең башлыгы подполковник Леонтьев полиция департаментына системалы рәвештә җиткереп бара: Киев мөселман студентлары 16 апрельдә Ахтямова квартирында, шул ук көн тагы бер тапкыр Алибеков квартирында, 17 апрель иртәсендә Ордубацкий квартирында, ә көндез Мәһдиев квартирында җыелышлар үткәргәнен хәбәр итә.

Күзәтүчеләр 17 апрельдә сәгать алты белән җиде арасында, Назарьев урамындагы 15 номерлы йортта җирле һәм читтән килгән студентлар җыелып беттеләр, дип охранкага хәбәр итәләр. Охранка шундук бу адрес буенча полиция җибәрә.

## VIII

Полиция килеп җиткәнче, оештыру комиссиясенең рәисе — хан Талышинский җыелыш мөнәсәбәте белән алдан язылып куелган кереш сүзен сөйләп өлгерә. Ул, читтән килгән студентларны сәламләп, аларны халык бәхете өчен көрәш юлында бердәмлеккә өнди һәм оештыру комиссиясе башкарган хәзерлек эшләре белән таныштыра башлый. Шул чак көтелмәгәндә полиция килеп баса. Җыелыштагы бөтен кешеләрнең исем-фамилияләрен язып ала да делегатларны тенти башлый.

Җыелышта барлыгы 14 кеше була. Боларның алтысы — Киев студентлары: хан Талышинский, Ордубацкий Фируз бәк, Ахундов Хөсәен бәк, Еникеев Хәлилулла, Вәзиров Җәмил бәк, Алибеков Али бәк, икесе — Киев курсисткалары Сона ханым Ахундова һәм Гөлсем туташ Ахтямова. Калганнары исә читтән килгән студентлар: Петербургтагы политехник институт студенты Мәһдиев Мир Якуб, Петербург университеты студенты Корбанов Нәҗиб Гали улы, Казан университеты студенты Имамбаев Әбүбәкер, Новороссийск университеты студенты, Иранннан сөрелгән шаһның шәхси секретаре Насырбеков Абдульфен, Мәскәүдә сәүдә институтының студенты Кәримов Мөхәммәд Гариф, Харьков университеты студенты Алибеков Ширин бәк.

Полиция килеп басу белән, мондый эшләрдә тәҗрибәләре булмаган студентлар аптырашып, куркып калалар. Кулларындагы язмаларны, протоколларны тизрәк келәм, карават, шкаф асларына, квартира хуҗасы Ахундова белән янәшә бүлмәдә яши торган рус студенткасының түшәк араларына яшерә башлыйлар. Ләкин тентү вакытында полиция боларның һәммәсен табып ала.

Тентү вакытында Галимҗан съездга килеп өлгермәгән була. Шулай булса да, ул тентүдән дә, төрмәгә утыртылудан да котылып кала алмый.

Полициянең килеп басуын һәм аның квартирын тенти башлавын Галимҗан үзе менә ничек тасвирлый: «Төн. Сәгать ике. Бөтен өй тирән тынлыкта йоклый. Төшемдәме-өнемдәме, белмим, кемнәрдер тышкы ишекне ачтырып керәләр дә, шундагы, беренче бүлмәдәге студентны уйгаталар. Ул куркып, аптырап, нидер мыгырдый.

— Яңылыш килгәнсездер,— дип маташа...

Аңардан фамилиясен сорыйлар.

— Юк, алайса хата... Безгә Ибраһимов кирәк. Ул кайда? — диләр.

---

[1] Шунда ук, 28 бит.

Мин бунардан уйганып җитә алмыйм. Зал ашасыннан бик каты, бик тәкәллефсез басып килгән итекләр, шпорлар минем бүлмә ишеге янына килеп туктыйлар, кемдер каты кага, фәрманлы, рәхимсез тавыш белән:

— Ачыгыз! — ди.

Яткан җиремнән кузгалмыйча:

— Кем бар анда? Мин чишенеп ятканмын, гафу итегез, кертә алмыйм,— дим.

Тагы каты кагалар, тагы фәрманлы тавыш:

— Сезгә әйтәләр бит, ачыгыз... Без кунакка килмәгән...

Мин сизенәм дә, электр яндырып, киемнәрне эзлим...

— Хәзер, тик бик аз гына киением,— дим.

Буңа илтифат юк. Ниндидер бер тимер белән ишекнең ярыгыннан тыгалар да келәне ачалар, керәләр...

Ни күрием? Алдымда үзенең бөтен коралы белән жандарм, аның артыннан берничә городовой, тагы йортның каравылчысы, дворнигы кебек берничә «әфәнде» тора.

— Жандармерия начальнигының фәрманы буенча сездә тентү ясарга ебәрелдек,— диләр.

Ялан өскә зур пальтоны салам, ялан аякка итекне киям дә:

— Рәхим итеп ордерыгызны күрсәтегез! — дим.

Жандарм шөбһә катыш шелтә белән күзләремә төгәлеп карый:

— Э!!. Сез... тәҗрибәле бүремени шулай? — ди.

— Юк,— мин әйтәм,— тәҗрибәм булганы юк, ләкин ишетмештән беләм рәсми ордерсыз ярамавын...— дим.

Күрсәтә.

Мин тәмәке яндырам да тирән креслога утырам...»[1]

Тентү таң атканчага кадәр дәвам итә, әмма околоточный надзирательнең тупас, җаһил теле белән язылган протоколы бик кыска була.

Тентү беткәннән соң Галимҗан Ибраһимовны Киев шәһәренең Бульварный дип атала торган участогына алып китәләр. Бу вакытта инде җыелышта кулга алынган бөтен студентлар да монда китерелеп ябылган була. Кызларны, ягъни Гөлсем Ахтямова белән Сона ханым Ахундованы, хатыннар камерасына, бу төнне тотылган фахишәләр янына ябалар.

Икенче көнне Галимҗаннан башкаларны полициянең Бульварный бүлегеннән алып китеп башка бүлекләргә — участокларга урнаштыралар. Галимҗанны исә допроска алып китәләр.

## IX

Полициянең Бульварный бүлегендә утырган арада, допрос вакытында жандармның сорауларына ничек җавап бирү турында студентлар алдан сүз берләшеп куйганнар булса кирәк. Хикмәт шунда, допрос вакытында алар барысы да бер төрле итеп җавап биргәннәр: «Безнең оешмабызның максаты фәкать мохтаҗ мөселман студентларына матди ярдәм күрсәтү һәм кичәләр, концертлар, китаплар бастырып тарату кебек юллар белән акча җыю гына иде. Без оешмабы [illegible] әлбәттә, легальләштерер[illegible] дип ышана идек. Шуның өчен дә бу эш белән ба[illegible]иверситетлы шәһәрләрд[illegible] мөселман студентларын таныштырыр өчен алар белән язышә башладык. Съезд чакыру мәсьәләсе дә менә шуннан килеп чыкты. Съездда без тик аң-белем таратуга, экономикага бәйләнешле мәсьәләләрне генә тикшерәчәк идек, сәяси мәсьәләләргә кагылырга уебызда да юк иде, дигән алар.

Жандармнарның аерым корпусы подполковнигы Вахнин Галимҗан Ибраһимовтан беренче допросны 18 апрельдә ала. Киевле мөселман студентларының түгәрәгенә мөнәсәбәте турында сораганда Галимҗан, бик тотнаклы гына итеп, уйлап куелган риваятен сөйли:

---

[1] Галимҗан Ибраһимов. Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә. Казан. 1922 ел. 21—22 битләр.

— «Мөселман студентлары җыеннар, мәҗлесләр ясыйлар дигән нәрсә моңарчы миңа мәгълүм түгел иде, тик менә кичә мине кулга алып участкага япканда гына мөселман студенткаларын һәм курсисткаларын җыеннары вакытында полиция тотып япканын белдем. Ләкин бу җыен нинди максат белән җыелганы миңа мәгълүм түгел. Мөселман студентлары белән очрашкалаган вакытта аларның үз түгәрәкләрен легальләштерергә теләүләрен ишеткәләгәнем бар»[1],— дип җавап бирә ул.

Тенту протоколына караганда, Галимҗанның квартирыннан бик күп китаплар, газеталар, кульъязмалар алынган. Кулга алу белән допрос арасында бер генә тәүлек үтүгә дә карамастан, жандармерия бу китапларны һәм кәгазьләрне, өстән-өстән генә булса да, тикшереп-карап чыгарга да өлгергән икән: Галимҗанның китаплары арасындагы яшерен таратыла торган революцион газеталарны, брошюраларны бик тиз табып алганнар. Алар арасында чит илдә басылып, Россиядә яшерен таратыла торган «Знамя труда» газетасының 13 саны, «За народ» газетасының бер саны, ул заманнарда Россиядә патшалык иткән Романовларга каршы язылган «Дом Самозвановых» дигән сәяси брошюра-памфлет һәм Киев студентларының гектографта басылып, идән астыннан таратылган прокламацияләре дә була. Ул прокламациядә дә Романовларның 300 ел дәвамында кылган золымнары саналган һәм Киев студентлары Романовларга багышланган тантанада катнашмаска тиешләр, дип әйтелгән. Шуның өчен дә подполковник Вахнин беренче допрос вакытында, я «аталарча» вәгазьләп, үгетләп, я жандармнарча куркытып, бу тыелган әдәбиятны каян алганын Галимҗаннан әйттерәсе килә. Ләкин Галимҗан аңа алданмый: «Миңа күрсәтелгән «Знамя труда» газетасының унөч саны һәм бер данә «За народ» газетасы (бу газеталарның басылып чыккан көннәре һәм саннары күрсәтелә — Г. М.) минем квартирымнан алындылар. Бу газеталарны мин Романовлар йортының өч йөз еллык юбилей бәйрәме көнне урамнан табып алдым. Миңа күрсәтелгән «Дом Самозвановых» исемле брошюра да «Знамя труда» һәм «За народ» газеталары төрелгән төргәктә иделәр»[2],— ди ул подполковник Вахнинга.

Галимҗанның бу җавабы подполковникны, әлбәттә, канәгатьләндерми һәм допрос дәвамында ул бу мәсьәләгә кабат кайта. Галимҗан исә үзенең беренче әйткән сүзендә нык тора, шуннан һич тайпылмый: «...Әченә «Знамя труда», «За народ» газеталары һәм «Дом Самозвановых» брошюрасы төрелгән төргәкне кемдер, Софийский собор янында бугай, халык арасына ташлаган булган. Кайчан икәнлеген төгәл генә әйтә алмыйм»[3],— ди.

Подполковник Вахнин Киев мөселман студентлары түгәрәгенең протоколлары, Галимҗан тарафыннан язылган программалары белән танышып өлгермәгән булса да, Галимҗанның яшерен түгәрәк әгъзалары белән якыннан аралашып йөргәнен шымчыларның доносляры буенча яхшы белә. Шуның өчен ул Ибраһимовның «мөселман студентларының яшерен түгәрәкләре турында бер нәрсә дә белмим, ә бу яшерен әдәбият минем кулыма очраклы рәвештә килеп керде, дип әйтүенә, әлбәттә, ышанмый. Ләкин әйберләтә дәлилләр табып, Галимҗан Ибраһимовның гаебен аның үзеннән таныттыр өчен, аның квартирыннан алынган һәм җыелыш җыелган квартирда табылган бөтен материалларны җентекләп тикшереп чыгарга кирәк булачак, һәм бу эш озакка сузылачак икәнен яхшы белә подполковник. Шуңа күрә Галимҗанны участоктан ала да төрмәгә яптыра.

## X

«Яшь кешеләр» белән аралашып, бигрәк тә алар белән бергә патша хөкүмәтенә каршы революцион көрәш ачарга хәзерләнеп йөргәне өчен, жандармерия башыннан сыйпамаячагын Галимҗан бик яхшы белә. Шуңа күрә төрмәдә бер кешелек камерага (одиночкага) утыртылуына да артык аптырамый ул. Аны икенче нәрсә: жандармерия кулына төшкән кульъязмаларның, аеруча «Казакъ кызы» романы кульъязмасының, язмы-

---

[1] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 3151. II бүлек. 318 бит.
[2] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 3151. Бүлек II. 318 бит.
[3] Шунда ук, 319 бит.

шы борчый. Ул романның кульязмасы аңарчы инде бер тапкыр басарга дип биргән җирендә, Кәримовлар нәшриятында, жандармерия кулына төшеп, югалган булган. Инде менә кулында калган караланмасы буенча яңабаштан эшләп чыккан нөсхәсе дә Киевтә жандармерия кулына эләгә.

Галимҗанны борчыган икенче бер нәрсә була: ул үзенең төрмәгә ябылу хәбәре яраткан әнисенә ишетелмәсә ярар иде дип хәвефләнә. Моның шулай икәнлеге иптәшләре Шәһит белән Заһитка[1] төрмәдән язган хатында бик әйбәт сизелә. Татарча язарга рөхсәт булмагач, рус телендә язган бу хат тагын бер ягы белән әһәмиятле. Анда Галимҗанның ул заманнарда ук рус телен һәм орфографиясен бөтен нечкәлекләре белән белгәне күренә.

Хат Шәһит белән Заһитның кулына тапшырылмыйча, жандармериянең кәгазьләре арасында батып калган. Ул хатта менә мондый юллар бар: «Шәһит вә Заһит!

Киев губерна төрмәсеннән сезгә үземнең беренче сәламемне җибәрәм. Минем кулга алынуым, мөгаен, сезгә билгеледер. Ләкин сезгә минем үземнән дә берәр нәрсә ишетү зарар итмәс дип уйлыйм. Бөтенесе бик гади булып чыкты. 17 апрель төн сәгать 12 дә, Киев жандармерия идарәсенең карары буенча, минем бүлмәдә тентү ясалды. Татар, рус һәм төрек телләрендәге бик күп китапларым алынды. Шулай ук бөтен хатларымны, рәсемнәремне, хәтта альбомнарны һәм, барысыннан да бигрәк, бөтен кульязмаларымны алдылар: алар арасында планнар, язмалар, газета өчен язылган мәкаләләр, кечкенә хикәяләр һәм, иң мөһиме, бөтен кыш буенча эшләп чыккан теге бәхетсез «Казакъ кызы» бар иде. Хәзер мин тик кульязмалар турында гына уйлыйм: әгәр миңа шуларны кайтарсалар, башкалары ул кадәр үк түгел!..

Мине участокка китергәннән соң, анда 12 мөселман студентын һәм җитмәсә тагы икенче камерада ике курсистка — берсе уфалы Ахтямова, икенчесе кавказлы Сона ханым — утыртылганнарын күреп, чиктән тыш хәйран булдым. Бу студентлар арасында Казаннан, Петербургтан, Мәскәүдән (Кәримовның энесе) һәм башка университетлы шәһәрләрдәге мөселман студентларының вәкилләре бар иде.

Без бөтенебез бергәләп шунда төн кундык, ә иртән мине төрмәгә, аларны каядыр озаттылар.

Менә инде ялгызым утырган бүлмәдә, ягъни камерада, көн-төн арлы-бирле атлавыма тулы бер атна үтеп китте. Минем белән янәшә (камерада) кавказлы студент Рустамбеков утыра. Ул да безнең белән бергә кулга алынган. Минем кебек бер кешелек камерада ялгыз утыра.

Шәһит (ул Казанда булмаса) яки син Заһит, Уф. губ. Стерлетамак. Уршакминск. вол., д. Султанмуратово, Шакиржану дигән адрес буенча минем абыйга кичектермичә хәбәр итегез...

Соңыннан, һәм бусы иң әһәмиятлесе, Шәһит, мин сиңа этимологиянең икенче басмасы турында эш тапшырам: «Гасыр»[2] белән сөйләш. Үзең ничек отышлы дип тапсаң, шундый шарт куй. Зинһар, игътибарлы бул. Һәммә нәрсә турында тәфсилле языгыз. Барчагызга сәлам. Хәзергә хушыгыз. Галимҗан»[3].

Хатның читенә: «Абый хатын русча язсын һәм ул минем турыда өйдәгеләргә бер нәрсә дә әйтмәсен. Шунысы да бар бит: эшебез уен түгел, ул округ судына ук барып җитәр төсле күренә»,— дип язылып куелган.

Галимҗанның кульязмалары турында борчылулары бушка булмаган.

## XI

Галимҗан Ибраһимовның бүлмәсендә тентү булган чакта жандармерия нинди китаплар, брошюралар, кульязмалар, хатлар табып алган?

Бу сорауга Казан жандармнарының аерым корпусы подполковнигы Добродеев тарафыннан бик җентекләп язылган 10/55 номерлы протокол тулы җавап бирә.

---

[1] Шәһит белән Заһит — Галимҗанның якын дуслары — Шәһит Әхмәдиев һәм Заһит Нуркин.

[2] «Гасыр» — ул чордагы нәшрият.

[3] УССР УДТА. Фонд 274. Язма 3. 236 эш. 1—2 битләр.

Подполковник Databases Добродеев ул протоколны язар өчен башта ике шаһит алдында һәм тәрҗемәче штабс-ротмистр фон Трентовиус ярдәме белән 19 көн буена Галимҗаннан алынган китап-язуларны тикшереп утырган.

Галимҗаннан алынган китапларның, кульязмаларның эчтәлеге турында сүз башлаудан элек, аларның ни өчен Киевтан Казанга килеп төшүләре турында бер-ике сүз әйтергә кирәк. Эш менә нәрсәдә: кулына төшкән татар, әзәрбәйҗан, төрек телләрендәге китапларны, газеталарны һәм кульязмаларны уку өчен Киев жандармерия идарәсендә бу телләрне белгән агентлар табылмаган. Ә жандармерия бу китапларда һәм язмаларда төрмәгә утыртылган студентларның «йөзләрен ачып бирә торган», «фетнәле» идеяләр язылган булуы ихтимал дип уйлаган һәм, шуны ачыклау өчен, аларны төрек-татар телләрен белүче тәрҗемәчеләре булган Казан губернасы жандармериясе идарәсенә юллаган. Шунда алар ул елларда төрек-татар телләре буенча тәрҗемәче булып эшләп маташкан кешегә — 15 нче татар улан полкының штабс-ротмистры А. Ф. фон Трентовиуска тапшырылган.

Галимҗаннан алынган төрек һәм татар телендәге китаплар гына да 130 дан артык була. Боларның күбесе (80 нән артыгы) матур әдәбият. Араларында Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев, Укмасый әсәрләре дә бар. Стамбулда төрек телендә басылган китапларның күбесе — Абдулхак Хәмиди әсәрләре. Төрек телендә язылган китаплар арасында Максим Горькийның «Ана» романы тәрҗемәсе дә бар. (Тәрҗемәче — И. М. Мөхетдин, 1327 ел һиҗри. Стамбул.)

Әдәбият тарихы һәм әдәбият белеме буенча да 15 ләп китап булып, алар арасында Габдерахман Сәгъди, Җамал Вәлиди, Әхмәт Риса, Кюпрюлю Задә һәм башкаларның хезмәтләре бар. Тарихи китапларның саны да 15 тән ким түгел. Алар арасында Г. Ибраһимовның үзенең Уфада басылган «Борынгы ислам мәдәниятенең тарихы» дигән китабының да исеме күрсәтелә. Болардан тыш, протоколда бер-ике фәлсәфи китапның исеме дә телгә алына һәм бик күп татарча һәм русча газета-журналларның исемнәре санала.

Менә бу мәгълүматлар яшь язучы Галимҗан Ибраһимовның ул заманнарда ук әдәбият, филология мәсьәләләре белән генә түгел, тарих, фәлсәфә, иҗтимагый хәрәкәт мәсьәләләре белән дә бик якыннан кызыксынып, бу мәсьәләләрне мөмкин кадәр тирәнрәк өйрәнергә, тикшерергә тырышканлыгын бик әйбәт раслап торалар. Хәер, бу хосусиятен ул актыкка гомеренәчә саклап килде.

## XII

Күреп үткәнебезчә, Галимҗан Ибраһимов Шәһит белән Заһитка төрмәдән язган хатында, тентү вакытында матбугатка чыкмаган мәкаләләре, кечкенә хикәяләре һәм теге «бәхетсез» «Казакъ кызы»ның кульязмалары жандармерия кулына эләгүен әйтә. Бу хәл подполковник Добродеев тарафыннан язылган протоколда да раслана. Анда иң элек «Казакъ кызы» романының 75 битлек кульязмасы телгә алынган.

Шунысы кызык: ни өчен Галимҗан «Казакъ кызы»н «бәхетсез» дип атый соң?

Архивта 1911 елның май ае башларында Галимҗанга язылган бер хат сакланган. Менә ул: «Кадерле борадәр Галимҗан әфәнде!

Тентү вакытында алынган әйберләрнең берсе дә, шул исәптән «Казакъ кызы» да, кире кайтарылмады. Кайчан кайтарылачагы мәгълүм түгел. Сезнең «Мөләхаза» исемле мәкаләгез «Шура» журналында басылып чыккан, имеш. Фатих Кәримов. 2 май, 1911 ел»[1]. Бу уңайдан 1923 елны гына дөнья күрә алган «Казакъ кызы» романына Галимҗан Ибраһимов үзе язган «Мөхәррирдән» дигән кереш сүзне искә алырга кирәк: «Казакъ кызы»,— дип яза ул анда,— 1909 елның җәендә Уралның Миасс заводында языла башланып, 1911 елда Казанда тәмам булган иде. Шул заманнарда бу әсәрне Оренбургтагы «Вакыт» нәшрияты идарәсе басар өчен алса да, дөньяга чыгара алмады. Фатих Кәримовның миңа язган хәбәренә караганда, типографиягә бирелгәч (яки бирелергә торганда) Сарапул өязендә башланган мәгълүм ябулар дулкыны

---

[1] УССР УДТА. Фонд 274. Саклау берәмлеге 3151. Бүлек 1. Язма 1. 615 бит. (Хат архивтагы русча тексттан татарчага тәрҗемә итеп бирелә — Г. М.)

башка шәһәрләргә дә күчеп, Оренбургтагы тентүләр чагында, бу китап жандармерия кулына эләкте дә кайтмады.

Кулымда караламасы бар иде. Шуның буенча 1912—1913 елларда мин моны яңадан аклап чыктым. Ләкин тагы казага очрады: шул елның язында, Киевта булган мәгълүм хәрәкәт эчендә, апрель 17 сендә үземне ябып, китапларымны, барлык кульязмаларымны охранка алды, унбиш айлар үткәч, күп нәрсәм кире кайтса да, «Казакъ кызы»ның җитмеш бите тагы югалды...»[1] — дип яза ул.

Бу вакыйгалардан соң 53 ел үткәч, Украинаның Үзәк дәүләт тарих архивында сакланып яткан документ Г. Ибраһимовның бу сүзләрен бөтен тулылыгы белән раслады. Аерма тик шунда гына: жандармерия романның 70 битен түгел, бәлки 75 битен кайтармаган.

75 битлек бу кульязма кайда югалып калган икән?

Подполковник Добродеев язган протоколда, «Киргизка»ның (штабс-ротмистр Трентовиус «Казакъ кызы»н шулай тәрҗемә иткән) һәм «Яшь куәтләр» дигән мәкаләнең кульязмаларын, уку өчен бик читен булганлыктан, тәрҗемәче тәрҗемә итә алмады, дип язган. Ләкин ул канцелярия күсесе эшне болай гына калдырмый, кульязмаларны җыя да Казанның матбугат эшләре буенча вакытлы комитетына җибәрә. һәм үзенең 10/55 номерлы протоколына шундый белешмә дә беркетеп куя: «...2) 33 нче пунктта күрсәтелгән һәм бер-берсенә тегелмәгән 75 биттән гыйбарәт булган татар телендәге «Киргизка» исемле һәм шул ук телдәге унбиш битлек «Яшь куәтләр» исемле кульязмалар, аларда политик яктан гаепкә алырлык бирәр нәрсә юкмы дип карап чыгар өчен һәм, андый нәрсә булган хәлдә шул урыннарын тәрҗемә итәр өчен, Казандагы матбугат эшләре буенча вакытлы комитет председателенә җибәрелде»[2].

Моңа каршы, вакытлы комитет рәисенең урынбасары А. Фролов, 1913 елның 2 июлендә: «Бу кульязмаларда һичбер төрле гаепкә алырлык һәм җинаятьчел нәрсә юк», дип җавап бирә. Ләкин комитет бу кульязмаларны Казан жандармериясенә кайтарып биргәнме-юкмы, бу турыда архивта бертөрле дә документ сакланып калмаган. Тик бер нәрсә ачык билгеле: алар Киевка кайтарылмаганнар. Бәлки, Галимҗанның кульязмалары бүгенге көнгәчә матбугат эшләре буенча вакытлы комитетның яки Казан губерна жандармерия идарәсенең архивларында ята торганнардыр.

«Казакъ кызы» романының язмышы менә шундый була. «Яшь куәтләр» исемле кульязманың да язмышы шуңа бик охшый. Архивта Ризаэтдин Фәхретдиновның 1912 елның 24 октябрендә Галимҗан Ибраһимовка язган хатының русчага тәрҗемәсе сакланган. Хатта: «Хөрмәтле Галимҗан әфәнде... «Яшь куәтләр» дигән мәкалә бик кызыклы, аны ничек кенә булса да бастырырга кирәк, ләкин «Шура»да бастырырга рөхсәт юк, шуңа күрә аны үзегезгә кайтарабыз»[3],— дип әйтелә.

1915 елның 8 февралендә «Йолдыз» газетасында басылган бер мәкаләсеннән башка, Галимҗан хезмәтләрендә «Яшь куәтләр» дигән бер мәкаләсе дә юк бугай. Ләкин бу мәкаләнең дә тулы исеме: «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр». Бу мәкалә 1915 елның әдәби хисабате рәвешендә язылганлыктан, 1912 елга да, 1913 елга да аның һичбер төрле мөнәсәбәте юк.

1913 елның башларында Киев мөселман студентлары рус телендә чыга башлаган «Мусульманская газета»га ачык хат язып, бу газетаны яратып укуларын һәм аңа үзләре дә язышырга теләгәнлекләрен белдерәләр. Бу уңай белән Р. И. Нәфыйгов иптәшнең сүзләренә кушыласы килә. Бу хат турында ул болай яза:

«...1913 елның февраль аенда татар язучысы Галимҗан Ибраһимов Киевта иде. Шундый бер сорау туа: Киев мөселман студентларының хатына аның мөнәсәбәте булмадымы икән? Сакланып калган архив материалларына карaганда, Галимҗан Ибраһимов Киев мөселман студентларының хәрәкәтенә актив катнашып, аларның түгәрәкләрен алдынгы революцион идеяләр белән рухландырып торганын күз алдында тотсак,— бу бик була торган хәл кебек күренә[4],— ди.

---

[1] Галимҗан Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. Т. 2. Казан. 1957 ел. 259 бит.
[2] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 3151. Бүлек II. 622 бит.
[3] Шунда ук, 619 бит.
[4] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казань. 1964 ел. 395 бит.

Чыннан да, Галимҗанның жандармериядә югалып калган «Яшь куәтләр» дигән мәкаләсе, Киев студентларының хәрәкәте һәм газетага язган ачык хатлары арасында нинди дә булса бер бәйләнеш юкмы икән?

Шул ук 10/55 номерлы протоколдан Галимҗанның квартирыннан охранканың тагы башка кульъязмалар да алганы аңлашыла. Ул протоколның 12 нче пунктында агач тартма эченнән бергә беркетеп тегелгән дүрт дәфтәр чыгуы һәм шул дәфтәрләрнең берсендә татар телендә язылган кульъязма булуы да әйтелә. Ләкин, кызганычка каршы, штабс-ротмистр фон Трентовиус ул кульъязманың тулы тәрҗемәсен дә, исемен дә әйтми, тик: «Монда, башка нәрсәләр арасында, мәдрәсә (мәктәп) тормышы тасвирлана һәм шунда ниндидер яңа бер мәдрәсәдә фетнәле чорда (кай җирдә икәне күрсәтелмәгән, ләкин сүз 1904—1905 еллар турында бара булса кирәк) җыелышлар ясалуы турында әйтелеп үтелә. Ул җыелышларда ниндидер Кызылбашевның күренекле роль уйнаганы күрсәтелә, аның исеме берничә тапкыр телгә алына. Моннан тыш, автор, ягъни Галимҗан Ибраһимов, социалистлар белән фикер алыштым, дип әйтә. Ә калган өч дәфтәрдә гаепкә алырлык бер нәрсә дә юк» [1],— дип кенә искәртеп китә.

Галимҗанның дөнья күргән әсәрләрендә Кызылбашев исемле каһарман булмаганы мәгълүм. Галимҗанның «тенту вакытында минем берничә хикәяләрем, мәкаләләрем жандармерия кулына төште» дигән сүзләренә нигезләнеп, бу дүрт дәфтәрдә татар шәкертләренең беренче революция чорындагы тормышлары, көрәшләре тасвир ителгән бер хикәя булгандыр дип уйларга кирәк. Ләкин бу хикәя дә, «Дустыма» дигән икенче бер хикәясе кебек, жандармериянең яки матбугат эшләре буенча вакытлы комитетның архивында югалып калган булырга тиеш.

10/55 номерлы протоколда «Дустыма» дигән хикәя турында да сүзләр бар. Анда: «4) Бергә кушылып тегелгән биш дәфтәр. Икенче зәңгәр дәфтәрнең 17 нче битендә, «Дустыма» дигән кульъязманың дәвамы буларак: «Бер вакыт без дини фәлсәфә вә ислам диненең өстенлеге тарафдарлары идек. Ислам вә мөселманнарга хезмәт итү юлында без, миссионерларга һәм «динсезләргә» җавап бирергә хәзерләнә идек дигән сүзләр язылган» [2],— дип әйтелә.

Бу әсәр — татар интеллигенциясенең дөньяга карашларының эволюциясе турында хатлар формасында (эпистоляр жанрда) язылган хикәя булган булса кирәк. Әмма ул да жандармериянең төпсез сандыгына батып калган.

Жандармериядә югалып калган кульъязмалар турында сүз киткәч, «Әдәбият мөгаллиме» исемле хикәя турында да әйтмичә үтеп булмый. Трентовиус бу хикәянең дә бер өлешен тәрҗемә иткән. Бу турыда ул протоколда менә ничек яза: «...Зәңгәр тышлы дәфтәрнең соңыннан санаганда дүртенче битендә түбәндәге сүзләр язылган: «Польша сәяси көчен югалтты. Хәзер инде ул үзенең язмышы тимер кулга эләккәнен сизеп алды. Шуның өчен дә ыңгыраша... Ләкин киләчәктәге азатлыкка ышана һәм бөтен эшләрен шул исәп белән, шул юнәлештә алып бара. Польша үзенең фәне, мәдәнияте белән безгә караганда бик югары, өстен тора. Шуның өчен дә ул үзенең үткәне, бүгенге көне һәм киләчәге турындагы уйлары буенча да, җәмгыятьтәге ролен аңлавы буенча да бик нык алга киткән. Без алардан өйрәнергә, күп нәрсәгә өйрәнергә тиешбез» [3].

Бу карашлар, мөгаен, Г. Ибраһимовның ул замандагы үз карашлары белән аһәңдәш булганнардыр? Әгәр ул хикәя сакланган булса, авторның шул чордагы башка вакыйгаларга мөнәсәбәте турында да тулырак фикер йөртергә мөмкин булыр иде. Ләкин бу хикәя дә Галимҗан Ибраһимовка кайтарылып бирелмәгән.

10/55 номерлы протоколда, югарыда күрсәтелгән кульъязмалардан башка, татарча язылган тагын ун дәфтәр турында әйтелә. Ләкин алар турында тәрҗемәче: «боларда һичбер төрле гаепкә алынырлык һәм хыянәтчел нәрсә юк» дип әйтеп китү белән генә чикләнә.

Архив документлары арасында бу кульъязмаларны Казаннан Киевка кайтару турында бер кәгазь дә очрамаганын әйткән идек. 1913 һәм 1914 елларда Г. Ибраһимовка

---

[1] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 3151. Бүлек I. 615 бит.
[2] Шунда ук, 616 бит.
[3] Шунда ук, 615 бит.

Киев жандармериясе кайтарган әйберләр исемлеге эчендә дә бу кульязмалар күренми. Аларны Украинаның Үзәк дәүләт архивында да табып булмады.

Казан жандармериясендә эшләгән подполковник Добродеевның һәм Казандагы матбугат эшләре буенча вакытлы комитетның архив документлары арасыннан бу кульязмалар ныклап эзләнелсә, зарар итмәс иде. Әгәр алар табылса, Г. Ибраһимовның әдәби мирасы тагын да тулылана төшәр иде.

Югалган кульязмалар турында сүз киткәч, Киев вакыйгасына мөнәсәбәте булмаса да, тагы бер-ике нәрсә турында әйтеп үтәсе килә. 1937 елда Галимҗанны Ялтада кулга алган чакта, аның квартирыннан бик күп документлар һәм кульязмалар да алынган булган. Бу кульязмалар арасында «Безнең көннәр» трилогиясенең икенче китабы һәм берничә хикәянең кульязмалары булган. Бу кульязмалар Ялта, Симферополь, Мәскәү һәм Казанның Дәүләт куркынычсызлыгын саклау комитетлары архивларыннан эзләнсә дә — табылмады. Ялта һәм Симферополь комитетлары, бу документлар 1937 елның 28 августында Казанга җибәрелделәр, дип җавап бирделәр. Мәскәү һәм Казан комитетлары исә, бездә бу документлар сакланмаган, дип кенә җавап кайтардылар. Ләкин бу җавапларга карап, Г. Ибраһимовның югарыда күрсәтелгән кульязмалары һәм документлары бөтенләй юкка чыкканнар диган фикерне күңел кабул итәсе килми. Дөнья тарихында йөз еллар буе югалган дип хисапланып килгән китапларның, кульязмаларның, рәсемнәрнең дә, әзли торгач, табылган очраклары бар бит.

Галимҗанның Татарстан музееннан юкка чыккан китапханәсе белән шәхси архивы турында да әйтми китә алмыйм. Бу турыда минем Татарстан матбугатында чыккан истәлекләремдә әйтелгән булса да, шуны гына кабатлап үтәсем килә: музейдан югалган әйберләр арасында да Галимҗанның әле беркайда да басылырга өлгермәгән кульязмалары да булып, аларның иң әһәмиятлеләре «Әдәбият кануннары» һәм Галимҗанның «Галия» шәкерте заманында язган «Корьән алладанмы — түгелме» дигән әсәрләре иде.

Мәдәният, әдәбият эшлеклеләре арасында, Г. Ибраһимовны кулга алгач, аның музейда сакланган китапларын да, архивын да алып юкка чыгарганнар, яндырганнар, диген риваятьләр яши. Ләкин бу — бер риваять кенә бит! Ул заманнардагы Галимҗанны кулга алган адәмнәр, аның китаплары, архивы музейда сакланганын каян белсеннәр икән? Төрмәдә чагында Галимҗанның да бу турыда әйтү ихтималы юк, чөнки, минем белгәнемчә, аны кулга алгач бер тапкыр да допроска чакырмаганнар. Музейдан югалган нәрсәләр турында башка төрле риваятьләр дә уйлап чыгарырга мөмкин бит. Музейның директоры, хезмәткәрләре алмашыну нәтиҗәсендә, музейга сакларга бирелгән әйберләрнең кемнеке икәне, бәлки, онытылгандыр да, хуҗасыз нәрсәләр дип, алар, бәлки, дәүләт фондына тапшырылгандыр. Бәлки, ул әйберләр берәр акыллы кешенең кулына төшкәндер дә ул аларны ераграк яшергәндер, ә соңыннан, үзе дә казага очрап, кая яшергәне турында беркемгә дә әйтә алмый калгандыр... Кыскасы, өметне өзәргә иртә әле.

## XIII

Тентү вакытында алынган китаплар, кульязмалар Киевтан Казанга озатылып, анда жандармериянең һәм матбугат буенча вакытлы комитетның төрле бүлекләрендә сәяхәт итеп йөргән арада, ике айга якын вакыт үтеп китә. Бу вакытка инде төрмәгә утыртылган мөселман студентларыннан алынган рус телендәге бөтен кәгазьләрне, документларны Киев жандармериясе укып чыккан була.

Казаннан 10/55 номерлы протокол килеп җиткәч, ягъни төрмәгә утыртылганнан соң ике ай чамасы вакыт үткәч кенә Галимҗанны допроска чакыралар. Допросны жандармнарның аерым корпусы подполковнигы Лахутин ясый.

Түгәрәкнең барлык протоколлары, документлары жандармерия кулына эләккәнен студентлар да, Галимҗан да бик яхшы белә.

Шул сәбәпле жандармериягә ачык мәгълүм булган нәрсәләрне яшереп маташу, инкарь итү мәгънәсез эш булганын Галимҗан, әлбәттә, аңлый. Ләкин ул җавапларын

бик уйлап, шомартып кына бирә, иптәшләренә дә, үзенә дә зарар китермәслек булсын дип тырыша.

Киев жандармерия идарәсенең архивында Галимҗанның подполковник Лахутин сорауларына язма рәвештә русча биргән җаваплары да сакланган. «Үземнең,— дип язган ул анда,— унсигезенче апрельдәге күрсәтүләремә кушымча буларак, тәкъдим ителгән сорауларга шуны аңлатам:

Мин хөкүмәткә каршы булган һичбер төрле оешмага катнашмыйм һәм катнашканым юк. Бу елның (1913) январь аена чаклы минем таныш студентым — Уфа шәһәре буенча якташым Еникеев, бер вакыт миңа Киев мөселман студентлары үзләренең якташлык оешмаларын легальләштерергә телиләр дип әйткән иде. Бераз вакыттан соң, студентлар үзләре оештырылырга уйлаган якташлык оешмаларының уставын, рәсмиләштерер өчен, губернаторга тапшырганнарын ишеттем. Губернатор уставны рәсмиләштермичә кире кайтарган. Февраль аендамы, марттамы, Еникеев миңа мөселман студентлары съездын чакыру буенча алдан җыелачак киңәшмәне хәзерләүче комиссиянең мине үз утырышына чакырганын әйтте. Мин аларның утырышында ике тапкыр булдым. Беренче тапкыр утырышуда, башка мәсьәләләр арасында, съездның физиономиясен билгеләү дигән тәкъдим каралды, мин съездда тик сәяси мәсьәләләр генә тикшерелергә тиеш, дигән тәкъдим ясадым. Мәсьәләләрне билгеләү эшен комиссия миңа һәм Еникеевкә тапшырды. Хәтеремдә, Еникеев белән икебез, кайбер нәрсәләр, мәсәлән, руханиларга мөнәсәбәт, Дәүләт думасының мөселман фракциясенә мөнәсәбәт, башка халыкларга мөнәсәбәт турында язгалаган идек. Ләкин, исемдә калганынча, анда хөкүмәткә каршы һичбер төрле нәрсә юк иде. Ул язмаларны комиссиягә мин үзем тапшырмадым. Аларны Еникеев комиссиягә тапшырдымы-юкмы, мин белмим. Комиссиянең бер утырышында ул язмалар турында сүз булган иде, дип Еникеев әйткән иде, ләкин аны җентекләп тикшергәннәрме, кабул иткәннәрме-юкмы, мин белмим. Мин катнашкан икенче утырыш кайсы көндә һәм кайсы айда булганын хәтерләмим. Бу утырышта нәрсә тикшерелгәне дә исемдә юк. Мин юкта комиссия мине съездның программасын төзү подкомиссиясенә сайлаганлыгы турында ничектер Еникеев сөйләп алган иде. Ләкин мин бу эштән баш тарттым. (18 нче номерлы протоколда тасвир ителгән әйберләтә дәлил күрсәтелә.) Миңа күрсәтелгән бу хатны мин үземнең танышыма — студент Кайбышев Хәнәфигә язган идем. Рождество вакытында туган йорты Уфага кайтканда, Казаннан үтешли, күрсәтелгән адресы буенча тапшырып өчен, ул хатны Еникеевкә биргән идем. Хатта булачак вакыйга — мөселман студентлары җәмгыятен легальләштерергә ниятләнеп йөрүләре турында әйтелә, ягъни сөйләнә. Шуңа күрә мин Казан студентлары бу эшкә нинди мөнәсәбәттә булырлар икән дип кызыксынган идем, чөнки мин, әдип буларак, яшьләрнең рухы вә аларның иҗтимагый мәсьәләләргә мөнәсәбәтләре белән кызыксынмый кала алмадым. Тентү вакытында минем квартирамнан, рус газеталары һәм журналларыннан башка, бик күп татарча язылган кулъязмалар, газеталар һәм китаплар алынды. Ләкин матбугатка чыгарылырга хәзерләнгән бу һәм цензурадан үтәргә тиешле ул материалларда хөкүмәткә каршы һичбер төрле нәрсә булуы мөмкин түгел. Артык аңлатырлык нәрсәләрем юк. Күрсәтүләремне үз кулым белән яздым. «Төзү», «мин», «үземнең», «һәм» дигән сүзләр сызылган юл өстенә «яшьләрнең» дип язылган, шуңа ышанырга кирәк.
Галимҗан Гирфанович Ибраһимов.

Подполковник Лахутин» [1].

Съездда тик сәяси мәсьәләләр генә каралырга тиеш, дигән тәкъдимен Галимҗан инкарь итә алмый, чөнки ул оештыру комиссиясенең бу протоколы жандармерия кулына төшкәнен яхшы белә. Ул шуңа аны яшереп маташмый, тик подполковник Лахутинның дикъкатен икенче тарафка юнәлтергә генә тырыша. «Кайбер нәрсәләр сызгалаган идек... ләкин... бу фикерләр Дәүләт думасының мөселман фракциясенә, руханиларга, Россиядәге башка милләтләргә мөнәсәбәт турында әйтелгән иделәр...» — ди. Әмма самодержавиегә каршы революцион көрәш идеясен пропагандалавы турында авызын да ачмый.

---

[1] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 3151. Бүлек II. 261—264 битләр.

Сүз арасында шуны да әйтеп үтәргә кирәк: жандармерия бу соңгы фактка аеруча дикъкать иткән булган: протоколдагы «съездда фәкать сәяси мәсьәләләр генә тикшереләчәк» дигән сүзләрнең астына гына түгел, читенә дә бик калын итеп сызып куйганнар.

Башка мәсьәләләргә килгәндә дә Галимҗан һаман шул үзәрә алдан сөйләшеп куелган риваятьләрдән читкә тайпылмый.

Ихтимал, подполковник Лахутин мәсьәләне бик кабартырга да теләмәгәндер, чөнки ул чакта инде жандармерия Киев студентларының «эшен» тикшерүне туктатырга кирәк дигән карарга килгән була.

## XIV

Киев мөселман оешмасының протоколлары, самодержавиегә каршы революцион көрәшкә чакырган программасының тезислары, якын киләчәктәге планнарын ачып биргән башка документлары — болар бик зур сәяси суд процессы тудырырга мөмкинлек биргән булырлар иде. Ләкин эш башкача булып чыга. Галимҗан үзе моны болай аңлата: «...Без ябылуга татар, мөселман доньясының бик зур, бик ышанычлы груһлары мәсьәләгә катнашты. Дума вәкиле Ахтямовлар, Кавказның һәртөрле мирзалары, байлары, бәкләре, бәйләре безнең белән әлеккән угылларын, сөйгәннәрен, кызларын коткару — мондый «хурлыктан» аклау өчен көне-сәгате белән Киевка килеп җиттеләр. Үзләренең югары даирәдәге мөнәсәбәтләре, фәләннәре, фәләннәре, фәләннәре мәсьәләне туктатуда беренче зур рольне уйнадылар» [1],— ди. Чыннан да, Киев мөселман студентларының төрмәгә утыртылулары мәгълүм булу белән, Шәфи бәк Рустамбековның агасы — хәрби врач Җафар бәк Рустамбеков Варшавадан килеп җитә. Абдулфәт хан Талышинскийның агасы Аббас хан Талышинский да Киевка ашыга. Сеңелесенә ярдәмгә дип Петербургтан Дәүләт думасының депутаты Ибнеәмин Ахтямов килеп чыга. Казаннан Гариф Кәримовның агасы Камил Кәримов килә. Ордубацкий, Вәзиров һәм башкаларның да югары даирәдә мөнәсәбәтләре булган туганнарытумачалары Киевка киләләр. Фәкать Галимҗан Ибраһимов белән Хәлилулла Еникеевкә генә һичкем килми һәм килергә ниятләнми дә. Ә теге югары дәрәҗәле кешеләр жандармериягә дә баралар, губернатор хозурында да булалар, нәүбәт көтеп тормыйча, төрмәдәге туганнары белән күрешергә рөхсәт тә алалар. Һәркайсы үз туганын допрослар вакытында ничек тотарга, ничек җавап бирергә өйрәтә, акча биреп, төрмәдән чыгару яки порукага алу юлларын карый. Шуның өстенә, Галимҗан әйтмешли, «фәлән», «фәлән», «фәлән» дигән чараларны да күрәләр. Кыскасы, Киевка җыелган бу халык, ярсынып, сызганып эшкә керешә. Бу тырышлыкның нәтиҗәсе дә була.

Дәүләт думасының депутаты И. Ахтямов Киевта күп тора алмый, әлбәттә. Аңа тизрәк Петербургка кайтып китәргә кирәк. Киевта чагында ул тиешле урыннарга кереп, студентларның бу хәрәкәтен, артын-алдын уйламастан, балаларча кылган бер кечкенә шаянлык итеп күрсәтергә тырыша һәм губернатор исеменә, сеңелесе Гөлсемне акча бәрабәренә төрмәдән чыгаруны үтенеп гариза язып калдыра. Губернатордан җавап килмәгәч, ул Петербургтан Киев губернаторы исеменә, Тавр сараеның бланкысына язып, хат җибәрә. Бу хатта Ибнеәмин Ахтямовның тоны җитәрлек дәрәҗәдә мөстәкыйль һәм катгый. Соңгы юлларында ул, минем сеңелемне тизрәк төрмәдән чыгарыгыз, чыгармасагыз мин Эчке эшләр министрына да, полиция департаментына да шикаять итәчәкмен, соңыннан үзегезгә үпкәләрсез, дигән мәгънәне аңлатып, губернаторга янап та куя. Губернатор бу хатны алганының икенче көнендә үк Гөлсем Ахтямованы төрмәдән чыгаралар. Киев вакыйгасының башка членнары да шуңа охшаш юллар белән азат ителәләр.

Әгәр бу хәрәкәт Киевта башланмыйча, Казан, Уфа, Оренбург, Астрахань кебек татарлар күп булган шәһәрләрнең берсендә башланган булса, югары даирәләрдә сүзләре үтә торган кардәшләре-туганнары булуына карамастан, мөселман студентлары каты җәзага очраган булырлар иде. Ләкин Киевта мөселманнарның саны бар-

---

[1] Галимҗан Ибраһимов. Татар студентлары хәрәкәтеннән кечкенә бер хатирә. 1922 ел. Казан. 37 бит.



*Киев төрмәсеннән чыккач төшкән рәсем. Сулда — Хәлилулла Еникеев, уңда — Галимҗан Ибраһимов. 1913 ел.*

мак белән генә санарлык булганлыктан, мөселман студентлары арасында башланган бу хәрәкәт бик үк куркыныч саналмый. Галимҗан Ибраһимов бу турыда бик дөрес әйтә: «Киев жандармериясе өчен мөселман куркынычы социал-демократларның, социал-революционерларның идән астыннан алып барган эшләре, латышлар, украинлылар, еврейләрнең революцион хәрәкәтләре кебек коточыргыч түгел»,— ди ул үзенең «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә» дигән китабында.

Әмма, шулай булса да, Киев жандармериясе мөселман студентлары оешмасының иң эшчән һәм шикле кешеләреннән тизрәк котылырга — Киевтан ераграк куарга ниятли. Менә шуңа күрә жандармерия оешманың төп максаты — патша хөкүмәтенә каршы революцион көрәш ачу икәнлеген ачыктан-ачык раслап торган документларга да күз йома һәм, алдан үзе ясаган нәтиҗәләргә капма-каршы килеп, түбәндәге карарны чыгара: «...Мөселман яшьләренең бу җыелышында фәкать мөселман халкының экономикасын, мәдәният-мәгърифәтен күтәрү мәсьәләләре турында гына сүз алып барырга ниятләнүен, сәяси характерда булган мәсьәләләр программадан алып ташланганын, шулай ук ул җыелышның башта ук — председательлек итүче Талышинскийның котлау сүзеннән соң ук фаш ителүен һәм, ниһаять, җыелышта катнашучылар: Ахундова ике айга, ә башкалар исә берәр айга кулга алынганлыгын исәпкә алып, югарыда исемнәре саналган 16 кешегә карата эшне нәтиҗәсез калдырып, бу турыдагы язышуны туктатырга кирәк һәм, дәүләт куркынычсызлыгы турындагы положениегә нигезләнеп, бу язышуны Киев губернаторының карамагына җибәрергә кирәк дип санар идем. Полковник Шредель» [1].

Сүз уңаенда шуны әйтергә кирәк: төрмәдә Сона ханым гына түгел, башкалар да икешәр ай утырганнар. Әйтик, Галимҗан Ибраһимов төрмәгә 1913 елның 17 апрелендә утыртылып, шул елның 13 июнендә генә чыгарыла.

Полковник Шредель үзенең карарында, бу эшне төрмәгә утыртылган кешеләргә карата нәтиҗәсез калдырырга мөмкин дип санаса да, Галимҗан Ибраһимов белән Хәлилулла Еникеевне сәяси иминлектән барыбер махрүм итәләр. Төрмәдән чыгарылган көненнән башлап, Галимҗан Ибраһимов артыннан яшерен генә түгел, ачыктан-

---

[1] УССР ҮДТА. Фонд 274. Язма 1. Саклау берәмлеге 3151. Бүлек I. 222 бит.

ачык күзәтү башлана. Ул яшәгән җиреннән башка берәр шәһәргә китә башласа, шунда ук аның артыннан жандармерия телеграммалар сугып, хатлар язып хәбәр бирә. Аның һәр адымын күзәтеп торалар. һәр әйткән сүзен, әллә нинди мәгънәләр биреп, язып алып, жандармериягә җиткерәләр, үзе язган хатларны да, аңа килгән хатларны да башта ачып укыйлар [1]. Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов та Февраль революциясенә кадәр охранка алдында сәяси яктан ышанычсыз кеше булып саналып килгән.

Әлеге архив материалларыннан күргәнебезчә, Киев мөселман студентларының хәрәкәте жандармерияне зур тәшвишкә салган. Моңа бик мөһим сәбәпләр дә булган. Бу хәрәкәттә катнашучылар, башлангыч хәлдә генә булса да, иң зур максаты — «патшалык хакимиятенә каршы русларның һәм Россиядә яшәүче башка милләтләрнең революцион куәтләре белән бергә кушылып көрәшергә кирәк»лекне үз бурычлары итеп куйганнар.

Дөрес, хәрәкәткә катнашканнарның күпчелеге алларында торган бу көрәшнең соңгы нәтиҗәсе нинди булырга тиешлеген тиешенчә аңлап җиткермәгәннәр. Алар Россия мөселманнары арасында аң-белем тарату, уку-укыту эшләрен реформалаштыру кебек максатларны гына күздә тотканнар.

Шуны онытмаска кирәк: студент түгәрәкләрендә лекцияләр укып йөрүче грузин-большевик, бөтен гомерен революция юлына багышлаган мәңгелек студент — Агаш кебек кешеләр Киев мөселман студентларының оешмасына бик якын булганнар. Тора-бара бу кешеләр, әлбәттә, киевлы мөселман студентлары оешмасының членнарына тәэсир итәрләр иде, аларның билгеле бер өлешен аңлы революцион көрәш юлына алып керә белерләр, ә иске карашлы, тар милләтчелек рухы белән сугарылганнарын үз араларыннан иләп аерырлар иде. Кыскасы, бу кешеләр Киев мөселман студентларының оешмасына да, Галимҗан Ибраһимовның үзенә дә туры юлга чыгуда ярдәмләшкән булыр иделәр. Ләкин бу хәрәкәт, провокатор «Теоретик» (Хәнәфи Кайбышев)ның һәм провокатор «Житель»нең (Тәхфәтулла Мамлеевның) доносларь нәтиҗәсендә яралгы дәверендә үк харап ителгән. Үренте бирергә өлгергәнче үк охранканың тупас итекләре белән таптап ташланган. Шуның өчен дә Галимҗан Ибраһимов үзенең «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә» дигән китабында бик әрнеп түбәндәге сүзләрне язган: «Реакция вакытында бездә бердәнбер яшерен хәрәкәт булган Киев вакыйгасы — кәгазьләре, планнары, эшләргә дигән карарлары, эләккән протоколлары буенча бик зур мәсьәлә тудырырлык бер нәрсә иде. Ләкин эшләгән эше, тудырган нәтиҗәсе белән чыннан да бер миф, бер гөтен тавы иде».

---

[1] Бу турыда Н. Таҗетдиновның «Совет әдәбияты» журналында (1964 елгы 11 санның 122—126 битләре) басылган мәкаләсендә шактый тулы язылган, шунлыктан аны кабатлап тормыйм.— Автор.

# ӘХМӘТ ИБНЕ ФАЗЛАННЫҢ ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЛАРЫНА СӘЯХӘТЕ

*Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе тарих фәнендә аерым бер урын тота. Ул — Идел буе болгарларының элекке тормышлары, гадәт-йолалары, иҗтимагый-сәяси хәлләре турында сөйли торган бердәнбер тарихи чыганак.*

*Моңа кадәр укучы борынгы бабаларыбыз хакындагы бу әсәрне русча тәрҗемәләре аша гына белә иде. Һәвәскәр тарихчы Җәгъфәр ага Мамедов, күп вакыт һәм көч сарыф итеп, сәяхәтнамәне татар теленә тәрҗемә иткән. Әсәрнең үзен тәрҗемә итүдән тыш, ул текстта очрый торган даталарга, кеше исемнәренә һәм географик атамаларга аңлатмалар биргән, кереш мәкалә һәм йомгаклау сүзе язган.*

*Журналыбызның бу санында укучыларны тәрҗемәнең турыдан-туры болгарларга караган кайбер өлешләре белән таныштырабыз. Өзекләр кыскартып алынды.*

**Бу китап әл-Мәкътәдирнең [1] сакләбләр падишасына илче итеп җибәргән Мөхәммәт ибне-Сөләйман химаясендәге Әхмәт ибне Фазланның... төрек вә хәзәр, вә рус, вә сакләбләр, вә башкорт, вә башка халыклар илләрендә үзе күргәннәре: алардагы дин аермалары, аларның падишаларының әхвәлләре һәм күп эшләре хакында хәбәр бирәдер.**

**Әхмәт ибне Фазлан әйтте: сакләбләр падишасы балтуар [2] углы әл-Хәсәннең [3] дин кагыйдәләрен өйрәтергә, ислам шәригатен белдерергә, мәчет салырга, шәһәр һәм бөтен мәмләкәттә дингә өндәү өчен мөнбәр корырга һәм үзенә каршы дошман падишалардан саклану өчен кальга салырга илчеләр җибәрүне үтенеп язган хаты... Әл-Мөкътәдиргә тапшырылгач, бу үтенечләрне кабул иттеләр. Бу эштә арадашлык итүче Нәзир әл-Хәрәми [4] булды. Болгарга баргач, әл-Мөкътәдирнең хатын укырга, җибәрелгән бүләкләрен падишага тапшырырга һәм дин кагыйдәләрен өйрәтүче галимнәр вә мөгаллимнәр өстеннән карап бару өчен вәкил итеп мин билгеләндем. Дин кагыйдәләрен өйрәтүче галимнәргә һәм мөгаллимнәргә вазифа бирергә һәм әйтелеп узган крепостьны салу өчен акча билгеләнде... Падишага вә аның хатынына, вә борадәрләренә һәм аның якыннарына биреләчәк бүләкләрне һәм хат белән аның Нәзирдән сораткан дарулары миңа бирделәр.**

**Шулай итеп, өч йөз дә тугызынчы елда, сәфәр аеның унберенче төне узгач, пәнҗешәмбе көн [5] әс-Селүм шәһәреннән [6] юлга чыктык...**

**Сакләбләр падишасына барып җитәргә бер көн, бер төн барырлык юл калгач, безне каршы алырга, падиша үзе-**

---

[1] Әл-Мөкътәдир — 908—932 елларда яшәгән Багдад хәлифәсе.

[2] Балтуар — галим, белгеч мәгънәсендә.

[3] Дөресе Әлмәс булырга тиеш.

[4] Нәзир әл-Хәрәми — сарай вәзире.

[5] Миладп белән 921 елның 21 июненә туры килә.

[6] Багдад шәһәре.

нең кул астында булган дүрт падишаны, үзенең борадәрләрен һәм угылларын җибәрде. Алар безне икмәк, ит, тары ярмасы белән каршы алдылар һәм безнең белән бергә киттеләр. Аның янына барып җитәргә ике фәрсах[1] калгач, падиша үзе чыгып безне каршы алды һәм безне күргәч, атыннан төште һәм аллаһе тәгаләгә шөкрана кылып сәҗдәгә китте. Җиңендә аның дирһәмнәр бар иде. Ул дирһәмнәрне безнең өстебезгә чәчте.

Безнең анда килүебез өч йөз дә унынчы елда, мөхәррәм аеның унике көне үткәч, якшәмбе көн[2] иде. Һәм Журҗаннан аның иле арасындагы юл җитмеш көн булды. Безнең өчен коббәләр кордырды, һәм без ул коббәләргә урнаштык. Хәлифәнең хатын укыганда, ишетер өчен, илендә булган падишалар, түрәләр вә башка кешеләр җыелып беткәнгә кадәр, якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрне без үзебезнең коббәләребездә калдык. Пәнҗешәмбе көн, алар җыелып беткәч, без үзебез белән алып килгән байрагыбызны ачтык вә бүләк итеп алып килгән атыбызны иńр белән иярләдек һәм падишага сәвад[3] кием киерттек һәм башына сәвад чалма киерттек вә шуннан мин хәлифәнең Болгар падишасына язган хатын чыгардым һәм мин аңа: «Бу хатны укыганда утырып тору килешми»,— дип әйттем вә шуннан ул торды һәм шунда аның мәмләкәтендә булган күренекле кешеләр дә тордылар. Падиша бик зур гәүдәле, юан кеше иде. Шуннан соң мин хатны укый башладым һәм мин хатта хәлифәнең падишага яхшылыклар теләгән урынына җиткәч, әйттем: «Син дә, боларга җавап итеп, Әмирел-Мөэмининнгә яхшы теләкләр теләп җавап бир»,— дидем. Ул һәм аларның барысы да яхшы теләкләр теләп җавап бирделәр.

Тылмач мин укыган хатның хәрефен хәрефкә тәрҗемә итеп туктый алмый иде. Без хатны укып бетерү белән аларның «аллаһе экбәр» дигән тавышларыннан җир тетри иде. Моның соңында хәлифәнең вәзире Хәмид ибне әл-Габбасның[1] хатын укыдым. Падишаһ басып тора иде. Шуннан мин аны утырырга өндәдем һәм Нәзир әл-Хәрәминең хатын укыганда, ул инде утырып тора иде. Аның хатын укып бетергәч, падишаның якыннары аның өстенә күп дирһәмнәр чәчтеләр. Моның соңында аңа, вә аның хатынына бүләк итеп җибәргән хуш исле майларны, киемнәрне, энҗеләрне чыгарып берсе артыннан берсен бирен бетергәнче туктамый дәвам иттем. Аннары хәлифә бүләк итеп җибәргән хөрмәтле чапанны падиша хатынының иңенә шундагы кешеләр алдында киерттем. Болгардагы гадәт буенча, падишаның хатыны шунда утыра иде. Чапан киерткәч, хатыннар аның өстенә дирһәмнәр чәчтеләр. Без кайтып киттек.

Бер сәгать үтәр-үтмәстән безне чакырып өндәү килде, без аңа барып кергәндә, ул үзенең коббәсендә утыра иде. Аның уң ягында падишалар утырган, безгә сул ягына утырырга әмер итте. Угыллары алдына, аңгы очына утырганнар, вә ул үзе рум парчасы белән ябылган тәхеткә утырган иде. Падиша аш табыны китерергә кушты. Аны аңа китерделәр. Табында бары тик кыздырылган ит кенә бар иде. Падиша пычак белән аннан өч мәртәбә кисеп алып, берсе артыннан берсен ашап, аннан бер кисәк кисеп алып рәсүл Сәүсәнгә бирде. Итне алу белән аның алдына кечкенә өстәл китереп куйдылар. Һәм гадәтләре шулай икән — падиша ашамлыктан авыз итмичә торып, һичкем ашамлыкка кул сузмыйдыр. Аннары ул миңа да ит кисеп бирде һәм миңа да өстәл китереп куелды. Аның соңында уңда утырган падишага кисеп бирде һәм аңа да өстәл куелды. Аннары дүртенче падишага бирде һәм аңа да өстәл китерделәр. Аннан соң үзенең угылларына бирде һәм аларга да өстәлләр китерделәр. Шулай итеп, шунда булганнарның һәркайсының алдына өстәлләр китерелеп куелганчы бу эш дәвам итте һәм без һәркайсыбыз үзенең өстәленнән башка һичбер кем белән өстәл буенча, шәриктәш булмыйча вә башка өстәлдән бернәрсә алмыйча, алдыбызга куйганны ашадык. Ул үзе ашап бетергәч, һәркайсыбыз өстәлендә калган ашамлыкны үзе белән өенә алып кайтырга алды. Без ашап бетергәч, ул

[1] Фәрсах — юл үлчәве; төрле җирдә төрле озынлыкта йөри.
[2] Милади белән 922 елның 1[?] маена туры килә.
[3] Сәвад — хәлифәләр һәм вәзирләр кия торган кием.

[1] Хәмид ибне әл-Габбас — Мөкътәдирнең баш вәзире.

балдан ясалган эчемлек китерергә кушты. Бу эчемлекне алар балдан шул ук көндә һәм шул ук төндә ясап, сәҗү дип атыйлар. Шулай ул үзе бер бокал эчте һәм без эчтек. Моның соңра ул аягүрә басты һәм әйтте: «Бу — минем хуҗам Әмирел-Мөэминин өчен шатланып күцел ачуым. Алла аның гомерен озын итсен»,— диде, һәм шулай, ул аягүрә баскач, дүрт падиша һәм аның угыллары аягүрә бастылар. Ул өч мәртәбә шулай дип әйткәнче без дәхи шулай ук аягүрә басып тордык. Шуннан соң без кайтып киттек...

...Мин аның илендә шул кадәр гаҗәеп әйберләр күрдем ки, аларның күплекләрен мин санап бетерә алмыйм. Мәсәлән, барып җиткән көннең беренче кунган төнендә, әле кояш нурлары югалганчыга кадәр, гадәттәге намаз сәгате вакытында, күк йөзенең бик кык кызыллануын күрдем һәм мин һавада каты шау-шу һәм авазлар ишеттем. Шуннан мин башымны күтәрдем һәм менә миннән ерак түгел ут шикелле кызыл болыт күрдем, әнә ул тавышлар һәм авазлар шуннан киләләр икән, һәм менә анда атларга атланган кешеләргә охшаган, кулларына уклар, җәяләр, сөңгеләр һәм ялангач кылычлар тоткан шәүләләр күренә. Алар миңа әллә шулай ачык күренделәр, әллә шулай күренгән шикелле булып кына күренделәр. Һәм менә алар белән янәшә, тагын бер отряд пәйда булды, анда мин шулай ук ир кешеләр, атлар һәм кораллар күрдем, гаскәр гаскәргә ташланган шикелле, бу отряд теге отрядка һөҗүм итә башлады. Без исә моннан куркып ялвара башладык, ә болгарлар безнең кыланышларыбыздан көләләр һәм гаҗәпләнәләр иде.

Бер-беренә һөҗүм иткән отрядларга без озак карап тордык. Алар икесе дә бериникадәр вакыт бергә буталыштылар да тагын аерылыштылар. Шулай итеп, бу күренешләр төннең байтак вакытына кадәр дәвам итеп, аннары югалдылар. Бу турыда без падишадан сорадык. Ул исә атка атланып сугыша торган бу гаскәрләрнең динле вә динсез җеннәр икәнен һәм бер-берсе белән һәр төн сугышканнарын бабаларыннан ишеткәнен сөйләде. Дөньяга яратылганнан бирле аларның сугышмаган төннәре юк, диде.

Багдад әһалисеннән булган һәм кайчандыр падишаның тегүчесе булган бер кеше белән сөйләшеп утырырга мин үземнең коббәмә кердем, һәм без аның белән шул кадәр озак сөйләштек ки, без сөйләшкәндә корьәннең җиде өлешеннән кимрәген укып бетереп булыр иде. Сөйләшкәндә ясту азанын көтә идек. Менә азан да әйтте. Шулай, без коббәдән чыктык, ә таң инде атып килә иде. Шуннан мин мөәзингә әйттем: «Нәндәен азанны әйттең?» — дидем. Ул әйтте: «Иртәнге азанны»,— диде. Мин әйттем: «Ә нигә соңгы төнneке түгел?» — дидем. Ул әйтте: «Ясту намазын ахшам белән бергә укыйбыз»,— диде. Мин әйттем: «Ә төн?» — дидем. Ул әйтте: «Күргәнеңчә»,— диде. «Төн моннан да кыскарак иде, ләкин хәзер инде ул озая төште»,— диде. Һәм ул үзенең иртә намазына уяна алмыйча, йоклап калмыйм дип, куркып ай буена йокламаганын һәм ахшам намазын укыгач, кайнатырга казан куйсаң, иртә намазын укыганда, аның кайнап чыгарга өлгермәвен сөйләде.

Болгарда мин көннең бик озын булганын күрдем. Елның берникадәр өлешендә көн озын, төн кыска була. Аннары төн озын, көн кыска була. Һәм шулай икенче төн кергәч, мин коббәмнән чыгып, тышта күккә карап утырдым, һәм анда бик аз, унбишләп булыр дип уйлыйм, чәчелеп яткан йолдызлар күрдем. Вә менә төннең караңгылыгы шул кадәр аз иде ки, анда кеше кешене аткан ук барып җитәрлек ераклыкта күрә ала иде.

Мин айның күк уртасына барып җитмәгәнен күрдем, ләкин ул бер сәгать чамасына күкнең кырыена чыга да, аннары таң ата һәм ай югала.

Падиша миңа үз иленнән өч ай барырлык ераклыкта вису дип аталып йөри торган халык барлыгын сөйләде, аларда төн сәгатьтән ким була, диде.

Бу илдә мин кояш чыкканда җир, таулар һәм кеше күзенә күренә торган башка нәрсәләрнең кызыл төс алганын күрдем. Һәм кояш чыкканда зурлыгы белән болытк[illegible] охшап чыга вә күкнең иң югары урт[illegible]ына кадәр җиткәнче, аның кызыллыгы бетми.

Бу илнең халкы миңа кыш булганда төннең җәйге көн шикелле озаюын, ә көннең төн шикелле кыскаруын сөйләделәр. Дөресендә дә, бездән берәү, таң атканда, Идел дигән урынга барырга чыкса, ә аның арасы безнең үлчәү белән фәрсәхтән кимрәк, инде анда барып җиткәнче, бөтен күкне йолдызлар каплап,

төн була диләр. Һәм без бу илдән төннәр озая башламыйча, ә көннәр кыскармыйча торып китмәдек.

Болгарда мин эт улавын үзләре өчен бик яхшылыкка юраганнарын күрдем. Эт уласа, алар аңа шатланалар һәм: «Бу иркенчелеккә вә бәрәкәт елы буласына»,— дип әйтәләр.

Мин боларда еланнарның шул кадәр күплеген күрдем ки, кайчакта алар агач ботагында унарлап һәм күбрәк тә чорналып торалар. Андагы кешеләр аларны үтермиләр һәм алар да кешеләргә зыян китермиләр. Чыннан да, бер җирдә мин йөз терсәк озынлыгыннан артыграк озын агач күрдем. Ул ауган иде. Кәүсәсе гадәттән тыш юан. Мин туктап аңа карап торганда, ул кинәт селкенде. Бу мине куркытты. Мин аңа дикъкать белән карап тордым. Һәм менә аның өстендә юанлыгы вә озынлыгы белән шул агачка тиңләрлек бер елан уралган. Ул, мине күрү белән, агачтан төште дә агачлар арасына кереп югалды. Мин исә куркып падиша һәм аның янында булган кешеләргә килеп бу турыда сөйләдем. Алар исә моңа әһәмият бирмәделәр. Ул: «Борчылма! Ул сиңа зыян тидермәс»,— дип әйтте.

Шулай бер вакыт без падиша белән бер урында туктадык. Мин, минем юлдашларым Тикин, Сәүсен һәм Барс вә падиша кешеләреннән берәү агачлар арасына барып кердек. Һәм менә падиша үсеп утырган кечкенә сабаклы, яшел, юанлыгы белән орчыкка охшаган, тармакларының очында җиргә яткан киң яфраклы үсемлек күрсәтте. Яфраклары арасында җиләкләре бар иде. Без аны ашап ләззәт алгач, туктаусыз эзләп йөрдек. Моны кем ашаса да, шиксез, имлисе гранаты дип белер иде.

Мин аларда үзләренең күп яшеллекләре белән бигрәк тә аракы серкәсе ачысына охшаган, ачылыгы белән аерыла торган алмалар күрдем. Аларны кызлар ашап симерәләр.

Бу илдә мин чикләвек агачларыннан да күп нәрсә күрмәдем. Дөресендә дә исә, мин һәркайсы кырык фәрсах озынлыгында һәм шуның киңлегендә чикләвек агачы урманнары күрдем.

Аларда мин, ниһаять, озын, белмим нәрсәдер, яфраксыз, очлары хөрмә агачы төсле, очына җыелган нәзек, бер-беренә кушылган яфраклы агач күрдем. Алар, бу агачның билгеле бер урыныннан кәүсәсен тишеп, шул тишек астына савыт куялар. Тишектән савытка балдан да татлы сыекча ага. Әгәр бу сыекчаны кеше күп эчсә, ул аны хәмер шикелле һәм катырак та исертә.

Аларның азыклары тары һәм хайван ите. Ләкин аларда арпа һәм бодай да күп була. Иген уңышы игенченең үзенә була. Падишаның анда өлеше юк. Тик алар ел саен йорт башыннан падишага бер кеш тиресе түлиләр.

Баскынлыкка җибәрелгән гаскәр табыш белән кайтса, падишага моннан өлеш чыга, туй яки зыяфәт булса, мәҗлеснең зурлыгына карап, эчемлектән падишага бүләк бирәләр. Ашлыкны саклар өчен махсус урын булмаганлыктан, аны базга салалар, күп вакыт үтми, ашлык дымланып бозыла башлый, шул бозылган бодайдан падишага тиешле өлешен түлиләр.

Аларда зәйтүн мае, симсим һәм хайван майлары да юк. Аларның тотканнары гел балык мае, шунлыктан алар исле булалар.

Алар арпадан сыек аш пешерәләр. Бу ашны кызлар һәм яшьләр ашый. Ә кайсы чакта аны ит белән дә пешерәләр, аның итен хуҗалар ашыйлар, арпасын кызларга ашаталар. Әгәр бу ит кәҗә тәкәсенеке булса, ул чакта итен дә кызларга ашаталар.

Аларның барысы да башларына кәләнсүә бүрек киялэр. Падиша атка атланып йөргәндә, үзе генә була, башкалардан берәү дә булмый. Һәм шулай, базардан ул узса, һичкем утырып калмый, һәркем башыннан бүреген салып, култыгы астына кыстыра. Узып киткәч, янәдән башларына киялэр. Һәм нәкъ шулай һәркем падиша хозурына кергәндә олысы, кечесе хәтта үз балалары вә борадәрләре, аны күрү белән, бүрекләрен салып култык асларына кыстыралар. Аннары падишага таба башлары белән ишарә итеп чүгәләр һәм янәдән торып, падиша утырырга әмер кылганчы шулай торалар. Падиша утырырга әмер кылгач, һәркем утырганда тез чүгеп утыра вә үзенең бүреген аның яныннан чыгып киткәнче күрсәтми, чыккач кына башына кия.

Аларның барысы да коббәләрдә торалар, бары тик шундаен аерма белән ки, падишаның йорты мең һәм артыграк җан сыйдыра, йортының уртасында рум парчасы белән ябылган тәхет тора.

Алардагы йолалардан берсе шундый: әгәр бер ир кеше углының баласы туса, гадәтләре буенча, баланы атасыннан элек бабасы ала һәм әйтә: «Моны үсеп зурайганчыга кадәр тәрбия итәргә атасына караганда минем хакым зуррак»,— ди.

Алардан бер кеше үлсә, аңардан калган малына балаларыннан әүвәл аның борадәре варис була. Мондый варислык безнең динебездә рөхсәт ителмәгәнен падишага белдердем вә варис булудагы хокукларны аңа аңлаганчы өйрәттем.

Болгар иленде́ге кадәр күп яшен яшьнәүне һичбер җирдә күрмәдем. Әгәр йортны яшен сукса, алар аның янына бармыйлар вә эчендә булган кешене һәм мал-мөлкәтне коткармыйлар вә барысын да, вакыт черетеп бетергәнче, шул килеш калдыралар һәм: «Бу йорт ачуга дучар булганнарныкы»,— диләр.

Әгәр болар арасыннан бер ир кеше ниндидер уй белән башка бер кешене үтерсә, алар аны җәзалап үтерәләр. Әгәр исә ул ялгыш үтергән булса, аңа хәләнҗә агачыннан сандык ясыйлар вә моның эченә аны салып, янына өч кабартма һәм савыт белән су куеп өстеннән кадаклыйлар. Аннары, дөя иярене таяклары шикелле итеп, җиргә өч багана утырталар һәм араларына аны асып куялар һәм әйтәләр: «Яңгыр һәм кояшның эшенә дучар булсын өчен, без аны җир белән күк арасына урнаштырдык, бәлки, алла аңа мәрхәмәт кылыр әле»,— диләр. Һәм ул шунда һәлак булып, калдыклары, заман узу белән, җил очыртып бетергәнче, асып куйган килеш кала.

Әгәр алар бик җитез вә артык хәрәкәт иясе вә һәр эштә белемле кешене күрсәләр, бу безнең раббебезгә хезмәт итәргә бик лаек диләр һәм аны тотып муеныннан бау белән агачка асып куялар. Ул шунда череп кисәкләргә таралып бетә. Дәресендә исә, падишаның тылмачы бу турыда миңа сөйләде: Бер һиндстанлы кеше бу илгә килеп, кыска гына вакытка падишаның хезмәтендә калган вә ул кеше бик җитез вә белемле булган. Менә сәүдәгәрләрдән бер төркемнең сәфәргә чыгуларын белеп, шулар белән бергә сәфәргә чыгарга падишадан рөхсәт сораган. Ул исә аңа рөхсәт бирмәгән.

Шуннан, теге кеше сүзендә торып, китәргә сорагач, ул аңа рөхсәт биргән һәм ул алар белән корабка утырып киткән, һәм менә алар бу кешенең сизгер вә җитез икәнен күргәч, үзара сөйләшеп әйткәннәр: «Бу кеше безнең раббебезгә хезмәт итәргә бездән артык, моны аның хезмәтенә җибәрик»,— дигәннәр. Аларның юллары урман яныннан үткән һәм, шулай итеп, алар аны корабтан чыгарып, муенына бау салып, биек агачның башына асып куйганнар һәм үз юлларына киткәннәр.

Әгәр алардан берәүсе, юлда барганда тышка чыгасы килеп, кораллары үзендә булган хәлдә, аларны салмыйча утырса, аның коралларын, киемнәрен һәм башка нәрсәләрен алалар. Бу — алардагы гадәт. Кем дә кем коралларын салып, читкә куеп утырса, ул чакта аңа тимиләр.

Ирләр һәм хатыннар су коенырга елгага бергә төшәләр һәм, бер-берсеннән тәннәрен яшермичә, ялангач килеш коеналар һәм һичбер төрле юл белән дә ирлек-хатынлык эшен кылмыйлар, ә кем дә кем алардан берәүсе зина кылса, аның кем булганына да карамыйча, дүрт казык кагып, шул казыкларга ике кулын, ике аягын бәйләп, муеныннан буйлыйга балта белән чабып аерып төшерәләр. Зина кылган хатын белән дә шул рәвешчә мөгамәлә итәләр. Аннары тәненең аерым кисәкләрен агачка элеп куялар. Мин хатыннар су коенганда тәннәрен ирләрдән яшереп коенырга тиешлеген никадәр әйтсәм дә, ләкин моңа ирешә алмадым.

Һәм алар каракны да шулай ук зина кылган кешене үтергән шикелле итеп үтерәләр.

Аларның урманнарындагы умарта ояларында бал күп була. Алар аның кайда икәнен беләләр һәм бал җыярга баралар. Кайсы чакта исә дошман булган кешеләр аларга һөҗүм итеп аларны үтерәләр.

Аларда сәүдәгәрләр күп, алар төреләр җиренә барып сарыклар алып кайталар һәм Вису дигән илгә барып кешләр һәм кара төлкеләр алып кайталар. Без аларда бер җирдә торучы ире вә хатыны биш меңләп булган халыклар күрдек. Болар барысы да исламны кабул иткәннәр инде. Аларның барысын да бәрәнҗәрләр дигән мәшһүр исем белән атыйлар. Аларга агачтан мәчет салганнар. Шунда алар намаз укыйлар, ләкин кыйраәт белмиләр. Аларның бер төркеменә намазны нинди сүзләр әйтеп укырга өйрәттем. Дәресендә дә, бер мәртәбә

минем җитәкчелегем астында Талут дигән кеше ислам динен кабул итте. Мин аны Габдулла дип атадым. Ул исә әйтте: «Мине Мөхәммәт дип үз исемең белән атавыңны телим»,— диде. Мин моны эшләдем. Һәм аның хатыны, аның анасы һәм аның балалары исламны кабул иттеләр һәм аларның барысын да Мөхәммәт исеме белән атый башладылар. Мин аларга әлхәмделилләһ вә коль һуаллаһ сүрәләрен өйрәттем. Һәм бу ике сүрәне укырга өйрәнгәч, аның шатлыгы сакләбләргә үзенең падиша булуыннан да зур булды.

Без падиша янына барганда, ул Холҗә дигән су буена туктаган иде. Ә бу — өч күл. Боларның икесе зур, ә берсе кечкенә, ләкин боларның берсенең дә төбенә җитәрлек түгел. Бу урын белән хәзәрләр иленә таба ага торган аларның Әтил дигән бик зур елгаларының арасы фәрсәх чамасында. Бу елга буенда уңайлы вакытта була торган зур сәүдә базары урыны бар. Анда бик кыйммәтле нәрсәләр саталар.

Кайчандыр Тикин (Болгар) падишасының илендә бер бик зур гәүдәле ир кеше барлыгын миңа сөйләгән иде. Һәм шулай, бу илгә килгәч, аның турында мин падишадан сорадым. Ул миңа әйтте: «Әйе, элек ул кеше бездә бар иде, ләкин ул үлде инде. Ул бу җирнең кешеләреннән түгел һәм шулай ук гади кешеләрдән дә түгел иде. Аның тарихы шундый: сәүдәгәрләрдән булган берничә кеше гадәттә чыккан шикелле, Әтил елгасына чыгалар, ә елга күтәрелеп, суы ярларыннан ташып чыккан була.

Бу көнне мин аңыма килеп тә өлгермәдем, минем яныма сәүдәгәрләр төркеме килеп тә җитте һәм миңа әйттеләр: «И падиша! Судан бер кеше йөзеп чыкты, әгәр ул безгә якын халыклардан булса, безгә бу җирләрдә торырга мөмкинлек булмас һәм безгә моннан икенче җиргә күчеп китүдән башка чара калмас»,— диделәр. Шуннан соң мин, атка атланып, елгага җиткәнче алар белән бардым. Менә минем алдымда шул кеше, менә мин күрәм: аның озынлыгы минем терсәкләрем белән үлчәгәндә унике терсәк булыр. Аның башы иң зур казанның зурлыгы кадәрле, борыны чиректән артык, ике күзе гаять зур, бармакларының һәркайсы чиректән артык. Аның күренеше мине теге кешеләр төсле куркуга салды. Без аның белән сөйләшә башладык, ә ул безнең белән сөйләшми, тик карап кына тора иде. Мин аны үзебезнең тора торган җиребезгә кайтарттым вә вису халыкларына, ә алар бездән өч ай барырлык юл ераклыгында торалар, аның турында сорап хат яздым.

Алар исә, миңа хәбәр итеп, бу кеше яэҗүҗ һәм мәэҗүҗләрдән дип яздылар. Алар бездән өч ай барырлык юл ераклыгында торалар. Алар белән безне диңгез аерып тора, чөнки алар диңгезнең безгә каршы ярында яшиләр. Алар кыргый хайваннар шикелле ялангач, ялан аяк, бер-берсе белән хайваннар шикелле якынлык итешәләр. Гыйззе вә җәл[1] алар өчен һәр көнне диңгездән бер балык чыгара һәм аларның һәркайсы килеп янындагы пычак белән үзенә һәм гаиләсенә күпме кирәк, шул кадәр аңардан кисеп ала. Әгәр дә исә ул үзенә һәм гаиләсенә җитәрлек кадәрдән артык алса, ул чакта аның эче авырта һәм шулай ук гаиләсенең дә эче авырта. Кайбер чакта ул үлеп тә куя, ул чагында барысы да үләләр. Кайчан исә алар балыктан үзләренә кирәк кадәр генә алалар икән, ул балык әйләнә дә диңгезгә төшеп китә. Һәм шулай итеп алар көн вә төн шул рәвешчә тереклек итәләр.

Ә безнең белән алар арасында бер яктан диңгез, икенче яктан әйләндереп алган таулар һәм киртә вә шулай ук гадәттә алар чыга торган капка бар. Ә кайчак исә гыйззе вә җәл аларны кешеләр яши торган җиргә чыгарырга теләсә, ул аларга киртәне ача һәм диңгез суы җиргә сеңә, алар өчен балык килүе дә туктый.

Шуннан, мин бу кеше турында аннан сорадым, һәм ул әйтте: «Ул берничә вакыт минем янымда торган иде һәм шулай була торган иде: аңа бала караса, ул бала үлә, корсаклы хатын караса, ул хатын йөген төшерә иде. Һәм болай да булгалады: әгәр ул бер кешене эләктереп алса, аны һич тә җибәрми, ике кулы белән үтергәнче кыса иде. Моны күргәч, мин аны бер биек агачка асып куйдым, ул шунда үлде. Әгәр дә син аның сөякләрен һәм башын күрәсең килсә, синең белән барып, аны сиңа күрсәтәм»,— диде. Мин әйттем: «Валлаһи, минем аны бик күрәсем килә»,— дидем.

Һәм шуннан ул атка атланып минем белән биек агачлар үскән зур урманга барды. Ул мине зур бер агач янына ки-

[1] Тәңре мәгънәсендә.

терде, аның төбендә тегенең башы ята. Мин аның кисмәк кадәр башын күрдем, менә аның кабыргалары иң зур кипкән пальма агачы ботакларына охшаган, шуның шикелле юан ике сыйрак вә терсәк сөякләре. Мин исә гаҗәпкә калдым да кайтым киттем.

Падиша, Холҗә дигән су буеннан Җаушир дигән елга буена күчте. Анда ике ай торгач, күчмәкче булды вә суаз дигән халыкка үзе белән бергә күчәргә кушты. Алар карыштылар һәм икегә бүленделәр. Бер груһы электә аларга баш булып маташкан Вирг исемле бозык кешегә ияргәләр. Падиша аларга әйтте: «Алла гыйззе вә җәл миңа ислам динен һәм Әмирел-Мөэминин дәүләтен бүләк итте, мин аның колы, карышканга кылыч белән барырмын»,— диде. Икенче груһ Эскәл кабиләсе башлыгы белән булдылар, ул ислам динендә түгел иде. Шулай да падишага буйсынды. Падиша аларга үзенең әмерен җибәргәч, курыктылар һәм аның белән бергә Җаушир елгасы буена күчтеләр, ә бу елга киңлеккә зур түгел, биш терсәк киңлегендә, ә суы аның кендеккә кадәр һәм урыны белән иңбашына кадәр җитә, ә күбрәк өлешенең тирәнлеге кеше биеклеге. Аның әйләнәсендә агачлар, аларның күбрәге хәзәнке һәм башка агачлар, менә аннан ерак түгел киң кыр, ул кырда дөядән кечерәк, үгездән зуррак хайван булганын сөйлиләр. Башы аның дөя башы төсле, койрыгы үгезнеке, ә гәүдәсе качырныкы шикелле, тояклары үгез тоякларына охшашлы. Аның башының уртасында бер юан түгәрәк мөгезе бар, ул югарыга таба күтәрелгән саен нәзегәя барып, очы сөңге очы кебек була. Аларның мөгезләре, хайванның зурлыгына карап, биш терсәктән алып, өч терсәк озынлыгыннан озынрак яисә кыскарак була. Ул бик яхшы яшел агач яфраклары белән туена. Атка атланган кешене күрсә, аңа таба бара һәм әгәр ул кешенең астында аргымак йөгерек ат булса, ул ат тиз чабуы белән генә аннан котыла. Әгәр ул атланган кешене куып җитсә, аны үзенең мөгезе белән элэктереп ат өстеннән ала һәм һавага чөя вә яңадан үзенең мөгезе белән каршы тотып ала. Шулай итеп аны үтергәнче туктамый, ә атка бернәрсә белән дә, берни рәвештә дә һәм берничек тә зыян гидерми. Алар аны үтерергә кырлардан һәм урманнардан күзәтеп йөриләр. Бу шулай эшләнә: болардан берничә кеше җыелалар да агуланган уклар белән бик агач башларына менәләр. Ул хайван түбәндә агачлар арасында күренү белән, аңа җәрәхәтләнгәнче һәм үтергәнче аталар.

Чынында исә мин падишада Ямәндәге шикелле бизәп эшләнгән өч зур аш табагы күрдем. Падиша аларны шул хайванның мөгезе төбеннән эшләнгән икәнен әйтте. Бу илдә торучыларның кайберләре моны кәркәдән [1] диләр.

Алар арасында мин кызыл йөзле кешене күрмәдем, ләкин аларның күбесе авырулар. Бу илдә күп вакытта алар чәнчү алу авыруыннан [2] үләләр. Чыннан да, бу авыру хәтта аларның имчәк балаларында да була.

Һәм әгәр болгарларда мөселман кеше яисә хавариземле хатын үлсә, аны алар мөселманча юалар, аннары арбага салып, флаг белән күмә торган урынга җиткәнче алып баралар. Күмә торган урынга җиткәч, аны арбадан алып җиргә куялар. Аннары әйләнәсеннән сызык сызып, аны кырыйга алып куялар. Моның соңында бу сызык эченә кабер казып вә эчендә аңа ләхет ясап аны күмәләр. Һәм шушы рәвештә башка үлгән кешеләре белән дә шулай итәләр. Хатыннар мәет өстендә еламыйлар. Ирләр аның үлгән көнендә ишегә төбенә килеп мөмкин кадәр әшәке тавыш белән кычкырып елыйлар. Бу елаучылар эшсез кешеләр булалар. Аларның елавы беткәч, коллар үзләре белән каештан үргән камчылар алып килеп һәм өзлексез елап үзләренең җан җирләрен вә тәннәренең бүлтәеп торган җирләрен камчы белән сугып, хәтта кара янып чыкканчы кыйныйлар. Һәм болар үлгән кешенең йорты ишегенә флаг кадап куялар. Алар үлгән кешенең коралларын кабере әйләнәсенә илтеп куеп, ике ел елап йөриләр. Кайчан исә ике ел уза, флагны алып, чәчләренең бер өлешен йолкыйлар вә үлгән кешенең туганнары гореф буенча дога кылырга мәҗлес ясыйлар. Шуның белән кайгы кичерү халәте беткәне мәгълүм була. Һәм әгәр дә аның тол калган хатыны булса, ул шуннан соң гына кияүгә чыга. Бу әгәр үлгән кеше башлыклардан булса гына эшләнә. Гади

[1] Кәркәдән — мөгезборын.
[2] Бизгәк авыруы булса кирәк.

кешеләрдән булса ул чакта горефләрдән кайсыберләрен генә эшлиләр.

Сакләбләр падишасының өстенә үзенең мәмләкәтендәге һәр йорт башыннан берәр кеш тиресе хәзәрләр падишасына салым итеп түләү йөкләнгән. Әгәр хәзәрләр иленнән Болгар иленә караб килсә, падиша атка атланып карабка бара һәм караб эчендә нәрсә бар, шуны санап уннан бер өлешен үзенә гошер итеп ала. Әгәр руслар яисә башка женес кәвемнәрдән булган кешеләр коллар белән килсәләр, ул чакта исә аларның ун баштан бер башын сайлап үзенә гошер итеп ала.

Сакләбләр (ягъни болгар) падишасының углы хәзәр падишасында рәһен (заложник) булып тора. Хәзәр падишасына сакләбләр падишасы кызының матурлыгы ишетелгәч, ул аны үзенә хатынлыкка сорап кеше җибәргән, болгар падишасы моңа риза булмыйча каршы килгән һәм бу эшне кире каккан. Шуннан теге, үзенең яһүд булуына вә кызның мөселман булуына карамыйча, гаскәр җибәреп кызны көч белән алган. Шулай ул кыз аның янында торып үлгән. Шуннан ул падишаһның икенче кызын сорап җибәргән. Бу хәбәр падишага ишетелү белән ул икенче кызын да көчләп алуларыннан куркып, үзенең кул астындагы Әскел дигән кабиләнең башлыгына кызын алдан хатынлыкка биреп куя. Һәм дөресендә дә сакләбләр падишасы хәзәр падишасыннан куркуыннан хәлифәгә хат язып, сакланыр өчен кальга салып бирүен сорарга мәҗбүр булган.

Бер мәртәбә мин аннан сорадым һәм аңа әйттем: «Синең мәмләкәтең бик зур, мал-мөлкәтең һәм табышың күп була торып, ни өчен син солтаннан крепостьны аның акчасына салып бирүен сорадың?» — дидем. Ул исә әйтте: «Мин, ислам дәүләтенең малы хәләл юл белән җыелганына күрә, бәхет китерер дип уйлаган идем. Әгәр дә мин кальганы үз акчама салырга уйласам, моңа минем көмешем яисә алтыным, әлбәттә, җитәрлек, бу эштә миңа бертөрле дә читенлекләр булмас иде, дөресендә исә, бары тик мин Әмирел-Мөэмининнең малы мөбарәк булыр дип, аннан сораган идем», — диде...

≈≈≈≈≈

Фатих Урманчиев

# ЛЕГЕНДАЛАР ЭЗЕННӘН

*(Бәет жанрының туу һәм формалашу тарихына карата)*

Еллар буе туплана һәм матбугатта басыла торган материалларга таянып, шикләнми әйтергә була: XV йөзнең икенче, XVI йөзнең беренче яртысыннан алып XX йөзнең урталарына кадәр бәет Идел буе татарларының поэтик иҗатында төп һәм иң нык таралган жанр булган. Шуның белән бергә, бәет шактый вакыт, һәрхәлдә, берничә гасыр элегрәк барлыкка килгән һәм халык иҗатының мөстәкыйль бер жанрына әйләнгән, дип уйларга нигез бар. Бәет тарихын өйрәнүче галимнәр бу мәсьәләдә күречекле татар тарихчысы Ш. Мәрҗани хезмәтләренә таяналар. Ул Идел буе Болгар иле мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән дәвердә анда болгар батырлары турында бәетләр һәм Нәүрүз бәетләре киң таралган булган, ди[1]. Аның шул сүзләреннән чыгып, «Борынгы татар әдәбияты»н төзүчеләр «Нәүрүз бәете»н хәтта VIII—XIII йөзләргә караган әсәрләр арасына кертүннәр (51—63 битләр). Әмма XIX йөзнең ахырларында гына басылып чыккан «Нәүрүз бәете»нең борынгы татар әдәбиятына да, Болгар дәверендәге фольклорга да мөнәсәбәте юк[2]. Күп кенә галимнәр дөрес күрсәткәнчә, Ш. Мәрҗани телгә алган борынгы бәетләр безнең дәвергәчә килеп җитә алмаган.

Әмма ни генә булмасын, халык авыз иҗатының мөстәкыйль бер жанры буларак, бәет Болгар чорында ук барлыкка килә һәм формалаша, дип фараз кылырга барлык нигезләр бар.

Шулай да, нинди дәрәҗәдә халкыбыз тарихының Болгар дәверенә бәйле конкрет әсәрләрне тикшерергә керешкәнче, бәетләрнең борынгылыкта туу ихтималын фәнни яктан исбатларга тырышып карыйк. Моны кайбер мөһим мәгълүматларга, барыннан да элек, бәетнең үз үзенчәлекләренә таянып эшләргә мөмкин. Фәндә күп тапкырлар билгеләп үтелгәнчә, бәет фольклор белән язма поэзиягә тоташкан урында туа, күп кенә бәетләрнең тел һәм стиль үзенчәлекләре нәкъ менә шул хакта сөйли. Күрәсең, шактый үсешкә ирешкән язма культурасы булган халыкларда фольклор белән язма әдәбият арасында тора торган жанрлар туарга мөмкин икән. Билгеле, моның өчен бер язма культура булу гына җитми. Аның халык арасында шактый киң таралган булуы да зарур. Борынгы Болгарда эш нәкъ шулай тора да. X йөздә яшәгән гарәп язучысы ибне-Даста бу хакта түбәндәгеләрне яза: «Аларның (болгарларның — Ф. У.) күбесе ислам дине тота һәм авылларында, мәзиннәре һәм имамнары белән, мәчетләре һәм башлангыч мәктәпләре

---

[1] Г. Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Казан. 1923 ел. 144 һәм 289 битләр; Х. Ярми. Бәетләр. Казан. 1960 ел. 24 бит һ. б.

[2] Карагыз: Ф. Урманчиев. Халыкның күңел көзгесе. «Казан утлары» журналы. 1971 ел. 6 сан. 165 бит.

бар»[1]. Болгар дәүләтенең югары мәдәниятле ил булуы XIX йөзнең беренче яртысында ук инде бәхәссез хакыйкать саналган: «Идел буе болгарлары хәзерге Россиядә яшәүчеләрнең барысыннан да элегрәк мәгърифәт җимеше татыйлар. Инде X йөздә, мөселманлыкны кабул иткәндә ук, алар гарәпчә куфи язулы үз акчаларын сугалар... Алар славяннар, гарәпләр һәм Константинополь белән эшлекле сәүдә алып баралар»[2]. Борынгы Болгарда әдәбиятның шактый югары үсешкә ирешкән булуы, анда күп кенә галимнәр яшәве шулай ук шик уятмый. Халык иҗаты белән язма әдәбият очрашкан урында торган бәетләр, күрәсең, нәкъ менә шундый шартларда туганнардыр да. Шуларның һәммәсен истә тотып фикер йөртсәк, Ш. Мәрҗанинең алда китерелгән фикерләре шактый нигезле булуын күрербез. Бу шулай ук Әминә Халит китергән фактлар белән дә раслана. «...Суык Су дигән авылдан «Шәһри Болгар»га (Болгар шәһәре хәрабәләренә) баручы бер төркем карчыклар Тәтеш районы, Кече Тархан авылына кунарга туктап, туктаган өйләрендә «Шәһри Болгар газыйлары» дигән бәетне әйткәннәр иде»[3],— дип яза ул.

Төрле галимнәрнең бәетләрнең кайчан туып, аерым бер жанр буларак, кайчан халык арасына урнашып китүләре турындагы фикерләрен өйрәнгәндә, татар халык иҗаты буенча зур белгеч Нәкый ага Исәнбәт карашларын да читләтеп узып булмый. Дөрес, аның гыйльми хезмәтләрендә бу хакта нинди дә булса мәгълүмат китерелми. Ләкин күренекле язучы һәм шагыйрьнең әдәби әсәрләрендәге фикерләре кызыклы. Н. Исәнбәтнең «Әбугалисина» исемле драматик поэмасы Болгар дәүләте чорындагы вакыйгаларга багышланган. Бу поэмада бәет әйтүче карчык образы бар. «Әбугалисина»—әдәби әсәр. Әмма аның авторы—гомер буе халык иҗатын җыйган, татар халык иҗаты буенча күп санлы тирән хезмәтләр язып, дистәләрчә фольклор җыентыклары чыгарган күренекле галим. Н. Исәнбәт фольклор жанрларының тарихын һәм теориясен, аларның яшәү формаларын искиткеч шәп белә. Шуңа күрә галимнең әдәби әсәрләрендә очрый торган карашларына да игътибар белән карарга кирәк. Инде «Әбүгалисина» поэмасына кертелгән бәет әйтү күренешенә килгәндә, шуны әйтергә кирәк: Н. Исәнбәт жанрның тууын Болгар дәүләте чорына нисбәт итә.

Аннан соң бәет жанрының борынгылыгы турында аның композициясендәге кайбер специфик элементлар да сөйли. Мәсәлән, «бисмиллаһи» кебек дини сүзләр яки әсәрдә тасвирланган вакыйганың вакытын күрсәтү белән башлап китү күпчелек бәетләрнең бер уртак үзенчәлеге булып тора. Мондый башламнарның беренчесе дә һәм соңгысы да халыкның борынгы йолалары белән бәйләнгән булса кирәк. Беренче очракта ул — дини доганың башы, икенче очракта мөһим тарихи вакыйганың яки аерым кеше тормышында булып узган хәлнең көнен, аен, һич югы, елын халык хәтерендә мәңгеләштереп калдыру. Безнең, барыннан да бигрәк, нәкъ менә соңгысына — вакыйганың вакытын күрсәтү алымы белән башланып китә торган бәетләргә тукталасыбыз килә. Күпчелек бәетләрдә фаҗигале хәлләр (илгә дошман басып керүе, крестьян сугышларының җиңелүе, берәр кешенең фаҗигале үлеме һ. б.) турында сөйләнә:

Тарих мең дә сигез йөз дә,
Җәй узубан һәм көзендә...
(«Мәһди бай бәете»)

Тарих мең дә сигез йөз дә,
Алтмыш өченче ел эчендә...
(«Солдат бәетләре»)

Шундый ук яки шуңа охшаганрак башламнарны яки шигъри формада мәрхүмнең вафат булган вакытын хәбәр итүне без Болгар яки Казан ханлыгы чорына караган

---

[1] Д. А. Хвольсон. Известия о хазарах, буртасах, болгарах... Спб. Рус телендә. 1869 ел. 23 бит.
[2] Указатель Казани на 1841 год. Рус телендә. 9 бит.
[3] Ә. Халит. Бәетләр тикшерү тәҗрибәсеннән. «Совет әдәбияты» журналы. 1934 ел. 6 сан. 56 бит.

кайбер ташларында да күп очратабыз: «Тарих тугыз йөз кырык тугызда, мөхәррәм аеның сүвәлендә ирде», яки «Тарих тугыз йөз илле икедә ирде кем Чура улы...» [1].

Бәетләрдә киң таралган типик башламнарның кабер ташларындагы язулар белән хәрефкә-хәреф тәңгәл килүе мондый гыйбарәләр ерак үткәндә, ихтимал, кабер ташларына язу өчен шигырь чыгару практикасы нигезендә формалашканнардыр, дип уйларга этәрә. Ахырдан, күрәсең, алар бәетләргә күчкәннәрдер. Әгәр кабер ташлары үзенчәлекле матди һәйкәл булса, бәетләр һәм халык арасында киң таралган мөнәҗәтләр бабаларыбызның шигъри һәйкәле булган. Аларның һәр икесе үлгән яки азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәштә һәлак булган кешенең истәлеген мәңгеләштерергә хезмәт итә. Кабер ташларындагы язмаларны бәетләрдәге традицион башламнар белән янәшә куеп карау, чагыштыру өчен аларның формалары гына түгел, бәлки эчтәлеге, төп функциясе белән бәйләнешле яңгырашы да мөһим җирлек булып тора. Кабер ташындагы язма үлем, күпчелек очракта бер кешенең үлеме турында сөйли. Күп кенә бәетләрдә дә без шул ук хәлне күрәбез. Тик шуны истән чыгармаска кирәк, бәетләр, бигрәк тә аларның халыклар һәм илләр язмышы турында сөйли торган тарихи пландагылары, кабер ташларындагы язмалар белән чагыштырганда, киңрәк тарихи-әдәби әһәмияткә ия. Нинди эпитафия (ул хәтта туганнар каберлегенә язылган булса да) дөньяга ил һәм халыклар тормышындагы фаҗигале хәлләр турында сөйли ала! Бу хакта сөйләү өчен фикер һәм образларның эпик киңлеге кирәк. Менә шуңа күрә дә, бәет композициясендәге бары бер элементны бөтен бер кабер ташындагы язу белән чагыштырганда, моның башта мөнәҗәтләргә, аннан, ихтимал, бәетләргә күчкән бер деталь генә икәнен истән чыгармаска кирәк. Ләкин ул бәетләрнең бик борынгы чорда барлыкка килүен раслый торган деталь!

Бәетләрнең барлыкка килү дәвере турында фикер йөрткәндә, аларның бик күптән, Болгар дәүләте чорында ук формалаша башлавы турында сөйли торган тагын ике нәрсәне аерып күрсәтергә кирәк. Беренчесе һәм, безнең уебызча, иң мөһиме шул: XVI йөздән безнең чорга жанрның аеруча борынгы үрнәкләре килеп җиткән. Үзләренең форма һәм эчтәлекләре, эстетик сыйфатлары ягыннан бу әсәрләр бәетләрнең гомуми үзенчәлекләрен шактый тулы чагылдыралар. Башкача әйткәндә, алар жанрның тәмам формалашып җиткән үрнәкләре булып торалар. Мондый камил бәетләр жанр әле формалашкан гына чорда туа алмаслар иде, билгеле. Аларның тууы өчен, әгәр шулай әйтергә ярасa, мәгълүм бер үсеш тәҗрибәсе соралган. Кызганычка каршы, бәетнең туган көннән XVI йөзгә кадәр үсешен без бары ярдәмчел, икенче дәрәҗәдәге мәгълүматлар буенча гына күз алдына китерә алабыз. Чөнки кулыбызда жанрның формалашу дәверен күрсәтерлек конкрет мисаллар юк. Бүгенге көнгә XVI йөздән дә иртәрәк иҗат ителгән бәетләр килеп җитмәгән, ә XVI йөздә исә алар халык иҗатының тәмам формалашкан бер жанры саналган.

Бәетләрнең борынгы дәвердә формалашуын раслый торган икенче дәлил шуннан гыйбарәт, XVI йөздән безнең көннәргә килеп җиткән кайбер бәетләр Казан ханлыгы чорындагы вакыйгаларны түгел, ә Болгар дәүләте чорындагы вакыйгаларны тасвирлаудан башланып китәләр. Безнең чорга килеп җиткән бәетләрнең күбесендә явыз Тимер тарафыннан Болгарның җимерелүе һәм үзеге Казан булган яңа дәүләтнең төзелүе сурәтләнә, ягъни XIII—XIV йөзләрнең илләр һәм халыклар язмышындагы борылыш чоры белән бәйле мөһим тарихи вакыйгалары гәүдәләнә.

* * *

Беренче мәртәбә К. Насыйриның 1881 елгы календарендә басылган «Казан бәете» яки «Казан тарихы» шундый әсәрләрнең берсе санала. Соңыннан Н. Ф. Катанов аны гарәп шрифтында, академик транскрипция белән рус һәм татар телләрендә кабат чыгара [2]. Үзенең кыска гына кереш сүзендә Н. Катанов бәетнең язылу вакытына да

---

[1] Г. В. Юсупов. Новые находки эпитафий периода Казанского ханства. «Эпиграфика Востока». XVI. Рус телендә. 1963 ел. 73—75 битләр.
[2] Н. Ф. Катанов. Исторические песни казанских татар. ИОАИЭ. Рус телендә. XV том. 3 чыгарылыш. 275—292 битләр.

туктала: «Насыйровның сүзләренә караганда,— ди ул,— бу шигырь бик күптән язылган һәм ул Казан губернасындагы барлык татарларга таныш икән»[1].

Бу әсәрләргә бераз киңрәк тукталган кешеләр — Г. Рәхим белән Г. Газиз. Бәетнең язылу вакыты турында алар шул ук фикерне куәтлиләр: «Теле һәм эчтәлегенә караганда, бу бәетнең шактый борынгы булуы ихтимал»[2],— диләр. Алар фикеренчә, бу әсәрнең авторы руханилар катлавыннан булырга тиеш. Күрәсең, ике дин — христиан һәм мөселман дине — вәкилләрен артык кискен төстә бер-берсенә каршы куюы шуның белән аңлатыладыр. (Гомумән, урта гасырларда дини карашлардан бөтенләй азат фольклор әсәренең тууын күз алдына китерүе дә читен.)

«Казан бәете» шактый зур күләмле әсәр, ул барлыгы 29 куплеттан тора. Эчтәлеге ягыннан да зур гына тарихи чорны иңли. Бу, безнең уебызча, Казан татарлары фольклорының язылу вакыты шактый төгәл ачыкланган бер эпик үрнәге. Кайбер натуралистик урыннары булуга да карамастан, ул татар халкы тормышындагы мөһим тарихи вакыйгаларны ярыйсы ук зәлекле сурәтли һәм, халык иҗаты әсәре буларак, үзендә бәетнең иң үзенчәлекле сәнгать чараларын шактый тулы чагылдыра. Соңрак туган башка күп кенә бәетләрдәге кебек үк, аның эчтәлеген фаҗигале вакыйгалар тәшкил итә. Барыннан да элек, хикәяләүнең характерын билгеләгән тарихи сәбәпләрне ачыкларга тырышып карыйк. Бәет Болгар иленең җимерелүе турындагы хәбәр белән башлана:

> **Тарих җиде йөзда**[3]
> **Килде Тимер Болгарга,**
> **Абдулла ханның кулыннан**
> **Болгар шәһәрен алдыя.**

Строфаның баштагы юллары чынбарлыкта булган реаль вакыйгалардан әллә ни ерак тормый. Билгеле булганча, Болгарга берничә Тимер һөҗүм итә. «XIII йөзнең 70 елларында Болгар халкы тагын монгол басып алучыларына каршы күтәрелә. Моңа җавап итеп, Алтын Урда ханы Мөңге-Тимер зур отряд белән үзенең темнигы Нугайны җибәрә, ул исә рәхимсез чаралар кулланып восстаниене бастыра»[4]. XIV йөздә Болгар иленә каршы Алтын Урда әмире Булат-Тимер сугыша. 1361 елда ул зур гаскәр белән Болгар дәүләтенә юнәлә. Елъязмалардагы мәгълүматларга караганда, ул Болгар шәһәрен ала, улусларны талый һәм бөтен Идел юлын үз кулына ала. һәм, ниһаять, «1391 елда Болгар дәүләте чикләренә Аксак Тимер (Тамерлан) гаскәре якынлаша»[5]. Аксак Тимер Болгарны алгандырмы-юкмы, төгәен билгеле түгел, һәрхәлдә, халык иҗаты әсәрләре алган дип раслый. Күп кенә тарихи язмалар да шул хакта сөйли, әмма ул әсәрләрдәге Болгар шәһәренең җимерелүе һәм Казанның төзелүе турындагы күп кенә мәгълүматлар халык легендаларыннан һәм риваятьләрдән алынган. Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» (1 том, 322 бит) җыентыгында Болгарны нәкъ менә Тимер җимерүе турында сөйли торган бер мәзәк тә бар. Ләкин әлеге бәеттә кайсы Тимер турында сүз баруын әйтүе кыен. Бәетнең тексты бу сорауга анык кына җавап бирми. Бәетнең башында «җиде йөзенче еллар» турында сүз бара, бу XIV йөзләргә туры килә. Алга таба Абдулла ханның ике улы тарафыннан салынган Казан шәһәренең «ике йөз алтмыш ике ел...» буе мөселманнар кулында булуы хәбәр ителә. Димәк, Болгар шәһәре Тимер тарафыннан XIII йөзнең ахырында җимерелгән һәм якынча шул чорларда ук Казан шәһәренә нигез салынган булып чыга. Бу версия буенча хөкем йөртсәк, бәеттә сүз нәкъ менә XIII йөзнең ахырында Болгар иленә һөҗүм иткән Мөңге-Тимер гаскәрләре турында бара дип әйтергә мөмкин булыр иде. Ләкин бәетнең тексты алай хөкем йөртергә нигез бирми, чөнки, алда бер тапкыр әйтелгәнчә, әсәрнең башында XIV йөздәге, ә берничә юлдан соң XIII йөздәге вакыйгалар турында сүз бара[6]. Бәетнең тарихи җирлеге турындагы

---

[1] Шунда ук.
[2] Г. Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Казан. 1925 ел. 140 бит.
[3] XIV йөздә.
[4] История Татарской АССР. Рус телендә. Казан. 1968 ел. 65 бит.
[5] История Татарской АССР. Рус телендә. Казан. 1968 ел. 66 бит.
[6] Бу мәсьәләгә, башка бәетләр уңае белән, соңрак тукталырбыз.

мәсьәләгә Болгар шәһәрен Тимер «Абдулла хан кулыннан алдыя» дигән юллар яктылык сирпергә мөмкин. Төрле тарихи язмаларда китерелгән күп санлы легендаларда һәм риваятьләрдә, әлеге бәеттәге кебек үк, Болгар шәһәрен Тимер Абдулла хан кулыннан ала, соңгысының Алимбәк һәм Алтынбәк исемле ике улы кала диелә. Алар Болгардан төньякка таба качып китәргә һәм яңа кала төзергә мәҗбүр булалар, аны, үзе утырган елга исеменнән чыгып, Казан дип йөртә башлыйлар. Яшь ягыннан өлкән булганлыктан, яңа төзелгән ханлыкның башына, гадәт буенча, Алимбәк утыра. Бик күп язмаларда кабатлана торган бу мәгълүматлар легенда төсе алганнар һәм һәр очракта тагын да ышанычлырак материаллар: төгәл документлар яки археология, нумизматика мәгълүматлары белән расланмыйлар. Ачыкланган кадәресе шул: Казанда «Алимбәк исемле (башка чыганаклар буенча Азиз-хан) князь яки патша» була, ул 1445 елда Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәт тарафыннан үтертелә [1].

Алга таба бәет Казанның Ядкәр хан кулыннан русларга күчүе турында сөйли. Чыннан да, 1552 елның 2 октябреннән Казан шәһәре җимерелгәнгә кадәр анда хан булып Астрахань патшасының улы Ядкәр утыра. Казанда ул бик аз патшалык итә. 1551 елның ахырында тәхеткә утыра, ә 1552 елда инде Казан алына. Шулай булгач, Казан тарихында Ядкәр нинди дә булса җитди эз калдыра алмаган, билгеле. Инде бәеттә нәкъ менә ул мактала икән, моны Казан алынган чакта аның хан булып утыруы һәм Иван IV кулына нәкъ менә аның әсир төшүе белән генә аңлатырга мөмкин.

Шулай да бәет тарихи вакыйгаларны бераз бутый. Анда «тугыз йөздә җиденче елда», ягъни 1550 елда Ядкәр бу дөньядан китә, диелә. Чынлыкта исә Ядкәр Иван IV гә әсирлеккә эләгә, аны Мәскәүгә җибәреп чукындыралар һәм Симеон дигән исем кушалар, 1565 елда гына шунда үлә [2].

Бәетнең шуннан соңгы вакыйгалары күбрәк легенда характерында. Имеш, Ядкәр үлгәннән соң аның ир туганнары ягыннан варислар калмый. Аптырагач, Ядкәрнең 9 яшьлек кызына хан булырга тәкъдим ясыйлар. Ләкин ул: «Шул хәтле ирләр булганда, мин нигә хан булыйм», дип баш тарта. Кыз үз-үзен үтерә. Хан нәселеннән бердәнбер кеше булып, русларга әсир төшкән Шаһгали кала. Бик күп акча бәрабәренә аны әсирлектән коткаралар һәм тәхеткә утырталар. Шаһгалинең тәхеткә утыруын бәет шулай аңлата.

Билгеле булганча, Шаһгали — Казан тәхетенә берничә мәртәбә утырган кеше. Тик Казанның бәйсезлеген саклап калуда ул зур роль уйный алмый. Әгәр ханлык җимерелгәннән соң иҗат ителгән бәеттә Шаһгали начар кеше буларак сурәтләнә икән, моңа һич гаҗәпләнмәскә кирәк. Алай гына да түгел, тарихи дөреслеккә тәңгәл килгәнчә, бәет аны бернигә яраксыз, принципсыз кеше итеп бирә.

Әсәрдә шәһәрне геройларча саклаучы Чура батыр образына зур урын бирелә. Бәеттә ул алла бәндәсе, дәрвиш итеп күрсәтелә, бу нәрсә тагын бер мәртәбә аны иҗат итүдә руханилар катнашуы турында сөйли. Әмма бу геройның тарихи прототибы булганмы-юкмы, әйтүе кыен. Билгеле булганча, Казанның дәрәҗәле кешеләре арасында Мәскәү тарафдарлары группасының актив эшлеклеләреннән Чура Нарыков дигән кеше була. Тик ул, Кырым тарафдарларына каршы фетнәдә катнашуда гаепләнеп, 1547 елда Сафа-Гәрәй тарафыннан үтерелә. Бу аның үз чорының алдынгы карашлы кешесе булуы турында сөйли. Билгеле, ул бәеттә сурәтләнгән Чура батырның бердәнбер прототибы була алмый. Сәбәбе бик гади, Казан алынган чорда ул күптән үлгән була. Аннан соң, әгәр Чура Нарыков бәет героеның бердәнбер прототибы булса, бу әсәрнең аерым строфаларындагы фикерләр белән дә каршылыкка керер иде. Чөнки бит Ядкәр (ә бәеттә ул уңай яктан характерлана) Мәскәү группировкасы яклы кеше, ягъни Чура Нарыков тарафдары булмый. Башкача әйткәндә, капма-каршы группировка вәкилләре асылда бер үк төсле бәяләнә булып чыга. Бу Чура образының прототибы бер Нарыков кына булмаган, аның тууы нининдидер бик мөһим башка факторлар белән бәйләнгән дип уйларга юл калдыра. Бәеттә халыкның милли мөстәкыйльлеге идеясе ярыйсы ук тулы чагыла, һәм бу идея барыннан да бигрәк Чура образында гәүдәләнә. Әгәр шулай икән, без аның прототибын шул

---

[1] История Татарской АССР. 69 бит.

[2] История Татарской АССР. 93 бит.

эпохада яшәгән тарихи шәхесләр арасыннан сайлау белән генә чикләнеп калмаска, ә мәсьәләгә күп мәртәбә киңрәк позициядән торып якын килергә тиешбез. Мәсьәләгә шул рәвешчә якын килеп, тагын бер мәртәбә бәеттәге Чура образының да, тарихи шәхес булган Чура Нарыковның да чорның прогрессив идеяләрен алга сөрүчеләр икәнлегенә басым ясыйк. Теләсә нинди деспотизмны дошман күргән халык массалары аңа каршы көрәшнең зарури булуын да аңлаганнар. Һәм деспотизмга каршы чыккан кешеләрнең һәммәсе дә аларда хуплау һәм теләктәшлек тапкан. Әмма азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәшүчеләрнең героик образын тудыру өчен конкрет тарихи вакыйгаларга мөрәҗәгать итү генә җитмәгән. Чөнки ул вакыйгалардагы һәммә нәрсә дә гади кешеләргә аңлашылып бетмәгән. Менә шул чагында инде, күрәсең, халык массалары үзләренең бай эпик традицияләренә мөрәҗәгать иткәннәр.

Ил һәм халык бәйсезлеген яклап көрәшкән эпик Чура батыр турындагы дастан күп төрки халыклар иҗатында бар. Җитмәсә, ул дастаннардагы Чураның да әтисе Нарык исемле була. Ихтимал, әсәрнең төп идеясен мөмкин кадәр ачыграк чагылдыру өчен, тарихи бәет төрки дөньяда шактый киң таралган әлеге образны файдаланган-дыр. Шул рәвешчә, бәеттә, бер яктан, алдынгы тарихи шәхес, икенче яктан, халыкның эпик традицияләренә нигезләнгән әдәби образ гаҗәеп кызык төстә бергә кушылалар. Безнең уебызча, бәеттә героик төстә идеаллаштырылып бирелгән Чура образының асылын бары шулай гына аңлатырга мөмкин.

Инде бәетләрдә, әдәби принцип буларак, борынгы эпик традицияләрне файдалануга килгәндә, шуны әйтергә кирәк: без тикшерә торган бәет мондый характердагы берданбер мисал түгел. «Ханәкә солтан» бәетендәге төп образны иҗат итүдә, мәсәлән, башка төрки халыкларның эпик традицияләре киң файдаланыла.

Шул рәвешчә, без тикшерә торган «Казан бәете» Идел буе татарлары тормышындагы зур бер дәвергә хас — Болгар дәүләтенең җимерелүеннән алып Казанның һәм Казан ханлыгының рус дәүләтенә кушылуына кадәр булган — мөһим тарихи вакыйгаларга багышланган. Бәет болгар-татар тәзелешендәге аеруча киеренке һәм мөһим тарихи вакыйгаларга бай ике моментны чагылдыра. Шуңа күрә ул «Казан тарихы» яки «Казан бәете» дип атала да.

Бәетнең барлыкка килүе, күрәсең, XVI йөзгә карыйдыр. Чөнки тарихи дата һәм вакыйгаларны төрлечә бутау аның бераз соңрак, вакыйгаларның кайнарлыгы сүрелә төшкәч язылуы яки, иң дөресе, әсәрнең ахырдан күп кенә үзгәрешләргә дучар булуы турында сөйли.

Бәеттә ике диннең бер-беренә капма-каршы куелуын да әйтеп узган идек. Казанның бәйсезлеге өчен көрәш бер үк вакытта дини көрәш тә була. Ул чактагы вакыйгаларга Казан халкыннан башкача мөнәсәбәт көтү беркатлылык булыр иде. Алай гына да түгел, бу марксизм тәгълиматының урта гасырлардагы күп тарихи вакыйгалар өчен дин пәрдәсенә төренгән булу хас, дигән өйрәтмәсенә үк каршы килер иде. XVI йөздәге сугышлар турында сөйләп, Ф. Энгельс: «XVI йөзнең дини дип йөртелгән сугышлары вакытында да сүз, барыннан да бигрәк, аерым сыйныфларның материаль мәнфәгатьләре турында бара; алар шулай ук сыйнфый сугышлар иде... Әгәр ул чагында бу сугыш дини пәрдә астында барган икән, әгәр аерым сыйныфларның мәнфәгатьләре, таләп һәм ихтыяҗлары дини пәрдә артына яшеренгән булган икән, бу әле һич кенә дә эшнең асылын үзгәртми һәм заманның үзенчәлекле шартлары белән җиңел аңлатыла»[1],— дип язды. Бераз соңрак шул ук хакта В. И. Ленин да яза: «Сәяси протестның дини пәрдә аша чагылуы бер Россия өчен генә түгел, үсешнең мәгълүм бер стадиясендә барлык халыклар өчен хас күренеш»[2]. XV—XVI йөзләрдәге бәетләргә бәя биргәндә без марксистик-ленинчыл методологиянең менә шушы принципиаль өйрәтмәсенә таянырга тиеш. Шул очракта гына без аларның әһәмиятен дөрес бәяли алачакбыз.

Шул еллардагы вакыйгаларның аерым эпизодларын Н. Ф. Катанов тарафыннан «Шаһгали ханның вәзирләре хакында чыгарган йыруы» дигән исем белән басылган икенче бер бәеттә дә очратырга мөмкин[3]:

---

[1] К. Маркс, Ф. Энгельс. Сочинения. Рус телендә. 2 басма. 7 том. 360 бит.
[2] В. И. Ленин. Сочинения. Рус телендә. II том. 520 бит.
[3] Н. Ф. Катанов. Исторические песни... 305—306 битләр.

**Дус, дус дигәнем**
**Дус түгел икәнсез;**
**Дус дип йөргәнем**
**Бар да дошман икәнсез.**

Шаһгали Казан тәхетенә өч мәртәбә утыра һәм өчесендә дә тәхетне ташлап качарга мәҗбүр була. Чөнки аны халык яратмый. Шаһгалигә XVII йөз сәяхәтчесе Адам Олеарий ифрат тулы характеристика биреп калдырган: «Тыштан караганда, ул салынып торган зур колаклы, зур табак битле, юан, кыска аяклы һәм озын, кәкре табанлы ямьсез бер кеше иде,— ди Олеарий.— Миңа шушы кешегә алар буйсынырга һәм ясак түләргә тиеш. Бу нәрсә Казан татарларын бик тә гарьләндерә иде»[1]. Шаһгалинең эчке дөньясы да Олеарий тасвирлаган тышкы кыяфәтенә тәңгәл килеп торган. Әгәр бөтен якыннары Шаһгалигә хыянәт иткәннәр икән (бәеттә сүз нәкъ шул турыда бара), бу бик аңлашыла. Тарихи шәхес буларак, Шаһгали халык арасында үзе турында бәет таралуга исәп тота алмаган. Күрәсең, артык зур да, сәнгатьчә эшләнеше әллә ни югары да булмаган бу бәетне Шаһгали үзе яки аның якыннарыннан кем дә булса чыгаргандыр. Казан ханлыгының рус дәүләтенә кушылуына каршы булган кешеләрнең милли хисләрендә уйнап, бәет авторы спекулятив алымнарга мөрәҗәгать итә.

Шул чор вакыйгаларына бәйле тарихи эчтәлекле бәетләрнең тагын берсе — «Мөхәммәт Әмин ханның Аксак Тимер хакында чыгарган йыруы» дип атала. Беренче мәртәбә ул М. Хөсәеновның 1883 елда чыккан «Болгар тарихы»нда басыла. М. Хөсәенов аны Казан ханы Мөхәммәт Әминнең төрек телендә язылган «Гыйкаб» («Җәза») исемле китабыннан алганлыгын әйтә.

Г. Рәхим һәм Г. Газиз, «Татар әдәбияты тарихы» китапларында әлеге мәсьәләгә тукталып, Мөхәммәт Әмин шагыйрь булгандырмы-юкмы, ул «Җәза» исемле поэма язгандырмы-юкмы, бу хакта берни дә әйтә алмыйбыз, диләр. XV йөзнең ахырында, XVI йөзнең башларында яшәгән Мөхәммәт Әмин, ихтимал, чыннан да, шагыйрь булгандыр. 1968 елда чыккан «Татарстан АССР тарихында» ул XV йөзнең ахырында, XVI йөзнең башындагы күренекле шагыйрьләр рәтеннән санала (96 бит). Әгәр чыннан да шулай икән, без борынгы чорда ук бәет язма әдәбият белән тыгыз элемтәдә үскән дип әйтә алабыз.

Мөхәммәт Әмин Казанда патшалык итә. Ә бәет Тимерләңкнең Болгарга һөҗүме турында сөйли. Тимерләңк Болгарга һөҗүм иткән, моның Мөхәммәт идарә иткәндә мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән Казан ханлыгына ни катнашы бар? Бу сорауга бәетнең үзендә җавап юк. Күрәсең, биредә сүз бик ерак заманда, Болгар иле кайсыдыр Тимер тарафыннан чыннан да җимерелгәч чорлар турында барадыр. Г. Рәхим белән Г. Газиз, тел үзенчәлекләреннән һәм анда төрек сүзләре күп кулланудан чыгып, бәетне соңрак чорда туган әсәр дип саныйлар. Безнең уебызча, бу бәет тә, «Казан бәете» дә бер үк чор җимешләре, чөнки икесендә дә бер үк тарихи вакыйга турында сүз бара. Эчтәлеге буенча зуррак вакыйганы иңләгән «Казан бәете»ннән аермалы буларак, «Мөхәммәт Әмин ханның Аксак Тимер хакында чыгарган йыруы»нда Тимернең Болгарны басып алуы турында гына сөйләнә. Бәет Тимерләңкнең басып алу политикасын кискен фаш итә һәм аның өстенә нәгъръләр яудыра:

**Чыкты һиҗрәттән җиде йөз илледә,**
**Төште хараплык, зилзилә галәмгә.**
**Үзе аксак, акыллы ахмак, фетнәдар**
**Золымны изһа кылды һәр җирдә.**

Бәет Тимернең Болгарны җимерүе, аның ерткычлыклары, күп галимнәрнең һәм югары дәрәҗәле дин әһелләренең һәлак булуы турында сөйли. Алда тикшерелгән башка бәетләр кебек үк, бу бәет тә мөселман руханилары исеменнән язылган һәм Тимерне теге дөнья, андагы җәзалар белән куркыта. Фольклор әсәрләрендә — күп санлы легендаларда һәм риваятьләрдә — Тимерләрнең исемен бутап йөртү күренешен та-

[1] Адам Олеарий. Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно. Спб. Рус телендә. 1906 ел. 370 бит.

рихчылар түбәндәгечә аңлата: «Халык арасында таралган легенда Тимерләңкне, татарлар аны Аксак Тимер дип йөрилар, икенче бер яулап алучы белән, 1391 елда Болгарны җимергән Булат-Тимер белән бутап йөртәләр»[1]. Күрәсең, Булат-Тимер шактый энергияле дәүләт эшлеклесе булгандыр. Мәсәлән, «Булат-Тимер Болгар белән идарә иткәндә, Болгар кнзьлегендәге экономик һәм политик тормышның кайнап, гөрләп торуы»[2] ачыкланды. Болгарны талаган Булат-Тимер исеме, күрәсең, соңрак бөтен Шәрык дөньясында рәхимсез яулап алучы буларак даны чыккан Аксак Тимер исеме белән алыштырылгандыр. Югарыда әйтелгәнчә, XIV йөздә Тимерләңк гаскәрләре Болгар җиренә дә басып керә, моның да билгеле бер тәэсире булгандыр, мөгаен. Кайбер тарихчылар, Болгар шәһәрен Тимерләңк алган дип тә уйлыйлар[3]. Шул рәвешчә, бәетнең төп герое Аксак Тимер булып чыга, авторның бөтен каргышлары аңа каршы юнәлдерелгән. Болай мөселманлыкны саклау рухы белән сугарылган булса да, асылда ул рәхимсез яулап алучыга каршы язылган. Бәеттә тасвирланган фактларның объектив нәтиҗәсе буларак килеп чыккан бәйсезлек һәм азатлык өчен көрәш идеясе аны татар халык иҗатының кызыклы истәлекләре белән бер рәткә куя.

* * *

Мәкаләдә күзәтылган мәсьәләләрне йомгаклар алдыннан жанрның тууы һәм формалашуы өчен уңдырышлы җирлек хезмәтен үтәгән, халыкның борынгы эпик традицияләре турындагы мәсьәләгә ачыклык кертерлек тагын бер әсәргә тукталабыз. Сүз бу жанрдагы бөтен әсәрләр арасыннан аерылыбрак торган, әмма баштан ахырга кадәр бары тик легенда характерындагы вакыйгаларга нигезләнгән әсәр турында бара. Без татар халкы яшәгән һәр җирдә очрый торган иң популяр һәм киң таралган, күп тапкырлар басылып чыккан «Сак-Сок» бәетен күздә тотабыз. Чама белән аны XVII—XVIII йөзләрдә иҗат ителгән әсәр дип була. Әдәби яктан ифрат камил эшләнгән бәет, үзе нигезләнгән легенда кебек үк[4], ике баланың әтиләре өйдә югында, сүз тыңламаган өчен, әниләренең каргышына дучар булуы хакында сөйли:

Җимләр ташыйдыр кошлар басудан,
Әнкәй каргады безне ачудан.

Әниләренең каргышы шул хәтле көчле була, балалар шунда ук Сак һәм Сок дигән мифик кошларга әйләнәләр һәм очып китәләр:

Ишек алдында җиктем кара ат,
Әнкәй каргагач, яралды канат,
Агачка кунгач, язылды канат,
Икәүләп бергә очтык шул сәгать.

Өйгә кайткач, әтиләре балаларын сорый. Әниләре исә, елый-елый, әлеге хәлне сөйләп бирә. Шул көннән башлап, Сак белән Сок, бер-берләрен күрмичә, кара урманда яшәргә тиешләр, чөнки әниләренең каргышы шундый:

Әйгән кибәнне җилләр тарата,
Кавышабыз дигәч хәзер таң ата.

---

[1] Материалы по истории Татарии. Рус телендә, 1 чыгарылыш. Казан, 1948. 213 бит.
[2] История Татарской АССР. 66 бит.
[3] А. Н. Смирнов. Волжские булгары. Рус телендә. Мәскәү, 1951 ел. 63 бит.
[4] М. Васильев. Памятники татарской народной словесности. Казан, 1924 ел. 45 бит.

Бәеттән күренгәнчә, яктыда балалар бер-берсе белән очраша алмыйлар. Алар шулай ук әти-әниләре белән дә очраша алмыйлар. Бу хәлне күреп, әниләре елый, ләкин соң инде, берни дә эшли алмый. Гомер-гомергә алар аерым яшәргә тиешләр:

Урман эчендә кошлар сайрыйдыр,
Кошлар эчендә Сак-Сок егълыйдыр.

Бу әсәрнең тарихи җирлеге һәм барлыкка килү вакыты турында ни дә булса әйтүе кыен. Башка бәетләрдән «Сак-Сок» эчтәлегенең оригинальлеге, үзендә мифология элементларының мул булуы белән аерылып тора. Татар мифологиясендәге персонажлар арасында Сак белән Сок дигән мифик кошлар булгандырмы-юктырмы, кызганычка каршы, бу хакта без берни дә белмибез. Бәет бар, булган дип раслый. Анда: «Әнкәй каргады Сак-Сок булсын дип», дигән сүзләр бар. Әнисе каргаган балалар үзара бер дә очраша алмый торган Сак белән Сок исемле кошка әверелә-ләр дигән ышану яшәгәндер. Ихтимал, Сак белән Сок турындагы миф әлеге бәеткә бәйсез рәвештә яшәгәндер. Татар телендә «Сак-Сок кебек яшәү» дигән тәгъбир бар. Ул аерым яшәүне белдерә. Халык җырларында: «Сак белән Сок диләр инде менә безнең кебекне» шикелле юллар очрый. Җырлардагы Сак-Сок образларының, идиоматик әйләнмәләрнең, алар турындагы легендаларның нигезендә бәет яткандыр дип уйларга мөмкин. Бәет исә, үз чиратында, мифология белән бәйләнешле ниндидер ышанулар җирлегендә туган булырга тиеш. Мәсьәләгә бу күзлектән караганда, «Сак-Сок бәете»нең Х. Ярминең «Бәетләр» җыентыгында «Аңлатмалар» бүлегендә (338—339 битләр) басылган варианты бик кызыклы. Анда әкияткә хас чалымнар бар.

Бер кешенең игезәк баласы була. Алар аерылмас дус булалар, бергә уйныйлар, бергә ашыйлар, бергә йоклыйлар. Әтиләре аларны бик ярата, аларга карата һәрвакыт яхшы мөгамәләдә була. Ләкин әниләре балаларны яратмый, гел орышып тора. Шулай бервакыт, уйнап күңелләре булганнан соң, игезәкләр кич кенә өйгә кайтып керәләр. Әниләре аларны төн буе каргап чыга. Иртән бер-берсенә карыйлар да гаҗәпләнеп калалар, икесе дә кошка әверелгәннәр. Бу хәлгә әтиләре нишләргә белми. Бу эше өчен әниләре дә үкенә башлый, ләкин соң инде...

Эчтәлегенә караганда, бу иң борынгы вариант булырга тиеш. Алай гына да түгел, бу вариант нигезендә үз үсешенең башлангыч чорында бәет таянган борынгы эпик традицияләр турындагы мөһим бер нәтиҗәгә килергә мөмкин. «Сак-Сок бәете» жанрының барлыкка килү һәм формалашуында, без «Казан тарихы» бәетен тикшергәндә күреп узганча, язма әдәбият һәм героик-эпик традицияләр генә түгел, әкияти, мифологик традицияләрнең дә билгеле бер роль уйнауларын күрәбез.

* * *

Югарыда тикшерелгән әсәрләрнең гомуми характерына тукталып шуны әйтергә мөмкин, ул әсәрләр жанрның беренче чордагы үсешен күзалларга һәм аларның күп кенә мөһим үзенчәлекләрен (бәетләрдәге эчтәлекнең тарихи чынбарлык вакыйгаларына мөнәсәбәтен, бәетләрнең төрле халыклар фольклорындагы эпик традицияләр һәм халык иҗатының башка жанрлары белән үзара мөнәсәбәтен) ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Югарыда китерелгән мәгълүматлар күрсәткәнчә, XV—XVI йөзләрдәге бәетләр, бигрәк тә «Казан тарихы» һәм «Ханәкә солтан бәете», органик төстә төрки халыклар фольклорының гомуми эпик традицияләренә барып тоташалар, гүя ки аларның аерылмас бер өлешен тәшкил итәләр. Инде аларның конкрет эчтәлегенә килгәндә, мәсьәләнең ул ягы, һичшиксез, татар ханлыгының тарихи язмышы белән бәйләнгән. Тикшерелгән әсәрләр бәетләрдә нинди характердагы вакыйгалар тасвирлануын ачыкларга мөмкинлек бирә. Жанрның үсеш юлын өстән-өстән генә күзәтеп чыкканда да, бәетләр — фольклорның татар халкының социаль-политик тарихы белән аеруча тыгыз бәйләнгән жанры дип әйтергә мөмкинлек бирә. (Ләкин шул нәрсәне искәртеп китик, жанрның сурәтләү объекты, бигрәк тә тормыш-көнкүреш бәетләрен күздә тотсак, моның белән генә чикләнми.) Бәет эчтәлегенең халыкның социаль-по-

литик тарихы белән тыгыз бәйләнгән булуы аның эчтәлек һәм форма төзелешендәге үзенчәлекләрне дә билгели. Бәек Октябрь революциясенә кадәр татар халкы фаҗига артыннан фаҗига кичереп тора (Болгар җирләренең монголлар һәм Тимерләнк тарафыннан яулап алынуы, берничә мәртәбә дәүләтнең башкаласы (Болгар, Биләр) җимерелү, царизмның колонизаторлык политикасы, крестьяннарның һәм эшчеләрнең помещик һәм капиталистларга каршы чыгышларын кан белән бастыру һ. б.). Бәетләрдә шул ук хәлләр һәм вакыйгалар хакында сөйләнә. Күп кенә бәетләрнең нигезендә яткан шундый фаҗигале, авыр, драматик хәлләр алардагы хикәяләү тонының да, халыкның лиро-эпик әсәрләрендәге эмоциональ яңгырашның характерын да билгели. Бәетләр халык иҗатының фаҗигале характердагы тарихи вакыйгалар әсәруча ачык һәм тулы чагылган төп жанры. Эчтәлекнең шундый үзенчәлеге үзенә лаек форманы да таләп итә: кабер ташы язуларын хәтерләтә торган бертөсле, катып калган башлам, һәлакәткә очраган кеше яки кешеләр, кайбер очракта үлгән кеше исеменнән алып барыла торган хикәяләү, бәхетсез язмыштан зарлану, туганнар һәм якыннар белән хушлашу рәвешендәге бертөсле бетем, трагик яки драматик характердагы тел-стиль алымнары һ. б.

Жанрның борынгы чорга каравы һәм аның әеруча иске үрнәкләре турындагы сөйләнгән сүзләргә йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: безнең уебызча, бәетләрнең барлыкка килү, туу вакыты Болгар дәүләте чорына карый. Ә жанрның тәмам формалашып җитүе, күрәсең, Казан ханлыгы чорына туры киләдер. Безнең көннәргә хәтле килеп җиткән бәетләрдә халык иҗатының шактый борынгы героик-эпик һәм экиятимифологик традицияләре йогынтысы ачык сизелү дә шул турыда сөйли

≈≈≈≈≈≈

Вячеслав Воздвиженский

# ЗУР ТАЛӘПЛӘР ЮГАРЫЛЫГЫННАН

*Татарстанда яшәүче рус язучыларының иҗаты*

Бүгенге әдәби хәрәкәтебезгә, язучыларыбызның бүгенге иҗатларына бәя биргәндә, КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары безнең өчен кыйммәтле кулланма булып тора. Анда тәнкыйтьнең әдәбиятыбыз үсешендәге уңышлы һәм кимчелекле якларны даими рәвештә яктыртып барырга, тәнкыйтьчеләрнең әдипләребез иҗатына карата игътибарлы һәм шул ук вакытта таләпчән булырга тиешлегенә басым ясап әйтелә. Бу мәкаләдә без Татарстанда яшәүче рус язучылары тарафыннан узган елда иҗат ителгән кайбер әсәрләрне әнә шул таләпләр югарылыгыннан торып бәяләмәкче булабыз.

Шунда ук тагын бер сорау туа: гомумән, язучының теге яки бу чордагы иҗатына нәрсәдән чыгып бәя бирергә соң? Беркемгә дә сер түгел, бездә әле язучыларның иҗади хезмәт нәтиҗәләрен илдәге экономик уңышлар, икенче төрле әйткәндә, турыдан-туры сан ягыннан булган үсеш күрсәткечләре ноктасыннан карап бәяләү тенденциясе яшәп килә. Сан ягыннан ирешелгән уңышлар турында без төрле җыелышларда булсын, отчет докладларында булсын, әледән-әле ишетәбез. Ә бит, ныклабрак уйлап карасаң, иҗат эшенең үз критерийлары, үз кануннары бар. Заводның планда каралганнан тыш илле машина артык эшләп чыгаруы бер нәрсә, язучыларның шул ук чорда, әйтик, биш роман тудыруы, я булмаса, шәһәрдә яңа театр ачылуы исә бөтенләй икенче нәрсә. Монда инде игътибарны әлеге романнарның идея-художество сыйфатына, яңа ачылган театрның нинди эстетик югарылыкта торуына юнәлтергә кирәк. Иҗади эшчәнлек нәтиҗәсе буларак туган теге яки бу әсәрнең әһәмияте аның эстетик көче, идея-художество сыйфаты белән билгеләнергә тиеш.

Узган әдәби елыбыз турындагы сүзне документаль характерда язылган әсәрләрдән башлап китәсе килә. Республикабыздагы рус язучылары очерк жанрында даими рәвештә эшләп киләләр. Ләкин алынган теманы, күтәрелгән проблемаларны башыннан ахырына кадәр эзлекле яктыртуга корылган бер бөтен очерк китабының дөньяга чыгуы бездә алай еш була торган күренеш түгел. Узган ел исә шундый характердагы ике китап — Геннадий Паушкинның «Чаллы җирендә» һәм Юрий Белостоцкийның «Сугышчан канатлар» дигән китаплары басылып чыкты. Бу китапларның беренчесе аеруча игътибарга лаеклы.

Камадагы промышленность комплексы төзелеше республикабыз тормышына өр-яңа үзгәрешләр алып килде. Г. Паушкинның «Чаллы җирендә» дип исемләнгән әдәби-документаль китабы әнә шул үзгәрешләрнең ничек башлануы турында сөйли. Г. Паушкин андагы күренешләрне өстән-өстән генә сурәтләп узу белән чикләнми, үзе тасвирлый торган материалга,

кешеләргә мөмкин кадәр якынрак килергә тырыша. Ул яшьлек дусты, Чаллы якларында туып үскән Зыя Закиров белән очрашуы турында язамы, комсомол төзелеше штабы начальнигы Валерий Стекольщиковның көндәлекләрен китерәме, аларның һәркайсын зур кызыксыну белән укыйсың. Кыскасы, Геннадий Паушкинның бу китабы темасы белән генә түгел, тормыштагы фактларны сайлап алуы һәм аларны әдәби яктан эшкәртүе белән дә игътибарны үзенә җәлеп итә. Ләкин моның әле «башлангыч эшкәртү» генә булуын да ачыктан-ачык әйтеп үтәргә кирәк. Автор материалны тирәнтен өйрәнүгә караганда, аны киңрәк мәйданда колачларга омтыла. Шуның нәтиҗәсендә безнең күз алдыбызда, производство һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр урынына, төзелешнең гомуми панорамасы гына гәүдәләнә.

А. Приставкин һәм В. Росляковның «Новый мир» журналы битләрендә басылган очеркларында төзелеш эшләренә бәйләнешле проблемаларның ничек тормышка ашырылуы тасвирлана. Әйтеп үткәнебезчә, Г. Паушкинга хәзергә әле нәкъ әнә шул җитми. Ләкин монда аның КамАЗ төзелешенә беренче булып мөрәҗәгать иткән автор икәнлеген дә истән чыгарырга ярамый. Башка авторлар исә аның артыннан баралар. Геннадий Паушкин моннан егерме ел элек, республикабызда «кара алтын» ургыла башлаган көннәрдә, нефть темасын күтәреп чыккан шикелле үк, бүгенге яңа тема һәм материалга беренче булып юл ярды. Ләкин бу юлы Г. Паушкин ул вакыттагы кебек зур темага юл ярып кына калмасын һәм яңа җирдә башкарасы эшләрен башкаларга йөкләмәсен иде. Әлбәттә, язучыга нинди дә булса күрсәтмә бирү кыен һәм тәнкыйтьченең моңа хакы да юк. Шулай да Геннадий Паушкин үзе ачкан теманы киләчәктә киңрәк яктыртсын иде, диясе килә. Лирик характерлы прозаикның иҗат мөмкинлекләре әнә шул юнәлештә эшләгәндә тагын да тулырак ачылыр шикелле. Бу тема аңа тагын шуның белән күп нәрсә вәгъдә итә, Чаллы яклары Г. Паушкинга бала чактан ук таныш һәм якын. Менә шуңа күрә дә автор Чаллы темасы өстендә эшләвен дәвам итәр, үзенә якын һәм кадерле булган материалны яртылаш үзләштергән килеш калдырмас дип ышанабыз.

Дөрес, без бу язучының Бөек Ватан сугышы темасына нык бәйләнгәнлеген дә яхшы беләбез. Үзара сөйләшкәндә, иптәшләре, Геннадий моннан утыз ел элек сугышчан постка ничек баскан булса, хәзер дә шул урыннан кузгалмый, дип юкка гына шаяртмыйлар. Әйе, бу темага тугрылыклы булып калуы, авыр сугыш елларын бергә кичкән дусларын онытмавы белән Г. Паушкин укучыларның тирән ихтирамын казанды. Алар тарафыннан авторга язылган күп санлы хатлар әнә шул хакта сөйли. Бу бик сөенечле күренеш, әлбәттә. Шуның белән бергәттән, «Чаллы җирендә» китабындагы Зыя Закиров турындагы бүлекләр сугыш истәлекләренең, Чаллы һәм КамАЗ темалары белән бергә үрелеп, тагын да көчлерәк яңгырый алуын күрсәтә.

Юрий Белостоцкийның «Сугышчан канатлар» исемле китабы сугыш героикасына бәйләнешле материалларга нигезләнеп язылган. Бу документаль хроникада Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан хезмәт ияләреннән җыелган акчага төзелгән самолетлардан торган 202 нче авиадивизиянең сугышчан юлы турында сөйләнә. Китапның сәләтле һәм тәҗрибәле автор тарафыннан язылганлыгын сиземләү авыр түгел. Юрий Белостоцкий дистәләрчә кешеләрнең биографияләрен һәм сугыш эпизодларын чагылдырган фактик материалларны җыеп эшкәрткән. Дөрес, бу әсәрендә автор, язучы булудан бигрәк, журналист буларак чыгыш ясый. Фактларны гомумиләштерүгә ул артык әһәмият бирми, хикәяләү алымын бары тик ара-тирә генә куллана. Әмма мондый китапларның кирәкле һәм файдалы булуы бәхәссез. Бөек Ватан сугышының елъязмалары әнә шундый әсәрләр ярдәмендә туа.

Художестволы проза китапларыннан иң элек ветеран язучы А. Булгаковның «Төньяк җиле» җыентыгын күрсәтеп үтәсе килә. Егерме ел буе төзүче-инженер булып эшләгәннән соң А. Булгаков менә ике дистә елга якын инде әдәби әсәрләр язу белән шөгыльләнә. Аның былтыр Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Төньяк җиле» җыентыгына «Без яшәячәкбез» исемле повесте һәм күп кенә хикәяләре тупланган. Дөрес, бу повесть һәм хикәяләрнең беренче тапкыр басылуы түгел. Әгәр нәшриятның бер үк әсәрләрне кабат-кабат чыгаруга бик үк ашкынып тормавын искә алсак, А. Булгаков әсәрләренең яңадан чыгуы үзе үк аның язучылык хезмәтенә әйбәт бәя булып тора ала.

Әйтергә кирәк, А. Булгаков әдәбиятта да төзүче булып калды. Монда эш теге яки бу әсәрдә вакыйганың төзелешләрдә

баруында гына түгел. Әлеге әсәрләрнең уңай ягы аларда авторның төзелеш коллизияләрен һәм проблемаларын тормышчан һәм ышандырырлык итеп тасвирлый алуында. Моны бигрәк тә «Язылып бетмәгән кәгазь», «Юбилей» һ. б. кайбер хикәяләргә карата әйтергә кирәк. Алардагы геройларны төзелеш үзе хәрәкәткә китерә. Төзелеш барышында хәлиткеч роль уйнаган вакыйгалар персонажларның эчке кичерешләре белән үрелеп үсә. «Без яшәячәкбез» повестенда да игътибарны, барыннан да элек, ерак тайгадагы төзелешнең колориты, андагы хезмәт атмосферасы үзенә җәлеп итә. Бирердә автор тормышның безгә әле таныш булмаган якларын ача. Укучы өчен әсәр шуның белән кызыклы да. Ә инде төзелеш мәйданын ташлап, геройларның эчке дөньяларына производство проблемаларыннан башка гына үтеп керергә тырышу А. Булгаковны ясалмалылыкка сөйри. Төзелештән аерып алынган кешеләрнең хисләре сүрелеп, күркәмлеге югалып калгандай була. Геройларга алдан ук әзерләнеп куелган билгеле бер схема буенча характеристика бирү аларга карата булган игътибарны бермә-бер киметә. Авторның әйтергә теләгән фикерен алдан ук белеп торганлыктан, укучы әсәрнең кайбер битләрен актарып кына уза.

Бездә А. Булгаков повестьлары кебек производство коллизияләренә нигезләнеп язылган әсәрләрне еш тәнкыйтьлиләр. Ни әйтсәң дә, аларда тәнкыйть өчен азык җитәрлек. Хәлбуки, В. Ажаевның «Москвадан еракта» романыннан башлап, мондый әсәрләр совет әдәбиятында үзләренә тулы хокук яулап алдылар. А. Булгаков шул традицияне дәвам иттерүе белән республикабызда яшәүче рус язучылары арасында аерым урын алып тора. «Төньяк җиле» китабы — әнә шуның ачык бер дәлиле.

А. Булгаков әдәбиятыбызда хаклы рәвештә ветеран булып саналса, Н. Орешина һәм Г. Бикушев әле яшьләр исемлегендә йөриләр. Ләкин инде аларны да бу исемлектән күчерергә вакыт җиткәндер шикелле. Аларга бирелгән «сынау чоры» күптән үтеп китте. Хәзер без аларның иҗатларына бернинди ташлама ясамыйча бәя бирергә тиешбез. Н. Орешина һәм Г. Бикушевның иҗатлары уңышлы башланды. Беренче тәҗрибәләре үк инде аларның укучыга әйтер сүзләре барлыгын күрсәтте. Моны аеруча «Бүген дә, иртәгә дә» исемле тирән эчтәлекле повесть язган Г. Бикушевка карата әйтәсе килә.

Бу әдипләрнең әсәрләрен укучы яратып кабул итте. Тәүге адымнарыннан ук аларга өлкән каләмдәшләре ярдәм кулларын суздылар. Әдәби тәнкыйть тә алардан җылы сүзен кызганмады. Болар барысы да бу яшь каләмнәргә киләчәккә бирелгән аванс иде. Аларга хәзер әлеге авансны түләр вакыт җитте. Узган ел Н. Орешина икенче китабын, Г. Бикушев өченче җыентыгын бастырды. Ул җыентыкларга кергән әсәрләр нинди югарылыкта торалар соң? Алдан ук әйтеп үтәргә кирәк, безнең уебызча, әдипләрнең үзләренә бирелгән авансны әлегә кадәр түләп бетерә алганнары юк. Бу, әлбәттә, Н. Орешина һәм Г. Бикушев әсәрләре гел кимчелекләрдән тора икән дигән сүз түгел. Ул китаплар, һичшиксез, үз укучыларын табачаклар. Монда без Н. Орешина һәм Г. Бикушев әсәрләренең уңышлы яклары турында сөйләүдән бигрәк, ул әсәрләрнең кимчелекле, җитешсез якларына тукталмакчы булабыз.

Н. Орешинаның яңа китабына ике повесть урнаштырылган. Аларның икесендә дә сүз яшь кешенең тормышка беренче тапкыр аяк басуы, андагы каршылыклар белән беренче тапкыр йөзгә-йөз очрашуы хакында бара. «Зәңгәр кояшым» повесте балалыктан әле яңа чыгып, буйга җитеп килгән яшүсмер кызның кичерешләренә корылган. «Җирдәге адым» әсәре исә «Зәңгәр кояшым» повестеның дәвамы рәвешендә язылган һәм анда без героиняның тормышта үз урынын табуын, җиргә үзен хуҗа итеп тоюын күрәбез. Н. Орешина яшь буын вәкиленең эчкерсез хисләрен, күңел сафлыгын, олы тормыш юлына аяк басканда аның үз-үзенә куйган әхлакый таләпләрен шактый тулы чагылдырган. Ләкин укучыга хәзер болар гына җитми.

Соңгы елларда рус прозасында тормышта үз урынын эзләүче яшьләр турында бер-берсенә охшашлы күп кенә повестьлар язылды. Ул повестьларда бүгенге чынбарлык тормыш тәҗрибәсе бөтенләй диярлек булмаган яшь геройның кичерешләре аша гәүдәләнә. Мондый әсәрләр яңа кеше, яңа характерлар тәрбияләүдә билгеле бер дәрәҗәдә уңай роль уйнадылар, әдәбиятыбызны җанландырып җибәрделәр. Ләкин үзләренә таләпчәнлекне киметкән авторлар, яшь кешегә багышланган әсәрләрен язганда, әзер өлгедән файдалануга, стандарт буенча эш итүгә күчтеләр.

Н. Орешина да беренче әсәрләрен нәкъ әнә шундый үрнәкләргә ияреп язды. Бу

алым, күрсәсең, аңа шул кадәр уңайлы булып тоелган, ул әле хәзер дә үз-үзен кабатлавын дәвам итә. Ә бит яшьләр өчен язылган повестьларның иң яхшы үрнәкләрендә герой үзе яши торган тормышка аек акыл, ачык күз белән карый. Бу тормышта ул үзе өчен генә түгел, безнең өчен дә ниндидер яңалык ача. Проза жанрында барлыкка килгән әлеге яңа төр әсәрләрнең әһәмияте дә шунда. Н. Орешина повестьларына нәкъ әнә шул җитешми. Аларда автор үзе дә, аның героинясы да укучы өчен бернинди ачыш ясамый. Автор башкалар һәм үзе тарафыннан инде күп тапкырлар кулланылган стандартка ияреп, яшьләр прозасында болай да аз булмаган йомшак якларны гына ишәйтә.

Артык уйланып тормастан, безнең чынбарлыгыбызга бәя бирүне, тормышта аерым вакыйгаларга нигезләнеп нинди дә булса гомуми бер нәтиҗә ясауны ул үзенең яшь-яшь геройларына йөкли. Үзе исә әнә шул тәҗрибәсез геройлары артына яшеренеп, гади бер күзәтче булып читтә кала. Болай эшләү, билгеле, авторны кайбер авыр проблемаларны хәл итүдән коткара. Шуның белән бергә, әсәрне дә тирән эчтәлектән, төпле фикерләрдән мәхрүм итә.

Чынбарлык һәм андагы каршылыклар Н. Орешина иҗатында өстән-өстән генә чагылдырыла. Андагы ситуацияләр һәм конфликтлар схемага, трафаретка әйләнәләр. Беренче карашка, Н. Орешина тормыштагы вакыйга-күренешләрне үзенчә яктыртырга омтыла кебек, чынлыкта исә моның бөтенләй киресе килеп чыга.

Мәсәлән, аның беренче повестенда төп конфликт итеп әсәрнең төп героинясы белән Княжин арасында булып узган күңелсез мөнәсәбәтләр алына. Әмма бу конфликтны чишкәндә язучы моңарчы инде башка әсәрләрдә күп тапкырлар кабатланган алымнар белән эш итә. Княжин шул әсәрләрнең берсеннән икенчесенә күчеп йөри-йөри шомарып беткән кире геройлардан бернәрсәсе белән дә аерылмый. Ә героиняның кичерешләре мелодрамик көрсенүләргә кайтып кала.

Н. Орешинаның икенче повестенда да шуңа ук охшашлы хәл кабатлана. Монда беренче планга тормыштагы драматик вакыйгалар куелган кебек булса да, автор ул вакыйгаларга шул ук яшүсмер кыз карашыннан чыгып бәя бирә. Ул карашның сай булуы авторга драматик ситуацияләрне дөрес яктыртырга, укучыны уйландырырлык җитди мәсьәләләр кузгатырга комачаулый. Әйтик, повестьтагы төп геройларның берсе — Димка һичбер нинди сәбәпсез, очраклы рәвештә һәлак була. Бу трагик үлемнән автор менә мондый нәтиҗә ясый: «Тормышта кеше үз-үзен кызганмыйча яшәргә тиеш...»

Повестьның героинясы һәм аның яшьтәшләре һәркемгә билгеле әнә шундый сүзләрне кабатлаудан ерак китә алмыйлар. Укучы өчен, әлбәттә, бу бик аз. Шуңа күрә әсәр аны дулкынландырмый.

Беренче карашка, Г. Бикушевның «Иң бәхетле чүмеч» повестенда хәл башкачарак тора шикелле. Бу әсәрендә автор мөстәкыйль тормыш юлына аяк баскан элекке яшь геройларыннан аерылган. Аның бүгенге герое — шофер Сәлим зур тәҗрибә туплаган кеше. Фин һәм Бөек Ватан сугышында машинасы белән фронт юлларын аркылыга-буйга айкаганнан соң, ул туган авылына, хатыны һәм бала-чак дуслары янына кайта. Ләкин өйдә аны күңелсезлек көтә. Хатыны Фатыйма, колхоз бозауларын үлемнән саклап калу өчен, аларга чәчүлек орлыкны ашаткан. Тиздән ул суд каршына басарга тиеш... Авторны, драматик коллизиягә караганда, геройның эчке дөньясы кызыксындыра. Сәлим үзенең яшьлек елларын, беренче мәхәббәтен, сугыш газапларын тагын бер тапкыр йөрәгә аша үткәрә.

Г. Бикушев сайлап алган теманың тормышчан булуы һәм аның чынбарлык вакыйгаларын киңрәк колачлау өчен зур мөмкинлекләр тудыруы хакында сөйләп торасы юк. Ләкин ул мөмкинлекләр әсәрдә тиешенчә файдаланылмый. Башта безне үзенә җәлеп иткән кешеләр язмышы повестьта төп урынны алмый. Әсәр аерым эпизодларга, истәлекләргә таркала, хикәяченең урынлы-урынсыз сүз уйнатулары аркасында тоныкланып, югалып кала. Ә бит автор геройларның язмышындагы драматизм аша халык һәм аерым кешеләрнең ул авыр еллардагы тормышын киеренкерәк, тулырак итеп күрсәтергә тиеш иде. Кызганычка каршы, әсәрдә без моны күрмибез.

Бәлки, Г. Бикушев бу повестенда тормыштагы вакыйгаларны драматик сурәтләүне түгел, гади кешенең эчке дөньясын лирик чаралар ярдәмендә ачып бирүне үзенә бурыч итеп куйгандыр. Ләкин монда да аны уңышсызлыктан башка нәрсә көтмәгән булыр иде. Г. Бикушев повестенда укучыны үзенә бәйләп тотарлык лирик

һәм психологик моментлар җитәрлек түгел. Мондый уңышсызлыкка китергән төп сәбәпләрнең берсе — автор тарафыннан сайлап алынган хикәяләү формасының камил булмавында. Г. Бикушев бүгенге авыл кешесенең җанлы сөйләм телен стильләштерә. Повестьта бер-берсенә бөтенләй бәйләнеше булмаган эпизодлар күп урын алып тора.

Әсәрнең төп герое — татар кешесе. Әмма язучы аның эчке дөньясын, психологик кичерешләрен рус теле колориты ярдәмендә чагылдырырга тели. Бу алымның кулланылуының табигый булмавы үзеннән-үзе аңлашыла. Шуның өстенә, Г. Бикушев үзе үк сайлап алган сөйләм алымын әледән-әле үзгәртә. Гомумән, ул сөйләгән сүзләрнең дөреслеккә туры килү-килмәве хакында бик аз кайгырта. Хикәяләүнең беренче заттан алып барылуына безне ышандыру мәҗбүри түгел. Моның шартлы алым икәнлеген белүдән без бернәрсә дә югалтмыйбыз. Ләкин авторның үзеннән бу шартлылыкны онытмау таләп ителә. Г. Бикушев исә нәкъ шуны исеннән чыгара. Беренче затта алынган геройның сөйләменә автор интонацияләре килеп керә. Сәлим, мәсәлән, сугыш башланган көнне «көнбатыш яктан плотина җимерелгәндәге шикелле, һаман үсә, көчәя барган куәтле тавыш» ишетелүе турында сөйли. Бу сүзләрнең лирик герой тарафыннан әйтелүенә, ничектер, ышанасы килми. Мондый гомуми фразалар әсәрнең буеннан-буена сибелгән. Аларны укыганда әсәргә булган ихтирам кимегәннән-кими.

Икенче яктан, повестьтагы вакыйгаларны кызыклы, җанлы итү өчен, Г. Бикушевка сүз запасы һәм тормышчан күзәтүләр җитми. Ул һәр очракта диярлек хикәяләү эффектын примитив чаралар ярдәмендә тудырырга омтыла. Нәтиҗәдә геройның эчке дөньясын тулыландырып, баетып торган эмоциональ-психологик кичерешләр кирәгеннән артык гадиләштерелгән һәм ясалмалылыкка корылган адымнар белән каршылыкка керә. Җыеп кына әйткәндә, кеше язмышын бөтен катлаулыгы белән сурәтләп бирү өчен ул кирәкле форманы таба алмаган, шунлыктан әсәрнең тукымасы үтә күренмәле булып чыккан.

Г. Бикушев, бүгенге проза әсәрләре вакыйга-күренешләрне бер-бер артлы сөйләп чыгуга корылмаска тиеш, дигән фикердә тора. Шул принциптан чыгып, ул «Иң бәхетле чүмеч» повестенда хикәяләүнең үзгәрәк формасын сайлаган. Ләкин әлеге форманы эчтәлекне ачып бирү өчен тиешенчә файдалана алмаган.

Безнеңчә, бу кимчелек Г. Бикушевның үз-үзенә җитәрлек дәрәҗәдә таләпчән булмавы белән аңлатыла. Монда, бәлки, аның яшьлегенә, иҗатына әлек ясалган ташламаларның дәвамлырак булуы үзен сиздерә торгандыр. Хәзер инде Г. Бикушев та, Н. Орешина да андый ташламалардан үзләре үк баш тартырга тиешләр. Бу авторларның әсәрләрендәге художество кимчелекләре аларның талантлары, сәләтләре үсүгә торган саен ныграк комачаулый. Бу хакта аларга турыдан-туры әйтергә кирәк.

Татарстанда яшәүче шагыйрьләрдән 1971 елда Р. Кутуйның «Яңа туган ай», А. Вольновның «Август, август» дигән шигъри китаплары дөньяга чыкты. Әдәби эшләнешләре, поэтик әһәмияте ягыннан бу китаплар бер үк югарылыкта тормый.

Р. Кутуйның «Яңа туган ай» җыентыгы «Седая льдина загорелась» исемле шигырь белән ачыла:

Седая льдина загорелась,  
И проступает сквозь нее  
Угласто и сипе  
Чеконм света моя зрелость.

...И ясные рождаются слова.  
Поземка след тихонька заметает.  
А за спиной всплывает острова  
Азорские...  
В душе моей светает.

Бу юлларда китерелгән фикер белән тулысынча килешергә мөмкин. Дөрестән дә, яңа лирик җыентыгы шагыйрьнең иҗади житлегүе турында сөйли. Тик бу җитлегү, минемчә, аңа шактый соңгарып килде. Аның каравы, Рөстәм Кутуй әдәбият мәйданына кемнәрдер биргән әзер рецептлар буенча түгел, озак эзләнүләрдән соң туган үз кичерешләре, үз хисләре белән аяк басты. Мин үзем әзер үрнәкләр буенча тиз һәм җиңел күтәрелгән шагыйрьләргә караганда, үз сукмагы буйлап килгән, иҗатындагы ялгышлардан арынаарына акрынлап үскән әдипләрне якынрак күрәм.

Рөстәм Кутуйның иҗади җитлегүен раслаучы мисалларның берсе — аның поэтик фикерләвенең ачык, шигырь формасының гади һәм аңлаешлы булуы. Кайчандыр бу шагыйрьнең шигырьне катлаулырак итеп язарга кирәк дигән карашны алга сөргәнлеге күпләрнең әле дә хәтерендәдер. Рөстәм Кутуй чыннан да озак вакытлар буе ясалма һәм уйлап чыгарылган шигырь-

ләр язу белән мавыкты. Ә менә бүген инде ул бик хаклы рәвештә: «якты сүзләр туа» дип авыз тутырып әйтә ала.

«Яңа туган ай» җыентыгы өч бүлектән тора. Беренче бүлеккә кергән шигырьләрендә Р. Кутуйның элеккеге поэтик темалары — сугыш елларына туры килгән бала чак, ятимлек, тол калган ана язмышы һ. б. лар яктыртыла. Еллар үтү белән шагыйрь гомумкешелеккә кагылышлы темаларга мөрәҗәгать итә. Сугышка бәйләнешле истәлекләрен ул башкалар белән уртаклаша, кырыс чорның ут-ялкыны көйдергән гади кешеләрнең эчке дөньясына тирәнрәк үтеп керергә тырыша. «Капка», «Ана», «Карчыкларны еш рак тыңлыйм» кебек шигырьләрендә аның поэтик фикерләве тагын да югарырак баскычка күтәрелә.

Китапның икенче бүлеге «Кайтаваз» дип атала. Биредә тормыш турында, илнең үткәне һәм бүгенгесе, үзенең һәм кешеләрнең язмышы турында уйланулар рәвешендә язылган шигырьләр тупланган. Шагыйрьнең поэтик фикерләве, лирик хисләре, җирнең ерак киңлекләренә ишетелеп, кайтаваз булып яңгырый.

Ләкин Р. Кутуйның яңа шигырьләрендә бөтенесе дә ал да гөл дип әйтеп булмый. Образ һәм детальләрне элеккечә катлауландырырга, бер-берсенә өеп бирергә тырышу аның кайбер шигырьләрендә хәзер дә үзен сиздерә.

И лес, как просто в сите
Над просекой крыльца...

Бу юлларның мәгънәсе укучыларның күпчелегенә аңлашылып җитмәячәге көн кебек ачык. Озаклабрак уйласаң, авторның нәрсә әйтергә теләвен аңлап та булыр иде. Ләкин безнең хис-тойгыларыбызга турыдан-туры тәэсир итәргә тиешле поэтик образның шулай катлаулы булуы үзе үк шигырьдән читкә этәрә.

«Өзәңге турында баллада»сындагы кораб трюмында «йөзеп» барган атлар образы да бик авыр аңлашыла. Балладада менә дигән әйбәт строфалар да бар, югыйсә. Әмма ул строфалар шигырьдәге төп фикерне ачып бирү өчен хезмәт итмиләр. Монда да укучы гаепле түгел, авторның тенденциозлыгы гаепле. Аның иҗатындагы бу тенденциозлык еш кына очракларда авторны инде күптән әйтелгән иске фикерләрне кабатлауга илтә. Мәсәлән, аның «Вакыт! Сентябрь...» дип башланган шигыре белән нәкъ шундый хәл килеп чыккан. Ләкин мондый кимчелекләрнең шагыйрь иҗатында кими баруын искәртеп үтмәү гаделсезлек булыр иде. Аның яңа җыентыгында, уңышсыз шигырьләргә караганда, уңышлы шигырьләр, һичшиксез, күбрәк. Моңа мисал итеп китапның икенче бүлегенә урнаштырылган «Урманнардай без дә югалтабыз...» кебек шигырьләрне алырга мөмкин.

Икенче бүлектәге шигырьләр чынбарлыктагы вакыйга һәм күренешләрне лирик «мин» аша чагылдыруга нигезләнеп язылган булсалар, «Акварельләр» дип аталган өченче бүлектә төп нагрузка поэтик картиналарның һәм тормыш күренешләренең үзләренә йөкләнә. Билгеле, китапка кергән шигырьләрне болай ике төргә аерып карау шартлы нәрсә. Өченче бүлектәге шигырьләрдә дә авторның лирик уйлануларына, лирик кичерешләренә шактый урын бирелә. Тик шулай да андагы шигырьләрдә поэтик сурәтләү үзе өстенлек итә. Дөрестән дә, ул шигырьләрдәге картина һәм детальләр акварельдәге шикелле ачык күзаллаулык итеп язылганнар. Бүлекне ачып җибәргән «Картина», «Авыл», «Шагыйрьнең этенә» исемле шигырьләр — әнә шуның матур дәлиле.

Боларның барсы да Рөстәм Кутуй иҗатының җитлегүе, аның диапазоны киңәю хакында сөйли. Аның яңа җыентыгындагы шигырьләре, интонацияләре буенча да, сурәтләү чараларының төрлелеге ягыннан да, элекке шигырьләреннән бик нык аерылып торалар.

Узган ел басылып чыккан икенче бер китапка — А. Вольнов җыентыгына да озаграк тукталырга туры килер шикелле. Әмма бу очракта инде бөтенләй икенче сәбәп аркасында. Безнең уебызча, бу җыентыктагы шигырьләрне укучыга тәкъдим итми торырга кирәк булгандыр. Безнең әдәбиятта бик күпләргә хас булган бер кимчелек бар. Мин ул кимчелекне «тышкы охшашлык» буенча әсәр язу дияр идем. Вакытлы матбугат битләрендә булсын, әдипләребезнең аерым җыентыкларында булсын, ул үзен әледән-әле сиздереп тора. Менә шул тышкы охшашлык әле бик үк сизгер булмаган укучыларны гына түгел, кайбер нәширларны һәм тәҗрибәле редакторларны да алдый. А. Вольновның китабында нәкъ әнә шундый охшашлыкка корылган шигырьләр тулып ята. Беренче карашка, ул шигырьләрдә поэзия өчен кирәк булган нәрсәләрнең бөтенесе дә бар шикелле: аерым кызыклы фикерләр дә әйтелә, рифмалар да матур яңгырый, шигырьнең

үлчәвенә дә тел-теш тидерерлек түгел. Ә ныклабрак карасаң, аларда әдәби әсәрдән таләп ителгән төп нәрсә — образлар ярдәмендә уйлау, фикерне шул образлар аша әйтеп бирү җитми. А. Вольнов шигырьләрендә образлы картиналар, образлы фикерләр юк. Аның «иҗат алымы» рифмалаштырылган строфаларны бер-бер артлы тезеп чыгуга кайтып кала. Сүзләр тукымасы шул чаклы ясалма ки, ул нинди дә булса әһәмиятле эчтәлеккә ия була алмый. Моның шулай икәнлегенә ышану өчен, аның теләсә кайсы шигырен укып карарга мөмкин. Мисалга «Август» шигырен алыйк. Җыентык үзе дә шушы шигырь исеме белән аталган. Шигырьнең беренче юлларында ук автор тарафыннан кулланылган образлы чараларның ясалма, уйлап чыгарылган булуы күзгә ташлана. Бу шигырьдә сүз бер аучы турында бара. Ул, автор әйткәнчә, йөрәгендә туган дәртне басар өчен, август аенда үрдәккә ауга чыгып китә. Һәм берничә үрдәк атып ала. Менә шунда инде ул кинәт кенә үз һөнәренең миһербансыз һөнәр икәнлеген аңлый. Сүз дә юк, авторның әйтергә теләгән фикере матур. Ләкин шигырьдә өстән-өстән генә сөйләнелгән вакыйгалар әхлакый һәм психологик кичерешләр аша да, логик уйланулар аша да сурәтләнмәгән. Бер сүз белән әйткәндә, шигырь эчтәлектән бөтенләй мәхрүм. Ә бит һәр әсәрнең эчтәлеге анда сөйләнгән теге яки бу фактка түгел, ә бәлки поэтик фикергә нигезләнгән булырга тиеш. А. Вольнов шигырендә исә фикер поэтик чаралар аша ачылмаган. Аның башка шигырьләрендә дә эчтәлекне тотып алу бик авыр. Шуңа күрәдер, ахры, шагыйрь үзе дә ниндидер билгесез хәлләр эчендә яшәве, аның белән ниндидер серле көчләр идарә итүе турында бертуктаусыз кабатлый. Аның шигырьләрендә без менә мондый юлларны бик еш очратабыз: «Хет үтерегез, ни өчендер, тагын белмим...», «Мине тагын билгесез көч били...» Аны хәтта туган якларына да «билгесез көч» алып кайта. Болар барысы да шагыйрьнең, чынбарлыкны поэтик фикерләр, табигый сурәтләүләр аша ачып бирәсе урынга, үз йөрәгендә туктаусыз казынуы белән мәшгуль булуы турында сөйли.

А. Вольнов шигырьләренә карата әйтелгән сүзләр кайберәүләргә, бәлки, артык кырыс булып тоелыр. Ләкин бу кырыслык кирәкле һәм урынлы. Шул ук 1971 елда Татарстан китап нәшрияты укучыларга А. Плеяченко һәм В. Панюковның «Заговор» исемле китабын токъдим итте. Әзер, шаблон сюжетка корылган, психологик яктан ифрат примитив һәм сәнгать алдына куелган иң элементар таләпләргә дә җавап бирә алмаган бу китап нәшриятның үзе чыгара торган әсәрләргә карата талымсыз булуын күрсәтә. Дөрес, нәшрият планына кертелгәннән соң әлеге кулъязма әдәби әсәр дәрәҗәсенә күтәрелә язган. Ләкин беркадәр генә. Бу авторлар китапларының дөньяга чыгуы өчен Тихон Журавлевка мең кат бурычлы. Әмма шунысы кызганыч, шушы чиле-пешле әсәрне тиешле конденциягә китерү өчен, өлкән яшьтәге язучыга күпме вакытын һәм көчен сарыф итәргә туры килә. Сорау туа: макулатурага тапшырыр өчен генә яраклы булган бу әйберне планга кертү һәм аннан башкалар кулы белән әдәби әсәр ясау нәшриятка нәрсәгә кирәк булды икән?

Татарстан китап нәшриятын биредә мин юкка гына телгә алмыйм. Нәшрият республикабызда яши торган рус язучыларының әдәби эшчәнлегендә зур роль уйный. Алар өчен ул төп әдәби трибуна булып хезмәт итә. Мәскәүдә яисә илебездәге башка шәһәрләрдә рус телендә чыга торган журналларда басылу безгә, кайберәүләр уйлаганча, җиңел эш түгел. Шуңа күрә бездәге рус язучыларының әсәрләрен башта журнал битләрендә бастыру практикасы юк. Алар үзләренең иҗат җимешләрен турыдан-туры нәшриятка күтәреп барырга мәҗбүрләр. Әлбәттә, Татарстан китап нәшриятының бу өлкәдәге эшчәнлеге гел кимчелекләрдән генә тормый. Г. Паушкинның КамАЗ турындагы китабы, А. Булгаков әсәрләренең яңа басмалары, Р. Кутуйның яңа шигырьләр җыентыгы, Н. Орешина һәм Г. Бикушев китапларының басылып чыгуы нәшриятның безгә үгисетеп карамавын раслый. Ләкин бары тик китап нәшрияты мөмкинлекләреннән генә файдалану безгә көннән-көн авырлаша бара.

...Без монда язучыларыбызның республикабыздан читтә басылган әсәрләре турында сөйләүне үзебезгә бурыч итеп куймадык. Шулай да М. Зарипов һәм Г. Ахуновның Мәскәүдәге «Советская Россия» нәшриятында күптән түгел басылып чыккан «Мы с Волги, из Казани» китабы хакында бер-ике сүз әйтәсе килә. Бу — безнең республикабызның табигый, экономик байлыклары, аның кешеләре турында сөйләүче әдәби, документаль-публицистик әсәр. Дөрес, анда авторларның яңа, үз

күзәтүләре артык күп түгел. Әмма ул бик күпләрне кызыксындырырлык вакыйгаларны һәм биографияләрне пропагандалый. Шуның белән бергә, аның оста язучы каләме белән иҗат ителгән булуын да билгеләп үтәргә кирәк.

Республикабыздагы рус язучыларының иҗади эшчәнлегендәге тагын бер якны искә алып китү зыян итмәс. Алар каләмдәш татар дусларыбызның әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү эшен бер генә минутка да туктатмыйлар. Узган елгы тәрҗемәләр турында сүз барганда, барыннан да элек, Н. Беляев исемен телгә алып узу урынлы булыр. Аның тәрҗемәләре укучыга инде байтактан таныш. Озакламый Н. Беляев тәрҗемәсендә И. Юзеевның шигырьләр җыентыгы, С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы басылып чыгачак. Н. Беляев үзен талантлы, оригиналь шагыйрь буларак та, безнең әдәбиятыбызда кирәкле һәм күптән көтеп алынган оста тәрҗемәче буларак та көннән-көн ныграк таныта бара.

Республикабыз тәнкыйтьчеләре былтыр үз иҗатларында мактанырлык активлык күрсәтмәделәр. Рус һәм татар язучыларының иҗат тәҗрибәләрен гомумиләштерү турында әйткән дә юк. Узган ел безнең тәнкыйтьчеләребез хәтта яңа чыккан китапларны да күрмәмешкә салыштылар.

Без монда 1971 елда укучылар кулына инде барып кергән әсәрләр турында сүз алып бардык. Әлбәттә, иҗади хезмәт нәтиҗәләрен аерым бер вакыт арасы белән үлчәү бик кыен. Узган ел дөнья күргән китаплар аннан алдагы еллардагы хезмәт белән туган әсәрләр. 1971 елда да язучыларыбыз кул кушырып утырмады. Якын киләчәктә укучыларны безнең әдипләребезнең өр-яңа әсәрләре көтә. «Молодая гвардия» нәшриятында А. Булгаковның «Домината» романы, М. Скороходовның яңа повесть һәм хикәяләр җыентыгы тәкъдим ителде. Г. Паушкин һәм Н. Беляев үзләренең яңа әсәрләрен Татарстан китап нәшриятына тапшырдылар. Озакламый, Т. Журавлевның хәрби повестьлары, Ю. Белостоцкий һәм Я. Винецкийның проза әсәрләре, В. Синевның шигырьләр җыентыгы басылып чыгачак.

Бүгенге көндә Татарстанда рус әдипләреннән ике дистәләп кеше Язучылар союзы члены булып тора. Башлап язучыларыбызның саны да арткannan-арта. Киләчәктә аларның тагын да күбрәк, уңышлырак әсәрләр тудырачагына безнең тулы нигезебез бар.

# ЯҢА СҮЗЛЕК БЕЛӘН ТАНЫШКАЧ...

Сүз составы озак вакытлар үзгәрешсез тора алмый. Ел саен, көн саен диярлек яңа терминнар һәм тәгъбирләр, яңа сүз тезмәләре туып тора. Сүз составының шулай өзлексез үзгәреп, тулыланып торуы, шулай ук элекке сүзлекнең файдалану өчен шактый уңайсыз булуы русча-татарча яңа сүзлек төзү мәсьәләсен көн тәртибенә куйды. һәм ул сүзлек безнең кулыбызда менә [1].

Яңа сүзлек зәвык белән бизәлгән, яхшы төпләнгән. Китапның башында кереш сүз, файдаланылган әдәбият исемлеге, сүзлекнең ничек төзелү принциплары, сүзлектә кулланылган тыныш билгеләре, шартлы кыскартулар исемлеге бирелгән. Текст матур хәрефләр белән җыелган. Мисаллар аңлатмадан үзгә шрифт — курсив белән бирелгән. Бу — укуны һәм текстны үзләштерүне шактый җиңеләйтә.

«Русча-татарча сүзлек» тәрҗемәчеләр, нәшрият хезмәткәрләре, газета һәм журнал редакцияләрендә эшләүчеләр, филологлар һәм киң катлау укучылар массасы өчен һәрвакыт кул астында тора торган кулланма. Шуңа күрә аның бер томлы булуы бигрәк тә уңайлы. Элекке дүрт томлы сүзлек 80 мең чамасы сүзне үз эченә алган иде. Бу сүзлектә 50 меңгә якын сүз татарчага тәрҗемә итеп бирелгән. Күренгәнчә, 30 мең сүз кыскартылган. Әмма моңа карап эчтәлеккә әллә ни зыян килмәгән диярлек.

Шул кадәр сүз нәрсә хисабына кыскартылган соң? Бу сүзлектә диалекталь сүзләрнең рус язма һәм сөйләм телендә күбрәк таралганына гына урын бирелгән. Мәсәлән, тата, татка, тать, татьба, татебный кебек сүзләр төшеп калган. Шуның белән бергә, фәнни һәм техник терминологиянең, профессионализмнарның актив кулланыла торганнары гына сайлап алынган. Төзүчеләр күп кенә фәннәр буенча русча-татарча терминологик сүзлекләрнең гамәлдә булуын күз алдында тотканнар.

Сүзлекнең җыйнаклыгын тәэмин итү максатыннан чыгып, бер мәгънәле сүзләргә мисаллар һәм аңлатмалар бирелмәгән. Бер үк төшенчәдәге сүзләрне бер оягa җыеп бирү (эгоистичный, эгоистический), шулай ук бер мәгънәдәге сүзләрнең женский һәм мужской родларын бер мәкаләдә бирү (татары, -татарин, -татарка; телефонист-телефонистка, ябедник-ябедница, радист-радистка, подпольщик-подпольщица) нәтиҗәсендә сүзлекне шактый кыскарту мөмкинлеге туган.

Сүзлекне төзүчеләр сүзләрне кыскарту һәм төшереп калдыру ягында гына тормаганнар. Алар соңгы вакытта барлыкка килгән һәм киң кулланышка кереп киткән лексик берәмлекләргә дә урын биргәннәр. Шундыйлар арасында жень-шень, иглотерапия, лайнер, прилуниться, ракетоноситель, шахиня кебек сүзләр бар. Шулай да барлык яңа сүзләр дә кермәгән. (Мәсәлән, лениниана, марсиянин, видеотелефон, околоземный, неуправляемый, цветомузыка, вирусолог кебек лексик берәмлекләр читтә калган.)

Элек тә һәм хәзер дә кайбер сүзләр ике төрле язылып килде һәм киләләр. Дүрттомлык аларның икесен дә күрсәтте. Бу сүзлектә берсе, әдәбиләшкәне, генә калган. Мәсәлән, элек обуславливать һәм обусловливать, абревиатура һәм аббревиатура, лилея һәм лилия, отара һәм отөра дип тә язарга була иде. Яңа сүзлектә

---

[1] Русча-татарча сүзлек. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел. 50 000 чамасы сүз. Төзүчеләре Ә. М. Ахунжанов, Р. С. Газизов, Ф. А. Ганиев, Л. Т. Мәхмүтова, Х. Н. Мөхәммәтшин, К. С. Сабиров, Ф. Х. Хәсәнов.

аларның соңгы вариантлары гына бирелгән.

Китапның уңай яклары болар белән генә чикләнми, билгеле. Анда мактап телгә алырлык яклар шактый. Әмма шулай да игътибарны ныграк аның кимчелекле якларына юнәлтәсе килә. Бу укучыларга да, төзүчеләргә дә күбрәк файда китерер дип уйлыйм. Яңа басмасын хәзерләгәндә ул кимчелекләр искә алынса һәм төзәтелсә, бигрәк тә яхшы булыр иде.

Төрле катлау укучыларны күздә тотып, аңлавы кыенрак булган кайбер сүзләргә кыска гына булса да контекст белән аңлатма бирелгән. Әмма аңлатмага мохтаҗ булган шактый сүзләр бернинди аңлатмасыз калган. Мәсәлән, депутат, матадор, конвейер, навигация, наркоз, рационализм. Югыйсә, матадор дигән сүзне күпләр беренче тапкыр ишетә дип шикләнми әйтергә була.

Кайбер очракта, артык озын булганда, сүзләрнең мисаллары кыскартылып бик дөрес эшләнелгән. Әмма, күбесенчә, мондый кыскартулар эчтәлеккә зыян китергән. Нәтиҗәдә полисемик сүзләрнең төп мәгънәсе генә калган. Мәсәлән, дүрт томлы сүзлектә «грива» сүзенең дүрт мәгънәсе бирелгән иде. Бу сүзлектә беренче мәгънә (ял) генә калган һәм «львиная грива — арслан ялы» дип өстәлгән. Күргәнегезчә, сүз бик тә ярлыланып киткән. Мондый характердагы кимчелекләр сүзлектә шактый.

Кыскартулар фразеологик һәм идиоматик әйтелмәләргә дә кагылган. Мәсәлән, «дух» мәкаләсеннән «как на духу», «вышибать дух», «присутствие духа», «собраться с духом» сүз тезмәләре төшеп калган. Шуларга алмашка «чтобы духу не было» дигән бер фразеология өстәлгән. «Играть» мәкаләсеннән ун, «черт» мәкаләсеннән 17 әйтелмә төшеп калган.

Телдәге фразеологик һәм идиоматик әйтелмәләр, билгеле булганча, турыдантуры тәрҗемә ителмиләр, аларның икенче телдәге шуңа охшаш ишләрен сайлап алалар. Кайбер очракта сүзлек нәкъ шушы ярамаган юл, ягъни тәрҗемә итү юлы белән китә. Мәсәлән, русларның «повесить голову» дигән фразеологиясе татарча «башны салындыру» дигән мәгънәне белдерми. Аның ише «боегу» була. Бер генә татар кешесе дә «минем күкрәк авызы әрни» дип әйтмәс. Күбесе күкрәк авызының нәрсә икәнен һәм кай җирдә урнашуын да белми. Халык бик матур итеп, «йөрәк әрни», ди.

Сүзлекләрдә фразеологияләр һәм идиомалар гадәттә аңлатманың соңында ромб билгесе белән аерылып бирелә. Сүзлекне төзүчеләр шуңа омтылырга тырышканнар. Тик кайбер очракта фразеологияне гади сүз тезмәләре, атамалар белән буташтырганнар. «Отличие» дигән мәкаләгә «имтияз» дигән сүз өстәп, төзүчеләр бик яхшы иткәннәр (гәрчә бу сүз элекке «Татарча-русча сүзлек»тә булмаса да), әмма «отличительный» мәкаләсеннән «характерлы» дигән тәрҗемәне алып ташлап эчтәлекне шактый ярлыландырганнар.

Кайбер сүзләргә мисал итеп китерелгән җөмләләр татарчага бик үк уңышлы тәрҗемә ителмәгән. «Характеризовать» сүзен ачыклау өчен «это хорошо характеризует его» дигән җөмлә бирелгән һәм ул «бу аны бик яхшы күрсәтә» дип татарчалаштырылган. Беренчедән, монда «бик» сүзе артык өстәлгән, икенчедән, «яхшы яктан күрсәтә» дию уңышлырак булыр иде.

Бер үк мәгънәне белдергән лексик берәмлекләр төрле урында бирелгән. Мәсәлән, летчик-авиатор, земельный-аграрный, защитник-адвокат, перерыв-пауза, сопровождение-аккомпанемент, зодчий-архитектор сүзләре үзара синонимнар. Аларның һәрберсен аерым-аерым тәрҗемә итеп тормыйча, икенче сүзне беренчесенә кайтарып калдырырга мөмкин иде. Югыйсә, аларга бер үк мисаллар да китерелгән. Мәсәлән, «аграрная реформа» һәм «земельная реформа» дигән мисаллар «җир реформасы» дип бер үк төрле тәрҗемә ителгән. Синонимнар булган «брадобрей», «цирюльник», «парикмахер» сүзләре дә, аерым бирелеп, аерым тәрҗемә ителгән. Аларның баштагы икесен «парикмахер» сүзенә кайтарып калдырырга иде, чөнки алар искергән, киң кулланыштан төшеп калган сүзләр бит. Бу лексик берәмлекләрне төрле кешеләр хәзерләгәнгә күрә шундый хәл килеп чыккан. Сүзлекне редакцияләүче аларны күрергә һәм төзәтмәләр кертергә тиеш иде.

Сүзлектә татарча төзелмәгән җөмләләр очрый. Мәсәлән, «объектив» сүзе «объектив (...яки берничә алдагы пыяласы)» дип тәрҗемә ителгән. Мондый җөмлә төзелеше татар теленә хас түгел. Сан нәкъ үзе бәйләнеп килгән сүз алдында, ягъни иярчүчесе янында торырга тиеш. Бу очракта «алдагы берничә пыяласы» дип әйтү кирәк иде.

Сүзлектә сүзләрнең күчерелмә мәгъ-

нәләрен, ягъни лексик метонимияләрен, төп мәгънәләре белән буташтырулар очрый. Мәсәлән, «средство от кашля» дигән сүз тезмәсенең ютәл даруы дигән күчерелмә мәгънә белдерүеннән чыгып, «средство» сүзенә дару, дару чаралары дигән мәгънә биргәннәр.

Тәрҗемә итүе авыр булган яки татарча тәңгәл килә торган мәгънәсе булмаган сүзләрдән яки сүз тезмәләреннән котылуның җиңел юлын тапканнар: аларны сүзлеккә кертеп тә тормаганнар. Мәсәлән, перекрытие, байстрюк, классность, осознанный, есть! (хәрби), общность людей, выхлопной газ, по-домашнему, до глубины души, сильные духом дигән сүзләрне һәм сүз тезмәләрен тәрҗемә итәргә кирәк булса, сүзлекне актарудан файда юк. Хәтта элекке сүзлектә булган «тактическое учение», «бой-баба», «голос сердца» һ. б. сүзтезмәләр яңа сүзлектә урын тапмаганнар. Шундый төшереп калдырулар, өстә әйтеп үткән уңышсыз кыскартулар нәтиҗәсендә, берәр әйбер тәрҗемә итәргә туры килсә, элекке дүрт томлы сүзлекне дә янга алып утырырга кирәк була.

Кайбер рус сүзләре татар теленә лексик берәмлек рәвешендә түгел, бәлки киңәйтелгән сүз тезмәләре белән тәрҗемә ителгән. Мәсәлән, «недотрога — чебен тимәс чер итәр, серкәсе су күтәрми (бик тиз хәтере калучан кеше)» дигән сүз тезмәсе белән аңлатылган. «Ты недотрога» дигән җөмләне ничек тәрҗемә итәргә соң? Алдан китерелгән мәкальнең ни өчендер бер өлеше генә бирелгән. Саба районында аны болай диләр: «Чебен тимәс чер итәр, тукмак тисә тик торыр». Гадәттә бу сүзне хәтере калучан кеше турында түгел, кагылырга, тияргә ярамаган кешегә карата әйтәләр. Китерелгән мәкаль дә шул турыда. «Недотрога» «трогать» дигән фигыльдән ясалган ич.

Еллар үтү белән күп кенә сүзләр, төп мәгънәләреннән тыш, күчерелмә мәгънәгә ия була баралар, ягъни метафора сыйфаты алалар. Мәсәлән, «морж» дигән сүзнең диңгез хайванын гына түгел, кыш көне бәкедә су коенучы кешене дә аңлатуы күпләргә билгеле. «Лопух» әрекмән генә түгел, җебегән, кыюсыз кеше дә. Ә яңа сүзлектә һәркемгә таныш булган менә бу мәгънәләр бирелмәгән.

Яңа әйберләр, яңа товарлар, яңа төшенчәләр барлыкка килү нәтиҗәсендә яңа сүз тезмәләре барлыкка килә. Ун еллап элек «голубое топливо», «голубой экран» дигән сүз тезмәләре юк иде. Хәзер аларның газ һәм телевизор яки телевизор экраны мәгънәсендә йөрүен бала-чага да белә. Ләкин боларның берсе дә сүзлеккә кертелмәгән.

Хәзерге татар телендә бик еш кулланылмасалар да, әмма әле архаизмнар рәтенә кертелмәгән һәм әдәби әсәрләрдә күренгәләп торган гарәп, фарсы, төрки сүзләре бик күп. Революциягә кадәрге һәм совет чоры язучыларының әсәрләрен укып үскән яшьләргә дә андый сүзләр бик таныш. Мәсәлән, золым, мәшһүр, әләм, тәкъдир дигән сүзләрне кем генә белми икән?! Алар явызлык, атаклы, байрак, язмыш дигән сүзләрнең синонимнары бит. Ләкин сүзлекне төзүчеләр «зло», «знаменитый», «знамя (флаг)», «судьба» дигән мәкаләләргә санап үтелгән сүзләрне кертмәгәннәр.

Элекке сүзлектә булса да, сирәк кулланыла торган техник, математик, авыл хуҗалыгы һ. б. терминнар бу сүзлеккә кертелмәгән дип әйтеп үткән идек. Алар кертелмәгәч, татарчага тәрҗемә ителми торган төрле дару исемнәрен дә язып тормау мәслихәт булыр иде. Барлык дару исемнәре дә рәттән санап чыгылмагач бигрәк тә. Мәсәлән, «аспирин» бар, ә шул ук составтагы «аскорбин кислотасы», «асфен», «аскофен» сүзләре, шулай ук киң таралган, халык еш куллана торган адалин, адонизид, акрихин, аллахол, анальгин, анапирин, антастман, астматол һ. б. ш. кебек дару исемнәре юк. Ни өчен бер даруга өстенлек, ә унысына юк? Без монда юри «а» хәрефенә генә башланган берничә дару исемен санап үттек, ә башкалары күпме әле аның?!

Кайбер дару исемнәренә аңлатма бирелгән, ә күбесе аңлатмадан мәхрүм булып калган. Моннан тыш аңлатмаларда бертөрлелек юк. Мәсәлән, валидол (дару), ихтиол (май сыман дару), ментол (бөтнек исе килә торган төссез дару), коллодий (медицинада һәм фотографиядә кулланыла торган куе ябышкак эретмә), морфий (авыртуны баса торган наркотик матдә, дару), пантокрин (болан мөгезеннән алынган дару) диелгән. Мисаллардан күренгәнчә, аңлатмаларның берсендә сыйфатына, икенчесендә исенә һәм төсенә басым ясалган, ә кайберләрендә куллану максаты һәм нәрсәдән ясалуы күрсәтелгән.

Алкушымы «макро»- һәм «микро»- сүзләреннән торган кушма сүзләр бик күпкә җыела. Элекке дүрт томлы сүзлектә бул-

маса да, бу сүзлектә ул алкушымнарны аерым мәкалә итеп биргәннәр һәм «макро»- сүзен «кайбер кушма сүзләр составына керә торган беренче сүз; гаять зур күләмдә булуны белдерә» дип аңлатып бик яхшы эшләгәннәр. Шушы сүзләр үрнәгендә ни өчен «дву(х)-», «еже-» алкушымнарын да аңлатып бирмәскә иде?! Ул вакытта бер-берсенә бик охшаган «ежесекундно», «ежеминутно», «ежедневно», «ежемесячно», «ежегодно» сүзләренең барысын да рәттән санап чыгуның кирәге булмас иде.

Безнең орфографик һәм орфоэпик сүзлекләребез юк. Аның ролен шактый дәрәҗәдә шушы сүзлек үти. Шуңа күрә сүзләрне дөрес язуга өйрәтүче игътибар итәргә кирәк иде. «Зять» сүзе «җизнә» дип тәрҗемә ителгән. Кайбер урыннарда ул шулай дип әйтелә торгандыр. Әдәби телдә «җизни» дип йөртелә.

Үз вакытында дүрт томлы «Русча-татарча сүзлек»нең һәр томына газета-журналларда тәнкыйть мәкаләләре басылып барды. Аларда эшлекле һәм игътибарга лаеклы тәкъдимнәр шактый иде. Әмма яңа сүзлекне төзүчеләр шуларда әйтелгән фикерләрнең берсен дә диярлек игътибарга алмаганнар.

«Сүзлектә рус телендәге «усиление», «нарушение», «обрусение», «изучение», «обессиление», «вскрытие» (мисаллар В. И. Ленинның «Критические заметки по национальному вопросу» әсәреннән) кебек фигыль исемнәрнең күпчелеге кертелмәгән. Сүзлекнең киләчәк басмаларын хәзерләгәндә бу мәсьәләне яңадан уйлап карарга кирәк булыр. Чөнки болар мәгънәгә бай (кимендә икешәр мәгънәгә ия) сүзләр... Ибо — чөнки диелгән, юкса мәгънәсе бирелмәгән... Маститый хөрмәтле дип тәрҗемә ителгән. Монда «атаклы» сүзе уңышлырак, ләкин ул да әле туры килеп бетми. «Эше белән танылган эре әһел дияргә иде»,— дип язган иде Г. Ахунҗанов («Совет әдәбияты». 1960 ел. 9 сан. 149—155 битләр). «Русча-татарча сүзлек турында» дигән мәкаләсендә ул файдалы һәм игътибарга лаек булган бик күп фикерләр әйткән. Ә яңа сүзлекне төзүчеләр аларның берсенә дә колак салмаганнар, хәтта ул мәкаләне укымаганнар да кебек. Ә. Ахунҗанов һәм Л. Мәхмүтова, М. Зәкиев, Л. Яфаров, Г. Мостафин, К. Сабиров фикерләре дә шундый язмышка дучар булган. Л. Яфаров элекке сүзлек турында язылган мәкаләсендә: «Байбак сүзенең беренче мәгънәсе байбак, суер (дала җәнлеге) дип бирелә. Ләкин суерның дала җәнлеге булмыйча, бәлки урман тавыгы (русча глухарь) булуын башка сүзлекләрдән бик җиңел табып була»,— дип язган иде. («Совет Татарстаны» газетасы. 1956 ел. 15 июнь.) Чыннан да шулай бит! Ә без күзәтә торган сүзлек сурокны — байбак, глухарьны суер, урман тавыгы дип тәрҗемә иткән. Шулай итеп, яңа сүзлектә иске ялгыш төзәтелмичә калган.

Л. Яфаровның «говорить», «адамово яблоко», «зайти», «банальность» сүзләренә карата әйтелгән фикеренә дә игътибар итмәгәннәр.

«Сүзлектә рус сүзләренең мәгънәләрен белдерүче кайбер татар сүзләре, кайбер сүзләрнең синонимнары тулысынча үк күрсәтелеп җитмәгән. Актуальный сүзенә «көннең кадагына суга торган» тезмәсен китерергә кирәк иде... Бездельничать — җил куу, тырай тибү; бестолковый — мәнсез; бессильный — куәтсез; вышить — каю; вялый — үшән (ат), җебегән; веять — җилпү, җилгә тоту; выветрить — җил ашау; жадный — нәфесле; жаждать — җан ату, аглыгу, җилкенү; затрудняться — кыймау кебек сүзләрне өстәп чыгарырга мөмкин булыр иде». Бу өзекне без М. Зәкиевнең «Русча-татарча сүзлек»нең беренче томына карата язган мәкаләсеннән китердек. Яңа сүзлекне ачып, шушы сүзләрне карап чыксагыз, бирелгән бер генә мәгънәнең дә өстәлмәвен күрер идегез. Бу — бик аяныч, билгеле.

К. Сабиров дүрт томлык сүзлек турында язган мәкаләсендә («Совет Татарстаны». 1959 ел. 23 декабрь) соңгы вакытта барлыкка килгән «глоукалывание», «межконтинентальный» кебек яңа сүзләрнең сүзлектә урын алмавына офтанган иде. Яңа сүзлектә ул Р. Газизов белән А—М хәрефләренә башланган сүзләрне тәрҗемә итүдә катнашкан. Ләкин үз фикере турында оныткан һәм шул сүзләрне сүзлеккә кертмәгән. Үз сүзе үзенә кадерле булмагач, башкаларныкы турында сөйләп тә торасы юк инде.

Яңа сүзлекне төзүчеләр сүзләргә яңа мисаллар эзләү белән мәшәкатьләнмәгәннәр. Элекке сүзлекнең мисалларын китерү белән чикләнгәннәр. Мәсәлән, более, зло, качество мәкаләләрендә. Шушылар һәм өстә әйтелгән фикерләр бу сүзлек дүрт томлы сүзлекнең кыскартылган яңа басмасы дип уйларга нигез калдыра.

**РЕНАТ ГАЛӘВИН.**

# «ИДЕЛ»нең ЯҢА САНЫ

Идел инешләрдән башлана. Яшь язучыларның әсәрләрен берләштергән «Идел» альманахы әнә шундый инешләрдән тора. Ниһаять, аның икенче саны китап-журнал киштәләрендә урын алды. Альманахның беренче битләре поэтик әсәрләр белән ачылып китә.

... Ут өләшәм!
Җемнәр сугышмый!
Кемгә изге туган Җиребез!
Ут өләшәм!
Гадел Кешеләр!
Ут өләшәм!
Миңа килегез!

Кадыйр Сибгатуллин «Утлар» дип исемләнгән зур күләмле бу шигырендә бүгенге җир, кешелек язмышын, дәверенең четерекле, катлаулы тирбәнешен чагылдырырга омтыла. Ләкин шигырьдә бу гуманистик идея тулысынча ачылып бетмәгән. Прометей образын кертү генә фикер киңлеген үстерә алмый. Бу тема үзеннән-үзе югары стильне сорый. Р. Фәйзуллинның «Керәшчеләр»е һәм «Гадиләргә гимн»ы моңа ачык мисал. Ирексездән, чагыштыру җәһәтеннәнме, Маяковскийның «Война и мир» поэмасын искә аласың. Шагыйрь Җир шарын учына алган. Ул үзе Прометей. Ә Кадыйр Сибгатуллинның «Миңа килегез!» дип дәшүе исә нечкә бер аваз гына булып яңгырый.

Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрендә кеше күңеле һәм табигать халәте аерылгысыз.

...Бишәрләп, бишәрләп кенә
өзелә яфраклар.
Җилпенә сыман күгемдә
яраланган канатлар.

(«Көз»)

Шигырь салмак моң белән агыла. Шагыйрь үзе дә, сүзләре дә сизелми. Бары илаһи аваз гына килә. Сине ярсыта, моңландыра, бәгъреңә кагыла. Үз хәлеңә кайткач кына, шагыйрьгә сокланасың. Аны тавышсыз алкышлыйсың.

...Тынгысыз җилләр йөрәккә
иртә дә, кич тә керә.
Җил дә җил...
Чаганнар түгел,
заманнар аягүрә.

(«Җил дә җил»)

Заман катлаулылыгын тоеп, борчылып, үзенең битараф түгеллеген искәрткән бу юлларны Мөдәррис Әгъләмов язган. Монда без Мөдәрриснең элеккерәк чорда язылган шигырьләре белән очрашабыз. Хәер, әйбәт әсәр искерәмени, уңамыни?!. Ләкин бер нәрсә бар. Шагыйрь әдәбиятта үз юлын тапкан кебек, җәмгыятьтә дә үз урынын табарга тиеш. Шагыйрь һәм шәхес гармоник үсештә булмаса, иртәме-соңмы иҗади үсеш эзлеклелеген югалтырга мөмкин...

Зөлфәтнең халык җырларына вариацияләре матур гына тәэсир калдыра. Бераз сәеррәк тә: дәвыллы йөрәкле Зөлфәтнең шигырьләре тау чишмәсе кебек йөгерек, шашкын, югары көчәнешле булуына күнеккән идек, ә болары тыйнак кына, тын гына, моңсу гына агышлылар. Шагыйрь халык авыз иҗатына изге ядкарь итеп карый. Үз йөрәге аша үткәреп, аңа яңа аһәң өсти.

...Мәхәббәтне зәңгәр яулык итеп
бер агызгач зәңгәр суларга,
әй, сылу кыз...
Агымсуны кире боралмассың,
кирәк түгел ямансуларга,
әй, сылу кыз...

(«Сөю җыры»)

Казан университетында укучы яшьләрнең «Әллүки» берләшмәсе членнары газета-журнал битләрендә сирәк кенә күренеп киткәлиләр иде. Бу альманахта да алар үзләренең барлыкларын раслыйлар, тавыш бирәләр. Фәннур Сафин, Рәшит

Бәшәров, Роберт Миңнуллин, Рәшат Низамиевларның лирик шигырьләре күңелне иркәләрлек, образлы, сәнгатьле. Түбән Камадан торып язучы «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе әгъзаларына да альманахта урын бирелгән.

Авторлар гаять күп. Ә шигырьләр аз. Бер-ике шигырь белән генә шагыйрьнең йөзен, эстетик принципларын билгеләү кыен. Шигырьләр санын, бәлки, кубәйтергәдер?

Яшь язучы Альберт Сафинның «Тагын мәхәббәт хакында» дип аталган хикәясе, һичшиксез, альманахта иң шәп әсәрләрнең берсе.

Хәйдәр — авыл укытучысы — үзенчәлекле образ. Аның яшьлеге тәссез, томанлы узган. Гамьсез, боек уздырган еллары өчен ул үзенә түгел, ә дөньяга үпкәләгән кебек. Мәхәббәткә карата аның үз фәлсәфәсе бар:

«...Гомумән, бездә мәхәббәт дигән нәрсә була алмый, ә бары ниндидер телек, омтылыш, кайвакытта соклану һәм боларның барысын да югалткан тәкъдирдә күңләшү генә бар...»

Хәйдәр сүлпән, аның күңелен тузан баскан. Мондый характерлар, әлбәттә, безнең арабызда бар әле. Автор аны социаль каршылыклар белән бәйләми. Чөнки монда шәхес үзе гаепле. Хәйдәр тышкы дөньядан ниндидер күречмәс тышча эченә яшеренгән. Ни өчен? Шулай ук тирә-юньдә ул таянырдай, якын итәрдәй кеше юкмыни?! Күрше кызы Мәрьямнең көреп йөрүен искәрмимени ул?

Мәрьямнең озакка, Ташкент якларына китүен белгәч, аны сагыш баса, күңелендә кемгәдер үпкә уяна. Димәк, бөтенләй үк битараф түгел икән. Еллар үткәч, Мәрьям кайтып төшә. Нәкъ элеккечә Хәйдәрләргә елмаеп килеп керә. Хуҗа карчыкның сөйләвеннән ул аның тормышка чыгуын белә.

«...Хәйдәр бу сүзләргә исе китмәгән төсле тәрәзәгә борылды һәм озак итеп саргая башлаган моңсу агачларга карап торды. Аның иреннәре кызганыч рәвештә елмая, ә бите буйлап яшь ага иде...»

Еллар үткәч, Хәйдәр өйләнә. Автор нечкә штрихлар белән генә аның күңелендә җуелмас хатирә калганлыгын искәртеп үтә.

Альберт Сафин эчтәлеккә ярашлы моңсу тел белән, матур сурәтләүләр аша ышандырырлык итеп яза алган. Өметле каләм!

Ирек Бәдретдиновның «Караңгы төшкәч» хикәясе тирән кичерешле. Укучыны үз пульсына яраштыра. Әсәрнең канвасы итеп гыйбрәтле вакыйга алына. Яшьлек хатасы. Үкенү хисләре...

Әсрар Галиевның һәм югарыда исемнәре телгә алынган ике авторның да хикәяләрендә сагыш артыбрак китә. Өчесендә дә үзәк геройлары — ир кешеләр. Өчесе дә хикәя соңында елап калалар. Әйтерсең, сүз берләшкәндәй, хор белән елыйлар. Бер үк журналда иңгә-иң торган хикәяләрнең мондый уртак ягы булу күңелсез тәэсир тудыра. «Тальян гармун» бөтенләй башка. Күяшлы. Җиңел генә, бераз юмор сирпетеп язарга яратучан Фаил Шәфигуллин үзенә хыянәт итмәгән.

Очерк — әдәби публицистик жанр. Шул таләпләргә җавап бирерлек, вакыт үңдыра алмый торган очерклар гына альманахта урын алырга тиеш. Минвагиз Зәйнетдиновның альманахка кергән язмасы («Бәйрәм кичендә») һич тә очерк була алмый. Берниндә проблемасы, күтәргән яңалыгы юк.

Публицистика бүлегендә тәнкыйтьче Р. Мостафинның «Офыклардан офыкларга» дигән баш астында яшь шагыйрьләр иҗаты турында уйлануы бирелгән. Җитди һәм кирәк әйбер.

«...Чын шагыйрь нәрсәдән башлана соң? Минемчә, шагыйрь, иң элек, үзенең дөньяга карашын ачыклаудан башлана. Аның халыкка җиткерергә теләгән сүзе, үз темасы, үзен борчый торган һәм әйтми калырга мөмкин булмаган уй-фикерләре булырга тиеш... Зөлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмов иҗатларында мин менә нәкъ әнә шундый сыйфатларны күрәм...»

һәм тәнкыйтьче бу ике яшь шагыйрьнең үзләренә генә хас якларын, характерларын ачып бирә. Спектакльдә актер тамашачы белән сәхнә арасын бәйләсә, әдәбиятта тәнкыйтьче — арадашчы — язучы белән укучы арасын якынайта.

Тәнкыйть мәкаләсе вакытында чаң сугарга тиеш. Әмма альманахтагы бу әйбернең элегрәк язылган булуы сизелә.

Идел буе төрки халыкларының үткән гасырларда рәсем сәнгате ничек үскән, нинди торышта булган? Галим Миркасыйм Госманов «Зур сәнгатьтән кечкенә исталекләр» дигән хезмәтендә тирән фикер белән, акыллы нәтиҗәләр ясап, бу турыда тәфсилләп күрсәтә алган.

«...моңарчы гыйльми хезмәтләрдә, элек татарлар арасында сурәтчелек сәнгате бөтенләй булмаган, чөнки ислам дине

рәсем ясауны катгый рәвештә тыйган, дип аңлатып килделәр.

Бу — билгеле дәверләр өчен дөрес аңлату, әлбәттә. Ләкин аны бөтен чорларга, барлык мөселман илләренә карата кулллану, фикеребезчә, тарихи конкретлык таләпләренә җавап биреп җиткерми кебек...»

Һәм галим шушы фикерләрен ышандырырлык итеп раслый да. Ул зур хезмәтенең фрагменты булган бу кечкенә генә бүлегенә бай эчтәлек сыйдырган. Рәсемнәр белән бирелүе — бер яктан, укучыда кызыклау, бәяләү мөмкинлеген арттырса, икенче яктан, альманахны төрлеләндерә, баета.

Өлкәнрәк язучыларыбызның һәм галимнәребезнең яшьләр табынына кушылуы, үзләренең җитди хезмәтләрен уртага салулары альманахның абруй-дәрәҗәсен күтәрә генә. Бу бик куанычлы күренеш.

Альманах ахырында Туфан Миңнуллинның кемгәдер махсус төбәп адресланган пародияләре бирелә. Хәер, нигә төбәп әйтү, сарказм белән язылган шигырьләр үзләре үк корбаннарын табарлар. Алар үткәнгә генә түгел, бүген һәм иртәгә туачак талантсыз әсәрләргә багышланганнар.

Альманахның бизәлеше, эшләнеше турында берничә сүз. Тышкы кыяфәте беренчесенә карый бераз яктырак, көләчрәк. Ләкин альманах ябыграк чыккан. Аны рухи һәм матди яктан үстерү, киңәйтү өчен повесть жанры кертү бик урынлы булыр иде.

Яшьләр журналы булгач, аның рәсеме дә яшьләрчә, хәрәкәтчән булырга тиештер. Ләкин художник Степан Кульбака рәсемнәре «Әлифба»га ясаган сыман. Артык гади, сүлпән эшләнгәннәр. Казан дәүләт университеты яшьләре дигән рубрика өстендә тырма тотып эшкә баручы колхозчылар сурәтләнә. Студент халкы елның күп өлешен аудиторияләрдә, гыйльми кафедраларда үткәрә ләбаса.

Республикабызда яшь язучылар саны елдан-ел арта бара. Бу бик табигый. Хәрәкәт-үсеш, зур тезелешләр дәвере. Шәхеснең офыгы, фикерләве, карашы киңәя. Ул инде үз эченә генә бикләнеп калмый, тар масштабларга гына сыя алмый. Кечкенә генә альманахның зур кораб шикелле әкрен, озак килүе яшь иҗатчыларны, әлбәттә, канәгатьләндерә алмый.

Инешләр бүләп тормасын, бергә кушылып Идел булсын иде.

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ,**
**Казан университеты студенты.**

# ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ РУС ТЕЛЕНДӘ

Татар халык мәкальләренең аерым үрнәкләре рус теленә әле узган йөзнең беренче яртысында ук тәрҗемә ителә башлаган иде. Күренекле фольклорчы И. Снегиров үзенең «Русские в своих пословицах» исемле китабында (I том, 1831 ел), рус мәкальләрен башка халыкларның мәкальләре белән чагыштыру максатында, татар халкының да 42 мәкален урнаштыра. Беркадәр соңрак профессор И. Березин «Народные пословицы турецкого племени» дигән мәкаләсендә һәм аңа бирелгән кушымтада 400 гә якын татар мәкаленең русча тәрҗемәләрен китерә. Татар халкының афористик иҗаты үрнәкләре атаклы тюркологлар В. В. Радлов һәм Н. Ф. Катанов хезмәтләрендә дә күп очрыйлар. Совет чорындагы басмалардан иң әһәмиятлесе итеп «Пословицы и поговорки народов Востока» җыентыгын (Мәскәү. 1961 ел) күрсәтергә кирәк. Анда татар халык иҗатыннан 745 мәкаль һәм әйтем кертелгән.

Әмма, татар мәкальләре русчага шактый күптәннән тәрҗемә ителеп килсәләр дә, әле безнең мәкальләрнең рус телендә **махсус җыентык** булып басылганы юк иде. Ниһаять, күптән түгел без шундый беренче җыентыкны кулыбызга алу бәхетенә ирештек: Мәскәүдәге «Детская литература» нәшрияты 100 мең данә тираж белән татар мәкальләрен аерым китап итеп бастырып чыгарды [1].

Күләме ягыннан зур булмаса да, җыентык илебездә яшәүче халыкларны татар мәкальләренең иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру бурычына җавап бирерлек итеп

[1] Татарские пословицы. Төзүчесе. Х. Ярми. Тәрҗемәчесе Р. Моран.

тезелгән. Ул халкыбызның туган ил, хезмәт, батырлык, дуслык, кумәклек, акыл, белем турындагы мәкальләрен эченә ала. Бу мәкальләр, эчтәлекләреннән чыгып, 9 тематик бүлеккә аерып урнаштырылган.

Җыентыкның моңа кадәр дөнья күргән басмалардан тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге бар: андагы мәкальләр сүзгә-сүз түгел, ә шигъри тәрҗемәдә бирелләр. Афористик әсәрләрне бер телдән икенче телгә күчерү никадәр кыен булуы мәгълүм нәрсә. Гомумән алганда, тәрҗемәче бу авыр эшне уңышлы башкарып чыккан. Үз тәрҗемәләрендә ул оригиналга хас булган фикер тирәнлеген, тапкырлыкны, җыйнаклыкны, сурәтлелекне саклый алган. Мәсәлән:

Иленнән аерылган —
Канаты каерылган.

Без родины милой
Будешь птицей
бескрылой.

Башта хезмәт,
Аннан хөрмәт.

Сначала труд,
А почести потом придут.

Тәрҗемәләрнең сыйфаты турында сүз алып барганда, аларда татар мәкальләренең ритмик төзелешенә, рифмалар системасына кагылышлы күп кенә үзенчәлекләр ачык күренүен әйтергә мөмкин. (Мәкаль юлларының цезуралар ярдәмендә ритмик буыннарга бүленүе, аларда иҗекләр санының һәрвакта да тигез булмавы, эчке рифмаларның киң кулланылуы һ. б.)

Слово сказать —
как ломоть отрезать.
Не приставишь назад.

Добрый попутчик — в пути сподручник,
С плохим отправишься — состаришься.

Для лежебок
И солнце всходит не в срок.

Әлбәттә, югарыда әйтелгәннәрдән тәрҗемәченең хезмәте кимчелекләрдән бөтенләй азат икән дип нәтиҗә ясарга ярамый. Мәсәлән, кайбер очракларда русча текст оригиналның мәгънәсен тәгәл ачып бирә алмый.

Идәне җир,
Ишеге җил булсын,
Әмма егете ир булсын.

Пусть и пол земляной,
И ветер из щели дверной,
Был бы он сам мужчина, герой,

Игътибар итегез: өченче юлда тәрҗемәче «егет» сүзен төшереп калдырган һәм үзеннән «герой» сүзе өстәгән. Нәтиҗәдә мәгънә үзгәргән. Халык телендә бу мәкаль батырлык, геройлык турында сүз барганда түгел, бәлки кыз ячылаганда, кияү сайлаганда кулланыла. Әйтик, кызның әтиәнисе, егетнең ярлылыгын сылтау итеп, кирелэнеп-икеләнеп торсалар, тәҗрибәле ячы бик тиз генә шушы мәкальне китереп әйтә. Ягъни, егетнең ярлылыгына бик игътибар итмәгез, иң мөһиме аның үзенең яхшы кеше булуында, ди. Бу мәкаль мәгънәсе белән русның «С милым и в шалаше рай» дигән мәкаленә якын тора.

Тәрҗемәдә мәгънәне тәгәл саклау, һичшиксез, мәҗбүри шарт. Шул ук вакытта бу мәгънәнең татар фольклорында нинди сурәт-тасвир чаралары ярдәмендә белдерелүен күрсәтү дә әһәмиятле. Бу таләп бигрәк тә традицион образлар кулланылган мәкальләргә кагыла. Кызганычка каршы, тәрҗемәче моны вакыт-вакыт онытып җибәрә.

Дөя дә бүләк,
Төймә дә бүләк.

И лошадь подарок,
И ложка подарок.

Сүз дә юк, тәрҗемә татар мәкаленең эчтәлеген — бүләк кешене якын итеп бирелә, шуңа күрә аның зуры да, кечкенәсе дә, кадерле, дигән фикерне ачык аңлата. Ләкин анда «дөя» һәм «төймә» урынына, күрәсең, аваздаш булулары өчендер, «лошадь» һәм «ложка» алынган. Монда рус укучысы өчен бер нәрсә билгесез булып кала: дөя һәм төймә белән чагыштыру татар халык иҗатында зурлык һәм кечкенәлек төшенчәләрен капма-каршы куеп күрсәтү өчен үзенә күрә бер эталон ролен үти. Моның мисалларын башка мәкальләрдә, хәтта табышмакларда да күрергә мөмкин: «Эше төймәдәй, шау-шуы дөядәй». «Үзе бара дөядәй, эзе кала төймәдәй» (таяк) һ. б.

Соңгы сүз итеп шуны әйтергә кирәк: татар мәкальләренең рус телендә аерым китап булып чыгуы бик күңелле күренеш. Бу беренче карлыгач артыннан, озак көттермичә, яңа, зуррак күләмле җыентыклар да дөнья күрер, тәрҗемәләрнең сыйфаты тагын да яхшыра барыр дип ышанасы килә.

ХУҖИ МӘХМҮТОВ.

# ТАГЫН КАРАИМНАР ЯНЫНДА

Укучыларыбыз хәтерлиләрдер, «Казан утлары» журналында (1968 елның 1 саны) караим шагыйре С. А. Фирковичның иҗаты турында шагыйрь Мостафа Ногман мәкаләсе басылган иде. Бу мәкалә укучыларда зур кызыксыну уятты, редакциягә бик күп хатлар килде. Укучылар караимнарнең тормышы, әдәбияты, фән эшлеклеләре турында тулырак мәгълүмат бирүне сорап яздылар.

«Казан утлары» журналы Польшада академик А. Зайончковский кулына эләгә. Тюрколог галим журналда басылган бу мәкаләгә уңай бәя бирә, аның авторына хат яза. Түбәндә без шул хатны һәм М. Ногманның караимнар тормышы белән киңрәк таныштырган яңа мәкаләсен урнаштырабыз.

**Хөрмәтле коллега!**

*Сезнең 12 июльдә язган хатыгызны һәм китабыгызны шушы арада, курорттан (Чехословакиядән) кайткач кына алдым. Сезнең иҗатыгыз белән танышып һәм Тракай караимнары турындагы эчтәлекле мәкаләгезне укып, бик канәгать булдым, игътибарыгыз өчен рәхмәт.*

*Хәзерге вакытта мине Көнчыгышны өйрәнүнең башка мәсьәләләре кызыксындырса да, элегрәк мин Литва караимнарының теле һәм әдәбиятына бәйләнешле фәнни мәсьәләләре белән дә шактый күп шөгыльләнгән идем.*

*СССРдагы каләмдәшләрем белән бергәләп язган караим теле сүзлегенең (русча-полякча тәрҗемәсе) чыкканын түземсезлек белән көтәм. Инша алла дигәндәй, 50 еллык хезмәттән соң фәнни җимешләремне күрермен дип өметләнәм.*

*Казан татарларының теле һәм татар культурасы миңа бик якын. Минем иң якын каләмдәшләремнең берсе — мәрхүм профессор Рәхмәти Арат (алла рәхмәт әйләсен!) үзе Казан татары иде.*

*Үземнең кечкенә генә булса да рәхмәтемне белдерү өчен, сезгә Шаһнамә турындагы мәкаләмне җибәрәм, тәрекләр әйтмешли, карынча-кадәренчә.*

*Киләсе айда, 21 августта, үзебезнең Академия эшләре һәм Азия халыклары институты белән хезмәттәшлек итү уңае белән мин Мәскәүгә барып чыгарга тиешмен. Әгәр август азакларында сез дә Мәскәү яки Ленинградта була алсагыз, сезнең белән очрашуыма бик шат булыр идем. Минем адресны Азия халыклары институтыннан белешә аласыз.*

*Ориенталистика өлкәсендәге зур традицияле атаклы Казан университетында эшләвегез белән мин бик шатмын.*

*Кызганычка каршы, минем анда булганым юк, мин аны әдәбият буенча гына беләм.*

*Дусларча кайнар сәлам белән*

*А. Зайончковский.*

Литва җирендә урнашкан гүзәл Тракай шәһәре. Аның әйләнә-тирәсендә күлләр җәйрәп ята. Бу тирән күлләрдә ел саен бөтен Союз күләмендәге су спорты ярышлары үткәрелә. Күлләрнең иң зурысы Гальвә дип атала. Күл уртасындагы атауда Литва князьләренең борынгы хәрби крепосте урнашкан булган. Анда хәзер — Литва тарих музееның филиалы.

Тракай — элек-электән караимнар яшәп килгән шәһәр. Өч тәрәзәсе белән урамга караган бер катлы караим өйләре шәһәрнең башка йортларыннан аерылып тора. Караимнарның көнчыгыш архитектурасы белән төзелгән гыйбадәтханәләре бар. Алар аны гарәптән алынган сүз белән «кинеса» дип атыйлар.

Тракайның үзәк урамына караим этнографик музее урнашкан. Анда кечкенә төрки халыкның тарихына, тормыш-көнкүрешенә караган бик кызыклы экспонатлар саклана. Алар барысы да диярлек көнчыгыш халыкларының көнкүреш әсбапларын хәтерләтә. Гаҗәеп бер маһирлык белән ясалган бу зиннәтле әсбапларны гиран дулкынлану белән карыйсың. Караим шагыйре Семен ага Фиркович бу әсбаплар турында аңлатмалар биреп бара.

Соңыннан шәһәр клубына юл тоттык. Халык шыгрым тулы. Анда Польша Фәннәр академиясенең хакыйкый члены профессор Ананьян Александрович Зайончковскийны искә алу кичәсе икән. Варшава университетының фәннәр докторы тюрколог Александр Дубинский (ул үзе дә Тракайда туып үскән караим) галимнең тормыш юлы, гыйльми хезмәтләре турында кызыклы лекция укый.

## А. ЗАЙОНЧКОВСКИЙ

Ул караим семьясында туып, балалык елларын шушы гүзәл Литва җирендә үткәргән, Вильнюс гимназиясен тәмамлаганнан соң, Краков университетында укып, мөселман көнчыгыш филологиясе буенча гыйльми эшче булырга хәзерләнә. Укуын тәгәлләгәч, төрки телләрнең чагыштырма грамматикасы темасына караган диссертация яклый. Соңыннан Германиядә, Франциядә һәм Төркиядә белемен камилләштерә. Чит илләрдән кайткач, яшь галим Варшава университетында эшли һәм караим теле буенча гыйльми хезмәт язып бастыра.

1933 елларда А. Зайончковский университетта гарәп, фарсы, төрек филологиясеннән лекцияләр укый, госманлы төрек әдәбиятын тирәнтен өйрәнеп, гыйльми хезмәтләр яза.

1945 елда А. Зайончковский профессорлык исемен ала һәм Варшава университеты каршындагы көнчыгышны өйрәнү институтының директоры итеп билгеләнә.

Ул, барлык төрки халыклар өчен уртак әдәби хәзинә булган «Хөсрәү вә Ширин» әсәрен тәрҗемә итеп, текстологик анализ ясый, аның сүзлеген төзи һәм бу хезмәтен өч томда бастырып чыгара.

Безнең Казан университетында да «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы А. Зайончковский текстларыннан күчереп бастырылды. Һәм бу китап студентларга, аспирантларга кыйммәтле кулланма булып хезмәт итә.

Көнчыгыш телләре галиме тюркологик хезмәтләр белән генә чикләнеп калмый. Аның Иран әдәбиятына караган гыйльми хезмәтләре дә бар. Ул аларны Польша һәм Иран матбугатларында бастыра. Әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә А. Зайончковский зур осталык күрсәтә. Бөек поляк шагыйре Адам Мицкевичның сонетларын караим теленә күчерә, Иран шагыйрь Хафиз Ширазиның алтмышка якын газәлен поляк теленә тәрҗемә итеп, кереш сүз һәм аңлатмалар белән бастырып чыгара.

А. Зайончковский 1961 елда Польша Фәннәр академиясенең хакыйкый члены — академик итеп сайлана һәм академиянең ориенталистика бүлегенә җитәкчелек итә. Ул үз гомерендә 250 дән артык гыйльми хезмәт бастыра.

Профессор А. Зайончковский көнчыгыш һәм көнбатыш телләрен яхшы үзләштергән, киң эрудицияле, дөньякүләм танылган галим һәм югары культуралы күркәм кеше иде. Ул Берлиндагы Гумбольд исемендәге университетның, Манчестер һәм Тбилиси университетларының почетлы докторы итеп сайлана һәм совет галимнәре белән һәрвакыт тыгыз элемтәдә тора. А. Зайончковский көнчыгышны өйрәнү буенча үткәрелгән халыкара конгрессларга да даими рәвештә катнашып килә.

Үткән ел май аенда А. Зайончковский Рим шәһәренә тюркологларның халыкара конгрессына Польша Фәннәр академиясенең вәкиле булып бара.

Кызганычка каршы, бу аның соңгы сәфәре булган икән — мәшһүр галимнең тынгысыз йөрәге чит җирләрдә тибүдән туктап калды.

Тюркология фәне дөньякүләм зур вәкилен югалтты. Караим халкы исә үзенең бөтен дөньяга танылган талантлы угылыннан мәхрүм булды.

Польша галиме А. Дубинскийның бу мәшһүр галим турындагы тирән эчтәлекле докладын без дулкынлану белән тыңладык. Яшь галим үзенең сүзен, А. Зайончковский профессор Т. Ковальскийның талантлы шәкерте иде, дип тәгалләде.

## Т. КОВАЛЬСКИЙ

«Казан утлары» журналында (1971 елның 9 саны) Марсель Бакиров «Шигырь тарихына сәяхәт» исемле мәкаләсендә Т. Ковальскийның «К вопросам формального изучения поэзии турецких народов» (Әзербәйҗан дәүләт университеты көнчыгыш факультеты хәбәрләре — 1926 ел) дигән фундаментал хезмәтенә ишарә ясый.

Билгеле булганча, Т. Ковальский да Литва караимнарыннан икән. Ул бик күп еллар Варшава университетының Көнчыгыш филологиясе профессоры вазифасында эшләгән һәм тюркология буенча кыйммәтле хезмәтләр язып калдырган галим була.

## М. В. КОБЕЦКИЙ

Тагын шуны да әйтергә кирәк, караим халкы профессиональ революционерлар да үстергән.

1903 елдан партия члены, В. И. Ленинның эмиграциядә вакытындагы якын көрәштәшләреннән берсе М. Кобецкий РСДРПның Баку, Екатеринослав, Петербург комитетларының революцион эшендә актив катнашып килә. 1906 елда полиция тарафыннан кулга алына. 1908 елдан башлап М. Кобецкий Копенгаген шәһәрендә политэмигрант булып яши. Партия кушуы буенча ул большевикларның чит илдә басылып килгән «Пролетарий» газетасын һәм соңга таба РСДРПның үзәк органы булган «Социал-демократ» газетасын яшерен рәвештә Россиягә үткәреп тору эше белән шөгыльләнә. («Известия». № 95. 22 апрель. 1967 ел. «Ясность и простота».)

1910 елда Копенгагенда II Интернационалның конгрессы була. Бу конгресста В. И. Ленин да катнаша. Анда барыр алдыннан В. И. Ленин М. Кобецкийга хат язып, шәһәрдә үзенә туктар өчен уңайлырак бүлмә хәзерләп куюын үтенә. Шул вакытта Ленин берничә көн торып киткән бу өй хәзергәчә сакланган икән. Анда хәзер мемориаль билге куелган. («Известия». № 216. 13 сентябрь. 1969 ел. «Есть в Копенгагене старый дом».)

М. Кобецкий эмиграциядә тугыз елга якын гомер кичерә. Шул дәвердә ул В. И. Ленин, Н. К. Крупская белән хатлар аша даими рәвештә бәйләнеш тота, алардан киңәшләр алып тора.

Бөек Октябрь революциясеннән соң М. Кобецкий партия, совет органнарында җаваплы эшләрдә эшли, озак еллар чит илләрдә Совет дәүләтенең дипломатик вәкиле булып хезмәт итә. 1971 елда М. Кобецкийның тууына 90 ел булды.

Без шушындый аз санлы бер төрки халыктан — караимнардан талантлы галимнәр, революционер, дипломатлар үсеп чыгуына чын күңелдән сокланабыз.

### ВОРОШИЛОВГРАД ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ АТНАЛЫГЫ

Ворошиловград өлкәсе шәһәрләрендә һәм авылларында СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы булды. Атналыкта катнашучыларны — Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе Зәки Нури, «Казан утлары» журналы баш редакторы Гариф Ахунов, Тукай премиясе лауреаты Шәүкәт Галиев, Шамил Рәкыйпов, Ренат Харисов, Рафаэль Мостафин, Габдрахман Минский, Нәби Дәүли, Марзия Фәйзуллина, Туфан Миңнуллин, Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Илһам Шакиров, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы Венера Шәрипова, Татарстанның атказанган артисты, Тукай премиясе лауреаты Айрат Арсланов, Татарстанның атказанган артисты Эмиль Җәләлетдинов, җырчылардан Нажия Теркулова, Вәфирә Гыйззәтуллина, консерватория укытучысы Тәлгат Әхметов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Нәзнинә Сабитовская составындагы әдипләр һәм сәнгать осталары делегациясен шахтерлар, завод-фабрика эшчеләре, инженер-техник хезмәткәрләре, авыл хуҗалыгы хезмәт ияләре бик җылы каршыладылар.

Татарстан язучылары, сәнгать осталары дүрт төркемгә бүленеп, өлкәнең уннарча шәһәрләрендә һәм авылларында булдылар. Хезмәт ияләре аларның чыгышларын зур кызыксыну белән тыңладылар, татар культурасына кагылышлы күп сораулар бирделәр.

### «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫ

Республикабыз җәмәгатьчелеге, Советлар Союзының төрле почмакларында яшәүче меңнәрчә укучылар, әдәбият сөючеләр «Казан утлары» журналының 50 еллык юбилеен киң итеп билгеләп үттеләр. Бу уңай белән клубларда, китапханәләрдә укучылар конференцияләре үткәрелде, журналның авторлары — татар язучылары һәм шагыйрьләре — укучылар белән очраштылар.

Юбилейга багышланган тантаналы җыелыш Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында үткәрелде.

Җыелышны Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе Зәки Нури ачты. «Казан утлары» журналының баш редакторы Гариф Ахунов докладыннан соң, редакция коллективына КПССның Татарстан өлкә комитеты, Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры коллективы, Камил Якуб исемендәге Матбугат комбинаты коллективы, Татарстан художниклары союзы идарәсе, СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты коллективы, «Татарстан яшьләре» редакциясе коллективы, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Хезмәт Кызыл Байрак орденлы Казан дәүләт университеты галимнәре һәм студентлары, Татарстан телевидение һәм радио тапшырулар комитеты коллективы, Казан дәүләт педагогия институты, Казан культура институты, КПССның Чаллы шәһәр комитеты, «Азат хатын» журналы редакциясе коллективы, Татарстан композиторлары союзы, Татарстан АССР Министрлар Советының Матбугат идарәсе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе коллективы, «Советская Татария» газетасы редакциясе коллективы, Татарстан Ленин орденлы нефть һәм газ чыгару берләшмәсе коллективы, Татарстан АССР Мәгариф министрлыгы, Хезмәт Кызыл Байрак орденлы Казан дәүләт авиация институты профессорлары, укытучылары, студентлары, КПССның Казан шәһәре Бауман район комитеты, «Яшь ленинчы» газетасы, «Ялкын» журналы редакцияләре коллективы,

КПССның Азнакай район комитеты һәм «Маяк» газетасы редакциясе коллективы, язучыларның Пермь шәһәре оешмасы, Татарстан китап нәшрияты, С. П. Горбунов исемендәге ике тапкыр Ленин орденлы һәм Кызыл Байрак орденлы Казан авиация заводы эшчеләре, инженер-техник хезмәткәрләре, Татарстан АССР Культура министрлыгы һ. б. предприятиеләр, учреждениеләр, уку йортлары исеменнән котлау адреслары тапшырылды, истәлекле бүләкләр бирелде.

«Правда» газетасы редакциясе, үзбәк язучылары исеменнән Әсгать Мохтар, Назир Сафаров, Зиннәт Фәтхуллин, Исхак Зәбиров, Бадулла Уразаев, Мәсгут Рәсүли, Таҗикстан язучылары журналы «Садои Шәрекъ» редакциясе, Татарстан АССРның Дәүләт музее, Арча район газетасы редакциясе, КПССның Әгерҗе район комитеты, КПССның Лениногорск шәһәр комитеты, Үзбәкстан язучылары органы — «Шәрекъ йолдызы» журналы редакциясе, Пермь өлкәсе, Барда районында чыга торган «Таң» газетасы редакциясе һәм редакция каршындагы әдәбият түгәрәге членнары, Татарстан язучылары союзының Әлмәт бүлеге, Мари язучылары журналы «Ончыко» редакциясе, Казандагы Горький исемендәге музей коллективы, Чуваш язучылары журналы — «Ялав» редакциясе коллективы, Татарстан журналистлар союзы идарәсе, Саратов шәһәрендә чыга торган «Волга» журналы редакциясе коллективы, Чиләбе шәһәреннән шагыйрь Камил Мостафин, «Дружба народов» журналының баш редакторы Сергей Баруздин, илебезнең төрле якларыннан күп санлы укучылар журналны котлап телеграммалар җибәрделәр. Шул телеграммалардан кайбер юлларны укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

*«Кадерле дуслар!*

*«Дальний Восток» журналы редакциясе һәм Хабаровск язучылары ерактагы чал Амур буйларыннан Идел-әнкә буйларына үзләренең туганлык сәламнәрен җибәрә. Ярты гасырлык юбилеегез белән кайнар рәвештә котлыйбыз. Сезнең журнал, аның тарихы, анда басылып килә торган әсәрләр Ватаныбызның күп милләтле әдәбияты үсешенең ышандыргыч дәлиле.*

*Без, Ерак Көнчыгышта яшәүчеләр, барлык совет халыклары белән берлектә коммунистик җәмгыять төзүче сезнең халыкның культура үсешендәге олы юлын аеруча ачык күрәбез.*

*«Казан утлары» журналы чәчәк атсын! Аның битләрендә совет кешесенә лаек булган югары художестволы әсәрләр һәрвакыт басылып барсын! «Казан утлары» тагын да яктырак янсын!*

**«Дальний Восток» журналы редакциясе, Язучыларның Хабаровск шәһәре оешмасы».**

*«Мизгелнең иң күркәм чагы,*
*Һәр яфрактан җыр-моң тама...*
*Ә «Казан утлары» тагы,*
*Илаһи бер кодрәт чәчеп,*
*Хозурланып, балкып яна!*

*Бер сезгә түгел, безгә дә*
*Бик кадерле бу минутлар.*
*Бу онытылмас минутларда*
*Нинди генә изге теләк*
*Телик соң якын дусларга?!*

*Безнең дуслык күңелегезгә*
*Һәрчак әйгор[1] — күпер булсын!*
*Җырларыбыз барчагызга*
*Ахактай ак «Агыйдел»нең*
*Ак сәламен юлыктырсын!*

**«Агыйдел» журналы редакциясе коллективы»**

*Хөрмәтле иптәшләр, каләмдәшләр!*

*Шушы тантанада утырганда, сөекле даһи Тукаебызның «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» дигән горур сүзләре искә төште. Шагыйрьнең хыялында олы әдәбиятлы һәм сәнгатьле, мәгърифәт үзәге Казан булуына шикләнмибез. Республикабызны гына түгел, ил чикләрен дә узып чыккан, күп тарала торган «Казан утлары» журналыбыз — нурлы Казанның иң якты нурларыннан берсе.*

*Без аны чын мәгънәсендә әдәбиятыбызның олы Казаны дип атый алабыз. Барлык яңа әсәрләр шушында кайнап, шушында пешеп, шушында өлгерә, язучылар һәм шагыйрьләр зур әдәбиятка юлга чыкканда шушы журнал путевкасын алалар. «Казан утлары» татар совет әдәбияты утларын еракларга илтә. Идел буенда һәм Уралда, Урта Азиядә һәм Ерак Көнчыгышта — илебезнең теләсә кайсы почмагында яшәүче татар укучылары совет әдәбияты һәм тугандаш халыклар әдәбиятларының иң яңа һәм иң яхшы үрнәкләре белән шушы журнал аша танышалар.*

*Журналның юбилее безгә, журналистларга да, күп меңләгән хәбәрчеләргә дә зур бәйрәм. Безне — барыбызны да яңа кеше тәрбияләү бурычлары берләштерә. Язучы-*

*лар вакытлы матбугатта актив катнашалар. Безнең теләк: бу иҗади дуслык һаман ныгысын, һаман үссен һәм һаман тирәнәйсен иде!*

*Без, журналистлар, безнең каләмдәшләребезгә, безнең юлдашыбызга — «Казан утлары»на әдәбиятыбызны замандашларыбызга багышланган яңа әсәрләр белән баетуын, әдәби-тәнкыйть материалларына күбрәк урын бирүен, публицистик тавышын көчәйтүен, очерк жанрына игътибарын тагын да арттыруын телибез.*

*Татарстан журналистлар союзы, газета-журналлар редакцияләре исеменнән, күп меңләгән хәбәрчеләр исеменнән «Казан утлары» коллективын, аның авторларын журналның 50 еллыгы белән чын күңелдән котлыйбыз; аның утлары мәңге сүнмәс булсын, аның нуры тагын да яктырак булып еракларга балкысын!*

**Татарстан журналистлар союзы**

*Илең күтәргәнне күтәрәсең,*
*Җылытасың безнең тормышны,*
*Рәхим ит дип, түргә уткәрәсең*
*Галиҗәнаб эшче сыйныфны.*

*Син — хезмәттәш безнең,*
*Рәхмәт сиңа,*
*Нурың тагын, тагын көчәйсен,*
*«Казан утлары»ның яктысына*
*КамАЗ утлары да өстәлсен.*

Кама автозаводы төзелеше эшчеләре,
Чаллы шәһәре».

*«Яңа Зеландия утравы,*
*Веллингтон шәһәре.*

*Без, совет илчелеге хезмәткәрләре, Казаннан бик еракта булсак та, сездә җәй, ә бездә кыш вакыты башланса да һәм севекле Совет Татарстанында көн икән, бездә караңгы төннәр вакыты булуына да карамастан, «Казан утлары»ның нурлары безгә тикле дә килеп җитә.*

*...«Казан утлары» 50 ел дәвамында укучыларны татар әдәбиятының иң уңышлы әсәрләре белән таныштыра, халыкны коммунистик рухта тәрбияләүдә партиягә зур ярдәм итә.*

*Мин һәм иптәшем Рәшидә, журналның подписчиклары буларак, ихлас күңелдән юбилей белән тәбрик итәбез, киләчәктә тагы да мөһимрәк иҗади уңышларга ирешүегезне телибез.*

*«Казан утлары»ның нуры, Чулпан йолдызы нуры кебек, кайсы илгә генә барсаң да балкып тора.*

Зур, бик зур ихтирам белән —
Рәшидә һәм Искәндәр Габдуллиннар».

*«Илле ел.*
*Уйласаң,*
*Күпме юл үтелгән.*
*Халкыбыз күңеленә*
*Күпме нур бөркелгән!*

*Күпме яшь бөреләр*
*Ачылган нурыңнан.*
*Пионер гаскәре*
*Агыла юлыңнан.*

*Яшәгән саен гел*
*Яшәреп бар шулай*
*Укучы каршына,*
*Гасырлар каршына.*

«Яшь ленинчы» редакциясе».

Җыелыштан соң Татарстан сәнгать осталары көче белән зур концерт куелды.

* * *

Пермь шәһәрендә дә «Казан утлары» журналының 50 еллыгына багышланган әдәби кичә үткәрелде. Я. М. Свердлов исемендәге культура сараеның 1200 тамашачыны сыйдырышлы Зур театр залында үткәрелгән бу кичәдә башта язучы Вакыйф Нуруллин «Казан утлары»ның 50 еллыгына багышланган доклад ясады, аннары РСФСР язучылары союзының Пермь бүлеге секретаре урынбасары Николай Доминтов «Казан утлары»на Пермь язучыларының котлау адресын тапшырды.

1970 елда Пермь китап нәшрияты татар шагыйрьләренең шигырьләрен «Четыре ветра» исемле китапта рус телендә бастырып чыгарган иде. Кичәдә әнә шул китапны русчага тәрҗемә иткән Пермь шагыйрьләреннән Алексей Домнин, Михаил Смородинов һәм В. Радкевич иптәшләр дә шагыйрьләребезнең шигырьләрен рус телендә укыдылар. Соңыннан Я. М. Свердлов исемендәге культура сарае каршындагы татар үзешчән сәнгать түгәрәге коллективы концерты булды.

## ОЧРАШУЛАР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Мәскәү шәһәренең Н. А. Некрасов исемендәге китапханәсендә язучы Әхсән Баяновның «Ут һәм су» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. РСФСР язу-

чылары союзы вәкиле Җәмил Мостафин конференциядә катнашучыларга язучының иҗаты турында сөйләде. Персональ пенсионер Ә. Галиқаев, укытучы М. Кутуева, инженер Р. Шәмсетдинов һәм Ф. Хәмитов, яшь язучы М. Юныс һ. б. лар роман турында үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар. Соңыннан Ә. Баянов бу әсәре өстендә ничек эшләве турында сөйләде һәм әдәбият сөючеләрнең күп санлы сорауларына җаваплар бирде.

* * *

Новгород өлкәсенең Бородовичи район китапханәсендә һәм Днепропетровск өлкәсендәге Никополь медицина училищесында язучы Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Күп кенә әдәбият сөючеләр романны яратып укулары турында сөйләделәр, әсәргә карата фикерләре белән уртаклаштылар.

* * *

Шагыйрь Р. Гатауллин, прозаик Х. Сарьян һәм артист М. Шиһапов Апас районы авылларында булып кайттылар. Уннан артык авыл клубларында, җәйләүләрдә, мәктәпләрдә уздырылган әдәби кичәләр авыл хуҗалыгы эшчәннәре күңелендә җылы тәэсир калдырды. Әдәбият сөючеләргә язучылар автографлары белән бик күп әдәби китаплар сатылды.

* * *

КПССның район комитеты чакыруы буенча, язучы М. Маликова, шагыйрь Р. Гәрәй һәм нәфис сүз остасы М. Шиһапов Тәтеш районында булып, СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышланган «Татарстан — республикам минем» дигән темага әдәби кичә уздырдылар.

## ИҖАТ ОЕШМАЛАРЫНДА

Чаллы шәһәрендәге әдәби иҗат берләшмәсенең чираттагы утырышында яшь авторларның КамАЗ турындагы әсәрләреннән җыентык төзеп, Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итү мәсьәләсе каралды. Утырышта язучы Эдуард Касыймов һәм Татарстан язучылары союзының әдәби консультанты, шагыйрь Гәрәй Рәхим катнашты.

## ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРИЗ ӨЧЕН

Әлмәт шәһәрендә инде менә дүртенче ел рәттән герой-шагыйрь Муса Җәлил исеменә багышланган приз өчен футбол ярышлары үткәрелә. Бу ярышларга, быел республикабызның иң көчле «Прогресс», «Ракета», «Синтез», «Буровик» командаларыннан тыш, Киров өлкәсенең Вятские Поляны командасы да катнашты.

*Хөрмәтле укучылар!*

Журналыбызның 10 санында сезнең игътибарыгызга Мөсәгыйть Хәбибуллинның *«Тау белән тау очрашмаса да...»* дигән повестен тәкъдим итәбез. Бу әсәр Кама буендагы гигант төзелештә эшләүче яшьләрнең эшләре һәм тормышлары, аларның коммунистик әхлак һәм мораль сафлыгы өчен көрәшүләре турында сөйли.

Поэзия бүлегендә Зәки Нури һәм Гәрәй Рәхимнәрнең лирик шигырьләрен укырсыз.

СССР төзелүгә илле ел тулу уңае белән рус, үзбәк, молдаван, болгар шагыйрьләренең шигырьләре урнаштырыла.

Журналның 9 санында башланып киткән бүгенге проза турында сөйләшү дәвам итә. Бу санда Флүн Мусинның *«Документаль материал һәм автор фантазиясе»* дигән мәкаләсе бар.

Фәнис Яруллин *«Җилкәнне җилләр еккач»* дигән повестена карата килгән хатларга җавап бирә.

Театр сәнгатен сөючеләр Дания Гыймранованың Наилә Гәрәева турындагы язмасы, Ильтани Иляловaның бүгенге драматургия турындагы зур мәкаләсе белән танышырлар.

*«Сатира һәм юмор»*. «Яңа китаплар», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» дигән бүлекләрдә басылган материаллар да журнал укучыларыбызга күп мәгълүматлар бирерләр.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210